# КАЗАН УТЛАРЫ

9
СЕНТЯБРЬ
1979

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**9**
СЕНТЯБРЬ
1979


## Бу санда


А. **РАСИХ.** Сынау. Роман . . . . . . . . . . 3

ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА
КОНКУРСКА КИЛГӘН ОЧЕРКЛАРДАН

Р. **МАКСУДОВ.** Камада ак пароход. Очерк . . . 67
С. **ХӘКИМ.** Яңа шигырьләр . . . . . . . . . 76
К. **СИБГАТУЛЛИН.** Кешеләрнең барын танып йөрим. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 80
Р. **ХӘЛИУЛЛИНА.** Бәби мунчасы. Шигырь . . . 83

ШАМИЛ РӘКЫЙПОВКА 50 ЯШЬ

Ш. **РӘКЫЙПОВ.** Кайдан син, Жан! Повесть . . . 86

А. **ГЫЙЛӘҖЕВ.** Без унике кыз идек... Драма . . 141

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

М. **КЛИПИНИЦЕР.** Муса Җәлил «Орлес» заводында . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Ә. **МӘХМҮДОВ.** «Моабит дәфтәрләре»ндә эстетик идеал гәүдәләнеше . . . . . . . . . 175

УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

Г. **ӘПСӘЛӘМОВ.** Күз карасы кебек кадерлә . . 180

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

З. **НУРИ.** Иң яхшы сый. Шигырьләр . . . . . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-69, **җаваплы** секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шамил Бикчурин, Аяз Гыйләҗев, Марсель Зарипов, Зөлфәт, Шәйхи Маннур, Фәрваз Миңнуллин, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Кояш Тимбикова** (җаваплы секретарь), **Нил Юзиев, Сибгат Хәким, Мирсәй Әмир.**

---

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Ф. Кадыйрова*

---

Производствога бирелде 22/V-1979 ел. Басарга кул куелды 20/VIII-1979 ел. ПФ 09029. Кагазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83 300 экз. Заказ Ц-217. Бәясе 50 тиен.

---

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1979 ел.

**Атилла Расих**

# СЫНАУ

РОМАН

**III нче БҮЛЕК**

1



Фәһимә хаты килгәннән соң үзен бер атна да көттермәде. Әйткән сүзендә нык тора торган кеше булырак, ары чапты, бире чапты, мәгәр үз дигәнен итте—каенатасы Зариф белән бергә, ике баласын ияртеп килеп төште. Апрельнең дүрте иде. Районара йөри торган самолетлар тәртипле очмый башлаган чак. Ләкин шулай да Фәһимәнең юлы уңды, алар очканда көн салкынча, ләкин аяз, аэродромнар очкычларны тәртипле рәвештә кабул иттеләр.

Чәршәмбе көн нәкъ төшке аш вакытында такси машинасы Фәрит яшәгән өй алдына килеп туктады. Зариф Фәритнең бу вакытны өйдә икәнлеген белә иде. Шуңа күрә алар, озын-озак уйлап тормастан, әйберләрен күтәреп, дүртесе бергә парадный ишегеннән өскә, Фәрит квартирасына менеп киттеләр.

— Өйдә булырга тиеш, — дип кабатлады карт, — бу вакытны ашарга кайта. Инде бер дә булмаса, күршеләренә кереп торып үзен телефоннан чакыртабыз.

Фәһимә көрән төстәге каракуль якалы пальтодан, «оек» дип аталган йомшак ялтыравык куныччлы аяк киеменнән һәм төлке мехы тотылган кырлы эшләпәдән иде. Балалар исә: олысы Ләйлә — шакмаклы бизәк төшерелгән яшькелт пальтодан, кызыл резин ботадан, кечкенә малай Маратик — кыршылып беткән мех туннан, чүчинкәдән иде. Икесенең дә башларында кара таплар төшерелгән сары, колаклы мех бүрекләр. Кызның да, малайның да күзләре кара, зур. Күрү белән үк нәкъ Фәритнеке булуын белеп була.

Әле аларның йөзләрендә ниндидер авыр кичереш — югалып, аптырап калу чалымнары сизелә иде. Ә Фәһимә исә артык тыныч, бик зур игътибар белән караганда гына бу тынычлыкның ясалма булуын аң-

Ахыры. Башы 7—8 нче саннарда.

ларга мөмкиндер. Зариф звонок төймәсенә басты, эчтә чылтыраган тавыш ишетелде. Кунаклар тын калып бер мәл көтеп тордылар. Инде өйдә юктыр, дип уйларга җыенганда гына ниндидер кыштырдау ишетелде.

— Өйдә, — диде Зариф күзләрен бердән кысып. Балалар төмрәешеп ишеккә төбәлделәр. Хәзер Фәһимәнең эчке кичерешләрен аның яшькелт күзләре әле ачылып, әле йомыла төшүеннән генә аңларга булыр иде. Әлбәттә, ул да качак ирен күреп сөйләшүне тетрәнеп көтә иде.

Ниһаять, ишек ачылды да муенына сөлге салган, өстенә майка һәм спорт чалбарын кигән Фәрит күренде. Ул ишекне ачу белән ничектер артка чигенгәндәй булды. Йөзе агарынды, күзләре зураеп китте. Фәһимә бүлмә коридорына алдан балаларын уздырды, аннан үзе керде. Фәрит исә алар якынлашкан саен артка чигенә бара иде. Зариф, миңа ганлә эшләренә катышмау яхшырак булыр дигәндәй, артка калды.

— Я, ник безне болай боз болытыдай караңгы чырай белән каршылыйсың? — диде Фәһимә. — Сине сагынып килдек. Әллә балаларыңны оныттың дамы?

— Ничек инде, хәбәрсез-нисез генә... — дия алды Фәрит. Ул әле генә әйбәтләп юынган, хәзер үк Әлфияләргә барырга һәм аның белән кушылу, тормышны бергә ничек оештыру турында сөйләшергә тиеш иде. Максатлары Галиәкбәр киңәшен дә тыңлау. Мәгәр шундый вакытта һич көтелмәгән бу хәл аны бөтенләй чыгырыннан чыгарды, ул акылына килә алмас булып тәмам югалып торды.

Ниһаять, йөрәге урынына утыргач, аның күзләренә беренче булып балалары чалынды. Йөрәк түрендә өзлексез кыбырдап яткан нәрсә кинәт калкып өскә чыккандай булды. Ул тора-бара бөтен күңелне билэп алды. Фәрит тиз генә чүгәләде дә ике баласын да берьюлы кочып күкрәгенә кысты.

— И балаларым, и бәгырьләрем, — дип пышылдый иде ул. Ниһаять, шуларга гына мөрәҗәгать итеп, «әйдәгез» диде, аларны чишендерә башлады. Балалар да хәлне аңладылар булса кирәк. Аларга да җан керде. Маратик хәтта әтисенең муенына сарылды. Ә Лэйлә исә Фәритнең дулкынланып торган юеш чәчләрен сыйпый иде. Олылар да иркен сулыш алып, өс киемнәрен салырга керештеләр. Ул арада Фәһимә, кая, без ач, балаларның бүген рәтләп ашаганнары юк дип, кухня якка чыгып китте.

Фәрит әле балаларыннан аерыла алмый иде. Алар аңа артык ябык, артык йончыгандай тоелдылар. Ә почмакта сүзсез генә утырган этисенә усал бер караш ташлады. «Ул оештырган инде мондый эшне». Тик ул, балаларның нидер текелди башлавын ишетеп, этисенә авыр сүз әйтергә өлгермәде, ә бераздан, этисенә шигырь сөйләп күрсәтү кыюлыгына кадәр барып җиткән Марат аркасында картка гомумән ни булса да әйтүне кирәк дип санамады да. Әйе, әйе, бу көтелмәгән кунакларга барысы да, барысы да бераздан әйтеләчәк. Фәрит нидер сорап кухня яктан кычкырган Фәһимәнең тавышын ишетте һәм тетрәнеп куйды, йөрәгенең авыртып кысылуын тойды. Лэкин балаларны калдырып кухня якка чыкмый мөмкин түгел иде.

— Нәрсә кирәк сиңа, нигә шул кадәр?..

— Бер дә «шул кадәр» түгел. Әйтеп торам ич, балаларың ач дип, синдә ата булу хисе шулай бөтенләй үк сүндемени? Кая, нәрсәдер этмәлләргә кирәк, тиз генә пешереп ашатырлык нәрсәң бар?

— Әнә холодильникта кукәй бардыр, ал шуны.

— Ә чәең, чәең кайда, этки чәйгә тилмерә әнә!

— Син миңа әнием авыр хәлдә ята дип язгансың. Ничек аны ялгызын калдырып киттегез?

— Аларын инде эткидән сора!

— Чәй әнә стенага эленгән шкафта, — диде дә Фәрит тагы балалары янына зур бүлмәгә чыкты.

Ул этисеннән дә энисе турында сорады.

— Булды, булды андый хәл, әниең йөрәге белән байтак җәфаланып ятты. Барсы да синең аркада, — диде карт.

— Хәзер ничегрәк соң хәле?

— Дарулар эчеп яши, шул, нишләсен.

— Син теге көнне әйтми-нитми яшертен генә китеп баргансың. Минем бит әнигә, балаларга җибәрәсе әйберләрем бар иде.

Кухнядан Фәһимә тавышы ишетелде:

— Нигә, почта юкмыни сездә? Җибәрәсе нәрсәләреңне, әгәр теләсәң, бик күптән безгә юллый алган булыр идең. Теләвең шул кадәр булгандыр.

Фәритнең кинәт ачуы кузгалды. Ләкин этисенә кадалды:

— Карале, эти, син нәрсә, мине бөтенләй кешелектән чыгару өчен алып килдеңмени моны? Җитмәсә кешеләрчә сөйләшергә дә теләми.

— Мин, Фәрит, хатыныңны, балаларыңны, ачыктан-ачык, күзгә-күз карашып аңлашу өчен алып килдем. Сиңа яхшылык теләп эшлим моны. Ә синең метод ул дөрес түгел.

— Яхшы, аңлашырбыз, — диде Фәрит. Ул тагы балалары янына барды. Бу юлы кызы белән булашты. Ләйлә исә этисенең өстәленнән ниндидер кәгазь алып тәрәзә төбендә рәсем ясарга тотынган иде. Фәрит тиз генә аның янына барды.

— Кызым, акыллым, бу минем эш кәгазем. Хәзер мин сиңа башкасын бирәм.

Ләйлә мәхәббәт тулы моңлы күзләрен күтәреп этисенә карады. Фәрит түзмәде, аның башын бөеренә кысты.

— Ошадымы соң безнең поселок? — дип сорады.

Балалар икесе дә Кама буйлары, кара куе урманнар калдырган тәэсирдән биһуш иде. Алар, бер-берен бүлеп, шуның турында сөйли башладылар. Ул арада чәй дә кайнап чыкты, табада куырган күкәй тәбәсе дә әзер булды. Кунаклар шау-гөр килеп табынга утырыштылар. Фәрит сәгатькә карап алды.

— Миңа китәргә вакыт.

— Кая, эти? — диде Ләйлә, куркына төшеп.

— Эшкә, кызым. Мин бит көндезге ашка гына кайткан идем.

Фәрит, ашык-пошык киенде дә, туп-туры Әлфияләргә юнәлде. Әле артык соңга калынмаячак иде, юкса аны көтеп аптырашырлар.

Чыннан да, Әлфия аны ишек төбендә үк көтә иде.

— Нишләп болай соңгардың? — диде ул аптырый төшеп.

Фәрит булган вакыйга турында сөйләп китте. Хәтәр эшкә юлыккан иде егет. Әлфия кашларын җыерып тыңлаганнан соң, бераз уйланды да:

— Борчылма, — диде, — бигрәк тә әйбәт, безгә барыбер бер сөйләшми мөмкин түгел бит. Аларның килүе төеннең чишелүен генә тизләтәчәк.

— Син чыннан да шулай дип уйлыйсыңмы, Әлфия? — диде Фәрит, кызның батырлыгына хәйран калып.

— Чыннан да шулай уйлыйм. Мин эштән соң ук сезгә барырмын. Дөресрәге, без эштән соң бергәләп керербез синең квартирага.

Фәрит агарына төште.

— Тукта, тукта, Әлфия, бераз сабыр итик.

Әлфия, гаҗәпсенә төшеп, Фәритнең күзләренә карады.

— Ник алай дисең, Фәрит?

Әйе, Фәрит нигә алай ди соң әле? Фәһимәне күрү куркыттымы аны, әллә балаларын күрү шул хәлгә куйдымы? Дөресен генә әйткәндә, Фәрит үзенең хәзерге халәтен үзе дә аңламый иде. Ул җавап көткән Әл-

фиягә ничектер сәер караш ташлады. Бу караште кызны өзелеп яратканлыгы да, шул ук вакытта аның гаҗизлеге дә, хәзер бернинди дә кискен, кыю эшләргә кулы бармаганлыгы да сизелә иде. Әлфия аны шулай аңлады.

— Ашыкмыйк, кадерлем, ашыкмыйк, — дип кабатлады Фәрит, — әз генә сабыр итик.

— Бәлки синең берәр мин белмәгән планың бардыр?

— Планым?

— Әйе, планың.

— Мин барысын да бераздан сиңа аңлатырмын, — диде Фәрит. Ләкин нәрсә, ничек аңлатасын ул үзе дә белми иде. Бары ул бу минутта, тәнендә генә түгел, җанында да хәлсезлек, көчсезлек сизә һәм ял итәргә, тынычлыкка магнитка тартылган тимердәй омтыла иде.

Алар ашыга-ашыга конторага киттеләр. Яңадан дуслашып вәгъдәләшкәннән соң, Фәрит урамда йөргәндә бик иркен рәвештә Әлфияне култыклап ала башлаган иде инде, тик бүген ул мондый батырлыкка бармады. Барысы да, барысы да шушы ук минутта Фәһимәгә дә, балаларына да мәгълүм булыр кебек иде. Алар сүзсез генә шулай бардылар да, контора янында аерылыштылар.

— Мин ничек тә сине бүген күрергә тырышырмын, Әлфия.

— Кайчанрак?

— Хәзергә өзеп әйтә алмыйм. Шалтыратырмын.

— Яхшы, — диде Әлфия һәм күзләре белән генә елмаеп, үзенең Фәриткә булган мәхәббәтен белдерде.

Ни өчендер профессор көндезге ашка кадәр үк Фәритнең кереп чыгуын үтенгән иде. Димәк, ул сынаулар уздырыла торган корпуска керергә тиеш. Ләкин хәзер аңа ялгызлык, барлык ыгы-зыгыдан, тетрәнүләрдән соң ял, ял кирәк.

Ул үзенең эш бүлмәсенә керде дә ишекне бикләп алды. Өстәле янына барып утырды, күкрәге белән өстәлгә авып, аска караган килеш тынып торды. Тәгаен теге — ягъни Фәһимә — хәзер үк дау куптарачак инде. Ул, билгеле, фабрика конторасына керер. Партия оешмасында булыр. Барын да, барын да сөйләр. А, юк, булганын гына түгел, үз файдасына мөмкин кадәр куертып, арттырып сөйләр. Хәлнең чиксез авырлыгы шунда: барлык оешма аның яклы булачак, Фәритнең үзен яклый алырлык бер генә дә мөмкинлеге юк. Аңа ни директор, ни парторг ышанмаячак. Бәлки шәхес буларак ышанырлар да, әмма рәсми оешма вәкиле буларак, аны аңларга теләмәячәкләр. Алар: «Син хатыныңны, балаларыңны ташлап качкансың, син гаиләне җимергәнсең, инде безнең фабриканың намуслы кешеләрен дә пычратырга телисең. Намуслы, гүзәл Әлфияне син ничек алдап бәхетсезлеккә дучар итәргә теләдең. Ярый хыянәтеңне вакытында сизгәннәр. Ярый атаң, хезмәт һәм сугыш ветераны, сине эзләп тапкан һәм җинаятьле эшләреңә чик куйган. Юкса, ниләр булмас иде!» — диячәкләр.

Фәрит шулай уйланды. Хәзер ул үзенең чарасызлыгы сәбәбен дә аңлый башлаган иде. Әйе, ул чарасыз, чөнки ул көчсез. Үзен берничек тә аклый алмаячак. Бума еланының авызына елый-елый үз ирке белән кереп китәчәк кролик кебек. «Ә моннан качсам? Тагы чыгып китсәм һәм, берни уйламастан, әллә кайда, әйтик анда, БАМга я булмаса Сахалинга китеп барсам?» Ләкин моның һич мөмкин түгеллеген ул башта ук, уйлаганы башына килү белән үк сизенде. Ничек итеп инде ул яңадан дөрләп кабынган мәхәббәтен ташлап, әллә кайларга олаксын? Әлфия дә аның белән китәргә теләк белдерсә генә...

Фәрит шул якты өмет чаткысыннан уянып киткәндәй булды. Башын күтәрде, тураеп утырды да яңакларын учлары белән кысып уйлана башлады. Теләк-уйлары ачыкланган саен йөзе яктыра бара иде. Ул бөтенләй урыныннан ук сикереп торды һәм ашкынып бүлмә буйлап

йөренергә тотынды. Бераздан катгый бер карарга килеп телефонга ябышты.

— Әлфия, синме бу? Синең вакытың ничек, хәзер бер ун минутка колбаларыңнан аерыла аласыңмы?

— И, Фәрит, берәр сәгатьсез башымны да күтәрә алмыйм. Ачуланма зинһар, соңгы партия комбиазык белән чиләнеп утырабыз. Үзем карап тормасам, Нина методиканы ялгыштырыр дип куркам.

Фәритнең йөзенә тагын борчылу галәмәтләре чыкты. Нинди уңайлы вакыт иде бит... Шушы дәртләнгән чагында сүзен әйтмәсә, кем белә тагы соңыннан ни буласын!

— Ярар инде, вакытың булу белән үзең шалтырат алайса, — диде ул.

Әмма шул ук минутта аның сынаулар корпусына керергә тиешлеге хәтеренә килеп төште.

— Каян табарсың икән соң син мине? — дип сорады. Ләкин Әлфия телефоннан киткән, инде реактивлары белән маташа иде.

Фәрит яңадан креслосына утырды. Юк, утырып өлгермәде, телефонда директор тавышы ишетелде.

— Фәрит Зарипович, килдеңме? Кер әле, слушай, — диде ул.

«Менә башлана», — дигән сизенү баш зоотехникның йөрәген өтеп узды.

## 2

Эльвира профессор килеп киткәннең икенче көнендә үк урыныннан торды. Картның борчылып йөрүе һәм, әз генә дә киная сакламаган хәлдә, бәхетсезлеккә очраган доцентка ихлас күңелдән ярдәм кулын сузуы, әлбәттә, гомере буена гадел булырга кирәк дигән тәрбия алып үскән кешегә, бала анасына, фән эшлеклесенә һәм хәзер инде кафедра мөдире дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән җитәкчегә тәэсир итми калмады. Ана хәзер бик оят иде. Җитмәсә әле Эльвираның беренче авырлыктан соң ук болай җебеп төшүен тагы аның иренең дә бөтенләй яратмыйча тәнбиһ ясавы, утка май сипкәндәй, оялтуны көчәйтә, ничек кенә булса да тизрәк хатаны төзәтергә өнди кебек иде.

Эльвира бу көтелмәгән хурлыктан качып кына котылып булмасын, ниһаять, аңлады. Ул Галиәкбәрнең, үзеңне кулга алырга кирәк, хата ясалган икән, аны төзәтергә кирәк, дигән сүзләрен кат-кат хәтерләде. Әйе, үзе өнәмәгән, Эльвира уенча, артык йомшак, либерал булып тоелган карт кичә аңа хатаны төзәтү юлларын да күрсәтте бит... Методика әзер, профессор үзе виварийда булып урын сайлаган, аны сынаулар башлау өчен чистартып, җайлап куярга кушкан. Ректорат та ярдәм итәргә әзер тора. Инде шундый бер вакытта үпкәләүчән истерикага бирелүче, кәҗәле үсмер кызлар кебек, мигрень җәфаларын кичереп ятагында аунасынмыни! Юк, Эльвира ул яшьтән узган инде, андый чебен тимәс чер иткән чаклар артта, яшьлекнең күләгәле бер ягы булып калган нәрсәләр инде алар.

Доцент урыныннан сикереп торды. Тиз-тиз генә өс-башын тәртипкә китерде һәм профессор белән бергәләп язган методиканы кулына алды. Турысын гына әйткәндә, ул методика дигән әйбер асылда профессор тарафыннан төзелде бит. Ул чакны әле исен-акылын җыеп өлгермәгән Эльвира профессорның тырышлыкларына ышанмыйчарак карый иде. Ә хәзер ул, махмырдан котылган эчкечедәй, үз акылына килде һәм бар нәрсәгә айнык акыл призмасы аша карый башлады. Ятып калганчы атып кал!

Эльвира ак кәгазь битләренә профессор язган сынаулар методикасының планын бөтен барлыгы белән бирелеп тикшерергә тотынды. Әйе,

бик төпле һәм бик оригиналь эш планы иде бу. Ләкин анда кайбер детальләр язылмый калган. Күрәсең, анысын ул чакны алар телдән генә сөйләшкән булганнардыр. Сөйләшкәннәр, әлбәттә, ләкин Эльвираның ул бер колагыннан кергән дә икенчесеннән чыккан. Һәрхәлдә, хәзер доцент аларны анык хәтерләми иде.

Эльвира тоташ бер сызык булып кушылган кара куе кашларын җыера-җыера өченче көнге хәлләрне хәтерләргә тырышты. Мәгәр барысын да төгәл генә исенә төшерә алмады.

Профессорны күреп яңадан бер сөйләшү теләге туды доцентта. Ләкин ул хәзер кайда, үзенең кош фабрикасындагы кызы янына китеп барганмы? Эльвира, профессор килеп чыкмадымы дип, кафедрага шалтыратты. Анда булмаганлыгын белгәч, картның өенә мөрәҗәгать итте. Ләкин анда да беркем дә юк иде — телефонга килүче булмады. Эльвира киенде дә ашыгып институтка китте. Җәяү генә барды. Карасана, нинди матур гөрләвекле, күңелләрне җилкендерә торган яз икән ләбаса урамда. Ә ул юләр өйдә ята. Хатын юлда очраган күлдәвекләрне, итәген чеметеп тота-тота чыгып, җил-җил атлап баруында булды. Эшкә керешергә кирәк дигән карарга килде ул. Бүген үк. Матбугатка чыккан мәкаләләрендәге хаталар хурлыгы хәзер ни өчендер аны ул кадәр куркытмый да, каушатмый да иде. Чөнки эчке сизенү белән ул хаталарны һичшиксез төзәтәчәген, үзендә хәзер аларны төзәтерлек һәм курыкмыйча, мин иптәшләр, ялгышканмын, ә дөресе аның менә ничек, дип әйтерлек көч-кодрәт барын тойды. Аңа бары оят кына иде. Шулай паникага бирелеп ятуы өчен оят, шулай карт кешене — кайчандыр кафедрадан аның китүенә үзе сәбәпче булган профессорны борчуы, мәшәкатьләве өчен оят иде.

Кафедрага керү белән, Эльвира дәрестән бушаган хезмәткәрләрен үз бүлмәсенә җыйды һәм үз диссертациясендә киткән хаталар турында сөйләп бирде. Мәсьәләне болай куйды: хәзер ул шул хаталарын төзәтү өчен берничә экспериментны кабаттан башкарачак, яңа методика белән уздырачак. Әгәр шул эш белән шөгыльләнеп, үзе алып барырга тиешле лекцияләрне, дәресләрне уздыруны иптәшләреннән үтенсә, моңа ничек карарлар?

Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Ләкин Эльвира күңеле белән шуны тойды: аның иптәшләре алдында үзен ачыктан-ачык фаш итүе барысына да ошады. Тагы шунысы ошады, ул клавишле электрон машинада исәп-хисапны алып барган ярдәмчеләрен гаепләмәде, барысы өчен дә үзенең, бары үзенең генә җаваплы икәнлеген әйтте.

Һәм кафедра кешеләре мөдирәнең әйткәннәренә риза булдылар. Хәтта дәресләрне үзара бүлешү турында да сөйләшә башладылар. Чөнки мөдирәнең уңышы — ул кафедра уңышы да иде бит!

— Мин әйтергә тиешмен, — диде Эльвира, — бу вакытлыча гына. Ягъни сез эшләрем төгәлләнгәнче генә минем өчен укытасыз. Эш беткәч, мин сезгә биргән сәгатьләрем кадәр үк сезнең өчен дәресләр уздырырмын.

Эльвира бераздан олы лаборантны һәм хуҗалык эшләрен алып баручы ассистентны ишек алдының аргы почмагындагы кирпеч бинага — вивариумга ияртеп китте. Алар тавыклар асралырга тиешле читлекләрне тикшереп чыктылар, урын әзерләнгәч, яңадан кафедрага кайтып, ректор урынбасарына институт хуҗалыгыннан кирәкле санда тавыклар китерелсен дип заявка яздылар. Һәм шунда ук сынауларның календарь планы төзелде, сынаулар беркетмәсе өчен махсус дәфтәрләр әзерләнде.

... Тик шулай да картны бер күрергә кирәк иде әле. Ансыз Эльвираның тагы ялгышып куюы бар. Шуңа күрә эшләр төгәлләнгәч, Эльвира тагы Галиәкбәрнең квартирасына шалтыратты. Бу юлы өйдә кемдер

бар иде. Лəкин телефоннан Эльвира белмəгəн кеше тавышы ишетел...: ир кеше, рус.

— Профессор районга очкан булырга тиеш, — диде ул. — хəер, — дип өстəде, — сезгə тулырак мəгълүматны менə хəзер Софа бирер.

«Кем ул Софа, алла белсен, — дип уйлап алды Эльвира, — хəер, Софа дигəне шул ук Сафурадыр əле».

Инде телефон трубкасын Сафура алды. Ул доцентны тану белəн иске дусларча сүзгə кереште. Хəл-əхвəл дə сорашылды, Казан хəбəрлəре белəн дə бүлешеп алдылар, аннан сүз Галиəкбəргə килеп житкəч, Сафура Эльвирага картның ни өчен кирəклеген сорады.

— Белəсезме, кайбер методик мəсьəлəлəр турында аннан мəгълүмат алмакчы идем, — диде доцент туры җавaптан читлəшə төшеп.

— Сез ул чагында этигə хат язгыз. Ул теге көнне, случайный транспорт туры килеп, Əлфия янына киткəн булса кирəк.

— Əлфия, кем ул Əлфия? Ə, аңладым, Галиəкбəр аганың икенче кызы!

— Əйе, үги кызы, — дип куйды Сафура. — Без аның киту-китмəвен белми дə калдык, между тем ул безгə бик тə кирəк иде. Шул дəрəҗəдə кирəк, мин иртəгə шунда очарга вынуждена. Əгəр хат язсагыз, мин аны этигə непременно тапшырырмын, ə калганын ул үзе карар.

«Ə бəлки миңа да берəр көнгə шунда барыргадыр. Əле кайчан ул үзе Казанга кайта ала?» — дип уйланды Эльвира. Аннан ул икелəнə калды. Ə баргач кайда урнашырга? Кемдə торып торырга? Самолетлар ничек оча икəн хəзер? Инде эш башлыйм дигəндə генə утырып калсаң шунда?

Ул телефон янында торган килеш шулай уйланырга өлгерде. Мəгəр профессор янына барып кайту фикере аның күңелендə нык кереп урнашкан иде инде. Барса, яңа фабрика белəн дə танышып кайтачак бит əле. Анысы да бер ганимəт. Анда гыйльми эшлəр башкарам, диде бит профессор. Димəк, ул нəрсə дə мөмкин икəн фабрикада! Чыннан да, дип куйды ул һəм, хат язмастан, шунда бару мөмкинлеге турында Сафура белəн сөйлəшеп кайту өчен, институттан туп-туры Галиəкбəрлəр квартирасына юнəлде.

Сафура аны якты чырай белəн каршы алды, өйнең җыйнаксызлыгына гафу үтенде, вакыт булмавыннан зарланды. Эльвира үзенең профессор янына барып кайту телəген белдергəч, ул башта моңа җанытəне белəн каршы килгəн иде, лəкин шул ук минутта бу хəлнең үзе өчен файдалы якларын да уйларга өлгерде һəм доцентка шатланып ризалыгын белдерде.

— Ни əйтсəгез дə, Əлфия минем сеңелем бит, — диде ул, бая ычкындырган ахмак сүзен төзəтергə тырышып, — без аның белəн бер туган балалардан да якынрак. Но шулай булуга да карамастан, мин аны əниебез үлгəннəн бирле күрə алганым юк. Бик тə ужас, ничек сагындым! Сеңелемнең тормышын күреп кайтасым килə.

— Ул фабриканың директоры кем икəн, сез белми торгансыздыр инде? — дип кызыксынды Эльвира.

— О, ул кадəресен белмим, — диде Сафура, болай да матур, өстəвенə бик нык эшкəртелгəн озын бармаклы кулларын уйнатып. — Понятия не имею!

Алар Галиəкбəр бүлмəсендə икесе дə диванда утыралар иде. Эльвираның күзе стенадагы портретка төште. Мəгъмүрə портретына.

— Мин сезнең əниегезне хəтерлим, — диде Эльвира. — Искиткеч ягымлы ханым иде.

— Да, ул үлеп киткəч, бөтен тормышның асты-өскə килде. Барысы да верх тормашкой булды. Эти дə үзгəрде, Əлфия дə, мин дə. Менə нəрсə ул центр притяжения: бер кеше бөтен семьяны гармониядə тотып торган.

— Сез бары Әлфияне күреп кайту өчен генә барасызмы анда? — дип сорады Эльвира.

— Анысы иң мөһиме, но тагы минем этине дә күрәсем бар...

Сафура, дөресрәге, этисеннән туйга акча сорарга дип барачак иде. Әле Эльвира да аның белән барырга теләген белдергәч, ул ахырда доцентның анда булуы ярдәм итәр, чөнки тәмам саранланып калган этисе, кызы доцент каршында акча сораса, бирмичә булдыра алмас дип уйлады.

— Нәрсә, берәр көтелмәгән ашыгыч йомыш килеп чыктымыни? — дип төпченде доцент.

Сафура әйтимме-юкмы дип бераз икеләнеп торды, аннан оялчанланып елмайды да:

— Беләсезме, мин кияүгә чыгам, — диде, — сезгә ищек ачкан блондин егеткә внимание обращать иттегезме? Менә шуңа. Ну үзегез дә аңлыйсыз инде, берәр мини туй да уздырмый булмый. — Сафура яшькелт күзләрен кыса төшеп, йөзенә матур гына, тыйнак кына елмаю чалымнары чыгарды, — меркантильный вопрос, акча кирәк, — дип куйды.

— Аңлашылды, — диде Эльвира, — яшьләр хәлен беләм. Тик акчаны үзе белән йөретми торгандыр бит этнегез. Димәк, ул шушы көннәрдә үк Казанга кайтырга тиеш булачак.

— Анысын әйтә алмыйм.

— Бәлки миңа анда барып йөрүнең кирәге дә юктыр. Үзе тиз арада кайтса дип әйтүем.

Хәзер карар кабул ителгән иде инде, Сафура моңа риза түгел.

— Юк, юк, сез непременно минем белән барасыз. Билет мәсьәләсен дә үзем кайгыртам, анда сезгә яшәү урынын табуны да үз өстемә алам, так што бергә барабыз, Эльвира Хәкимовна.

— Минем анда барасым килә. Инде Галиәкбәр абыйны күрүдән тыш... Мин дә бит кошчылык буенча белгеч, ә фабрика яңа, шуны күреп кайту бик кирәк.

— Ну вот, алай булгач, без договорились. Булса, билетка акчагызны калдырыгыз, иртәгә очабыз. Прогноз да яхшы, летная погода булачак. Нинди рейс уңайрак булыр?

Эльвира эшләнәсе эшләрен, кафедраны, өен, улын, ирен уйлады. Алай тоткарлый торган берни дә күренми иде.

— Яхшы, — диде тәвәккәлләп, — очабыз.

Алар иртәгесен кичке дүрт рейсы белән Кама буйларына ИЛ-18 самолетында очтылар.

## 3

Шулай итеп, олы максат буларак, Рәмзи Әлфияне сайлап алды, ә вакытлыча тору өчен ул моннан ике ел элек кенә иреннән аерылып, инде фабрикада төпләнеп калган, столовой кассасында эшләүче Резедага ияләште.

Рәмзинең бу хатынга тукталуы ул шактый ягымлы, беркатлы, шаркылдык һәм тулы бәдәнле, елтыр күзле булган өчен генә дә түгел. Резеданың мондый әйбәт сыйфатларыннан тыш тагы поселок читендә генә торган аулак өе бар һәм әле аны-моны аңламый торган балалары бөтенләй икенче бүлмәдә йоклыйлар иде. Рәмзи шул хатынга тукталды һәм артык күп изаланмыйча гына үз теләгенә иреште. Җитмәсә хатынның күрше авыл кешесе булуы да бик җайлы иде Рәмзигә. Ял көннәрендә, ул, һич шик кузгатмыйча, шунда да кереп чыга ала иче. Кыскасы, Рәмзи, кулайрагы табылганчы бик ярап торыр дип, үзеннән биш яшькә олырак шул Резеданы сайлады.

Мәгәр аның күңеленнән бер генә минутка да Әлфия чыкмады. Уйланмыйчарак ясалган теге дуамаллыгы барып чыкмавыннан соң да, инде вакыйга начальствога җитеп хәлләр «швах» булудан куркып йөргән көннәрдә дә, ул профессор кызын онытмады. Ирлек гайрәте белән шуны үзенеке итү, әсир ясау аның тормыш максатына әверелде.

Рәмзи дежур торган көнне баш зоотехник белән булып узган сөйләшү чак кына планнарны җимереп ташламады. Һәрхәлдә, егеткә шулай тоелды. Фәрит барысын да белә, аңа тәгаен Әлфия сөйләгән, озакламый директорга да эш мәгълүм булачак, ә аннан соң гитараң белән капчыгыңны ас та, яңадан колхозыңа кайтып кит. Рәмзи шулай уйлады. Тик, бәхеткә каршы, барысы да узды тагы. Ә инде көннәрдән бер көнне Фәритнең Әлфияне култыклап кинога баруын күргәч, егет бөтенләй тынычланды. Димәк, кыз тирәсендә баш зоотехник үзе сырпалана икән. Бу хәл Рәмзине көнләштерәсе урында тынычландырды гына. Аның өчен бигрәк тә яхшы. Әгәр Фәрит оҗмах алмасыннан башлап үзе авыз иткән икән, итә бирсен, ул бит Рәмзинең хәлен җиңеләйтәчәк кенә, аңа юллар ачык булачак. Рәмзи шулай уйлады.

Апрель аеның дымсу кичләренең берсендә Рәмзи, фабрикадан чыгып, үзенең тулай торагына таба юнәлде. Кар хәзер тротуар читләрендә генә калган, хәтта гөрләвекләр дә тынган, бары поселок урамнарындагы агачларда кошлар сайрашуы гына колакка керә. Ә урам артында башланган калын нарат урманы җиңелчә шаулый, аннан поселок урамнарына нарат чәере исе тарала. Тик Рәмзинең күңелен биләп алган нәрсә хәзергә язгы уяну түгел иде. Хәтта хатын-кызлар турында да уйланмады ул бу минутта. Аның башында хәзер читлектәге чебиләр иде. Чыелдавыклар хәйран гына үсәләр бит. Профессор башлы кеше шул! Үзгәртте азык рецептын, мәҗбүр итте зоотехникны, дирекцияне — витаминын да, аминокислоталарын да таптырды, барын да үз белдеге буенча ясатты. Һәм менә нәтиҗә! Һич уйламаган-көтмәгәнчә, читлектәге чебиләр идәндә үстерелә торганнарыннан калышмыйлар, хәтта уздырыбрак та җибәрәләр әле. Бу, чыннан да, кызык иде. Бүген генә әле Рәмзи үзе үлчәде. Нәкъ профессор әйткәнчә килеп чыкты. Артым көтелгәннән дә яхшырак. Бу хәлне ишеткәч, директор үзе корпуска төште, үзе яңадан үлчәтте, аның да, баш зотехникның да авызы колакта иде. Ләкин шатланучыларның Рәмзи бәлки иң беренчесе булгандыр. Ни әйтсәң дә, ул үз куллары белән тәрбияләп үстергән чебешләр бит алар!

Мәҗбүрән генә керешелгән эш хәзер аны кызыксындыра башлады. Тавык кетәге исе аңкыган, чебиләр чыелдавы һәркайда артыннан ияреп йөри торган бу эшнең күңелле нәтиҗәсен күрү егет өчен рәхәт иде.

Ул сынауларның яңадан бер ай, ай ярымнан соң киң колач алачагын уйлап барды. Бу вакытта инде Рәмзи абзаң җитәрлек тәҗрибә алган, профессор агайдан шактый күп нәрсәгә өйрәнгән булыр, белмәссең, әле бәлкем аны шул эшнең башына да куярлар. Ә көзгә яки кышка ул читтән торып укырга институтка керәчәк. Ә гаилә корачакмы Рәмзи? Ни пычагыма кирәк аңа, үз иркен югалтып, хатын типкесенә калулар! Күрмимени ул үзенең яшьтәшләре ни хәлдә икәнен. Хатыннарының күзләренә генә карап яшиләр. Так не пойдет! Әлегә яши Рәмзи, кирәгенә аптырап тормый.

Рәмзи кайчандыр авылда яшүсмер чактан ук өзелеп сөйгән кызын да еш кына искә ала иде. Сагына идеме ул аны? Кем белсен инде ул кадәресен.

Поселок урамындагы бер чатлыкта Рәмзи тукталып уйланып торды. Өйгә кайтыргамы, әллә Резедага сугылыргамы? Юк, соңрак барырмын, дигән карарга килде. Өс-башны да алыштырырга кирәк, аннан саграк кыланганда да зарар итмәс.

Баш зоотехник яшәгән өй турысыннан үткәч, колагына ниндидер ят тавыш ишетелде аның. Рәмзи артына борылып карады. Бер тулырак кына гәүдәле, көрән төстәге кышкы пальто кигән хатын, ике бала ияртеп, парадный ишегеннән чыкты. Алар үзара нилләрдер сөйләшеп Рәмзи барган юлдан киттеләр. Ул да булмады, Әлфия яшәгән өй турысында ук аптырашып, кая барырга белмичә торган ике хатын-кызны очратты егет. Аларның берсе зәһәр кара күзле, күс кашлы олырак хатын, ә икенчесе нечкә билле, ап-ак йөзле, яшь «карлыгач сыңары» иде. Рәмзи игътибарын шуңа юнәлтми булдыра алмады. «Ярый торган нәрсә бу, сөлек кебек, чукынмыш».

Бу поселокка нинди генә кешеләр килеп китми, дип уйларга өлгермәде, әлеге «карлыгач сыңары»ның үзенә мөрәҗәгать итүен ишетте. Тәгаен бу хатыннар Рәмзине ерактан ук күреп, нидер сорау өчен көтеп торалар иде.

— Әйтегез әле зинһар, — диде Сафура русчалатып. — Безгә Әлфия Максудова дигән кеше кирәк иде.

— Ах, сезгә Әлфия Галиәкбәровнамы? — диде Рәмзи ачылып. — Мин аның квартирасын беләм.

Бу сүзләрдән соң Сафура, елмайган килеш, сынаулы һәм бераз хәйләкәр карашын егеткә ташлады.

— Белсәгез, безне шунда озатыгыз әле.

— Бик рәхәтләнеп, — диде Рәмзи. Тышкы ишекне ачып кергәч ул, монда караңгырак дип, юри Сафураның беләгеннән тотты. Алар өчәүләшеп өскә, якты баскыч мәйданчыгына менделәр. Рәмзи ишекне күрсәтте.

— Рәхим итегез, менә шунда яши ул!

Шактый нәзакәтле килеп чыкты аның кыланышлары. Сафура бу дулкынланып торган кара чәчле, сызылып киткән кара мыеклы чибәр егеткә тагы бер көлемсерәп карамый булдыра алмады. Рәмзи исә ул арада җиңелчә генә баш иде һәм йөгерә-атлый баскычтан төшеп тә китте.

Икенче көнне көндезге аш вакытында фабрикадан өенә кайтканда Рәмзи Сафураның ялгызын гына очратты. Бу юлы инде алар күптәнге танышлар кебек куллар бирешеп исәнләштеләр.

— Ну, кичә күрештегезме соң сеңлегез белән? — диде Рәмзи.

— Күрештем. Ә сез Әлфиянең минем сеңел икәнлеген кайдан беләсез?

— Ә мин бит күрәзәче. Миңа сезне күздән бер кичерү җитә. Мин барысын да үтәли күрәм.

— Вот как! — диде Сафура көлемсерәп. — Алайса сез волшебник икән.

Рәмзи әле бүген генә Галиәкбәрнең сөйләгәннәрен хәтерләде.

— Әгәр теләсәгез, мин сезнең исемегезне дә әйтә алам. Телисезме?

— Ягез, әйтеп карагыз.

— Сез гүзәл Сафура.

Сафура яңгыравык тавыш белән көлеп җибәрде.

— Да-а, сезнең белән шаярып булмый икән. Әле сез кая соң болай?

— Өйгә кайтам, көндезге аш вакыты безнең. Ә сез кая юнәлдегез?

— Мин кибеткә генә. Минем белән килгән ханым сезнең фабрикада эти янында калды әле, без Әлфия белән икәү генә. Тегеләрнең кайтуына ашны бераз тәмләндерергә кирәк дигән фикергә килдек. Магазиныгыз шушы яктамы?

— Мин сезне бу юлы да бик рәхәтләнеп озатып куя алам. — диде Рәмзи.

Сафура Рәмзинең өс-башын күзеннән кичерде дә әйтми кала алмады:

— Культура, мин әйтәм, авылларга да барып җитте. Хәзер авыл егетләре дә шәһәрчә киенә, шәһәрчә модно иттереп чәч үстерә башлады.

— Сез мине күздә тотасызмы?

— Ну да, кемне тагы!

— Әгәр сез мине авыл егете дип исәплисез икән, ялгышасыз. Мин Чаллыдан. Ә Чаллыда ике йөз илле мең кеше яши. Аны авыл дип атап булмый торгандыр бит?

— Ах, шулаймыни? Алайса гафу итегез.

Рәмзи үзенең ничек монда килеп эләгүе турында сөйләп алды. Әлбәттә, ул кайбер төзәтмәләр кертеп сөйләде. Мәсәлән, үзен ни өчендер КамАЗда техник булып эшләдем дип әйтте. Мәгәр барысы да җайлы килеп чыкты. Ул бит техниктан бер ягы белән дә ким түгел, КамАЗда булмаса, ул монда техник хезмәтен башкара.

Үз чиратында Рәмзи дә сорашты. Сафура да сөйләде, тик үзенең кияүгә чыгарга, дөресрәге, туй уздырырга җыенуын яшерде. Хәлбуки профессор, бер дә аны-моны уйламыйча, Рәмзигә, сорашуына җавап итеп, Сафураның бер рус егетенә кияүгә чыгарга җыенуын әйткән иде инде. Кызы шул туйга кунакка чыкыра килгән, диде әле өстәвенә.

Сафураның уенчак тонда сөйләшүен, матур итеп чытлыкланып көлүен ишеткән егет, ни өчен ул миннән кияүгә чыгарга җыенуын яшерә икән дип баш ватты. Соңыннан үзенчә хәтәр бер нәтиҗә ясады.

Рәмзи яшәгән торак кибеттән арырак иде. Озакламый алар аерылырга тиеш. Ләкин егет моны һич теләмәде, юлны озынайту өчен ул Сафураны, чатка җиткәч, аркылы урам буйлап алып китте. Болай барганда кварталны әйләнеп чыгарга һәм кибеткә килү өчен Рәмзи торагы яныннан узарга кирәк булачак.

— Между прочим, мине КамАЗда д'Артаньян дип атыйлар иде,— диде Рәмзи сүз арасында.

— Да, пожалуй, — диде Сафура, һаман уенчак тонда сөйләшүен дәвам иттереп, — сез нәкъ Александр Дюма героена охшагансыз. Ә шпага белән эш итә беләсезме соң?

— Анысына өйрәнергә туры киләчәк әле, — диде Рәмзи.

— Сез Казанга килегез, мин сезне бер спорт мастеры белән таныштырырмын.

— Ярар инде, без үзебез генә, как-нибудь.

Алар шулай юкны-барны сөйләшеп квартал тирәли әйләнделәр. Алда фабриканың тулай торагы саналган, ләкин яртысыннан күбрәк өлешендә гаиләле кешеләр яшәгән ике катлы таш өй күренде. «Сынап карыйк», — дип уйлады Рәмзи, сәгатенә карап, һәм бик житди тонда:

— Беләсезме, Сафура иптәш, без сезнең белән бераз ялгышканбыз, — диде. — Хәзер кибет көндезге ялга ябылган икән.

— Неужели? — диде Сафура, ихластан куркынып.

— Ул нәкъ унбиш минуттан ачылыр. Әйдәгез, вакыт уздыру өчен минем аппартаментка кереп утырыйк. Минем тормыш белән дә танышырсыз, кызыксынсагыз, конечно. Теләсәгез, гитара уйнарбыз.

— Сез кайда торасыз соң?

— Менә шушы йортта

Сафура теләмәгәндәй йөзен җыерды.

— Әйдәгез, әйдәгез, мин бит кеше ашамыйм,— диде Рәмзи аны култыклап, — Миндә кайбер кызыклы фоторәсемнәр дә бар. Карарсыз.

— Ну что ж, — диде, ниһаять, Сафура тәвәккәлләп.

Алар Рәмзинең аскы каттагы аерым ишекле кысан, тар бүлмәсенә керделәр. Сафура сәерсенеп бүлмә эчен күзләре белән сөзеп чыкты.

— Бик кечкенә түгелме соң?

— Ә миңа шул җитә. Салыгыз пожалысты өстегезне, юкса эсселәрсез.

Рәмзи урталыкта аптырабрак калган хатынның киемен салдырырга әзерләнеп аның артына басты.

— Ну что ж, — диде Сафура бу юлы да, тәвәккәлләп. Егет киемнәрне чөйгә элеп куйгач, кунагына урын тәкъдим итте. Үзе аның каршысына, караватка утырды.

— Хәзергә ярый квартира, — диде ул, — мин аның тынычлыгына кызыктым.

— Да, анысы бар. Сез шушында өнендә яткан аю кебек яшисез алайса.

Рәмзи бу сүзләрдән, үзенчә башка мәгънә чыгарып, көлеп куйды.

— Юк, алай димәс идем. Кайчагында ат кебек эшлим, кайчагында бүре кебек тамак кайгысы белән дә йөрим.

Ул үрелә төшеп Сафураның ак матур йөзенә, яшькелт очкынлы күзләренә текәлде.

— Сез беренче күрүдән туа торган мәхәббәткә ышанасызмы, Сафура?

Сафура имән бармагын күтәрде:

— Ну-ну, глупостьлар белән шөгыльләнмәгез! Бик примитив прием.

Рәмзи кинәт урыныннан сикереп торды да хатын янына килде, кинәт аның иңбашларыннан тотты.

— Мин сезне күрү белән яраттым. Сездән дә матуррак хатынны күргәнем юк әле минем.

— Китегез, безобразник, нишлисез сез, — диде Сафура зәһәрләнеп. Ләкин хатынның артык каршы килергә теләмәвен Рәмзи шунда ук аңлады. Аны иңнәреннән тоткан килеш өскә күтәрде, кайнар итеп иреннәреннән үпте. Сафураның күзләрендә ахмак бер тетрәнү күренә, ә ак йөзе комачтай кызарынган иде. Егет аны кочты да караватына аудара башлады. Ләкин хатын, көтелмәгән гайрәт һәм җитезлек күрсәтеп, Рәмзинең кулыннан ычкынды.

— Сумашедший!—диде ул.—Псих ненормальный, күлмәгемне йомарлыйсың бит, аю!

...Соңыннан Сафура Рәмзинең кайнар яңакларын үзенең матур куллары белән чәбәкләде дә, авыз почмагын үбеп куйды:

— Яратам шундый смельчакларны!

## 4

Сафура ул көнне әтисенең һәм Эльвираның өйгә кайтуларын түземсезлек белән көтеп йөрде. Аның әтисеннән акчаны Эльвира барында сорыйсы килә иде. Ләкин бәхетсезлеккә каршы дигәндәй, фабрикада эшләүчеләр һаман кайтырга ашыкмадылар. Алар дүртәүләшеп бик озак (директор, баш зоотехник һәм галимнәр) Гатауллин кабинетында сөйләшеп утырдылар. Аннан тагы бер тапкыр сынау корпусына төшеп менделәр, булачак олы экспериментка хәзерлек турында озаклап киңәштеләр. Барлык кирәк-яракны, һәрбер ихтималны исәпкә алып, хәзерлек эшләренең календарь планын төзеделәр. Башланачак эш җитди иде. Казанда булып кайтканнан соң,

ул директива төсен алды, фабрикада эшләүчеләр генә түгел, трест әһелләре дә хәзер бу эшкә зур өметләр баглый, аның уңай барып чыгуы белән кызыксына иде.

Хәлбуки, боларның берсен дә Сафура белми дә, белергә дә теләми. Аңа хәзер булачак туй мәҗлесен иркенләп уздырырлык акча кирәк, һәм ул, әтисен баш тарта алмаслык шартларда калдырып, үз дигәнен итү турында гына хыяллана иде. Ул өйдә япа-ялгызы оекчан аякларын астына җыеп диванга утырган килеш, Әлфиянең мода журналларын актарды. Әледән-әле бүген көндез, теге дуамал егет белән булган хәлне дә искә төшерде. Булса да була бит шундый сюрпризлар дөньяда! Сафура үзалдына көлемсери һәм күзләрен нык йомып, башын артка, кулларын читкә ташлап рәхәтләнеп киерелеп куя.

Ишектә звонок ишетелгәч, сикереп торып, сөрлегә-сөрлегә туфлиларын аягына эләктерде дә, коридорга ташланды. Керүчеләр дүртәү иде. Сафурага мәгълүм кешеләрдән тыш пөхтә киемле, җыйнак кына бер ир кеше дә бар. Ул үзен «Фәрит» дип тәкъдим итте. Сафура аны шунда ук, тәҗрибәле хатын буларак, бәяләргә ашыкты. Ярый торган нәрсә бу, тик артык җитди, күрәсең, аның өчен иң мөһиме эштер.

Кунаклар чишенгән арада Галиәкбәр Әлфиягә йомыш кушарга да өлгерде:

— Кызым, без төгәлләнмәгән сүзне дәвам иттергән арада чәй кайнатып алчы. Чәй алдында сөйлисе сүз тәмлерәк булыр кебек. — Ул елмая төшеп, шәрехләп, тамак кипте, дип куйды.

— Үзем кайнатырмын, — диде Сафура, — бәлки сезнең сүзгә Әлфия дә катнашырга тиештер.

Галиәкбәр куанычлы аптырау белән олы кызына карап алды. Бик ошарга тырыша, тәгаен, үтенече бардыр.

— Ярый алайса, — диде ул. Ләкин бу арада Әлфия кухняга чыгып чәйнеккә су агыза башлаган иде инде. Ул чәйне газ плитәсенә куйды да, үзе янына чыккан Сафурага, әгәр авырсынмаса, су кайнап чыккач кечкенә пыяла чәйнектә куерак итеп чәй пешереп куярга, суыткычтан һәм буфет шкафыннан азык-төлек алырга, чәй кирәк-яраклары әзерләп, теге якка кертергә кушты.

Ул кергәндә инде кунаклар утырышып сүз башлаганнар иде. Сафура кухняда гына бу яктагы сүзгә колак салды.

Анда ниндидер чебиләр, комбикорм, батареялар, витаминнар, аминокислоталар һәм тагы бик күп төрле һич аңлашылмый торган, һәм шуңа күрә Сафурага кирәксез нәрсәләр турында сөйләшәләр иде. Сүзне нигездә Галиәкбәр алып бара. Ләкин еш кына Фәритнең дә тавышы ишетелгәли. «Артык серьезный, яратмыйм шундый делягаларны», — дип уйлады Сафура Тик шулай да, күрәсең, егет бик төпле сүзләр әйтә иде. Аңа беркем дә каршы килми, сораулар гына бирәләр.

Ниһаять, Эльвираның да тавышы ишетелде, ләкин аның ни турында әйткәнен Сафура ишетеп бетермәде, бары әтисенең доцентка биргән җавабын гына ачык ишетте.

— Ай, алай димәгез, Эльвира Хәкимовна, — диде әтисе, — мин сезне аңлы рәвештә алдагы эшнең нечкәлекләре белән таныштырырга тырышам. Сез аңларга тиеш, мин бит инде яшь җилкенчәк түгел, бүген мин исән, ә иртәгә...

— Авызыгыздан җил алсын, юкны сөйләмәгез, — диде Эльвира.

— Юк, мин үләргә җыенмыйм, шулай да мин бүген сәламәт, ә иртәгә сырхауланып калуым бар. Ә инде шул хәл була калса, Эльвира Хәкимовна, мин сезгә ышанам. Сез эшнең гыйльми ягын җитәкләргә тиеш буласыз.

Аннан соң тагы Фәритнең көр тавышы ишетелде:

— Монда инде Әлфиягә бик зур җаваплылык йөкләнәчәк, — диде ул.

— Әйе, әйе, кызым, син башта ук аяк киен. Ә бәлки аңа, вакытлыча гына булса да, берәр ярдәмче кирәк булыр, ә?

— Анысы турында, әлбәттә, уйлашырга туры килер, тик менә бу турыда юкка директорга әйтмәдек. Мине тагы бер нәрсә борчый. Бу корпуска вакытлыча, эш көйләнеп эзенә төшкәнче, аерым цех дип карарга кирәк булыр. Әмма кемне цех мөдире итеп сайларга?

— Күп уйлап торасы юк. Ул эшкә тиешле әзерлек алган Рәмзиебез бар бит, — диде Галиәкбәр. Сафура ирексездән колакларын торгызды, бераз каушый калды. Мәгәр бу баштагы тойгы гына шундый иде. Егетнең бу кешеләр арасында Сафураның абруен сатып мактанмаячагын ул күңеле белән тоя иде. Шуңа күрә шунда ук тынычланды, тагы үз эше белән шөгыльләнеп, тыңлавын дәвам иттерде.

Әйе, боларның мәгънәсез сүзләре бик озакка китте бит әле, дип уйланды ул бераздан. Кичәдән бирле ни кадәр гомер узды, ә аның әтисенә мәсьәләне чишә алганы юк әле. Ә бәлки менә хәзер, чәй урыны әзерләгәндә үк әйтергәдер?

Чәйнектәге су буларын бөркеп кайнап чыкты, бераздан пыяла чәйнектәге чәй дә кызарып пешеп өлгерде. Сафура теге бүлмәгә чәй кирәк-яракларын ташый башлады. Ул башына килгән уйны тормышка ашырмыйча калмый торганнардан иде. Өстәлгә нәрсәләрне урнаштырып кунакларны сыйлауны Әлфия кулына тапшыргач, ул куерган аһәңгә үзенең көчле тавышы белән басып, әтисенә мөрәҗәгать итте:

— Гафу үтенәм, әти! Минем сиңа бер үтенечем бар иде. Сезгә тәнәфес булсын, ә мин шуны әйтим әле.

Барысы да тукталып Сафурага текәлделәр. Ләкин Галиәкбәр сүз агымын икенче юлга җибәрергә ирек бирмәде.

— Ай, кызым, — диде ул, — мин синең нинди үтенеч белән килүеңне аңлыйм, тик син әз генә сабыр ит. Менә безнең сүз беткәч әйтерсең.

Ул шулай диде дә ниндидер биологик актив элементлар, яктылык режимы һәм тагы әллә нинди, Сафурага кызыгы булмаган әйберләр турында сүз башлады. Башкалар исә аның авызына карап тынып калдылар. Сафураның җен ачулары чыкты, тик хәзер моны һич сиздерергә ярамаганлыгын ул яхшы аңлый. Ул эчтән тынып, үзенең чынаягына шикәр салды, балкашыгын чокырында болгата башлады.

Кунаклар яңадан бер сәгатьтән дә ким утырмадылар. Һәм, Сафураның әйтәсе сүзен бөтенләй онытып булса кирәк, дәррәү купшылар да таралыша ук башладылар. Уңайсыз хәлдә калды Сафура, гарьлегеннән еласылары килде.

Ул өйдә тагы япа-ялгызы калды. Сафура бу кимсетелүләрнең үчен ала белер иде инде югыйсә, тик хәзер ярамый, ярамый.

Өйдән чыгып киткән кешеләр башта өчәүләшеп Эльвира Хәкимовнаны контора белән янәшә үк торган таш өйнең ике бүлмәсен генә билгән кунак өенә алып киттеләр. Аны шунда урнаштырып урамга чыккач, Галиәкбәр яшьләрне ялгыз калдыру өчен, мин бераз һава алыйм, дигән сылтау белән уң якка таба китте.

Караңгы төшкән, күләгәләр озынайган, Кама ягыннан җиңелчә рәхәт җил исә иде.

— Елганы бер карап менәсе бар, — дип куйды Фәрит. — Ул бүген булмаса, иртәгә кузгала, диләр.

— И, хәзер нигәдер ташулар элеккеге кебек тантаналы да, шаушулы да булмый башлады, — диде Әлфия.

Алар әкрен генә ераклашкан Галиәкбәргә карап әле һаман кунак өе каршында тротуарда торалар иде.

— Кая барабыз? — дип сорады, ниһаять, Әлфия.

— Әйдә, мине озат алайса.

Алар салмак кына атлап Фәритлар яшәгән якка киттеләр. Башта уйланып, сүзне нидән башларга белмәгәндәй, тын гына бардылар. Бу юлы Әлфия тәвәккәлрәк булып чыкты.

— Син, Фәрит, әйдә китик, шул чакны гына бергә була алырбыз, дисең. Ләкин безнең мондагы эшебез тиз генә бетмәячәк бит. Нинди кызыклы эшләр башкарырга җыенабыз, Фәрит. Ничек шуларны ташлап китмәк кирәк?!

— Әле генә мин сездә дөньямны онытып утырдым. Минем өчен син һәм эш кенә калды. Ә менә хәзер, Әлфия, өйгә кайтырга кирәк булгач, барысы да, барысы да җимерелеп, уалып төште. Барысы бетте! Мин хәзер үзем яратмаган кеше янына кайтырга тиеш, аның хурлауларына, мине кешелектән чыгарып әрләүләренә түзәргә тиеш. Китик, миңа башка юл юк!

Әлфия дәшмәде. Ул ни әйтергә дә белми иде. Фәрит сүзен дәвам иттерде:

— Әле кыямәтләр алда, Әлфиякәй! Әле ул директор янына, парткомга керәчәк. Шуннан ниләр башланачак? Монда инде миңа беркем дә ярдәм итмәячәк. Хәтта син дә.

— Ә бәлки мин булыша алырмын. Мәхәббәттән дә көчлерәк нәрсә бармы соң дөньяда! Бәлки син миңа ышанмый торгансыңдыр?

— Мин бары сине ятратканымны гына беләм.

Алар тагы сүзсез генә атладылар.

— Телисеңме, мин хәзер үк аның янына керәм дә ачыктан-ачык барысын да сөйләп бирәм, — диде Әлфия бераздан.

— Кирәкми, кадерлем.

— Ни өчен?

— Чөнки син аны белмисең. Ул ярсыган чагында әдәп кагыйдәләре белән бөтенләй исәпләшми торган кеше.

— Нәрсә, бугазыма килеп ябышыр дип уйлыйсыңмы?

— Әйе, ул барысын да эшли ала. Һәрхәлдә, әдәм рәтле сөйләшү булмаячак, бары хурлашу, кычкырышу гына... Ә минем, Әлфия, сине бер кемнән дә хурлатасым килми.

— Соң нишләргә инде болай булгач?

— Мин сиңа әйттем инде.

— Фабриканы, башланган эшне, этине калдырып китәргә?

— Мәхәббәт барыннан да көчлерәк.

Алар Фәрит яшәгән өйгә килеп җиткәннәр иде инде. Өй почмагында тукталып калдылар. Әлфия Фәритнең йөзенә тәвәккәл, хәтта кырысрак бер караш ташлады:

— Әгәр мәхәббәт барысыннан да көчлерәк икән, озын-озак уйлап тормыйча гына минем янга күчәсең дә киләсең.

Фәритнең күзләрендә өмет чаткысы кабынды, ул елмая төшеп башын күтәрде, шул ук секундта ул шундый җиңел чара табылуына шатланып, ризалыгын белдерергә теләде. Тик әчке тавыш аңа: «Тукта, ашыкма», — диде, һәм ул, тел очындагы сүзен әйтмичә, тын гына Әлфиягә караган килеш таптанып торуында булды. Йөзеннән елмаюы җуелды, күзләрендәге өмет очкыннары әкренләп сүнде.

— Мин бу турыда уйланырмын, — диде ул.

— Ярый. Мин киттем, — диде Әлфия, кискен рәвештә борылды да, тар гына асфальт тротуардан каты үкчәле туфляларын түкелдәтеп китеп тә барды.

Фәрит аны карашы белән озатып калды. Авыр иде аңа хәзер. Ул үзен ике ут арасында калгандай сизде. Ләкин алар нинди утлар, хә-

зергә әле ул бу сорауга анык кына җавап бирә алмас иде. Бер генә нәрсә ачык: аңа юллар ябык. Инде ул ниндидер өметләр белән үзен дәртләндерә икән, болар барысы да үз-үзеңне алдау, барысы да коры иллюзия. Ә хәзергә иң-иң хәтәре яңадан менә Фәһимә янына кайтып керү. Менә ул монда гына. Шушы подъездан керәсең, икенче катка менәсең, каршыдагы ишекне ачып керү белән аның хөкемендәге кеше син. Килеп төшү белән ул бөтен хакимиятне үз кулына алды. Фәритне беркемгә дә бирмәячәген ачык итеп аңлатты. Ир бирмәк — җан бирмәк. Менә аның кредосы. Һәм ул шул кагыйдәсен үтәү өчен барысын да эшләячәк. Әле фабрика җитәкчеләре аның турында белмиләр. Ул үзе дә мәсьәләне тиешле оешмалар алдында күтәрергә ашыкмый булса кирәк. Фәритне үз кодрәте белән сындырырга тели, аны шантаж, куркыту белән буйсындырырга өметләнә. Ләкин Фәрит бу юлы алай бирешмәс. Ул да кеше, аның да кешечә яшисе килә, һәркемнең гомере бер генә.

Ләкин нәрсә тота соң Фәритне, нигә ул кискен адым ясарга, кем әйтмешли, күперләрне яндырып ташларга базмый. Бәлки ул эштән кууларыннан курка торгандыр? Бәлки югары оешмалар алдында, коллектив каршында яманаты чыгудан?.. Курка микән соң? Әгәр кешенең вөҗданы саф булса, ул үзенең гаепсез икәнен белсә, бу эш шул кадәр куркыныч микәнни?

Фәрит шундый чуалчык уйлар белән баскычтан менде, ишекне ачып эчкә үтте. Колагына беренче килеп кергән тавыш Маратның шатланып: «Әти, әти кайтты», — дигән сүзләре булды. Малай диваннан атылып төшеп җан-фәрманга әтисенә таба йөгерде, сикереп аңа асылынды. Аның артыннан шулай ук шатланып Ләйлә килеп чыкты. Ул да әтисенә килеп сыенды. Фәрит балаларын берәм-берәм үпте, башларыннан сыйпады, ашханә буфетыннан берәр конфет алып кайтмавына үкенеп куйды. Балаларның шулай үзен өзелеп яратуын, әтиләренә карата шулай тирән, эчкерсез ышаныч саклавын тою аңа бик рәхәт иде. Бала! Нәрсә соң ул бала? Юк, ул кешенең дәвамы гына түгел, ул ниндидер тылсымлы бер кодрәткә ия бугай!

## 5

— Кая югалдыгыз сез барыгыз да? — диде Сафура. Ул Әлфиянең ялгыз икәнлеген күргәч, тагы да аптырый төште:

— Ә әти кая?

— Ул шулай һәр көн кич, йоклар алдыннан, озак кына һавада йөри, — диде Әлфия.

Сафураның кулында «Огонек» журналы. Күрәсең, ул шуны укып вакыт кыскарткандыр. Әлфия чишенеп, өстәл җыештырырга кереште, Сафура исә диван-карават почмагында аякларын астында калдырып утырган килеш, укуын дәвам иттерде.

— Ятып тор, апа, — диде Әлфия, Сафурага каршыдагы караваттан бер мендәр ташлап.

— Чыннан да, — дип куйды Сафура. — Шул кадәр арыдым, сездәге урман һавасы шулай изрәтә, ахры.

Ул матур аякларын диван-караватка сузып киерелеп ятты да тагы журналын кулына алды.

— Иске журнал инде ул, — диде Әлфия.

— Ә минем өчен яңа ул. Күптән кулыма газета-журнал тотканым юк.

Әлфия өстәлне җыештырып, савыт-сабаны кухня ягында юып урнаштырды да апасы янына чыкты.

— Кая, мин дә синең белән ятыйм әле.

Алар бер мендәргә башларын куеп яттылар. Икесе дә бер буйда, зифа һәм матур иде алар. Сафура журналны баш аркылы идәнгә атып бәрде.

— Безнең кайчаннан бирле инде шулай бергә яткан юк, ә? — дип куйды ул.

— Әйтмә дә! Бер ун ел бардыр инде ким дигәндә.

— Әле ул чакны әни авырмый иде. Хәтерлисеңме, без синең белән һәр вакыт алар караватына ятып хыялланырга ярата идек.

— Хәтерлим, без космонавт булу турында планнар кора идек. Ходаем, бар иде бит кызык чаклар!

Алар шул кызык чакларны күңелләреннән кичереп, бераз сөйләшмичә яттылар.

— Әти докторлык диссертациясен яклагач безгә Мәскәүдән бүләкләр алып кайтты. Икебезгә дә бәйләм кофталар, сиңа зәңгәр, миңа оранжевый. Аннан икебезгә ике китап, сиңа Робинзон Крузо, миңа буяулы, бик бай оформить ителгән «Аш пешерү остасы» дигән китап. Шунда әтигә хәтерем калган иде. Менә, җүләр түгел диген инде мине!

— Ә син бит соңыннан ялынып-ялварып миннән кофтаны да, китапны да алдың. Миңа үзеңнең бүләкләреңне бирдең. Ә мин әтигә шул аш остасы китабы өчен рәхмәтләр әйтеп бетерә алмадым. Өйдән киткәч тә үзем белән бик озак йөрттем. Тик Бөгелмәдә яшәгәндә бер җүнсезе урлап киткән.

— Бар иде инде җүләр чаклар, — диде Сафура. Аннан дустанә тон белән сорап куйды: — Син ничек яшисең соң? Язмышыңнан канәгатьме?

— Нәрсә әйтим, апа? Эшемнән канәгать, үземне яраталар, хөрмәт итәләр, премия биреп торалар.

— Ә личный тормышыңнан?

Әлфия көлеп куйды:

— Личный тормышым әле чәчәк атарга өлгермәде.

Сафура аңламады. Ул башын борып Әлфиягә карап алды. Аларның чәчләре бер-берсенә тиеп тора иде. Әлфиянең чәче куерак, көрәнрәк, арттан төйнәгән, ә Сафураның исә сыеграк, аксыл-сары, таралып җилкәгә төшкән. Сафура Әлфиянең матур сөякчел, уртасында әз генә калкуы булган борынына, чак кына алга чыгып торган иягенә, тулы матур иреннәренә карап куйды, һәм, үги сеңелесенең матурлыгына соклангандай, озын ясалма керфекләрен сирпеп әйтте:

— Син һаман сафмы?

— Менә тагы? — диде Әлфия гаҗәпсенеп. — Саф булмыйча!

— Ну и дура!

Бу юлы Әлфия зур коңгырт күзләрен тутырып апасына борылырга мәҗбүр булды. Ул сүз әйтмәде, ләкин аның күз карашында, нинди ахмак сораулар бирәсең син миңа, дигән мәгънәне укырга булыр иде. Шулай да Сафура тыела алмады, сүзен дәвам иттерде:

— Син мондый эшнең азагы начар беткәнлеген беләсеңме?

— Әйе, беләм, — диде Әлфия теләмичә генә.

— Белгәч соң? Тап бирәрсен вакытлыча гына булса да.

Әлфия урыныннан сикереп үк торды:

— Син нәрсә сөйлисең, апа?

Ул утырган килеш апасына өстән карап тора башлады. Сафураның йөзендә оятсыз елмаю балкый иде. Аның матур тулы күкрәкләре әле күтәрелә, әле иңә.

— Юк, — диде Әлфия катгый рәвештә. — Мин андый эшне булдыра алмыйм.

— Ул башта гына кыен, ә аннан гади бер нәрсәгә әйләнә.

— Юк, юк, — диде Әлфия.

— Ят, — диде Сафура. — Тыныч кына сөйләшеп ятыйк. Мин дә кайчандыр синең кебек мәхәббәт, фәлән-фәсмәтән дип, мудрить итә идем. Ә барысы да на поверку условность икән. Хәтеремдә, сигезенче класста укыганда, Рашитка дигән бер егеткә безума гашыйк булдым. О, боже, ул гына дөньяда, ул гына беренче егет, аннан да чибәр кеше юк. Җуләрләнеп беренче булып аңа хат яздым, беренче булып аның белән свидание билгеләдем. Ул да, яратам, дип йөргән булды. Яратам, ди. Мин, дура, ышанам. И нәрсә булып бетте? Син дә белмәдең, әниләрем дә белмәде, мин больницага кереп чыгарга мәҗбүр булдым. Чөнки Рашитка кирәген алды да миннән йөз чөерде. Мин сине знать не хочу, ди. Ул инде унынчы класста укый иде. Тиздән мәктәпне бетереп, бөтенләй Казаннан ук китеп барды. Менә ул нәрсә, син әйткән чын мәхәббәт.

— Син үзең гаепле. Син йомшаклык күрсәтергә тиеш түгел идең.

— Ничек инде, яраткан кешеңә ышанмаскамы?

— Яраткан кешегә ышанырга, тик җебеп кенә төшмәскә. Нигә, син әниең безгә сөйләгәннәрен оныттыңмыни?

— Нәрсә сөйләгәнен? Кызык, абсолютно хәтерләмим.

— Ә син гомумән әни белән әтигә гомер буе кимсетеп карадың.

— Булгандыр инде, Әлфия. Булгандыр. Бәлки аның довольно веский сәбәпләре дә булгандыр.

— Аңламыйм.

— Как аңламыйсың? Нәрсә күреп үстек без? Детсадмы? Анда нинди генә балалар һәм тәрбияләүчеләр юк иде. Инде мәктәпне әйткән дә юк. Без бит семья җылысын белми үскән инкубатор чебешләре.

— Белмим тагы. Мин үзем алган тәрбиямнән канәгать. Әнигә дә, әтигә дә, шул ук детсадыма, укыган мәктәпләремә дә рәхмәттән башка сүзем юк. Мине — ятим, ташландык бер баланы кеше иттеләр, белем бирделәр, рәхмәт. — Ул кашларын җыерып апасына сораулы кырыс караш ташлады. — Бәлки син нянкалар, гувернанткалар тәрбиясендә үсәргә теләгәнсеңдер?

— Мин бернәрсә дә теләмәдем һәм теләмим дә. Мин бары хөрлек кенә телим. Кешенең һәр адымы регламентацияләнгән икән, ул инде ирекле тормыш түгел.

— Кем тарафыннан регламентацияләнгән?

— Кем тарафыннан булса да.

— Регламент дәүләт администрациясе тарафыннан булырга мөмкин, ул булырга мөмкин эш урының тарафыннан, ул милли йола, я җирле йола була ала. Ул кешенең вөҗданы тарафыннан куелган регламент булырга мөмкин. Алар бик күп һәм төрле-төрле. Син аларның берсен дә кабул итмисеңмени? Алар бер очракта чиратлашып, икенче очракта бергәләп, кешенең һәр адымына регламентация ясап торалар. Элек аллага тапшырганнар бу миссиянең иң эффектлысын, ә хәзер вөҗданга. Ничек, син барысыннан да азатмы бу регламентларның?

Сафура дәшмәде. Бераздан ул сүзне икенчегә борды:

— Мин кияүгә чыгам.

— Әйе, әти әйтте миңа.

— Миңа туй уздырырга акча кирәк. Туй дип әллә нинди шикарный түгел инде. Ну шулай да иптәшләр белән бер күңелле итеп утыру турында сүз бара.

— Син әтидән акча сорарга килдең инде?

— Кемгә барыйм мин? Әнә Димканың әтиләре простой колхозниклар и то 200 сум җибәргәннәр. Ә ике йөзгә нәрсә алып була, костюммы, обручальный йөзекләрме? Я, әйт?

— Ә син Димкаңны яратып чыгасыңмы соң?

— Мин ярату-яратмау мәсьәләсендә сиңа әйттем инде. Сүз кешенең приятныймы, неприятныймы булуы турында гына барала. Ул довольно приятный егет. Атлет. Блондин, характеры покладистый.

— Ә син аңа, Сафура апа, шулай да чыкма.

— Ә мин чыкмыйм дигән идем. Болай гына яшик дигән идем. Чөнки мин беләм, ир-хатын булып торуы ул әле үзе бер өстәмә нагрузка. Юк, ди, минем тәрбиям андый эшкә рөхсәт бирми, ди. Ул да синең кебек бер чудак.

— Без синең белән, апа, бөтенләй ике төрле кешегә әверелгәнбез икән.

— Ничево, тора-бара син дә минем арттан китәрсең әле. Тормыш куша аны.

— Шундый тормышта яшибез микәнни без? Мин алай уйламыйм. Син, минемчә, артык эгоист һәм ялкау, шуңа күрә ирек, мәхәббәт дип, тузга язмаган сүзләр сөйләп ятасың да. Син бит менә физик. Сәләтеңә мәктәптә дә хәйран калалар иде. Шуның өчен сине махсус мәктәпкә дә бирделәр. Аннары физика факультеты бетердең. Инде нигә дип гади секретарь-машинистка булып эшләргә кирәк? Әти бит сине менә дигән институтка урнаштырган иде.

— О, бу катлаулы мәсьәлә. Әйдә без синең белән дусларча гына сөйләшик, Әлфия. Минем бүген настроением шундый.

— Ихтыярың, — диде Әлфия. Бу минутта аңа кечкенәдән үзен әтиәнисе сизмәгәндә һаман, һаман рәнҗеткән үги апасы бик-бик кызганыч иде. Рәнҗеткән дигәндә дә, аларның дус, сердәш чаклары да булмады түгел. Сафура аңа урта мәктәптә укыганда азмы ярдәм итте. Аның ярдәме булмаса, бәлки бөтенләй башка юлга кереп китәр иде Әлфия. Ул түшәмгә карап шулар турында уйланып ятты. Әкренләп апасына карата булган ачуы сүрелде. Бары тик кызгану хисе калды.

— Син бер дә Лиана турында сөйләмисең.

— Мин сиңа әйтмәдеммени, ул бит хәзер санаторийда, аның перкесы положительный. Үпкә чиренә шикле балаларның Займищеда санаториесе бар. Ул шунда.

— Ничек яши соң ул минем нәни сеңелкәем, баргалыйсыңмы?

— Баргалыйсыңмы дип, син минем занятостьны беләсең, Әлфия. По мере возможности инде.

— Мин ул нәни кыз өчен борчылам. Ә Дмитрий ничек соң, аны яратамы?

— Аның баланы рәтләп күргәне дә юк. Билгеле, үз баласы түгел инде. Әле өйләнешеп бетмәдек, ул чудак үз баласы турында хыяллана башлады. Табып бир бер малай ди. — Сафура көлеп куйды. Әлфия дә апасының күңеле өчен дип кенә елмая башлады. Әйе, ятим балалар хәле. Ул үзе ятимлеген соңыннан гына, үскәч кенә сизде. Шулай да ятим кеше карашыннан барлык узган гомерен бәяләде һәм үзен янә дә ятим итеп тоя башлады. Күрәсең, шуңа күрәдер, ул ятимлек мәсьәләсендә артык сизгер, аларны артык кызганучан иде. Ул Лиана турында уйланды. Кинәт аның күз алдында Фәритнең ятим булып калачак балалары җанланды. Әлфиянең ул балаларны күргәне юк. Ул аларны берничек тә анык кына төсмерли алмый, мәгәр алар балалар иде һәм ятим килеш үсәчәкләр иде. Ул үзе дә тоймастан, аһ орып, авыр сулыш алды.

Сафура күзләрен йөретеп кенә Әлфиягә сынаулы караш ташлады.

— Син аның өчен ут йотма, — диде ниһаять, кызның борчылуы Лиана өчен генә дип уйлап. — Без Митя белән аны интернатка бирергә сөйләштек. Анда ул вольный казак булып үз иркендә үсәчәк.

— Мин мондый эшне иң зур әшәкелек дип исәплим, — диде кинәт Әлфия кызып.

Аның тыелгысыз рәвештә күзләрен яшь каплады. Монда барысы да җыелган иде, Сафураның бу рәхимсез сүзләре, күңелен тутырган авыр хисләренә өстәлеп, кызның түзем буасын җимерүче соңгы тамчы булды.

— Ни булды сиңа, — диде Сафура куркынып. Ул торып утырды да Әлфиягә табан иелеп, сеңелесенең колакларына агып төшкән күз яшьләрен куллары белән сөртә башлады.

— Кирәкми, нигә андый сентиментлар. Ул бик бәхетле булачак.

Әлфия, авызы белән сулаган хәлдә, яшьле күзләрен Сафурага текәде.

— Син безнең әтиләрне гаеплисең. Безне тиешенчә карый алмадылар, бары эш, эш, эш иде аларның күңелләрендә, дисең. Ә син үзең соң, бердәнбер кызыңнан да котылмак буласың. Мин әтиләрне гаепләмим, алар зур эшләр майтарганнар, ә син соң, син ни өчен, ни өчен үз рәхәтең өчен, просто хайвани рәхәтең өчен...

Ул артык сөйләшә алмас булды. Аны, күз яшьләре буып, бөтенләй өнсез калдырдылар.

— Беләм мин, беләм, — дип пышылдады Сафура, — бала ата-анасы белән бергә булырга тиеш, бу табигать законы. Ләкин нишлим соң мин, Әлфия, минем дә яшисем килә бит!

Әлфия борынын тарткалап алды.

— Яшәү? Шул яшәүме?

— Әйе, минемчә, яшәү шул.

## 6

Иртәгесен чәй янында Сафура әтисенә:

— Мин бүген китәм, чөнки министр белән өч көнгә генә дип сөйләшкән идем, — диде.

— Ярар, бик әйбәт булган, менә сеңелеңнең тормышын күрдең. Кияүгә сәлам әйт, — диде карт.

Сафура авыз чите белән генә елмайды да:

— Я, хәйләкәр дә син, әти, — дип куйды. — Әлфиянең тормышын күрү өчен генә монда килеп китәрлек хәлдәге кешемени мин! Син бит минем ни өчен килгәнемне бик яхшы беләсең.

— Мин сиңа бары алачак пенсиямә ышаныч кәгазе генә язып бирә алам. Шуны алырсың, ә башка акчам юк минем, кызым, мин сиңа аны Казанда ук әйттем.

— Күрсәт сберкнижкаңны, — диде Сафура, — әгәр син честный икәнсең.

Карт пинжәк кесәсеннән бумажнигын алды да саклык кассасы кенәгәсен Сафурага сузды. Анда унбер сум акча язылган иде.

— Оят, билләһи, — диде Әлфия, — әтигә карата шундый мөнәсәбәт була аламыни!

— Ничево! — диде Сафура, — сочтемся. Ул шуны заслужил. Менә бу юлы да хитрить итә. Аның наверняка икенче книжкасы да бар.

Карт тамак кырып куйды.

— Юк, минем башка кенәгәм, кызым. Теләсәң, пенсиямне алырсың, ышаныч язуы бирермен.

Ул тәрәзә янындагы кечкенә өстәлдән кәгазь һәм каләм алып, язарга утырды.

— Әти дим, язма! — диде Әлфия гасабиланып. Ул ачу белән апасына текәлде: — Үзем биреп торам сиңа акча.

— Миңа бер биш йөз сум житә, — диде, бераз югала төшеп, Сафура.

— Яз расписка!

— Расписка?

Сафура нидер эзләгәндәй, Әлфиянең йөзенә карап торды, аннан тагы да ачырак елмаеп:

— Менә хәзерге заманда туганнар нинди, ә! — дип куйды.

— Ни чәчсәң, шуны урасың,— диде Әлфия тыныч кына.— Расписка язганда акчаны кайчан кайтарып бирәчәгеңне ачык яз. Мин эшкә барышлый саклык кассасына сугылырбыз. Бирермен.

Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Галиәкбәр Әлфиянең мондый нык та була алуын әле беренче тапкыр күрә иде. Әйе, Әлфия хаклы. Шулай да картка акча мәсьәләсендәге мондый ипсез сөйләшүне тыңлау авыр иде.



Әлфия квартирасында сүз туйга дигән акча турында барганда, Фәритләрдә сүз бөтенләй башка турыда бара иде.

Аларда да иртәнге чәй вакыты иде. Чыр-чу килеп табынга утырыштылар. Балаларның тамакларын туйдыргач, Фәһимә аларны киендереп, урамга чыгарып җибәрде. Җитди сүз өстәл тирәсендә өч олы кеше калгач кына башланды.

— Я, карткаем, — диде Фәһимә ясалма бер тынычлык белән, — сиңа да авыз ачып бер кәлимә сүз әйтер вакыт җиткәндер. Синең куышыңда өчне кундык. Иртә таңнан торып китәсең дә кояш баегач кына кайтып керәсең. Кайтып керәсең дә, ә юк, бә юк, ясаган чәйне эчеп урыныңа түнәсең. Мин бит монда синең борын сызгырта-сызгырта гырлавыңны тыңлар өчен килмәдем. Менә син хәзер өздереп кенә әйт: үз иркең белән, үзең ризалык биреп, безнең белән каласыңмы, әллә юкмы?

Фәрит төнне саплам-саплам гына йоклап уздырган, арып-алҗып уянган иде. Ул үзенә текәлгән Фәһимәне күрмәскә тырышып, тирәюненә карангалады.

— Юк, — диде ул, ниһаять.

Фәһимәнең йөзенә алсулык йөгерде, ә Зариф исә җәһәт кенә башын күтәрде.

— Улым, чү-чү, сүзеңне әйтер алдыннан уйлан.

— Барысы да бик күп тапкырлар уйланган инде, әти. Аларны кабатлап торуда мәгънә юк.

— Ярый алайса, — диде Фәһимә янау тоны белән. — Миңа бераз аяк киеме туздырырга туры килә икән болай булгач, мин газиз балаларымны бәхетсезлеккә дучар итә алмыйм. Аны бел!

— Теләсәң нишлә, — диде Фәрит, буш чынаягын шыкылдатып тәлинкәгә куйды.

Карт өтәләнеп чытык йөз белән сүзгә кереште.

— Һай, егетләр! Бу нинди бетмәгән киреләнү инде. Бу нинди атабаба күрмәгән бер галәмәт эш инде, валлаһи...

Фәрит барысына да әзер иде. Ул урыныннан торды да, коридорга, кием элгеченә таба ашыкты.

— Мине көндезге чәйгә көтмәгез, әти, эшем бар, — диде ул ишек ачып урамга чыгар алдыннан.

Урамда аны апрель сулышы, сыерчыклар сайравы, балалар чырчуы каршы алды.

Фәрит йөгерешеп йөргән бала-чага арасыннан үз балаларын эзләде. Тапкач, аларны кисәтеп, урамда уйнарга кирәкмәгәнлеген, ишегалдында уйнау хәвефсезрәк икәнлеген әйтеп, аларның җилбәгәй киткән киемнәрен төймәләп, аннан икесенең дә битләреннән үбеп фабрикага таба китте. Нилэр генә уйлый башласа да, Фәритнең уйлары ахыр чиктә, уйсу җиргә ашкынган гөрләвекләрдәй, тагы гаилә мәсьәләсенә барып тоташа иде. Менә ничә көннән бирле инде ул шулай директорның, я секретарьның үзен чакырып алуын көтеп яши. Телефон шалтырады-

мы, шул мәсьәлә турында сөйләшү өчен чакыралар шикелле. Буласы жәзаңны көтеп йөрү бик үк рәхәт түгел икән шул! Фәритнең әле үз гомерендә мондый хәлгә тарганы юк иде.

«Әүзем кереп әйтсәм, — дигән уй килде аның башына кинәт. — Нигә миңа шул кадәр газап чигеп, акылсыз хатынның таш атуын көтәргә!.. Юк, булмый, — дигән нәтиҗәгә килде ул шунда ук. — Чөнки, — дип уйлады, алданрак, Фәһимә килгәнгә кадәр ачылсам, минем иелгән башны бәлки кылыч чапмас та иде, ә болай ышанмаячаклар. Алар, барыр чарасы калмагач кына батырлана, диярләр».

Ул шулай уйланып, нинди нәтиҗәгә дә килергә белмәстән, урам буйлап бара бирде. Менә уңга борылды, агачлык аша инде асфальты арчылган фабрика юлы буйлап китте. «Ә болай азапланып көтү рәхәтме соң? — дип сорады ул тагы. — Ярый, синең турыда, качар чамасы калмагач шулай иткән, дип уйласыннар. Ә бөтенләй бармасаң, нәрсә уйларлар? Тагы да начаррак уйламаслармы? Нинди хәлдә дә бит әле мин эшне үзем кузгатсам, көтү газабыннан котылам. Ә мин күрәсене беркем дә күрмәс. Ах, нигә, нигә соң Әлфиянең китәсе килми! Ул эш, ди. Житди эксперимент башланачак, ди. Анда да хаклылык бар. Әгәр мин динле булсам, я хода, миңа көч-куәт бир, бу авырлыкларны канатларымны сындырмыйча гына уздырырлык түземлекләр бир, дип дога кылыр идем».

Һәм, ниһаять, башлыкларга үзе кереп, сүзне үзе башларга, дигән нәтиҗәгә килде ул. Фәрит директор белән секретарьның бергә булган чагында сөйләшергә теләгән иде. Авыр минутлар кабатланмас, жиңелрәк булыр дип уйлаган иде. Әмма директор үз кабинетында булмады, ә секретарь исә, ни сәбәптәндер, бүген бик иртә килгән һәм үз бүлмәсендә утыра иде. Фәрит аңа шалтыратып йомышы барлыгын әйтте.

— Давай, сүзең булгач кер, мин кайчан гына килсәм дә, миңа барыбер шулай тынгылык бирмәсләр инде, — диде ул, көлә биреп.

— Сүз бик житди булачак, — диде Фәрит телефон көпшәсенә. — Шуңа күрә син дә мине бик житди кыяфәт белән тыңла.

— Булдыра алган кадәр тырышырбыз.

Фәрит секретарь кабинетына керде. Фабриканың партия житәкчесе чандыр гына, кыска буйлы, кара тутлы бер татар егет иде. Гомумән Жамалиевны Фәрит беренче көннәреннән үк яхшы егет дип тапты. Аның белән күп нәрсәне бергәләп хәл итәргә туры килде аңа. Кайчак алар бәхәсләштеләр, ара-тирә катырак тавышланып сөйләшүләр булгалады. Тик Жамалиев мин-минлек белән жәфа чигүче кешеләрдән түгел иде. Шуңа ул кинә саклау, үч алу кебек түбәнлекләргә беркайчан да бармады. Аның өендә элек кош караучы булып эшләгән гади генә ачык йөзле хатыны һәм жиде баласы бар. Гомумән, әйбәт оештыручы булу өстенә секретарьның гаиләдә дә яхшы кеше булуын сөйлиләр иде.

Фәрит газета подшивкалары белән тулган озын өстәл янынннан узды да түрдә, аркылы куелган өстәл артында нидер язып утыручы Жамалиев каршына ук барып басты.

— Тыңлыйсыңмы? — диде.

— Тыңларга исәп. Давай утыр, сайрый башла.

Фәрит утырды.

— Тон алай ук мажорный булмас кебек. Лутчы елый башла, диген.

Жамалиев каләмен өстәлгә куеп, бераз сәерсенгән хәлдә, Фәриткә текәлде.

— Менә нәрсә, мин синең алдыңа бик зур жинаять ясаган аморальный кеше сыйфатында килдем, — диде Фәрит.

Жамалиевның эчкә баткан кара күзләре беткәнче ачылды. Ул бермәл бу шаяртадыр, дигәндәй елмаерга да итте. Ләкин Фәрит артык

житди иде — секретарь сүзенең дәвамын тыңлар өчен бөтен игътибарын җикте.

— Эш шунда, мин моннан бер ел элек хатынымны һәм ике баламны ташлап, дөресрәге, алардан качып, сезгә эшкә килеп урнашкан кеше. Бер ел буена алимент акчасы түләмәдем, бер ел буена өемә хәбәр итмичә яшеренеп яттым. Менә мин шундый кеше.

Җамалиев, Фәритнең әйткәннәренә ышанмады булса кирәк, имән бармагын чигәсенә төртеп боргалый-боргалый сүзне бүлдерде:

— Синең шөрепләр барысы да урынындадыр бит?

— Хәзергә урынында. Мин сиңа, иптәш Җамалиев, дөресен сөйлим. Әгәр инде ышанмасаң, әнә бар минем квартирага, хатынымнан сора. Өченче көн алар җыйнаулашып бирегә килеп төштеләр.

Фәритнең хәзергә әйтер сүзе беткән иде. Җамалиев исә, һич көтелмәгән бу яңалыктан югалып калгандай, өнсез торды, бер Фәриткә, бер тәрәзәгә карап алды, ниһаять, ул акылын җыеп сорады:

— Ниемә дип шундый тинтәклек ясадың соң?

Фәрит әнә шул сорауны бирмичә генә хөкем чыгара башларлар дип курыккан иде. Ул иркен сулап куйды.

— Чөнки мин хатынымны яратмый идем.

— Яратмый идең... Яратмагач, ник өйләндең? Бәлки сине көчләп өйләндергәннәрдер?

— Ахмак булдым. Яратам дип уйладым. Шуңа өйләндем.

— Ә яратмавыңны шулай бик соң белдеңмени? Балалар, дисен түгелме?

— Балалар. Олысы җиденче белән бара, кечесе биштә. Ә яратмавымны күптән белдем, тик түздем. Аның холкында, карашында үзгәрешләр көттем, бәлки аны яңадан ярата башлармын дип өметләндем.

— Ә өметләр сүнде?

— Сүнде. Башка юл калмады.

— Юл калмагач, нигә закон нигезендә судлашып аерылышмадыгыз?

— Ул теләми. Аннан балалар... бәлки киләчәкнең билгесезлегеннән курку да бардыр.

Җамалиев, ни әйтергә дә белмичә, авыр итеп бер сулап куйды.

— Мин бары шуны гына әйтә алам,— диде ул, ниһаять,— сиңа сөйләгәннәреңне ачык итеп партбюрога язып бирергә кирәк булыр.

— Авыр эш йөклисең син миңа. Бәлки телдән әйтелгәннәр дә житәр, ә?

— Юк, алай булмый.

Фәрит терсәгенә таянган хәлдә, чигәсен кашып, йөзен чытты:

— Син минем хәлемне аңласаң иде, Җамалиев. Мин хәзер өйрәнеп житмәгән эквелибрист кебек. Аяк астымдагы аркан да чайкала, кулымдагы колга да әле бер якка, әле икенче якка авыша. Минем мәтәлеп китү ихтималым бар.

— Син ни теләсең соң миннән? Яклавымнымы?

— Белмим, — диде Фәрит. Чыннан да, әле эшнең асылын аңлап бетермәгән секретарь нишли алсын! Аннан, гомумән, аңлармы әле ул? Фәрит үзе дә аңламаган нәрсәне чит кеше ничек аңласын?!

Җамалиев учы белән өстәлгә җиңелчә генә суккалап алды.

— Мин үзем гаилә мәсьәләсендә консерватор кеше, — диде ул. — Сайлап алгансың икән, өлешеңә чыккан көмешеңнән риза бул, яшә, матур гына итеп, балалар үстер.

— Шулай ул, үз башына төшмәгән кешегә акыл сатулары җиңел. Ә менә сез, ир белән хатын, психологик яктан бер-берегезгә тиң килмәсәгез, ничек?

— Мондый чатаклык килеп чыкмасын өчен, минемчә, өйләнгәнгә кадәр бер-береңне бик нык сынарга кирәк.

— Ә мена мин ул кагыйдәне үти алмадым, чөнки яшьлектә акылдан да бигрәк хисләренә буйсынып яшисең икән ул.

— Аңлыйм мин анысын. Ләкин бит һәр эштә нәтиҗәгә карап хөкем йөртәләр. Син хатыныңа һәм балаларыңа гына мәңгелек күңел ярасы эшләмәгәнсең, анысы да, әлбәттә, бик мөһим, ләкин син бит семья таркатып безнең дәүләткә, җәмгыятькә дә зур зыян ясыйсың.

Җамалиев урыныннан торды да ишек янындагы элгечкә асылган пальтосы янына барды. Пальто кесәсеннән сигарет кабы чыгарды.

— Гаилә, дибез, ул дәүләтнең беренче күзәнәге, шул бинаның кирпече, дибез, нигез нык булырга тиеш, дибез. Ә фактта нишлибез? Хәтта коммунист иптәшләр дә кайчак бу нәрсәгә җиңел генә карый. — Ул кырыс, хәтта ачулана төшеп, Фәриткә текәлде. — Туктале, син нигә килдең миңа, Фәрит Зарипович? Нигә син кычытмаган җирне кашып, үзеңне дә, безне дә борчып йөрисең? — Җамалиев яңадан үз урынына утырды, сигарет сузды. — Тартасыңмы? — Фәрит рәхмәт әйтеп баш тарткач, ул сүзен дәвам иттерде. — Син бит хатыным балаларымны ияртеп килде, дидең. Шулаймы?

— Шулай. Ул шушы көннәрдә килеп төште.

— Шулай булгач. Бик әйбәт, тыныч кына яшәгез. Хатыныңнан гафу үтен, юмала, җайла, башка алай итмәм, диген. Менә салынып яткан бинадан сезгә өч бүлмәле квартира бирербез. Хатының да белгечме?

— Юк, ул сберкассада эшли иде.

— Сберкассада? Ну аңа бездә дә шундыйрак эш табылмый калмас дип уйлыйм. — Җамалиев, барысы да шулай ансат кына хәл ителүенә үзе дә шатлангандай, яктырып китте. Фәритнең ачуы богырдап ташый иде. Ул түзмәде, читкә борылды. Ниһаять, әйтте:

— Шулай итеп сарыклар да исән, бүреләр дә тук булачак, дисең инде син.

— Нигә, — диде Җамалиев, җитдиләнеп. — Шулай түгелмени? Тормышта бит бик хитри әйберләр бар, Фәрит Зарипович, алар ялгышуны күтәрмиләр. Гаилә кору ул минер хезмәтен үтәү кебек. Анда ялгышырга ярамый. Ялгыштыңмы, беттең. Син аны үзең дә чамалыйсыңдыр.

— Минемчә, син бик иске категорияләр белән эш итәсең.

— Юк, мин алай димәс идем. Әйдә, синең белән килештек, ди. Син үзеңне гаепле санамыйсың, чөнки яшь булгансың, ялгышкансың.

— Мин мена ялгышымны төзәтү өчен ул хатыннан аерылырга телим. Чөнки мин аның белән барыбер яши алмыйм.

— Даже? — дип куйды Җамалиев. — Димәк, берсе дә мин әйткәнчә барып чыкмаячак?

— Әйе, чыкмаячак.

— И син инде шуннан соң үзеңә бәхет эзләячәксең, шулаймы?

— Һичшиксез. Һәм мин аны табачакмын.

— Ай-һай. Таба алмассың кебек. Чөнки син ясаган өйләнү акциясе бик зур, бик тирән эзләр калдырган. Син бәлки үзең яраткан кешене табып тормыш корырсың, тик балаларың беркайчан да күз алдыңнан китмәс. Вөҗданың һәр вакыт сыкранып торыр, дип уйлыйм.— Ул сигаретын тирән итеп бер суырды да озак кына читкә төтен өреп торды. — Әлбәттә, бу минем личный карашым, Фәрит Зарипович, син аны парткомның рәсми карары дип уйлый күрмә.

— Аңлыйм.

Җамалиев Фәритнең балалары турында сораша башлады, аннан хатынына күчте. Фәрит, берни дә яшермәстән, аңа ачыктан-ачык булган хәлләрне сөйләп бирде. Тик күренә, болар берсе дә Җамалиевның кристаллашып өлгергән фикеренә йогынты ясый алмый иде. Хәер, Фәрит әллә ни көтмәде дә. Гаилә мөнәсәбәтләре, андагы эчке конфликтлар, әгәр алар хулиганлыкка барып җитмәсә, читләрнең тыгылуын күтәрми.

Моны Фәрит аңлый иде инде. Һәрхәлдә, хәзер аңа җиңелрәк булып китте. Ул уйлаганын эшләде, чәчми-түкми булганын партком секретарена сөйләп бирде, бары бер нәрсәне генә, Әлфияне телгә алмады. Үзенең аңа булган чиксез мәхәббәте турында ләм-мим сүз катмады. Бу яшеренү куркудан түгел иде, үзенә бирелгән зур бәхетне, яшәү һәм дәрт чыганагы буларак, үзе өчен генә, үз йөрәгендә генә саклау өчен иде. Аны башкаларга ачып күрсәтсә, бу тирән нәфис хис кимсетелер, җәберләнер кебек тоелды аңа. Гүяки битараф кешеләр үзләренең гамьсез, хәтта әле дорфа мөгамәләләре белән бу гүзәл тойгыны мәсхәрәләрләр кебек иде.

Фәрит парткомнан чыккач бөтен барлыгы белән эшкә чумды. Директорга кереп тормады, чөнки аның яңадан бу турыда сөйләшерлек көче калмаган иде инде. Партбюрога аңлатма язуны да башка вакытка калдырып, ул цехлар борынча китте. Алтынчы цехта бүген әзер бройлерларны тотып сугым цехына тапшыру көне иде. Ничегрәк, артык вак түгелме чебиләр. Аларны тотканда бик җәрәхәтләмиләрме? Түшкәне бозмыйлармы? Болар барысы да фабрика өчен бик мөһим иде. Юлда баш ветеринар очрады. Икәүләп корпуска уздылар. Эчтә шаушу, чебешләр җәнҗалы купкан, түшәмгә кадәр тузан күтәрелгән. Менә идәндә асрасаң ничек ул, аларны тотуы да бер проблема!

Челтәрле калкаңнар белән коралланган эшчеләр чебиләрне кысрыклап бер почмакка куалар. Бу эшнең ахыры әйбәт бетмәячәген сизенгән чебиләр тирә-юньгә сибеләләр, хәтта кайберсе кеше биеклегендәге тимер чыбык челтәр аша сикереп тә чыга.

— Әкренрәк, тынычрак, — дип кычкырды Фәрит, — нигә шулай травма ясарга?! Болай да, аллага шөкер, түшкәләрне югары сорттан уздырып булмый.

Алар цех начальнигы, ветфельдшер һәм сугым цехы мөдире янына килделәр. Һәркайсы белән кул биреп исәнләшкәч, Фәрит цех мөдиреннән уртача үлчәүнең күпме булуы белән кызыксынды. Кило да өч йөз иде.

— Аз, — дип куйды Фәрит борчылып.

— Арык тотуда файда юк. Артым бирмиләр, ашату бушка китә, — дип зарланды башлык.

— Азык күпме тотылган?

— Дүрткә якын.

Фәрит йөзен чытты:

— Ой-ой-ой!

— Комбиазыкта житешмәүчелек.

— Кушабыз бит: маен да, үлән онын да.

— Барыбер дефицит.

— Җен алгыры, — дип мыгырданды Фәрит.

Бераз карап торганнан соң, ул ветврачны һәм сугым цехы мөдирен ияртеп корпустан чыкты.

— Ничегрәк, сезнең яңа суыргычлар шәп эшлиме әле, чыгымчыламыймы? — дип сорады ул цех мөдиреннән.

— Хәзергә зарланып булмый.

Сүз суелган түшкәләрне чистартучы, әле күптән түгел генә гамәлгә кертелгән машина турында бара иде. Бу машина берничә секунд эчендә түшкәнең эчен суыртып чистарта.

Алар шул турыда сөйләшә-сөйләшә ярым автоматлаштырылган сугым цехына килеп керделәр. Монда барлык эш диярлек машиналар ярдәмендә эшләнә, тавыкның йонын йолкудан алып баш-аяк, эчке әгъзаларын аертуга кадәр. Монда берни дә югалмый, тавыкның йоны да, конфискатлары да, хәтта каны һәм калдыклары да җыелып, я комбиазыкка кушыла яки ашламага әйләндерелә, ә йон, эшкәртелеп, мендәр, ястык мастерскойларына озатыла.

Корпуска килеп керү белән борынга төчкелтем чи ит исе бәрелде. Фәрит буйдан-буйга берничә рәт итеп ыргакларга эленгән түшкәләрне карап узды. Ярый, күгәргәннәре, начар эшкәртелгәннәре алай күп түгел. Шулай да алар ветврач белән икәүләп цех мастерына тәнбиһ ясаштырдылар. Тагы да азрак булырга тиеш мондый брак.

## 7

— Әлфия, бәлки син минем туема барырга мөмкинлек табарсың?

— Ышандыра алмыйм, апа.

— Ник?

— Эш күп.

— Эш, эш, эш. Бетмәгән эш булды инде ул синең. Эш тә эш, ә яшәргә кайчан соң?

— Эш арасында.

Алар поселок яныннан гына уза торган олы юл чатындагы автобус тукталышында эскәмиядә утыралар иде. Машина кирарга юлга чыккан Эльвира әйләнеп керде һәм аларның арасына килеп утырды.

— Гаҗәп матур җирдә икән поселогыгыз. Чын мәгънәсендә курорт урыны, — диде ул.

— Менә ял көненә кадәр калмадыгыз ич, бергәләшеп Кама буйларына чыккан булыр идек. Искиткеч матур урыннар бар монда.

Әлфия җәй көнен үзенең шул җирләрдә йөрүен хәтерләп сөйли башлады, җәйге ялга үзләренә кунакка чакырды.

Эльвира, әлбәттә, килергә әзер һәм киләчәк тә. Чөнки фабрикада башланган тәҗрибә эшләре аның өчен чыннан да кызыклы, кирәкле иде. Ул Галиәкбәргә шулай юмартлык белән бөтен эш планнарын сөйләгән өчен күңеленнән рәхмәтләр укый иде. Сафура җәен бу якларга килеп чыгу мөмкинлеге табылыр дип уйламады. Чөнки алар, Дима белән, җәйне «кыргый» рәвештә ял итеп Кара диңгез буенда уздырырга сөйләштеләр. Лиананы китереп китсәң генә инде бирегә, дип уйланды ул. Ләкин моны әлегә әйтергә базмады, ничектер түбәнсенде. Аныңча Әлфия үзенең дәрәҗәсе белән дә, гомумән, хатын-кыз буларак та Сафурага житми иде. Сафура уенча ул район тирәсендә, авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшләп хәзер бөтенләй тупасланган иде. Шуңа күрә апасын аңламый да. Өстәвенә көнчелек тә бардыр. Сазаган кыз булып калу көннәре аның әллә кайда түгел, егете юк, ир-ат каршында абруе юк, ә апасы инде менә икенче тапкыр үзе сайлап, бары егетнең ялварып, үтенүеннән соң гына, кияүгә чыга.

Дөреслектә Сафура үзен тынычландыру өчен генә шулай уйлый иде. Ул күңел күзе белән Әлфиянең үзеннән өстенлекләрен күрми түгел. Аның беренче өстенлеге шунда: ул үзенә-үзе хуҗа. Аның тапкан акчасы үз теләкләрен башкарырга җитә (әле артып та кала), аның квартирасы бар, аны җитди кешеләр санга сугалар. Тагын шунысы да бар: Сафураныкы кебек тәртипсез богема тормышы аркасында күз тирәләренә җыерчыклар да кунмаган.

Ләкин эгоист кеше һәр вакыт үзендә башкалардан өстен яклар табарга тырыша, һәм тапмый калмый да. Чөнки өстенлек табылмаса, ул үлде, бетте, дигән сүз. Юк, болай гына китмәячәк әле Сафура моннан. Әлфиягә исендә калырлык берәр сүз әйтәчәк!

Сүзгә Эльвира Хәкимовна кушылды.

— Мин сезгә менә нәрсә әйтмәкче идем, — диде ул Әлфиягә. — Галиәкбәр Хафизович миңа ни өчендер артык картаеп киткән кебек тоелды. Сез аны саклый күрегез инде. Күрәсез бит ул алтын хәзинә.

Әлфия ирексездән әтисенең сөйләгәннәрен хәтерләде. Чак әйтми түзеп калды. Булмаган гаепләр тыгып кафедрадан китәргә мәҗбүр

иткәндә ник бу турыда бер дә уйламадыгыз соң, дип әйтәсе килде аның. Мәгәр кыз түзде, яхшысынмады.

— Тырышырмын, булдыра алганча тырышырмын,—гына диде.

Үр өстенә, тәрәзә пыялаларын кояшта ялтыратып, автобус килеп чыкты. Тавык түшкәләре салынган сеткалар кулга алынды. Ниһаять, җылы гына саубуллаштылар. Автобус баскычына менгән Сафура борылып, ачы елмайган хәлдә, мәкерле сүзен әйтеп куйды:

— Теге расписканы югалта күрмә тагы, Әлфия!

Әлфия дәшмәде, ачудан кызарынды. Оста һәм бик рәхимсез рәвештә алды үчен апасы!

Кыз тасма булып сузылган асфальт юл буйлап поселокка таба юнәлде. Ачу әкренләп сүрелде. Сафура нинди зәһәр һәм көнче булмасын, ни әйтсәң дә Әлфия өчен әле дә кызганыч тоела иде. Нигә, ни өчен кешеләр үзләренә бирелгән сәләтне кешеләргә бүләк итәргә теләмиләр. Ни өчен үзләре эшләү урынына алар әүвәл кешене эшләтүне алга сөрәләр. Күрәсең, шуннан килеп чыккандыр ул берәүләрнең армый-талмый хезмәт итүдән ямь табып яшәүләре, икенчеләрнең эшләмичә байлыкка ашкынулары.

Әлфия үзенчә шундый фәлсәфә корып, урман арасындагы юлдан бара бирде. Аны хәзер сандугачлар сайравы, тукраннар тукылдавы озата иде. Кичә генә тын утырган урманга бүген җан керде. Әле алда бик матур көннәр көтәдер бәлки Әлфияне.

Ул бүлмәсенә килеп керүгә әтисенең диван-караватта ятуына аптырый калды:

— Әти, нишләп болай?

Галиәкбәр ничектер гаепле кеше кебек елмаеп куйды.

— Нәрсәдер кәеф китеп тора әле. Рәмзи белән яңа читлекләрне карап йөрдек. Аларны күтәргәләргә дә туры килде. Шул ярамады, ахры, кызым.

— Яшь егетләр барында нигә соң андый эшләргә тыгыласың, әти. Эшләсеннәр, көчләрен кая куярга белмиләр ич ул Рәмзиләр.

— Нигә? — диде Галиәкбәр, бик аптырап. — Рәмзи шәп егет ул, кызым. Ул булмаса әле безнең эш болай ук көйле бармас та иде.

— Яратмыйм мин шул Рәмзиегезне.

Карт тәмам аптырашта калды.

— Ни өчен?

— Яратмыйм инде. Яратмагач яратмыйм.

— Юк, алай димә син, кызым, ул сине бик хөрмәт итә. Гел синең турыда сорашып тора.

Әлфия борынын гына җыерып куйды. Һәм бу бик көлке килеп чыкты, Галиәкбәр дә елмайды.

— Ярар, калдырыйк вак-төяк нәрсәләрне, — диде Әлфия. — Кай җирең авырта соң синең, бәлки врач чакыртырга кирәктер. Безнең монда кечкенә генә булса да врачебный пункт та бар бит.

— Бу юлы аяк түгел, йөрәк, — диде карт. — Әйе, йөрәк. Ул шулай авырткалый инде карт кешенең. Син аңа артык игътибар итмә, эшеңә бар. Апаларыңны озаттыңмы?

— Озаттым ла, — диде Әлфия. — Бәлки берәр дару алып кайтырга кирәктер, әти.

— Юк, кызым, даруларым бар. Чемоданымда бер уч дару йөртәм. Ансыз булмый хәзер.

— Мин шулай да врачка әйтәм, — диде Әлфия, катгый бер фикергә килеп һәм коридордагы телефон аппараты янына чыгып китте.

Ул башта врачка шалтыратты. Аннан лабораториягә. Ярдәмчесенә әлегә бераз тоткарланасын, башланган анализларны дәвам иттерергә кирәклеген әйтте.

— Менә шулай, — диде ул, этисенең баш очында торган утыргычка урнашып. — Врач килеп сине карамый торып, бер кая да китмим мин.

Галиәкбәр җиңелчә көлеп куйды:

— Теләсәң нишлә инде алайса, тик эшләреңә зыян килмәсен.

— Юк, мин монда булганга карап эш тукталмас. Йөрәгең бик авыртамы?

— Син яныма килеп утыргач, бөтенләй басылды инде, кызым.

— Шулай да мин, әти, Сафура апага аптырыйм. Нинди кеше ул? Кайда тәрбияләнгән?

Әлфия аның китәр алдыннан үзенә агулы сүз әйтеп рәнҗетүен сөйләп алды.

— Нигә кирәк иде ул? — диде ачынып. — Булдыра алганча кунак иттем, күчтәнәчен төяп җибәрдем. Рәхмәт сүзе шул рәвештә әйтелергә тиешмени?

— Аттан ала да, кола да туа икән шул, кызым. Халык белми әйтмәгән. Мин аны аңлыйм булса кирәк. Ул барлык кешене үзенә бурычлы дип исәпли. Менә аның чире шунда. Кем белә, бәлки аны бәләкәй чагында артыграк иркәләгәнбездер.

— Юк, анысы булмады, мин шаһит, безнең икебезгә дә өлешләр тигез бүленә иде. Беләсең бит, мәрхүм әнием бик акыллы хатын иде. Әле миңа өлешнең зуррагы да эләкмәде микән дип уйлыйм. Мин моның сәбәбен, билгеле, соңыннан гына белдем. Ул мине ятим дип, кызганып шулай күкрәгенә ныграк кыскандыр.

— Мин берни дә әйтә алмыйм, кызым, — диде карт, — бары шуны тоям: кешене кеше генә тәрбияләмидер, ахры, кеше иң беренче чиратта үз-үзен тәрбияләргә тиештер.

— Син мендәрнең дә бик җайсызын алгансың, әти, аннан ботинкаларыңны салдырыйм әле, өстеңә одеял да япмагансың.

Әлфия әтисенең аякларын чишендереп, өстенә бөркәнчек ябып, яңа мендәргә яткырды да, үзе тагы аның янына утырды.

— Синең хәлләр ничегрәк соң, кызым? — дип сорады Галиәкбәр.

— Бер көе.

— Син теге көнне ничектер бүген безгә Фәрит килергә тиеш, синең белән киңәш-табыш итәсебез килә дигән идең...

— Әйе, шундый бер теләк бар иде. Тик ул барып чыкмады бит, әти.

— Сәбәп?

— Фәритнең хатыны балаларын ияртеп килеп төшкән.

— Шулаймыни? Һәм ул киңәш-табышның шул вакыйгага бәйләнеше бармы?

— Бар, әти. Без синнән ул көнне моннан соң нишләргә, ничек бергә булырга дип киңәш сорамакчы идек.

— Бергә булырга? — диде Галиәкбәр, куркынып.

— Әйе, мин Фәритне аңлыйм, аңа ышанам, әти.

— Кирәкми, кызым, кирәкми. Син язмышыңны аның белән бәйләргә ашкынма. Аның гаиләсе, балалары бар. Бу эш мөмкин түгел.

— Ни өчен, ни өчен, мин бит аны яратам, әти, — диде кинәт Әлфия, ачыргаланып. Аның күзләре яшьләнеп китте, йөзенә алсулык йөгерде. — Ул да мине ярата. Ә хатыны аны бөтенләй яратмый. Нигә безгә кушылырга мөмкинлек юк?!

Әлфия артык тыела алмастан, әтисенең башын кочаклап еларга тотынды.

Карт кызын тынычландырырга тырыша, аның чәчләреннән сыйпап иркәли иде. Ләкин Әлфия аның саен ныграк елый, тавышсыз гына әтисенең йөзен күз яшьләре белән чылатып сулыга иде.

— Тынычлан, кызым, — диде Галиәкбәр. — Мондый хәлдә күз яшьләре ярдәм итмәс сиңа.

Кыз кинәт үзенең елавы белән этисенең кәефсезлеген арттырачагын аңлап, башын өскә күтәрде, күз яшьләрен, борынын тиз-тиз сөртеп, гафу үтенде:

— Онытылып киттем, бер дә ярамаган эш эшләдем. Син моңа бер юләрлек дип кенә кара, эти.

Әлфия әле һаман үзен тәртипкә китерү белән мәшгуль иде, Галиәкбәр үзе сүз башлады:

— Мин аңлыйм сине, кызым. Син чын күңелдән гашыйк булгансың. Ләкин тормышның бик катлаулы законнары бар. Анда һәр төенне чишеп була дип карарга ярамый. Минә бу да шулайрак хәл, минемчә. Түз, үзеңне кулга ал, нык бул, ул үзмый калмас. Өметсез мәхәббәттән кеше үлми, мәхәббәт яңадан туа, яңадан, өр-яңадан чәчәк ата ала. Шуңа күрә батыр бул, мәхәббәткә омтылу кебек үк, аннан баш тарта алу да кешене кеше итүче сыйфатларның берсе.

— Юк, мин аны ташлый алмыйм, эти. Ул инде минем көндәлек тормышыма, яшәү ихтыяҗыма әйләнде.

— Анысы бик әйбәт, матур итеп ярата белү ул зур бәхет. Ул бәхет яратканың белән кушылудан ким түгел. Кушылу, өйләнеп, кияүгә чыгып, бергә яши башлау, ул инде мәхәббәтнең, яңачак әйткәндә, материальләшүе. Ә ул кайчагында мәхәббәтне сүндереп тә куя. Син шундый кешеләрне белмисеңмени, яратышып кушылалар, ә бераздан бер-берсен ярату гына түгел, үзара дошманга әвереләләр. Мәхәббәт билгеле бер шартларда нәфрәткә әйләнә.

— Димәк, алар яратышып кушылмаган булалар.

— Яратышып кушылган хәлдә дә, эш кушылуга барып җиткәч, яратусыз булмый. Ләкин нинди зурлыкта ул хис? Аннан син шул олы тойгыны тормыш ваклыкларыннан имгәтмичә саклый аласыңмы? Монда кешенең акылы да, ихтыяр көче дә зур роль уйный, кызым.

— Без, күрәсең, мәхәббәт кебек олы тойгыны шулай төрлечә акыл иләкләре аша уздыра-уздыра юкка чыгарабыздыр. Мәхәббәт, минемчә, шундый тойгы ул, айнык башлы кешенең салкын канлылык белән тикшерүен күтәрми, эфир кебек, һавага очып юкка чыга.

— Син, кызым, киңәш сорадың, мин белгәнемчә аны сиңа бирдем. Ә ахыр чиктә бу мәсьәләдә вөҗданың хаким.

— Мин дә шулай дип уйлыйм, эти. Кайбер нәрсәләрне коллегиаль-но хәл итәргә ярамый торгандыр, ахры. Вөҗданым хаким. Әйдә ул хөкем итсен барысын да.

Кинәт ишектә звонок тавышы ишетелде.

— Кайда этиегез? — диде хатын-кыз тавышы ишектән килеп керү белән, — нәрсә булды аңа?

Врач кысык күзле яшь кенә чуваш кызы иде. Алар Әлфия белән поселокта очрашкан көнне үк дуслаштылар. Әлфия кебек ул да әле кияүгә чыкмаган кыз. Үзенең якын итүен күрсәтергә теләп, ул аерата өтәләнеп Әлфия артыннан бүлмәгә узды. Профессорны игътибар белән тикшерде һәм, күрәсең, үз итүен тагы да ачыграк сиздерү өчендер, Галиәкбәргә татарча:

— Җүрәкне сакларга кирәк, бабай, — диде. — Сезнең җүрәк шактый тузган.

Ул дарулар язып, Әлфиягә бүген үк алып кайтырга кушты. Кухня якка чыккач:

— Дару эчсен дә тыныч кына ятсын. Иртәгә мин кереп чыгармын,— диде.

Врач чыгып китәргә җыенды.

— Тукта, бергә,— диде Әлфия. Ул тиз генә этисенә термостан лимонлы чәй ясады, ашарга куйды.

— Әти, мин китәм алайса, — диде. — Берьюлы дарулар да алып кайтырмын.

— Әлфия, фабрикага керсәң, күз-колак бул әле, теге син яратмый торган егет читлекләрне каплатты микән?

Әлфия, йөзен чытты, мәгәр каршы сүз әйтмәде.

Урамда ул врачны куып житте:

— Ничегрәк соң? Бик серьезный түгелме этинең авыруы?

— Әйттем ич инде, — диде Таисия Степановна, аннан башка да кысык күзләрен кысып елмая-елмая.

— Юк, син авыруга әйтерлеген генә әйттең.

— Әтиеңнең йөрәге әйбәт түгел. Аның коронар кан тамырларында ишемический чир бар. Сак булсын, егетләнмәсен, авыр эмоцияләрдән саклансын, стресс булмаска тиеш. Берничек тә...

## 8

Фәһимә каты-каты басып «Партбюро» дип язылган ишектән кереп китте. Ләкин ни кадәр батыр кыланмасын, аның йөзендә каушау сизелә, күз карашы таркау, яңак итләре калтырый иде. Кергәч тә аңа карап алган һәм кем булуын чамалаган Жамалиев яңадан кәгазьләренә чумды.

— Сез буласызмы партком секретаре?

— Әйе, мин, ни йомыш?

Фәһимә утырды да, һичбер сүз әйтә алмас булып, еларга керешге. Кинәт куркуга калган Жамалиев урыныннан сикереп торды, хатынга графиннан су агызып бирде.

— Эчегез әле башта, тынычланыгыз, сез минем белән сөйләшергә кердегезме?

Хатын ияк кагып кына шулай булганлыгын аңлатты.

— Сөйләшергә кергәч, сөйләгез. Ни йомыш?

Фәһимә үзенең кем икәнлеген һәм нинди йомыш белән килгәнлеген аңлатты.

— Ачыграк сөйләгез әле, — диде Жамалиев. — Сез бик ярсыгансыз, ахры, шуңа әйткәннәрегезнең бер дә ата-анасы юк.

— Әйтеп торам ич, мин сездән ярдәм сорап килдем. Семьябыз җимерелә. Сездә эшләүче Фәрит Еникеев бер ел буе семьясыннан качып йөрде. Сез аны акылга утыртасы урында, үз канатыгыз астында саклап тордыгансыз.

— Без бит аның гаиләсен ташлап китүен белмәдек.

— Менә шул-шул, ул бик оста яшеренә белә. Тыштан бик ялтырый, ә эче тулы зәһәрле агу.

— Сез тынычрак сөйләшегез. Нинди сәбәптән булуы мөмкин соң мондый эшнең? Ул бит бала түгел, акны карадан аера белә. Нинди сәбәпләр аркасында ул шундый юлга баскан?

— Ул семья турында кайгырта белми торган бер Дон-Жуан булды, аның күңелендә гел чит хатын-кыз. Киенеп-ясанып чыгып китәр иде дә шулар арасында себерелеп йөрер иде. Ә мин гомер буе балалар белән интектем. Әллә...—Фәһимә сүзен әйтеп бетермәде, тагы елый башлады.

— Ул шундый кеше икән, сезгә нигә шул кадәр ут йотарга, — диде Жамалиев, хатын тынычлана төшкәч. — Сез, минемчә, андый ирнен китүенә шатланырга гына тиеш идегез.

Фәһимә жиң очыннан яулыгын алып күз яшьләрен сөртте, аннан булдыра алганча тулы, аңлаешлы жавап бирергә кереште:

— Ни өчен дисез сез. Ул бит нинди генә булса да миңа ир. Балаларны тәрбияләүдә, семьяны матур итеп оештыруда ул жаваплы түгелмени? Инде балалар тугач та качып китмени? Кем тәрбияләргә тиеш соң аларны? Ул бит бер ел буена өйгә сукыр бер тиен дә жибәрмәде. Аннан

шунысын да уйлагыз, мин бит аны яратып матур итеп оя корырбыз, тынычлыкта, иминлек-тәгәллектә яшәрбез дип, үземнең гомеремне, саф йөрәгемне аңа тапшырдым. Ул нишләде, йөзе кара? Барысын да аяк астына салып таптады. Өмет иттем, түзим, түзим, дидем, бәлки бу җүнсездән дә бер көн кеше оешыр, дидем, акылга утырыр, дидем. Әле дә өметне өзгән кеше түгел мин. Инде сезнең оешма белән бергәләп йогынты ясасак, ихтимал, ул бераз уйланыр, алмадай балаларым бар бит минем, үземә тиң тырыш хатыным бар бит дип уйланыр. Ахырда, бәлкем, кеше рәтенә керер дип өметләнеп эшләгән эш. Юкса!..

Җамалиев Фәритнең сүзләрен хәтерләде. Ул да өмет итү, бәлки хатыным үзгәрер, ярата башлармын дип өмет итү аркасында вакытны сузуын әйткән иде. Менә син бел инде гаилә тормышын! Җамалиев эчтән генә сукранып куйды. Кем хаклы, кем хаксыз, белеп кара!

— Үз кешегез булгач сез аны, бәлкем, якларга тырыша торгансыз инде. Тик бит айнык акыл белән караганда алиментган качып йөрүе өчен генә дә аңа бер строгачны чәпәргә була.

— Анысы бюро эше инде, — диде Җамалиев хатынның күзләреннән янау билгеләре төсмерләп.

Дөресен генә әйткәндә, Җамалиев Фәһимәне күрү белән, аның хатын-кызларга хас сыйфатлардан мәхрүм булуын абайлады. Хатынның артык чаялыгы, ирдәүкәлеге күзгә ташланып тора. Бу сыйфат исә иратта хатын-кызга карата хөрмәттән дә бигрәк бераз өркү кебегрәк тойгы тудыра. Җамалиев Фәһимә белән сөйләшкәннән соң, күңелендә Фәритне акларга теләү кебек бер тойгы тууын сизенде. Ләкин ул эш кешесе иде, һәм аңа узгынчы хисләр белән исәпләшергә ярамый иде. Ул һәр вакыт объектив хөкем чыгару өчен сайланып куелган кеше бит! Шулай да ул тикшерүне Фәрит язган аңлатма буенча уздырырга кирәк дип тапты, шуңа күрә хатын белән никадәр төпченеп сөйләшмәсен, аның сөйләгәннәрен никадәр тулы итеп язмасын, Фәһимәдән бернинди дә гариза яздырмады. Сораша торгач, ул үзе дә сизмәстән әйтеп куйды:

— Ә менә мәхәббәт дигән нәрсә булырга тиештер бит сезнең арада?

— Ун елга якын яшәгәннән соң нинди мәхәббәт булсын?!

— Ә ул сезне яратамы соң?

— Яратса ташлап китәр идемени?

— Ә сез аны?

— Әгәр мин аны яратсам, сезгә килеп әләкләп йөрер идеммени?

— Бер-берегезне яратмаган килеш яшәп булырмы соң?

— Мин сезгә бик ачык итеп әйттем булса кирәк, монда инде бер-береңә ияләшү, бер-береңә семья алып баруда ярдәмләшү генә кала. Балаларга күчә ул сез әйткән мәхәббәт дигән нәмәрсә.

«Бәлки чыннан да шулайдыр», — дип уйлап куйды Җамалиев. Ул ун елдан артык гаилә җылысын тоеп яшәсә дә, беркайчан да үзенә мондый сорауны биргәне юк иде. Әле уйлангач, үзенә сорау бирде: «Яратаммы соң мин хатынымны? Кем белсен, диде ул, шунда ук җавап итеп. — Яратаммы-юкмы икәнен белмим, тик мин аны кызганам. Ул чирләсә, миңа да авыр, ул күңелсезләнсә, миңа да күңелсез, ул миңа үпкәләсә, миңа бик авыр. Кем белә, бәлки шулдыр инде ул ярату».

— Дөресен генә әйтегез әле,— дип сорады ул Фәһимәдән.— Без ирегезне бу начар эшләре өчен партия җәзасына тартачакбыз, ул бәлки бик авыр хәлдә калыр. Сез аны бер дә кызганмаячаксызмы?

— Кызганмаячакмын. Ә ул соң семьясын ташлап, ел буена балаларының авызыннан өзеп алынган акчага типтереп яшәгәндә, безне кызганганмы?

Җамалиев үзенә-үзе күңеленнән генә, шулай шул, диярге мәҗбүр булды.

Артык сүз куертуда мәгънә юк иде. Җамалиев хатынның күпмегә килүе белән кызыксынды да, шушы көннәрдә чакыртырбыз дип, аны

өенә кайтарып җибәрде. Үзе уйга калды. Ул Фәрит яклы булган хәлдә дә, аны берничек тә яклый алмый иде.

Сәер, бик сәер хәл иде бу. Хәлнең катлаулылыгы тагы шунда иде — ул ничәмә гасырлар буена фаҗигале көрәш алып барылган һәм менә, ниһаять, безнең шартларда гына ирек яулаган мәхәббәткә каршы кул күтәрергә тиеш иде. Вөҗданы аңа болай дия: син, Фәрит Зарипович, зур хата ясагансың, син беренче тойгыларыңа буйсынып, үзең яратмаган бер кеше белән яши башлагансың. Бездә социаль ирек белән бергә гаилә иреге дә яуланып алынды. Син ирекле кеше. Әгәр син Фәһимәне яратмыйсың икән, аннан аерыл, ул үзенең мәхәббәтен, син үзеңнекен эзләгез, бәхетле булыгыз. Семья ирекле булмаса, ул нык булмый.

Тик Җамалиев болай дип әйтә алмый иде, чөнки семьяны ныгыту, балаларны тигез гаиләдә илгә лаеклы гражданнар итеп тәрбияләү мөһим мәсьәлә түгелмени? Аннан кем белә аны, әйтүен әйтә дә Фәрит, бәлки ул хатыны сөйләгәнчә бер чәчәктән икенче чәчәккә кунып йөрергә ярата торган чуар күңелле күбәләктер. Өйләнгән, ошамаган, киткән. Бәлки тагы өйләнер, бәлки тагы ошатмыйча, качып китәр. Кешенең күңелен актарып булмый бит, бәлки Фәритнең дә күңелендә әллә нинди мәкерле уйлар ятадыр. Менә ачыла башлады бит, бәлки әле иртәгә тагы да хәтәррәк сыйфатлары фаш ителер.

Җамалиев озак уйланып утырды. Ниһаять, фабриканың директоры, бюро әгъзасы Гатауллин янына кереп, киңәшергә булды. Нишләтергә бу Фәритне? Бәлки әле шау-шусыз, бюросыз, нервыларны артык теткәләмичә генә бер-бер нәрсә эшләп булыр.

Җамалиев кабинетка килеп кергәндә директор япа-ялгыз гына утыра иде. Секретарь аның кәефе яхшы икәнлеген шунда ук чамалады. Күрәсең, ул әле генә селектор аша цехларны тикшереп чыккан һәм нидәндер бик канәгать булып калган иде. Ул секретарьны якты чырай белән каршы алды:

— Нәрсә, Җамалиев? Әйдә утыр әле. Менә профессорның булачак сынаулары турында трест белән сөйләштем. Эш киң колач алырга тора. Хәбәре өлкә комитетына кадәр барып җиткән. Эшегез барып чыксын өчен барлык ярдәмне күрсәтәбез, диләр.— Директор күз кысып «белдеңме, без шулай ул» дигәндәй елмаеп куйды.

— Бик шәп, мин моны хуплыйм, — диде Җамалиев, директорның шатлыгын уртаклашып.

— Тик менә хәзергә төп цехларда азык артык күп тотыла, — диде Гатауллин пошынып. — Нишләргә?

— Комбиазыкка әнә профессор әйткән нәрсәләрне кушарга. Җитми бит витамины да, аминокислоталары да.

— Ә аларны кайдан табарга? Бу хәл бит бер безнең генә бәла түгел, бу азапны күпчелек кош фабрикалары кичерә.

Җамалиев хәл ителмәслек нәрсә түгел бу дигән караштa иде.

— Алдынгы фабрикалар бу хәлдән ничек чыгалар соң? Азык та, хезмәт тә норма тирәсендә аларның.

— Аларга игътибар. Алар комбикормга үзләре контроль ясый.

— Алай гына түгелдер. Алар, минем белүемчә, югары сыйфатлы азык әзерли беләләрдер тагы.

— Анысы да бардыр, тик безнең хәл катлаулырак. Без әле барысын да бүре күк телне җилкәгә асып йөгергәндә генә табабыз. Ну ничево, менә читлектә асрауны көйләп җибәрсәк. Шул тәҗрибәгә таянып, шундый-шундый шартлар тудырылырга тиеш дип, без киләчәктә аякны нык терәп сөйләшә алачакбыз.

Әле күптән түгел генә сынаулар уздыруга каршы торган директорның хәзер бөтенләй башкача сайравын парторг көлемсерәп тыңлады да, әйтеп куйды:

— Мин сиңа күңелсез бер хәбәр белән кердем әле, — диде. — Фәрит Зарипович синең белән сөйләшмәдеме?

— Юк, нәрсә турында сөйләшергә тиеш иде ул?

— Алайса, менә болай инде, — диде Җамалиев. Ул зур карчыга борынын җыера төшеп өстәлгә карап торды.

— Ну? — диде Гатауллин түземсезләнеп.

Секретарь Фәрит мәсьәләсен сөйләп биргәч, директорның күзләре түгәрәкләнеп килде.

— Булмас!

Җамалиев Фәритнең язуын кесәсеннән чыгарып директор алдына ташлады. Директорның кызыл кан тамырлары күренеп торган тук яңаклары тартышып куйды. Укыган саен аның йөзендәге кызыллык арта бара иде. Укып чыккач, ул күзләрен ярым йомып, хәлсезләнгәндәй, өстәленә таба иелә башлады. Аннан бер урында тукталып катып калды.

— Чорт возьми! Көтмәгән идем, — дип куйды ул бераздан. — Билләһи көтмәгән идем. Ну, син нишләтмәк буласың инде аны?

— Менә синең белән киңәшергә кердем.

— Ну, мин сиңа аны корбан тәкәседәй чалып ташларга ирек бирмәячәкмен!

— Бер кем дә аны чалырга теләми, тик ул үзенең кабахәт эше өчен партия оешмасы каршында җавап бирергә тиеш, минемчә.

— Юк, мин аны сиңа суярга ирек бирмим, теләсәң нишлә! — диде директор. — Син бит аның яшь, энергичный һәм талантлы белгеч икәнлеген беләсең, неужели без аны бетерергә тиеш? Алдагы перспективалы эшләр шуның практик житәкчелеге астында алып барылачак бит, син шуны аңлыйсыңмы?

— Аңлыйм. Минемчә, ул андый изге эшкә чистарынган килеш, пакь килеш керешергә тиеш.

— Нәрсә, башта үкертеп мунча чабындырыйк дисеңмени?

Парторг тыела алмыйча көлеп җибәрде:

— Без бит бу эше өчен дәшми кала алмыйбыз. Моннан ярты сәгать элек кенә аның хатыны минем янда булды, егетне бик нигезле рәвештә тетә. Чара күрмәсәгез, мин сезнең белән генә чикләнмим, югары инстанцияләргә язам, ди.

— Елыймы?

— Килеп керү белән үкереп еларга тотынды.

— Шулай икән, — диде директор, уйга калып. Алдындагы кәгазьне парторгка таба этте. — Тегеләй ярыйсымы соң үзе, төскә-биткә дигәндәй?

— Ярыйсы, Фәриткә тиң, тик бик усал булырга тиеш, әллә инде мондый драма килеп чыккач кына шулай холкы бозылганмы... җен белсен!

— Шулай икән, нинди эштәге кеше икән үзе?

— Белеме бар, тик һөнәре юк, ахры, саклык кассасында эшли икән. Алар икесе дә бер мәл тынып тордылар.

— Я, нинди киңәш? Мин бюрога куярга кирәк дип уйлыйм. Коммунист үзенең оешмасын алдап, гаиләсеннән качуын яшереп, безнең арада йөргән. Хәзерге чорда, үзең беләсең, мораль сыйфат мәсьәләсе көн тәртибендә беренче урында булырга тиеш.

— Шуннан? Аны партиядән чыгарып ташларгамы?

— Мин кайдан белим. Анысын бюро хәл итәчәк инде, агайне.

— Ә анда чыгарып ташларга дигән тәкъдим булачак. Менә син дә, мин дә каршы килмәячәкбез. Мин бит белеп торам. Шунысы да бар: партиядән куылу аның өчен үлем белән бер. Димәк, ул бездән дә китәчәк, китмәсә безнең арада аның кабыгы гына йөриячәк, ә җаны булмаячак.

— Ә бәлки ул үзен саклап калыр. Бәлки аның моңа көче җитәр?

— Китмәячәк, — диде директор, кырт кисеп. — Китәрлек булса, качып та китмәгән булыр иде. Бу бит көчсезлек билгесе. Ә көчле кеше алай итми.
— Димәк, нәрсә әйтмәкче буласың инде син?
— Хатыны балаларын да алып килгәнме?
— Килгән.
— Килсә бик әйбәт, үзләре белгәнчә яшәсеннәр. Менә яңа корпус салынып бетү белән аларга иркен квартира бирербез. Теләсә хатынын эшкә урнаштырырбыз. Яшәсеннәр.
— Ничек инде? Фәрит Зариповичка бер сүз дә әйтмәскәме? Май кап, шым бул, без синең оешманы алдап йөрүеңне гафу итәбез, дияргәме?
— Юк, бер дә алай димәскә. Без аны менә шушында чакырып алабыз да тозлап-борычлап аңлатабыз. Ул аңларга тиеш. Хатаңны төзәт, гаиләңә кайт, тормышыңны көйлә, диячәкбез. Инде сүзне тыңламый икән, тиешле чаралар күрергә мәҗбүр булырбыз. — Директор урыныннан купты, селекторга иелде. — Хәзер үк эшләргә кирәк бу эшне, калган эшкә кар ява ул.
— Сез нәрсә, аны бирегә чакырмакчы буласызмы?
— Ие, нигә?
— Кирәкми, ашыкмыйк әле. Эш катлаулырак. Бәлки хатын-кыз гайбәте генәдер, тик Фәрит Зарипович безнең Әлфия Галиәкбәровна артыннан йөри дигән сүз бар.
— Булса ни! Мин дә ишеттем аны. Хатын югында яшь кешенең хатын-кызлар арасында булырга теләве бик табигый нәрсә.
— Ә ул житди әйбер булса?
— Нинди инде ул житди?
— Ну, саф, әйбәт мәхәббәт.
Директор җилкәләрен җыерып куйды. Аннан мыскыл аша елмаеп:
— Син дә, Җамалиев яратасың идеализацияне. Нинди мәхәббәт? Ни өчен? Хатыны булган хәлдәме? Сөяркәсе булырга мөмкин, ну нинди мәхәббәт инде ул? Яшүсмер малай штоли ул Фәрит Зарипович!
— Юк, шулай да, минемчә, ашыгудан файда юк. Бик деликатный мәсьәлә бит. Яхшылабрак өйрәник.
— Өйрәнү өчен башта үзе белән сөйләшик. Курыкма, мин ничек сөйләшергә кирәклеген белермен.
Гатауллин селектор төймәсенә басты:
— Син үзеңдәме, Фәрит Зарипович?
— Әйе, әле генә цехлардан йөреп кердем, — диде Фәрит.
— Кер әле безнең янга!
— Биш минуттан мин сездә булырмын.
Гатауллин урындыгын тартыбрак өстәле янына ук утырды да:
— Каян килеп чыга мондый хәлләр, чүп өстенә чүмәлә! — дип сукранып куйды.
— Дөнья диләр аны, — диде Җамалиев, Фәритнең аңлатмасын кисәсенә тыгып.
Алар көндәлек эш, йөкләмәләрнең үтәлеше, партиягә яңа кандидатлар алу, инде килеп эштәге тәртип турында сүз алып барганда, кабинетка Фәрит тә килеп керде.
Ул директор янында секретарьның утыруын күргәч, барысын да аңлады. Ул озын колактан парткомда Фәһимәнең булуын да ишеткән иде инде. Хәл-әхвәлнең ничегрәк сөйләнгәнен дә бераз чамалады ул. Аңа хәзер директорның ни рәвештә сүз башлаячагы һәм нindирәк позициядә торып, һөҗүмгә ташланачагы гына мәгълүм түгел иде.
Фәрит кабинетның урта бер җирендә тукталып калды.
— Утыр әле менә икебезнең уртага гына, — диде директор.

Фәрит бераз кызарына төшеп елмайды һәм директорның кушканын үтәде.

— Ну, эшләр ничек бара? — диде директор Фәриткә карамыйча гына.

— Ал да гөл, — диде Фәрит, бу булачак сүзнең бары кереш өлеше генә икәнлеген белгән хәлдә.

— Нәрсә, сиңа анда кунаклар килгән диме? — дип куйды директор. Фәритнең кинәт ачуы килде:

— Мин ачыктан-ачык, ирләрчә, курыкмыйча, барысын да сөйләп бирергә әзер, иптәш директор. Әйдәгез, битлекләрне салып сөйләшик.



## 9

Фәрит директор кабинетыннан бөтенләй чырае качкан кыяфәттә чыкты. Бер сәгать буе директорның үзен пешекләү нәтиҗәсе иде бу. Ул коридорда бер мизгел тукталып торганнан соң, ашыгып үз кабинетына таба юнәлде. Кереп бикләнде һәм гадәтенчә утыргычына чумәште. Ул әле генә үзенә бирелгән киңәшләргә җаны-тәне белән каршы иде. Ачынып фабрика җитәкчеләренең «яратам, яратмыйм» төшенчәләрен аңларга теләмәүләре, гомумән мондый төшенчәне исәпкә алмаулары турында уйлады. Алар өчен бары урнашкан кагыйдә бозылмасын, гаилә җимерелмәсен, балаларга травма ясалмасын, алар эти-әни кулында үссеннәр. Бәхәсләшеп кара син алар белән, әйтеп кара син аларны хаксыз дип. Ә мәхәббәт? Бу сүзне ишеткәч Гатауллинның кул селтәп ачы елмаюын күз алдыннан уздырды Фәрит. Димәк, сезнеңчә мәхәббәт дигән нәрсә юк, дип сорады ул. Бар ул, диде директор, нишләп булмасын, тик син хәзер мәхәббәт дигән нәрсәне үзеңне саклап калу өчен бер калкан итеп кенә кутәрәсең.

Ни өчен шулай әйтә ул, дип баш ватты Фәрит, димәк, аныңча мәхәббәт ул бар, тик ул синең белән миңа тәтеми торган нәрсә.

Юкка гына мин мескенләнеп аңлатмалар язып йөргән булам, минем өчен изге булган тойгыларның тапталуын ни пычагыма кемнәргәдер ачып күрсәтергә!

Чыннан да, Фәрит бер генә секундка үзен ниндидер буталчыклык аркасында халык белән шыгрым тулы зал алдына, сәхнәгә, шәрә килеш килеп чыккан кеше хәлендә тойды. Бу куркыныч төш кебек иде.

Ул тәвәккәл рәвештә соңгы карарга килеп, хәзер үк, хәзер үк үзенең Әлфиягә күчеп китәчәге турында уйланды. Аннан миңа димәгәе барысы да чәнчелеп китсеннәр. Теләсә нишләсеннәр! Фәрит бер нигә дә карамаячак, Әлфия белән бергә, мәңгегә бергә калачак, үлгәнгә кадәр. Явыз телләр гайбәтне сата бирсеннәр, тик кешеләр Фәритнең Фәһимәгә карата нәфрәт, ә Әлфиягә карата мәхәббәт хисләре белән янганлыгын аңларлар. Аңларлар да тынарлар, барлык кеше аны гафу итәр.

Фәрит сәгатенә карап алды, тиз генә пальтосын киде, һәм ашыгып бүлмәсеннән чыгып китте.

Бераздан көндезге ашка Әлфия үз квартирасына кайтачак. Аның өчен сюрприз булачак бу. Фәрит асфальт юл буйлап поселокка таба китте. Юл читендәге чокырлар хәзер яшел үлән белән өртелә башлаган. Юлның ике ягын да каплаган куе урманда искиткеч җанлылык. Гадәттәгедән иртәрәк килгән сандугачлар хәзер үзләренең могҗизанә сайраулары белән күңелләрне җилкендерәләр, уй-хәсрәтләрне таратып, күңел күген пакьләндерәләр. Эчтәрәк тукран кызу гына тукылдатып куйды.

Күңелдә ниндидер җиңеллек. Күптән шундый карар кабул итәсе урында җүләрләнеп әллә нинди сентиментлар колы булып йөрде шунда Фәрит!

Ул адымнарын кызулатканнан-кызулата бирде. Әйтерсең лә аның артыннан куа киләләр, гүя аның шатлыгын, бәхетен кемдер тартып алачак.

Хыяллары белән шул кадәр мәшгуль иде Фәрит, поселок урамына килеп кергәч, онытылып, чак кына үзе яшәгән якка китмәде. Ләкин вакытында искәрде, һәм Әлфиягә күчкәч ниләр эшләнергә тиешлеге турындагы уйлар килеп китте. Тик Фәрит аларны шундук башыннан куып чыгарды, аларның берсе турында да хәзергә бирелеп уйланасы килми, алар аны тоткарлар кебек тоела иде.

Таныш өйнең подъездына кергәч тә кызулыгын киметмичә таш баскычтан менеп китте. Звонок төймәсен басар алдыннан да ул үзенә тукталып, сулыш алыштырырга рөхсәт бирмәде, төймәгә каты итеп бер-бер артлы басып торды.

— Ачык, — дип кычкырды эчтән ирләр тавышы. Фәрит шунда гына искәреп алды, бу тавыш профессорныкы иде. Гаҗәп бер аңлашылмау туды, Фәрит бит Әлфия тавышын ишетергә тиеш иде. Соңгы көннәрдә фабрикада күренмәгән, шуңа күрә кунаклары белән Казанга киткән дип уйланылган. Галиәкбәрнең өйдә ятуы Фәритнең һич башына да кереп чыкмаган иде.

Фәрит тавышны ишеткәч каушый калды. Шулай да тукталмыйча ишекне ачып эчкә узды. Карт кушаклы халаттан (күрәсең йокы пижамасы өстеннән генә кигән) караватта утырган сулы стаканга кечкенә шешәдән дару агыза иде. Фәрит кинәт барысын да хәтерләде. Аңа бит Рәмзи «карт авырып китте» дип әйткән иде. Әйе, әле кичә генә, эш арасында, сынау корпусында. Фәрит өске киемен, туфлиләрен тиз генә салып урнаштырды да профессор янына керде.

— Исәнмесез, кәефләр ничегрәк Галиәкбәр ага?

Картның шушы өч көн эчендә йөзе суырылып калган, күз карашлары таркауланып киткән. Ул Фәритне таныгач шатлыгыннан елмаеп куйды.

— Менә рәхмәт, Фәрит. Хәл белергә керүегез өчен рәхмәт.

— Ничек соң, терeләбезме? — диде Фәрит.

— Бүген ярыйсы, шөкер, ярыйсы. Болай булса бер-ике көннән тәмам аякка басам.

Фәрит буш урындыкка утырды.

— Әлфия кайда соң?

— Әлфия бүген бераз тоткарланам, диде. Минем янга врач килеп китте. Бик әйбәт, игътибарлы врач.

Карт үзенең авырып китүе турында тәфсилләп сөйли башлады. Шактый озакка сузылган бу сүз беткәч, ул эш турына сорашты.

— Сынаулар бер көйгә бара. Нәтиҗә сез әйткәнчә, безне канәгатьләндерә, — диде Фәрит. — Инде теге зур экспериментка әзерләнәбез. Чөнки без җиңдек, скептиклар калмады, дияргә була. Директорның авызында хәзер гел шул нәрсә. Корпус та билгеләнде. Ике атнадан без ул корпусның яртысын бушата башлыйбыз. Аннары бинага читлекләр кертеләчәк. Сез тәкъдим иткән план буенча яктылык һәм һава режимы булдырылачак.

— Бик әйбәт, бик әйбәт, — диде Галиәкбәр кулындагы дарулы стаканын тоткан килеш.

— Тик авырырга ярамый, Галиәкбәр Хафизович.

Карт даруын йотып җибәрде.

— Менә боларны эчкәч терeләбез инде, — диде көлемсерәп.

— Әлфия эшендә озак тоткарланачакмы соң?

— Озакмы дип, анысын ачык әйтмәде, миңа ашарга әзерләп калдырды. Үзе ашханәдә генә капкалармын, эш күп, диде. Бик кирәк булса, телефон аша да белешә аласың.

— Ул миңа бик кирәк.

— Нинди йомыш соң алай? — Карт «өйгә килеп әйтерлек» дип өстәмәкче иде. Фәрит моны аңлады һәм картның соңгы вакытта, курәсең, авыру аркасында, аерата куп җыерчыклар белән бизәлгән йөзенә текәлде.

— Йомыш менә нинди, Галиәкбәр Хафизович, мин уз квартирамны ташлап, Әлфиягә кучеп килергә булдым. Сез белә торгансыздыр инде, без аның белән килештек, ул мине гафу итте. Аннан, бәлки, монысын да белә торгансыздыр, минем элекке хатыным биргә килде. Мин артык ул өйдә кала алмыйм.

Галиәкбәр ни әйтергә белмәстән, өнсез калды. Ул елмаерга итте, ләкин анысы да барып чыкмады. Бу ярым елмаю, ярым аптырау галәмәтләре шул килеш, аның йөзенә ягылып калдылар. Фәрит урыннан торды да телефоннан шалтыратырга коридорга чыкты.

Тик лаборатория буш түгел, кемдер сөйләшә иде.

Фәрит яңадан Галиәкбәр янына кереп утырды.

— Сез каршы түгелдер бит... минем сезгә күчеп килүемә?

Карт баштагы югалып калудан хәзер айный төшкән иде.

— Мин сезнең арага кереп, үземне нидер әйтергә хаклы дип санамыйм. Мин үзем дә монда кунак кына.

Ул яңадан урынына ятты да, күзләрен йомып тынып калды. Карт кинәт ишетелгән бу яңалыктан нык кына тетрәнгән иде. Фәрит шундук үзен саксызлыкта гаепләп өлгерде. Ләкин аның уз хәле дә хәл иде. Әлфиянең өйдә булмавы аны тагын да ныграк хафага салды.

Өстәл уртасында яткан рецепт ни өчендер аның өстәл тартмасында калган документларын исенә төшерде. Ул Фәһимәнең артык кызыксынучанлыгын, Фәрит югында аның барлык нәрсәсен актарып чыгарга яратуын, хәтта кием кесәләренә кадәр кармалау гадәтен белә иде. Документларны хәзер ук алып куярга кирәк, дигән фикер туды Фәриттә. Әлбәттә, өстәл тартмасы бикле, ләкин бит аның ачкычы да әллә кайда түгел, шул ук өстәл тартмаларының ачыгында ята. Кара инде син аны, бу ничек моңарчы Фәритнең башына килмәгән! Өстәл тартмасында аның саклык кассасы кенәгәсе дә, үзе Себергә тәҗрибә тупларга киткәч Әлфия язган хатлар да. Аларның берсе дә Фәһимә кулына эләгергә тиеш түгел. Фәритнең бөтен зиһене шул нәрсәләргә туплана башлады. Безнең заманда документсыз калу, ул инде үзеңне югалту дип уйланды.

Фәрит тагы бер тапкыр Әлфиягә шалтыратып карады. Әле һаман кемнеңдер сүзе бетмәгән иде. Фәрит кесәсеннән блокнотын тартып чыгарды. Аның бер битен ертып Әлфиягә үзенең бөтенләйгә килүе турында язмакчы булды, тик Галиәкбәрнең хәзер инде шактый тынычланып үзенә карап ятканлыгын күргәч, әйтәсе сүзләрен профессорга гына әйтеп китәргә булды. Тик авыз ачып сүз әйтергә өлгерми калды, Галиәкбәр аңа сорау бирде:

— Ничек соң, Фәрит, барысын да уйлап эшләвеңме!

— Аны-моны уйларлык тәкатем калмады минем, Галиәкбәр Хафизович. Мин җаным сөймәгән хатынымнан гына качмыйм, мин үлемнән, рухи үлемнән качам.

— Әлфия турында да уйларга кирәк.

— Ул мине үзе чакырды.

— Чакырыр ул. Мәхәббәт, нәфрәт кебек үк күзсез дә, колаксыз да, башсыз да.

— Мин Әлфиясез яши алмыйм. Мин бары шуны гына беләм.

— Кара аны, вөҗдан газаплары кичереп яшәрлек булмагыз соңыннан!

Фәрит кинәт аягүрә басты.

— Минем сезгә зур бер үтенечем бар. Әгәр Әлфия мин әйләнеп кергәнче кайтса, аңа түкми-чәчми барысын да сөйләгез.

— Нәрсә дип?

— Фәрит безгә бөтенләйгә күчеп килде, дип әйтегез. Калганын үзе аңлар. Ә мин хәзер бер җиргә барып киләм.

Фәрит каударланып үзенең квартирына кайтып керде. Кухня якта хатыны һәм балалары тары боткасы ашап утыралар иде. Әтисен күрү белән Марат йөгереп аның янына килде, бик яратканлыгын белдереп, аякларыннан кочып алды.

— Ботка ашыйсыңмы? — дигән тавыш ишетелде кухня яктан. Бу Фәһимә тавышы, тәнне чиркандырып җибәрә торган котсыз коры тавыш. Фәритнең соңгы елларда җанын каезлаган, үзәгенә үткән тавыш. Фәрит дәшмәде. Аякларын кочып күзләрен мөлдерәтеп әтисенә төбәлгән Маратка текәлде. Баланың башы зур, колак яфраклары тырпайган, ә күзләрендә ялыну-ялвару билгеләре чагыла иде.

— Әтием, кайчан аласың миңа велосипед? — диде ул.

— Мин кичә алам дип вәгъдә бирдем бит, значит алып бирәм, бераз сабыр ит, улым, — диде Фәрит. Кухнядан Ләйләнең тавышы ишетелде.

— Ә миңа, миңа, әтием? Теге «ма-ма» дип әйтә торган курчакны алып бирәсеңме?

— Сиңа да алып бирәм, кызым.

Фәрит әтисенең өйдә юклыгын абайлады.

— Дәү әтиең кайда, улым?

— Ул китте. Кайтып китте. Бакалыга.

Фәрит сәерсенеп куйды. Аннан улының нәни кулларын аякларыннан ычкындырды да үз бүлмәсенә узды. Тиз генә өстәл тартмасын ачкыч табып ачты, андагы документларны өстәлгә салды, кирәк дигәннәрен сайлап кабалана-кабалана кесәләренә яшерде. Бу эш төгәлләнгәч, шифоньер эченнән чемоданын алып аңа кирәк дип тапкан киемнәрен сала башлады. Шунда гына ишек яңагына таянган килеш үзен күзәтеп торган хатынын абайлап алды. Башта сискәнеп китте, ләкин игътибар итмәгәндәй кыланды, эшен дәвам иттерде.

— Кая болай? — диде Фәһимә.

Фәрит бер мәл дәшмичә торды. Сорау тагы кабатланды, ул бу юлы ныграк, таләпчәнрәк тавыш белән кабатланды. Фәрит чемоданны бикләде дә аны күтәреп ишеккә таба атлады.

— Мин китәм.

— Кая китәсең?

— Синең яннан бөтенләйгә китәм.

Кинәт Фәһимә ишеккә аркылы басты.

— Балалар! — дип кычкырды ул.— Әнә әтиегез тагы безне ташлап китә!

Балаларның йөгерешеп кухня яктан чыгулары ишетелде.

— Бәдбәхет, ходай каргаган бер эт кеше икәнсең инде син! — дип чәрелдәп елый башлады Фәһимә,—үлсәм үләм, тик сине җибәрмим. Ишеткән идем аны, бер көчек белән бутала дип, шул дөрес икән. Сагалап тор, шуңа ычкынмасын дигәннәр иде. Я, хода, я, хода! Кая гына куйым бу бәхетсез башларымны,ниләр генә итим! Ниләр генә итим! Син бит минем, явыз җан, яшьлегемне ашадың, син бит, миһербансыз, кеше ашаучы палач. Сабыйлар өлешенә керүче оятсыз, зина кылып йөрүче бит син! Үтер мине, тик мин сине тере килеш моннан чыгарып җибәрмим. Бер ел, ун ел торырмын монда, иллә мәгәр сине җибәрмәм, бел аны!

Ул сүзләрен бүлеп-бүлеп, елый-елый Фәритне каргаган арада куркынган балалар аның артына посып әтиләрен күзәтәләр иде.

Фәритнең ачудан каны кайнагандай булды, тыны кысылды. Ул Фәһимәне читкә этеп җибәрергә уйлаганда каршысына балалар килеп чыкты. Алар бердән үкереп еларга тотындылар. Өзек-өзек сүзләреннән

Фәрит төштәгедәй тоныкh һәм ничектер бик ерактан әйтелгән җөмләләрен шәйләде.

Балалар елый-елый әтиләренең ташлап китмәвен, үзләрен ятим калдырмавын үтенәләр иде. Фәритнең бөтен гәүдәсен тыеп булмый торган чирканчык калтырану биләп алды. Кулыннан чемоданы төшеп ауды, тез буыннары камырдай йомшарды, ул үз авырлыгыннан сыгыла башлады. Фәрит куллары белән күзләрен каплады һәм стена янындагы караватка ауды. Көтелмәгән тетрәнү аның бөтенләй хәлен алды. Ул хәтта берни дә ишетмәс булды, хатынының чәрелдәп үзен каргавын, балаларының елап тагыниләрдер сөйләнүен аңламаган хәлдә йөзтүбән ятуында булды.

## 10

Әлфия ул көнне көндезге ашка кайтмады. Таисия Степановнага шалтыратып әтисенең хәлен сорашты да, кризисның узуын, куркырга урын юклыгын белгәч, тынычлана төшеп, яңадан эшенә чумды. Аксымдагы аминокислоталар микъдарын хромотографик ысул белән билгеләүне, ягъни әле моңарчы бу лабораториядә кулланылмаган ысулны үзләштерергә кирәк иде.

Әлфия эшеннән гадәттәгедән ярты сәгатькә кичегеп кайтты. Ул үзен авыру әтисе алдында гаепле саный иде. Шыпырт кына бүлмәгә узды, әтисенең ниндидер китап укып ятканлыгын күргәч, тынычланды, алай да уңайсызлана төшеп, аның янына узды, кәефен сорашты. Галиәкбәр борын очына төшерелгән күзлеген маңгаена күтәрде, китабын мендәр астына кыстырды һәм бик батырланган булып:

— Бик шәп, кызым,— диде.— Мин инде бүген үземне бөтенләй еңетләрчә сизәм. Иртәгә фабрикага барырмын дип торам.

Әлфия өстәлдәге тәлинкә-кашыкларны җыештырган арада:

— Ә Таисия Степановна рөхсәт бирдеме соң?— дип сорады.

— Бирер, кызым, бирер.

— Башта бирсен әле, аннан чыгам диярсең,— диде Әлфия һәм тәянеп кухняга чыгып китте.

Ул эшен бетереп яңадан әтисе янына кергәндә, карт, торып, караватка утырган иде.

— Кызым,— диде ул ничектер серлерәк итеп,— мин сиңа бер яңалык әйтергә тиеш. Әлфия сүзсез генә аңа сорау белән текәлде.— Өйлә вакытында Фәрит килеп китте.

— Фәрит?— Әлфиянең чырае яктырап китте.— Синең хәлне белешергәме?

— Алай гына түгел. Ул сиңа бүген үк безгә күчеп киләчәген әйтергә кушты.

— Чыннан дамы?

— Менә инде! Үзе шулай әйтте. Язу-да калдырмакчы иде.

Әлфиянең талчыккан йөзенә җан кереп киткәндәй булды, күзләре нурланды, йөзенә алсулык йөгерде.

— Димәк, ул өйдәгеләре белән сөйләшкән. Әйтмәдеме анысын? Балалары белән күчеп киләме?

Галиәкбәр аптырый төшеп кызына карап алды.

— Балалары? Нигә, сез шулай сөйләшкән идегезмени?

— Нигә аның турында сөйләшү, әгәр анасы балаларын үзе белән калдырырга теләми икән...

— Юк, мин ул кадәресен белмим. Минемчә, ул үзе турында гына әйтте. Сезгә күчү ул минем өчен үлемнән качуга бәрабәр дигән кебегрәк әйтте.

Карт авыр сулап тагы китабын кулына алды. Әлфия исә хәзер бәхетнең иң югары биеклекләрендә гизә иде. Ул чак кына ишетелерлек итеп авыз эченнән генә, җырлап җибәрүен дә тоймады. Аяклары да кинәт җиңеләеп китте, ару-талуның эзе дә калмады.

Ул, кухняга чыгып, итле дөге боткасының җылынганын көтә-көтә Фәритне ничегрәк урнаштыру, аңа эшләү һәм яшәү өчен ничегрәк җайлы шартлар тудыру турында уйланды.

«Әти шул диван-караватында йоклар инде, ә яңасын алганчы, минем караватны стена буена такта өстәп киңәйтергә туры килер. Мендәрләрем җитәрлек, ярый әле җәймәләрен дә, юрган-көрпәләрен дә мул итеп әзерләп куйган идем. И, болай булгач, тормышны башлап җибәрергә шулар бик җиткән».

Ботка көеп китмәсен өчен ул утны кыса төште. «Инде балалар белән үк күченсә, ике раскладушка алып кайтырбыз. Зарар юк. Барсы да әйбәт булыр». Ул соңгы вакытларда тәмам бетерешкән Фәритнең йөзен, элек нурланып торган, хәзер эчкә баткан күзләрен күз алдына китерде. «Бәгырем, — дип пышылдады, — кешечә яши башласа, тазарып, матурланып китәр әле».

Әлфия саплы таба белән җылытылган ботканы, суы кайнап торган чәйнекне, башка ашау-эчү әсбапларын бүлмәгә чыгара башлады. Ул өч чынаяк, өч тәлинкә-кашык алды. Белмәссең, бәлки хәзер үк Фәрит килеп керер. Ул килүгә барысы да әзер булып торсын.

Әлфия әле гаилә тормышының моңарчы ачык төсмерләнмәгән татлы мәшәкатеннән, ир белән хатынның бер-берсе турында кайгыртудан туа торганниндидер рәхәтеннән авыз иткәндәй булды. Ул канатланып очынып йөрде, кичке ашны да бәйрәм көннәрендә генә куллана торган ап-ак эскәтерләр җәеп, кыйммәтле савыт-сабалар куеп әзерләде. Мәңгегә истә кала торган булуы ихтимал бүгенге көннең!

Ул һаман эрле-бирле килеп кичке ашка әзерләнде. Галиәкбәр барысын да тоеп торды, кыз зарыгып Фәритнең килүен көтә иде.

Ахырда Әлфия яхшысынмады, этисенең тамак кыргалап сабырсызланып бер табынга, бер үзенә караштыруыннан, чәйне дә суытырга ярамаганлыгын аңлады. Шушы минутта аның телефон көпшәсен алып Фәритнең өенә шалтыратасы, аның кайчан килеп җитәчәген сорыйсы килү теләге тыелгысыз булып күңелен били башлады.

Ул кыюсыз елмайган хәлдә, этисенә мөрәҗәгать итте.

— Әллә Фәриткә шалтыратыйм микән, эти?

— Кирәкми, кызым, — диде Галиәкбәр, — әйдә утыр, минем дә бүген аппетит ачылыр кебек, табынны бигрәк матур әзерләгәнсең.

Әлфия елмаю белән генә чикләнде. Югыйсә инде Фәритнең вәгъдәбирең тә билгесезлектә югалуы, аның тәмам түгәрәкләнгән бәхет бөҗрасын кимерә башлаган иде.

Алар ишек артындагы һәрбер кыштырдауга сагаеп, ара-тирә ашаудан, эчүдән тукталып, тын гына утырдылар. Әлфия элекке кебек тиз-тиз ашамый иде бүген, ул һаман әле күңеле белән звонокның шалтыравын көтә, аңа менә-менә Фәрит елмаеп килеп керер кебек тоела.

Ләкин Фәрит күренмәде. Кичке аш та тәгәлләнде, Әлфия савыт-сабаны да юып куйды. Иртә тору белән, кыздырып алу өчен бәрәңге дә әрчелде. Гадәттәгедән байтак соң яттылар алар. Төнге берне сукканда гына Әлфия тәмам өметен өзеп, саташулы авыр йокыга талды.

Иртәгесен Фәритнең иртәнге автобус белән Чаллыга киткәнлеген әйттеләр. Тәгаен ул өеннән эшкә бару өчен чыккан, тик фабрикага керү урынына олы юлга төшеп автобуска утырган.

Бу Әлфия өчен бөтенләй көтелмәгән бер хәл иде. Серле, хәтта шомлы хәбәр иде бу. Ничек инде Әлфия янына кереп чыкмаска, я булмаса

телефон аркылы эшнең ничек торганлыгын аңлатып кызны тынычландырмаска?!

Әлфиянең тынычланасы килде. Бәлки Чаллыга, КамАЗга ашыгыч эш буенча киткәндер, дип уйлады ул. Әмма кемнән сорашып белергә була соң моны? Әлфия лабораториягә кереп эшенә керешкәч, байтак вакыт шул турыда баш ватты. Аннан батырчылык итеп директорның үзенә шалтыратты.

— Миңа баш зоотехник кирәк иде, аны Чаллыга сез җибәргәнсез булса кирәк. Кайчан кайтып җитәргә тиеш ул?

— Нәрсә сөйлисез сез, иптәш Максудова, — диде Гатауллин корырак бер тонда,— минем аны беркая да җибәргәнем юк. Ул үзенең кабинетында булырга тиеш.

— Мин сезгә аның Чаллы автобусына утырып киткәнлеген белеп әйтәм.

— Белмим, белмим, — диде директор, аптырый төшеп.

Әлфия телефон көпшәсен куйды да, яңадан үзенең эш урынына барып утырды. Ул директор белән сөйләшеп тынычланмакчы иде, киресе килеп чыкты. Бәлки Фәритнең өенә шалтыратыргадыр. Әлфия, озынозак уйлап тормыйча, яңадан телефон янына килде. Ярдәмче кыз Әлфиянең гасабиланып йөрүен анык сизенә иде. Башка вакыт булса бәлки Әлфия аңардан уңайсызланыр да иде. Ләкин хәзер ул чикне узган, үзе турында кемнеңдер нидер уйлавы белән исәпләшеп торыр хәлдә түгел иде.

Әлфия телефон көпшәсен алды да үзе өчен күптән таныш, моңарчы гадәттә беркемнән дә курыкмыйча шалтырата торган, ә хәзер ничектер бөтенләй күңелне өркеткән телефон номерын җыйды. Борчылып җавап көтте.

Хатын-кыз тавышы, мөгаен, Фәритнең хатыныдыр, русча:

— Мин сезне тыңлыйм, — диде.

— Бу фабрикадан, — диде Әлфия шулай ук русчалатып, — срочно баш зоотехник иптәш Еникеев кирәк иде.

— Ул эшкә китте.

— Ләкин ул фабрикада юк, без аны тапмадык.

— Алайса белмим, — телефон көпшәсеннән бераз вакыт кыштырдау гына ишетелде, ахры, Фәһимә икеләнеп сүз дәшә алмый тора иде. — Алайса ул үзенең сөяркәсендә инде,— диде ул кыюланып.— Ул кичә үк шунда китәргә җыенып бер шашынган иде. Кичә ул ният барып чыкмагач, бүген эшкә барам дип, безне алдап шунда ычкынгандыр.

Әлфиянең күзләре зур булып ачылды. Ул телефон көпшәсен колагыннан алды, хатын һаман ниләрдер әйтә, сукрана, Фәритне хурлый калды. Әлфия көпшәне аппаратка ташлап якындагы утыргычка чүкте. Бөтен тәне буйлап дерелдәү узды. Ул ни өчендер хәзер Фәрит дөньяда юктыр, үлгәндер дип уйлый иде.

Хәлбуки Фәрит үлмәгән иде. Ул бу минутта зур ак биналар тезелеп киткән автозаводчылар шәһәренең Тукай исемендәге матур урамыннан бара иде. Ул, көннең шактый җылытып җибәрүенә карамастан, үзенең кун киеменнән. Аның башындагы эшләпәсе ялгыш алды артка киелгән, туфлялары пычранган, үзе чак кына исерек.

Фәритнең борчылуы йөзенә бәреп чыккан иде. Аны бу хәлендә күргән һәркем бу кеше бары кайгыдан, бары үзен кая куяр урын тапмаудан эчкән, ә гомумән эчкече булмаска тиеш, юньле, аек кеше дип уйлар иде. Фәрит туры гына атларга, үзенең исереклеген сиздермәскә теләсә дә, артык тырышу аркасында, отыры нык чайкала һәм, шуны сизеп, үзен тагы да киеренке тота иде.

## 11

Фәрит күзләрен ачып җибәрде. Башы чатнап авырта, авызы кипкән иде аның. Язгы кояш нурлары уйнаклап күзне чагылдыралар. Димәк, төн узган, иртә килгән. Мин кайда соң, бер дә тирә-юнь таныш түгел ич, дип уйланды ул. Фәрит борылып уң ягына карады һәм корылган ширма артында кемнеңдер җиңелчә гырлап йоклавына игътибар итте. Аның күзе идәнгә төште, ул сискәнеп башын калкытырга мәҗбүр булды. Идәндә, йомарланып, баладай нәни генә булып, Әлфия йоклап ята иде. Карасана, Әлфияләрдә икәнмен ич, дип сәерсенеп куйды Фәрит.

Әле сәгать алтынчы гына иде. Кояш яңа күтәрелеп килә. Ачык форточка аша кошлар чыр-чуы ишетелә. Фәрит хуҗаларны уятудан куркып, башын яңадан мендәргә салды. Кичә булып узган хәлләрне исенә төшерергә тырышты. Ул кичә ресторанга керде. Анда ниндидер бер грузин белән серләре бик килешкәнен хәтерли. Ә аннан ниләр булды? Ничек итеп ул автобуска утыра алган. Я булмаса аны теге грузин егете утыртып җибәргәнме? Ничек итеп ул Әлфиягә килеп кергән. Кергәнме соң әле? Бәлки аны Әлфия үзе табып кайткандыр?

Фәриткә бик-бик оят иде хәзер. Ничек инде кызның әтисе алдында, яраткан кешесен кимсетеп, исерек, пычрак, кешелек кыяфәтләре беткән бер хәлдә, монда керергә җөрьәт иткән?!

Ул үзенең өен хәтерләде. Күңеле өшеп китте. Фәһимә аны, әлбәттә, мыскыллауның иң үзәккә үткеч алымнарын кулланып әрлиячәк. Балалар алдында аны тере килеш үтерәчәк. Ләкин кайтмый булмый. Оят, оят.

Фәрит мөмкин кадәр шыпыртрак булырга тырышып, урыныннан торды. Чалбарын, пинжәген эзләп карады, тик киемнәр якын-тирәдә күренми иде. Фәрит караваттан төште дә, мәчедәй тавышсыз адымнар белән кухня якка таба атлады. Бу квартирада кайда нәрсә барын ул яхшы белә. Үзе яшәгән өй дә нәкъ шундый ич. Ул юыну бүлмәсенә кереп, салкын суда башын чылатты, чигәләрен кат-кат уды һәм ничектер аңны томалаган авыр томан тарала төшкәндәй булды. Ул шарлап аккан краннан кушучлап су эчәргә кереште. Авыз кибүләре бетте, зиһене сафланып киткәндәй булды. Киемнәрне табарга да, хуҗалар уянганчы ычкынырга кирәк, яхшы түгел, дип уйланды ул. Киемнәрен эзләп кухняга керде. Чыннан да, пинжәге дә, чалбары да шунда эленеп торалар иде. Күрәсең, Әлфия аларны чистарткан, пычранган урыннарын юган, иртә беләнгә кадәр кипсен дип булса кирәк, газ плитәсе өстенә элгән. Камфоркаларда күгелҗем ут кыяклары ялтырый, кухняда эссе.

Фәрит тиз генә киемнәрен аркылы тартылган баудан алды. Чалбарын киеп куйды. Нәкъ шул вакыт ишектән килеп кергән Әлфияне күрде ул. Кызның күзләрендә әле йокы шәүләсе чагыла, чәчләре таралмаган, ә өстендә эре роза чәчәкләре төшкән көрән халат. Кызның йөзендәге талгын елмаюга игътибар итте Фәрит. Димәк, үпкәләмәгән, димәк, әллә ни ахмаклыклар ясамагандыр әле ул бәлки.

Әлфия Фәрит янына ук килде дә аны кочаклап алды, күкрәгенә хуш исле башын салды.

— Бәгырем, бәгырькәем.

Фәрит бер кулы белән кызны кочып аның йомшак чәчләреннән сыйпый башлады.

— Син мине гафу ит инде, Әлфия, гафу ит,— дип пышылдады.

— Әйдә, ул турыда сөйләшмик, — диде Әлфия, — мин сине аңлыйм.

— Мин бит кичә бөтенләй эшкә дә бармадым.

— Беләм.

— Барысы да шаккатканнардыр инде.

— Белмим.

Фәрит кызны ике куллап кочты да, аның башын, чәчен үпте.

— Кичә мин сине эзләп Чаллыга барып кайттым. Кич белән, эштән соң. Ләкин сине очрата алмадым. Ничек табасың! Чаллы хәзер зур шәһәр бит.
— Шуннан?
— Шуннан кире кайттым. Инде әти белән кайгырышып утырганда син үзең безгә килеп кердең.
— Килеп кердем? Нинди кыяфәттә икәнлегемне күз алдыма китерәм. Котчыккыч булганмындыр.
Әлфия якты күзләре белән Фәриткә карап матур итеп елмаеп куйды.
— Син кичә еладың. Бик кызганыч итеп еладың. Беркем дә мине аңламый, дип еладың. Аннан кичә сиңа күчеп килмәвемнең сәбәбе балалар аркасында дидең, аларны калдырырлык көчем булмады, дидең. Менә хәзер инде мин үземдә шул көчне таптым, дидең.
— Шулай дидемме?
— Әйе, шулай дидең. Берсе дә исеңдә юкмы?
— Менә бер генә деталь истә калган булсачы! Мин Чаллыдан ничек кайтканымны да, ничек итеп сезгә килеп кергәнемне дә хәтерләмим.
— У, ярты төнгә кадәр әти белән икәүләп сине тәртипкә китереп, чишендереп маташтык.
— Я, хода, — дип куйды Фәрит, — гомеремдә бер тапкыр да мондый хурлыклы хәлгә калганым юк иде.
— Ярар, Фәрит, ут йотма. Оныт барысын да. Исән-сау кайтып кердең, хәзер без синең белән бергә, калганын ничек тә, ничек тә җиңеп чыгарбыз! Син бит ир кеше, әйдә, тормышыбызның шундый җаваплы бер вакытында бирешмик.
Фәрит дәшмәде. Ул әле һаман кичә булып узган хәлләрне хәтерләргә тырыша иде.
Әлфия Фәритне кочагыннан ычкындырды да:
— Син бераз гына ял итә тор. Әле бик иртә. Мин аш әзерли торыйм. Ул арада әти дә уяныр.
— Юк, юк, мин әтиеңнең күзенә күренергә оялам, — диде Фәрит куркынып.
— Сөйләмә юкны, ул синең нинди авыр хәлдә калганлыгыңны аңлый. Аннан син үзеңне бик тәртипле тоттың.
— Тәртипле, — дип куйды Фәрит ачынып, — булгандыр инде ул тәртипләр!
— Чын, чын. Бар ятып тор, мин бик тәмле итеп чәй пешерәм. Син коймак яратасыңмы? Минем бик әйбәт коймак оным бар.
— Рәхмәт, — диде Фәрит, утыргыч аркасына эленгән пинжәгенә үрелеп.
Әлфия плитә янында кайнашкан арада ул кухнядан чыгып, ишек янындагы кием элгеченә таба юнәлде. Киемнәре янында тукталып калды. Хәзер үк киенергә дә чыгып китәргә. Тик кая барырга? Өйгә диган җавап килде аның башына. Ләкин шундук кайтуны бөтенләй җаны тартмаганлыгын тойды ул. Хәзер Фәһимәнең тәнбиһләренә һәм истерикасына каршы торырлык көч тоймый иде үзендә. Ниндидер эчке бер сизенү белән ул үзенең түземлелеген югалтып, төзәтелмәслек ахмаклык, хәтта җинаять ясап куюдан курка иде. Ул вакытта инде бөтен өметләр челпәрәмә киләчәк, сөйгәнең белән кавышу мөмкинлеге бөтенләй өзеләчәк. Бәлки тагы кичәге кебек Чаллыга таба юл тотаргадыр? Юк, Фәритнең яңадан исерәсе килми. Ул чынбарлыктан исереклек чаршавы артына яшеренеп котылмакчы иде. Ләкин бүген аңлады. Нәкъ киресе килеп чыкты. Аракы аның хәсрәтен ачыттыра гына төште, гүя ярага тоз сибелде. Әлбәттә, иң яхшысы хәзер фабрикага бару һәм җиң сызганып барысын, барысын онытып, эшкә чуму. Чыннан да, дип уйланды ул, Әлфияләрне дә борчымам, үзем дә оялып кыйналмам.

Ул сәгатенә карады. Сәгать туктаган иде. Ишектән үрелеп бүлмә стенасындагы сәгатькә күз ташлады. Яңа алты тулып җиденче киткән. Хәер, җидегә кадәр территориядә йөрергә була, ә җидедә ашханә ачыла.

Ул шулай уйланып иңнәрендәге пинжәген рәтләп кияргә кереште. Кинәт ишектә звонок чылтырады.

— Хәзер үзем ачам, — диде Әлфия. — Марзия апа сөт китергәндер. — Ул Фәритнең ишек янында тик торуын күреп бераз аптырый төште.

— Син ятып тормадыңмыни, Фәрит?

— Кая яту инде хәзер! Эшкә барыр вакыт җиткән.

— Әле иртә, хәзер коймак җитешә, — диде Әлфия һәм ишекне ачып җибәрде. Ишек янында Фәһимә басып тора иде.

Әлфия аны ерактан гына булса да урамда бер күргән иде инде. Ул шул ук минутта барысын да аңлады, ишекне кулы белән тотып торган хәлдә:

— Сезгә кем кирәк? — диде.

Фәһимә шактый тупас рәвештә эчкә уза башлап:

— Миңа син кирәк,— диде,— Әлфия бит син?

— Әйе, Әлфия. Сезнең миндә нинди йомышыгыз бар?

— Өеңә керт әле башта, аннан йомышымны әйтермен.

— Әле без тормаган. Авыру әтием йоклый әле минем.

Фәһимә артык тәкәллеф күрсәтмәстән, Әлфияне тупас рәвештә этеп, эчкә узды. Коридорда торган Фәритне күргәч, аның йөзенә кызыллык йөгерде, күзләрендә әйтеп бетергесез нәфрәт чаткылары кабынды.

— Ә менә кайда икән безнең кадерле ир кисәгебез! Шуңа күрә өеңә кертми маташасың икән әле, сөйрәлчек, нәгаләт, фахишә!

Ул йодрыкларын йомарлап Әлфиягә таба бара башлады. Кыз куырылып килде:

— Тыел, акылыңа кил, Фәһимә, — диде Фәрит.

— Бозык җаннар, — диде Фәһимә, — шөкерана кыл, гадина, кислота таба алмадым, кеше ирләрен аздырып йөрүең өчен күзләреңне яндырыр идем, кабахәт.

— Фәһимә! — дип кычкырды Фәрит.

— И, монысы тагы кәнтәй көчек, өреп торган була! Инде начальстваң белән бер табактан ашап, аларны үзең яклы иткәнсең икән, шуның белән котылдым дип уйлама, буш куык. Мин синең җиде бабаңның җиде кабер тактасын ачтырып, акылга утыртырмын!

Фәһимәнең чиреләдәвенә Әлфия башта шашып калган иде. Теге бүлмәдә яткан Галиәкбәрнең: «Кем ул анда шундый затсыз кыйлана?» — дигән соравыннан уянып киткәндәй булды.

Кыз Фәһимәнең кулыннан тотты да:

— Чыгып китегез минем өемнән. Сезгә мине болай хурларга беркем хокук бирмәгән, — диде.

— Ах, шулаймени әле, — диде Фәһимә, тәмам зәһәрләнеп. Ул кычкырып елап Әлфиягә ташланды. Аның чәчләреннән умырып тотты, кулларын болгап үзен сакларга тырышкан, ләкин берни эшли дә алмаган кызның башын әле бер якка, әле икенче якка боргалый башлады.

Тәмам шашып калган Фәрит, Галиәкбәр килеп чыкмаса, һәм: «Фәрит, нигә тик торасыз», — димәсә, бәлки шок халәтеннән котыла да алмас иде.

Ул Галиәкбәрнең тәнбиһле сүзләрен ишеткәч, аңына килде, чытырдатып хатынының кулларыннан кысып тотты.

— Тиле, акылсыз хатын. Әйдә хәзер үк чыгып кит, эзең булмасын монда!

Ул хатынын этеп тышка чыгарды, күн пальтосын киде, башына эшләпәсен чәпәде дә аның артыннан ташланды.

Фәһимәнең Әлфиядән үчен алмыйча торып өенә кайтасы килми иде әле. Фәрит аны сөйрәп диярлек үз квартиры ягына алып китте.

— Оят, әдәп дигән нәрсә юк синдә! Мене бөтен поселок халкы алдында хур иттең, тәрбиясез, — дип мыгырданды ул.

— Һа, сөяркәсе куенында кунган ир тәрбияле, ә аның якасыннан эләктереп алган хатын тәрбиясез. Мин әле ул Әлфияне кислота белән яндырам. Менә табыйм гына, табыйм гына.

Алар эшкә баручы эшчеләр төркеме янына җиттеләр. Фәһимә кинәт тукталды да барлык көченә каршыга килүчеләргә карап кычкырды:

— Карагыз әле, иптәшләр! Менә сезнең начальникларыгызның берсе. Бу Фәрит Еникеев. Минем ирем ул. Мин аны әле генә Әлфия Максудова белән тоттым. Уйнаш кылганда, зина кылганда. Менә шушыны, менә шушыны тоттым!

Фәрит түзмәде, Фәһимәне өстерәп алып китте. Хатын исә аның саен хахайлап көлә, Фәрит белән Әлфия өстенә бөтен кабахәтлекне өя иде.

Ниһаять, алар кайтып җиттеләр. Фәрит ишекне ачып җибәрде дә Фәһимәне этеп эчкә кертте. Юк, ул бөтенләй алай каты этмәгән иде. Ләкин шуңа карамастан, хатын коридорда йөзтүбән ауды һәм куркышып бүлмәдән килеп чыккан балалары алдында үкереп, сулыгып, аратирә кызганыч рәвештә ыңгырашып, еларга тотынды. Аның чәчләре тузган, мехлы эшләпәсе идәнгә төшкән, кием итәкләре кайтарылган һәм юан шәрә ботлары ялангач булып күренеп тора иде.

— Җитәр сиңа истерика оештырырга! — диде Фәрит, шкафтан валерианка алып хатынына эчертте. Фәһимә әкрен генә күтәрелде. Елау аркасында күз яшьләренә мул чыланган йөзен балаларына текәде һәм тагы да кызганычрак рәвештә көйләп-көйләп елый башлады.

— Ниләр генә эшлим, ниләр генә эшлим! Бу башкайларымны кая гына куйыйм, балакайларым! Ичмаса җир дә йотмый бит шул явыз адәмнәрне! И, алла, и, алла! Кемнәрдән генә ярдәм сорыйм, кемнәргә генә барып хәсрәтләремне сөйләп җан тынычлыгы табыйм.

Фәритнең артык түзәрлек тәкате калмады. Ул кухняга кереп плитәгә чәйнек белән су куйды. Аның башы хәзер чуен кебек авыр, күңеле болгана, ә колаклары өзлексез чыңлый иде.

Фәрит чәй кайнап чыкканын көтеп тормады, термостагы җылымса суны эчте дә эшкә китәргә җыенды.

Ул киенергә дип коридорга чыкканда Фәһимә бүлмәдәге диванга утырган, агарынып, куркынып калган балаларга шыпырт кына нидер аңлата иде.

— Мин киттем, — диде Фәрит һәм үзе дә сәбәбен аңламастан, — эшкә, — дип өстәде.

Фәһимә урыныннан торды.

— Тукта, тукта, шашма! — Ул гадәтенчә кулларын бөеренә куеп, Фәрит янына килеп басты.— Белеп тор, сөяркәң янында бүлмаячаксың син! Сәгать саен эшләгән җиреңә шалтыратып белешеп торачакмын. Инде дә эшеңдә юк икәнсең, соңыннан үпкәләмә, эш бүлмәңә кереп җәнҗал оештырачакмын. Инде шунысын да әйтим, җәнҗалны оештырганда да гомергә истә калырлык итеп оештырачакмын! Аңладыңмы?

— Кеше түгел син, — диде Фәрит, — мондый кешенең дөньяда башка булуы мөмкин түгел.

— Менә мин әйткәнчә эшләми кара, аннан минем кем икәнлегемне белерсең! Син бик юаш дип уйлап, минем өстән издеваться итәсең, күрсәтермен әле мин, — дип калды Фәһимә.

Фәритнең чыгып китәр алдыннан балаларына нидер әйтәсе килгән иде, тик батырлыгы җитмәде, ул һаман әле йөзләреннән дәһшәт билгеләре китмәгән, һаман әле бер-берсенә сыенып утырган балаларына карап алды да ишекне ачты.

Фәрит фабрика юлына чыккач, шикләнә төшеп тирә-юненә күз ташлады, аннан тар сукмак буйлап урман эченә кереп китте. Урманда кар беткән иде инде. Бу тар сукмакның олы юлга, автобуслар йөри торган юлга чыкканлыгын Фәрит яхшы белә. Тиздән ул автобуста Чаллыга юл тотты.

Ләкин ул Чаллыга бер нәрсәне белми китте. Нәкъ шушы минутта Галиәкбәргә инфаркт булганлыгын белмәде ул.

Кызының, сөекле Әлфиясенең, ниндидер дивана хатын тарафыннан мәсхәрәләнүен, алай гына түгел, физик җәбер күрүен күтәрә алмады профессор. Кинәт аның тез буыннары йомшарды, карт әкерен генә идәнгә чүкте. Аны беркем дә күрмәде. Фәритләр чыгып киткән иде. Әлфия исә тетрәнүдән айнып, тирә-юнен күрерлек хәлгә килгәндә карт идәндә ята иде инде. Әлфия барысын да онытып әтисенә ташланды. Үзендә моңарчы һич булмаган көч-куәт табып, әтисен диванга күтәреп салды. Шул ук минутта Таисия Степановнага шалтыратты.

Бераздан ашыгыч ярдәм машинасында Галиәкбәрне Чаллы больницасына алып киттеләр.

## 12

Иртәнге җидедә бөтен бүлмәне яңгыратып, әле йокыларыннан айнымаган яшьләрне сискәндереп телефон шалтырады.

Сафура, тагы кем инде монсы, дип сукрана-сукрана урыныннан торды, телефон көпшәсенә үрелде.

— Тыңлыйм.

— Апа, апа дим, зур бәхетсезлек. Әтигә инфаркт миокарда булды. Әле генә больницага китереп салдык.

Сафура аңгармыйча торды.

— Кем сөйли, каян сөйлисез?

— Нәрсә, начар ишетеләме әллә? Мин, Әлфия, Чаллыдан шалтыратам. Әле генә әтине больницага салдык. Хәле бик начар. Инфаркт. Ишетәсеңме, инфаркт миокарда. Аңладыңмы, апа?!

— Аңладым, ничек булды соң андый хәл, ул таза иде бит әле.

— Булды инде, апа, телефон аша барысын сөйләп торып булмый. Бүген үк очып кил. Ишетәсеңме, бүген үк.

Телефон аша Әлфиянең үксеп елавы ишетелеп калды. Сафура ни әйтергә дә белмичә аптырап торды. Телефон тагы телгә килде.

— Апа дим, апа, бу хәбәрне зинһар Эльвира Хәкимовнага да җиткерә күр. Аңладыңмы? Көтәм. Хәзергә хуш.

Әлфиянең тагы елаганы ишетелде. Ләкин Сафура сүз әйтергә өлгермәде, элемтә өзелде, кыска гудоклар гына шомлы һәм кайгылы авазлар чыгарып, өзлексез кабатланып тордылар.

Уянса да торырга иренеп яткан Дмитрий Сафураның ни турыда сөйләшүен аңламады. Шулай да ниндидер хәтәр бер яңалык барлыгын Сафураның йөз үзгәрешеннән чамалаган иде.

— Нәрсә бар? — диде ул шомланып.

— Әтигә инфаркт. Хәле начар ди.

Дмитрий сикереп урынынннан торды.

— Димәк, сиңа анда барырга кирәк.

— Әлбәттә, барырга. Тик нинди акчага, кем тагы безгә бурычка акча биреп торыр? Бөтен акчаны туздырып бетердек, өстәвенә муеннан бурычка баттык.

— Ничектер табарга кирәк, — дип куйды Дмитрий.

— Әйттем мин аңа, — диде Сафура сукранып, — йөрмә шундый ерак җирләргә барып дидем. Сүз тыңламады. Инде хәзер безгә дә борчу, үзе дә...

— Хәзер акыл сатар чак түгел инде, — диде Дмитрий, — хәзер акча табарга кирәк.

— Ах, онытып та җибәргәнмен. Әлфия бит Эльвира Хәкимовнага да хәбәр итәргә кушты. — Сафура күз кысып куйды. — Шуннан алып торабыз. Бәлки әле үзе дә барыр.

Әтисенең авыр хәлдә булуын ишетү Сафураны бик каты тетрәткән булса да, баштагы авыр тойгы әкренләп тарала, җиңеләя төште. Ул начар уйларын башыннан куып чыгарырга теләде. Шул ук вакытта аның күңелендә ниндидер җиңеллек тә сизелде. Димәк, квартира, бөтен нәрсә безгә кала, дип уйлады ул эчтән генә. Җүләр, җүләр, әтием үлем белән көрәшеп ята, ә мин аның тизрәк үлемен теләгәндәй, меркантиль нәрсәләр белән үземне юатам, миннән дә җүләррәк кеше юктыр инде, билләһи, дип тә уйлады ул аннары.

Ул мөмкин кадәр кайгылы кыяфәттә булырга тырышып, иренә таба борылды.

— Ничек уйлыйсың, уянды микән әле ул?

— Кем, кем?

— Соң әйтеп торам ич, Эльвира Хәкимовна дип.

— Ә мин каян белим аны!

— Син һәр вакыт шундый. Синнән берәр киңәш сорасаң, хәзер аркаң белән борыласың, — диде Сафура, кинәт ачуланып.

— Куй инде, куй инде, зинһар, ничек борылам, ди. Мин просто белмим.

— Просто белмим генә түгел шул, ә «каян белим аны». Әйтерсең лә пан, әйтерсең лә мин аның асрау хатыны, җүнләп сөйләшә дә белми. Ничек оялмыйсың син! Ичмаса минем кайгылы чагымда борчуларымны җиңеләйтергә тырышып игътибарлырак булыр идең!

— Нәрсә сөйлисең инде син, кадерлем, нигә андый гасабиланулар. Беләсең бит, мин сине яратам. Әгәр ялгыш тупаслык ычкындырганмын икән, гафу ит.

— Гафу, гафу,— диде Сафура, аны үртәп.— Көненә йөз тапкыр гына гафу үтенмисеңдер. Ә гафу иткәч тә тагы үзеңнең мокытлыкларыңны кабатлыйсың.

Сафура тубыгына җиткән сары, юка, үтәли күренмәле эчке күлмәктән, җилкәләренә кадәр төшкән җитен чәчләре белән хәзер аерата гүзәл иде. Аның матур күкрәкләре, нечкә биле, сыгылмалы зифа буе Дмитрийны һәр вакыт үзенә магниттай тартып тора. Ләкин бүген егет хатынының хәтерен калдырды. Шуңа күрә уянганда ук алар арасыннан кара мәче йөгереп узган иде.

— Җитәр инде, Софа, тынычлан, фәрештәм,— диде Дмитрий, ялына төшеп. Сафура аңа карады да борынын җыерып куйды.

— Карап торуга Геракл диярсең, ә эшкә килгәндә...

Ул сүзен әйтеп бетермәде, кискен хәрәкәт ясап, аркасына салынып төшкән чәчен икенче җилкәсенә күчерде дә яңадан телефон аппаратына таба китте.

Сафура Эльвира Хәкимовнага шалтыратты. Аның йөз чалымнарын Дмитрий тикшереп торды. Сафура гаҗәеп бер тизлек белән үзенең йөз кыяфәтен үзгәртә белә иде. Әле генә зәһәрлеген чагылдырган йөз хәзер бәхетсез, моңлы бер сабый бала йөзенә әверелде. Аның тавышы һәм сөйләшү рәвеше дә бөтенләй үзгәрде, ул бик әкрен, бик кызганыч булып ишетелә иде хәзер.

— Сез мине гафу итә күрегез инде, Эльвира Хәкимовна, — диде Сафура, Әлфиядән ишеткәннәрен доцентка җиткереп.

— Профессор кайчан егылган? — дип сорады Эльвира. Аның да тавышында ихлас күңелдән тирән тетрәнү сизелә иде. Сафура доцентның

соравына җавап кайтарды, һәм сак кына: — Мин бүген үк Чаллыга очарга җыенам, сез дә барырсыз дип ышанам, — дип куйды.

— Әлбәттә. Мин хәзер үк үземнең ярдәмчеләремә шалтыратам. Институтка оарып тормамдыр, ахры.

— Беләсезме, сезнең ярдәмчеләрегез күп, бәлки миңа да билет заказать итә алырсыз, соңыннан исәпләшербез.

— Яхшы, — диде Эльвира.

— Мин хәзер эшкә барам. Без Чаллыга өйләдән соң гына китә алырбыз.

— Ничек инде «өйләдән соң?» Мин билет мәсьәләсен хәзер үк кайгыртам. Безгә мөмкин кадәр тизрәк барып җитәргә кирәк. Сез эшләгән җирегезгә өйдән генә хәбәр итегез. Беркая да китмәгез, мин сәгать ничәгә аэродромга барырга икәнлеген телефоннан әйтермен.

Сафура үзен күзәтеп торган Дмитрийга хәйләкәр генә күз кысып куйды. Әле генә усаллык белән тулган йөздә хәзер максатка ирешүдән соң туган куаныч шәүләсе чагыла иде.

— Яхшы, — диде ул, телефон көпшәсен аппаратка куеп. Дмитрий һаман усал да, чая да, хәйләкәр, ләкин үзенең җанын, акылын әсир иткән бу гүзәл хатынны күзәтеп, аның матурлыгына сокланып ятты. Сафура иренең соклануын аңлагандай, телефон яныннан китүгә өстендәге төнге күлмәген салып, матур, ак, яшь тәне белән Диманы тетрәтеп анадан тума шәрә калды.

— Күзләреңне тозландырма,— диде ул иренә, тагы зәһәрләнә төшеп.

Сафура утыргыч өстендә тәртипсез ташланган эчке киемнәрен актара башлады.

Ул ашык-пошык киенгән арада тагы әйтеп куйды:

— Син мин әйткәннәрне ишеттеңме, юкмы?

— Соң минем көндезге ашка дигән акчам гына бар.

— Булса ни!? Син анда табарсың әле. Мин бит бөтенләй бер тиенсез юлга чыгып китә алмыйм.

Алар менә өч көннән бирле инде туй мәҗлесеннән калган азыкларны ашап туеналар иде. Бүген дә алар теш үтмәслек булып каткан бәлеш кисәкләрен җебетеп иртәнге чәйләрен эчтеләр. Ашап туенгач, Сафура иренә автобуслык кына акча калдырып, калган байлыгын сыпырып үзенә алды. Саубуллашканда үбешеп тормадылар. Сафураның ачуы суынмаган иде әле.

Ике сәгатьтән соң ул Эльвира белән янәшә утырган хәлдә, самолетта Чаллыга таба очып бара иде инде. Алар икесе дә уйга калып, моторның талгын гөрелтесенә калгып-калгып киткәләделәр. Эльвира үзенең ышанычлы ассистентларыннан берсенә сәгать тугызда трестка шалтыратып, профессор турында хәбәр итәргә кушкан иде. Ул йомышы үтәлде микән дип уйланды. Аннан ул үзенең башланган тәҗрибәләре тирәсендә чуалды. Ул профессор белән ул-бу була калса, бройлер фабрикасындагы эшнең фәнни җитәкчелеген үзенә алырга туры киләчәген дә искәреп куйды. Теге чакны профессор төрле хәл булуы бар дип юкка гына әйтмәгән икән. Карт кешенең әҗәле ике каш арасында диләр.

Сафура исә, этисе үлә-нитә калса, алдагы тормышының ничек булачагын күз алдына китерә алмый интекте. Ул бу уйларның бик начар, рәхимсез икәнен белеп, алардан качарга тырышса да, җүнсез гомантеләкләр аны, озын борыннар өередәй, әледән-әле чолгап ала иде. Ул ничектер үзе дә сизмәстән, эти үлсә, Әлфия дә мираска кул сузар әле дип куйды. Дөрес, теге вакытта энидән калган нәрсәләрдән баш тартты Әлфия. Миңа бер нәрсә дә кирәкми дип рыцарьланды. Ярый ла бу юлы да шундый батырлыкка бара алса!

Галиәкбәр күзләрен ачып җибәрде. Аның моңарчы бу дәрәҗәдә үк хәлсезлек кичергәне юк иде әле. Ә йөрәк сыкрап авырта, әйтерсең лә йөрәктән нидер суырып алганнар һәм аның авыр, тирән ярасы бөтен тәнне сулкылдатып сызлый. «Димәк, тагын йөрәк», — дип уйлады карт. Хәзер аңа хәтта уйлавы да авыр иде. Шулай да күңел түрендә өметкә охшаш бер тойгы кыбырдый.

Галиәкбәр булып узган хәлләрне исенә төшерергә тырышты. Кинәт Әлфия, ниндидер таза, юан хатын тарафыннан җәберләнгән, кимсетелгән Әлфия, күз алдына килеп басты. Йөрәк кинәт тагы бик каты авырта башлады. Профессор, күрәсең, кузгалырга чамалады, ак халатлы сестраның, кузгалмагыз, кузгаласы түгел, дигән кисәтүе ишетелде.

— Әлфия, Әлфия, — дип пышылдады Галиәкбәр.

— Мин монда, әти, синең янда. Тыныч кына ята күр, әти, — диде Әлфия. Баксаң-күрсәң ул бөтенләй баш турысында гына утыра икән.

Йөрәк авыртуы бераз басыла төшкәндәй булды. Галиәкбәр хәзер генә үзенең больницада икәнлеген аңлады. Бу исә аңа ниндидер җиңеллек китерде кебек. Ул түшәмгә карады, борылып Әлфияне күрергә теләде. Ләкин аңа хәрәкәтләнергә рөхсәт итмәделәр.

— Тыныч кына ятарга тиеш сез!

— Әти, зинһар, сөйләшмә дә, селкенмә дә,— дип үтенде Әлфия.

Галиәкбәр күз кырыйлары белән генә карап, алайса син сөйлә дигәнне аңлатты.

— Борчылма, тыныч ят, барысы да үтәр, — диде Әлфия. — Әле генә Сафура апа да килеп төште.

— Лиана, — дип куйды Галиәкбәр. Кызганычка каршы, Сафура аның турында берни дә әйтмәгән иде. Әмма дәшми калырга ярамый, әтисенең Лиананы яратканлыгын Әлфия яхшы белә.

— Лиана исән-сау икән, — дип куйды ул, — сиңа сәлам әйтергә кушкан.

Галиәкбәр, нәни сары песнәген күз алдына китереп, елмаерга теләде. Ләкин елмаю барып чыкмады, ниндидер кызганыч бер чалым гына хасил булды.

— Сафура апа белән Эльвира Хәкимовна да килгән, — диде Әлфия.

— Анысы әйбәт, — диде Галиәкбәр, — ул хәзер үк эшкә керешсен. Бу турыда Фәрит белән сөйләшсен.

— Яхшы, әйтермен, әти.

Ниндидер йомыш белән читкә киткән сестра килеп Әлфияне ачуланып алды:

— Сез нәрсә, әйткәнне аңламыйсызмыни? Әйтелде бит аңа сөйләшергә ярамый дип!

— Әти, артык сөйләшмибез, әйтәсе хәбәрләр бетте. Хәзер ял ит, — диде Әлфия.

Профессорны яңа төзелгән ак таш больницаның өске катында аерым бер бүлмәгә салганнар иде. Тирә-юньне авыр тынлык басты. Картка болай җайлырак иде, чөнки сөйләшү болай да хәлдән тайган организмны тәмам йончытты һәм Галиәкбәр, үзе дә сизмәстән, алҗып ойый башлады.

Әлфия әтисенең җыерчыклар белән сырланган киң маңгаена, яннан караганда, шактый җыйнак булып күренгән, хәтта матур дип әйтерлек борынына, теш протезлары булмау аркасында артык эчкә батып киткән авызына карап уйланып утырды. «Үләргә тиеш түгел ул, үлмәячәк, үлмәячәк». Ничектер Галиәкбәрнең яшь чагы, ә үзенең кечкенә балалык чоры күз алдында җанланды. Киң җилкәле, көләч йөзле, бик шәфкатьле һәм батыр кеше иде Галиәкбәр. Һәрхәлдә, Әлфиянең исендә ул шулай булып сакланган. Әйе, аннан да акыллырак, аннан да кешелек-

ләрәк кеше юк иде кечкенә кызның ышануынча. Буш вакытта өчәүләп күңелле итеп әтисе, Сафура, Әлфия уйныйлар иде. Һәм нинди уеннар диген әле син. Әтиләре аларга кибеткә килгән һәр яңа уенчыкны алып торды. Бер заман әтиләре бик күп шакмаклар алып кайтты. Аларның төрле кош сурәтләре ясалганы, төрле хайваннар, чәчәкләр белән бизәлгәне, һәм тагы бик күп, бик күп төрлеләре бар иде. Уен шуннан гыйбарәт иде: шакмакны атып бәрәсең дә, аның ничәле чокыр ясалган ягы чыкса, үзеңнең тәтәеңне шул кадәр шакмак аркылы уздырасың. Тукта, тукта, алай да түгел. Ничек соң әле? Әлфия әтисенең ара-тирә ыңгырашып куюына кашларын җыергалап, бала чакта уйналган уеннарын исенә төшерергә тырышты. Әйе, тагы әтиләре аларга әкият сөйли иде. Менә алар иркен караватта өчәү яталар. Уртада әтиләре, ә аның ике ягында Сафура һәм Әлфия. Галиәкбәр әкиятен: «Борын-борын заманда, кәҗә команда, сарык урәтник, карга сотник булып торган заманда», — дип башлый. Ул Камыр батыр әкиятен сөйли, аннан, убырлы карчыклар, дию пәриләре турында. Нәниләр шак катып, күзләрен беткәнче ачып тыңлыйлар. Шул чакларда бик-бик күңелле була иде аларга. Ә бер вакыт, монысы инде үсә төшкәч, Галиәкбәр кызларына үзенең яшьлек истәлекләрен сөйләде. Үзенең бик яшьли әтисез калуы, ачлы-туклы узган балалык еллары турында. Аннан әнисе белән ерак кардәшләренә Казанга килеп сыенуы турында. Ул ерак кардәшләренең әнисен һәм үзен көн-төн эшләтеп тә, әрәм тамаклар гына итеп караулары хикәя кылды. Ә аннан соң инде әнисе үлгәч, ул үзенең бай туганнары тарафыннан нахакка гаепләнеп куылуын да сөйләде. Боларны тыңлаганда Әлфия артык түзә алмыйча кычкырып елап җибәрде, әтисенең муеныннан кочып алды.

Хәзер үлем белән көрәшеп яткан әтисен бик-бик ярата иде Әлфия. Әгәр мөмкин булса, ул аңа үзенең җанын бүләк итеп булса да исән калдырырга әзер иде.

Галиәкбәрнең йөрәге бераз тынычлана төшкәндәй булды. Ләкин шомлы тойгы күңелдән китмәде. Шулай ук үлем килер микәнни дигән дәһшәт иде ул. Юк, үлем хәзер үк килмәскә тиеш, якты дөньяны яңадан күрдем, димәк, үлмим әле. Әйе, үләргә әле, кем әйтмешли, вакыт юк. Мондый хәлләрне кичермәдемени Галиәкбәр. Үлем белән яшәү арасында берничә тапкыр калмадымыни әлеге кырык беренче елның шыксыз салкын көзендә.

Алар Белев шәһәре янына килеп җиткәннәр иде. Немец гаскәрләре һөҗүм итә. Аларның бер шәһәр артыннан икенче шәһәрне алулары турында, бер армия артыннан икенче армияне камалышта калдырып Мәскәүгә, безнең башкалага омтылулары турында йөрәк әрнеткеч хәбәрләр белән бөтен дөнья тулган. Менә озакламый дошман Белев шәһәренә һөҗүм итәчәк. Тик ул кайсы яктан килеп чыгар, шәһәрнең кайсы очында кан түгелә башлар, анысы билгесез. Яңгырлы октябрь көннәре. Ни җылы блиндажлар, ни шәп ныгытмалар юк. Солдат окопта яши, ячейка түбәсе плащ-палаткадан гына тора, ә аста, ячейка төбендә, юеш салам. Һәр төн көтмәгәндә приказ яңгырый, Галиәкбәр взводын, җылынып яткан урыныннан кузгатып, тагы яңа позициягә алып китә. Яңа урында алар окоплар казып урнашырга өлгермиләр, тагы приказ, тагы яңа позициягә күчәргә. Рота башта колоннага охшаш бер тәртип белән барса да, бераздан солдатлар һәрберсе үзенә юл табып кайда җайлырак шуннан баралар. Взводлар кайда бетә, кайда башлана, алла белсен. Ә солдатларның өс-башларына карарлык та түгел, таеп егылулар, ә кайчак үрләргә күкрәктә шуышып менүләр аркасында алар муеннан пычракка батканнар. Яңа урынга барып җиткәч, көн яктыра башлау белән СВТ мылтыгының хәнҗәр сыман штыгы белән шинельләрен кырып чистартырга керешәләр. Менә шундый шыксыз һәм дәһшәтле көннәр иде. Шундый көннәрнең берсендә Галиәкбәргә

бөтен взводы белән сугышчан сак бурычын үтәргә һәм хуҗасыз калган җирдә, һөҗүмгә килүе ихтимал булган дошманны каршы алырга әмер бирелде. Кичке эңгердә алар плащ-палаткаларына төренеп шунда юнәлделәр, барып җиткәч, окоплар казып, әйбәт кенә урнаштылар. Мәгәр дошман һич көтмәгән яктан килеп чыкты. Полкның флангасыннан һөҗүм итте, аты коргыры. Уйламаганда, көтмәгәндә арттан миномет һәм пулеметлардан ату тавышы ишетелде. Әле хәрби өйрәнүне дә юньләп узмаган кешеләрдән тора иде Галиәкбәрнең взводы. Взводта паника купты. Егетләр курка калды. Тәртипсез алып барылган сугышта кешеләр кырылып бетте. Галиәкбәр янында бары бер генә солдат исән калды. Взводын югалткан өчен Галиәкбәргә бик каты эләгәчәк иде. Ихтимал аны хәрби трибунал иң каты җәзага ук хөкем итәр иде. Тик шуңа да карамастан, Галиәкбәр теге солдатны алып ут эченә, дошман белән тиңсез сугыш алып барган безнең гаскәрләр ягына китте. Әле анда, әле монда туфрак һәм ут көлтәләре ясап шартлаган немец миналарының һәм снарядларының шартлавы, әледән-әле чытырдап пуля сиптергән пулемет һәм мылтык тавышлары якынайганнан-якыная барды. Көнчыгышка таба сузылган сөзәк, яшел чирәм белән өртелгән чокырны аркылы чыккач, сизми калдылар, алда күренгән куаклыклар артыннан кемдер автоматтан сиптереп куйды. Бәлки немец солдатының Галиәкбәрләрне күреп атуы да булмагандыр, чөнки бөтен тирә-юньне күе томан сарган иде. Әмма пуля кызылармеецның күкрәген тишеп үтте, ә Галиәкбәрнең уң як кабыргасына эләкте. Кызыларммеец шунда ук ауды, Галиәкбәр исә уянып киткәндә үзенең кан эчендә ятканлыгын тойды. Күрәсең, ул артка чокыр төбенә тәгәрәгәндер. Күпме вакыт ятканын ул белә алмады, мәгәр кан күп агу аркасында аның кыл кыймылдатырлык та хәле калмаган иде. Әйе, ул чакта да нәкъ хәзерге кебек ул үлем белән яшәүнең уртасында ятты. Һәм дымлы чокыр төбендә үлеп калуы бик мөмкин иде, тик, бәхеткә каршы, аңа үләргә ирек бирмәделәр, күрше авыл кешеләре төн караңгысында өйләренә алып киттеләр һәм ул дошман тылында ярасы төзәлгәнгә кадәр ятты.

Менә шулай булды аның беренче тапкыр үлем белән янәшә яткан чагы. Тик бу соңгысы түгел иде. Сугыш аңа тагы көтелмәгән үлем янәшәлекләре хәзерләгән иде әле...

Галиәкбәр янына врач керде. Күренеп тора, ул профессорның хәленнән бер дә риза түгел. Хәзер үк укол кадарга кушты. Хәзер минем хәлем яхшыра төште, җитәр, кадамагыз артык, диярга теләде карт, тик ул үзендә сүз әйтерлек көч тапмады.

Әлфия дәһшәт белән тулган күзләрен тутырып, һаман әтисенең йөзенә текәлгән иде әле. Укол кадаганнан соң врач белән сестра бераз тынып тордылар, аларны профессорның ничек сулыш алуы кызыксындыра иде, ахры. Ниһаять, врач: «Ярар, хәзергә җитәр», — диде. Әлфиягә җитди мәгънәле бер караш ташлады, профессорны сөйләштерергә ярамаганлыгын әйтте.

Уколдан соң Галиәкбәр кинәт тәненә талгын рәхәтлек һәм көч-куәт иңгәнлеген сизде. Әйтерсең лә аның гәүдәсе ныгый, әйтерсең лә куыкны тын белән тутыргандай аңа энергияне өреп кертәләр иде. Ул күз кырые белән генә кызын эзләде.

— Сафурадан минем барлык китапларымны һәм гыйльми хезмәтләремне үзеңә алырсың, — диде ул.

— Сөйләшмә, әти, врач кушмады, — диде Әлфия, — син үлмисен.

— Юк, үлмәсәм дә, — диде карт юаш кына. — Инфаркт ул минем яшьтә...

— Алла хакы өчен сөйләшмә инде, әти, — дип үтенде Әлфия еламсырап.

— Бетте, — диде Галиәкбәр, авыз читләре белән генә елмаерга тырышып.

Ишектән килеп кергән сестра Сафурадан язу сузды. Ул анда Галиәкбәрнең хәлен сораган, үзенең дә әтисе янында утырырга теләвен, Әлфия арыгач, үзенең аны алыштырачагын әйткән. Ул тагы Эльвира исеменнән Галиәкбәрнең авырудан исән-сау котылуын теләгән.

Әлфия блокнотын тезенә куеп апасына җавап язды. Ул, дөресен әйткәндә, апасының хәзер әтисе янында булуын бөтенләй теләми иде. Сафураның дорфа сүз әйтүеннән курыкты ул. Аннан гомумән әтисенең аны яратмавын белми идемени ул! Ләкин Әлфия боларны язмады. Апасына үзенең әле бөтенләй армавын, ә инде арый калса хәбәр итәчәген генә сызгалады. Хәзер юл мәшәкатьләреннән соң ял итәргә кушты. Монда якында гына, Иске Чаллыда, үзенең якын танышлары барлыгын хәбәр итте. Бернинди тартынусыз шунда урнашуын үтенде. Адрес белдерде. Ул шулай ук Эльвира Хәкимовнага да әтисенең бая ук әйткән үтенечен, поселокка кайтып, хәзер үк директорны күреп сөйләшергә кирәклеген дә язды.

Әлфия шуларны язып утырганда кинәт Фәритне хәтерләде. Аның бугазына авыр төер килеп тыгылгандай булды. Кайда ул хәзер? Нигә ул килеп чыкмый? Берәр бәхетсезлеккә таргандыр. Юкса ул мондый эш эшләмәс иде. Фәрит өчен хас түгел мондый рәхимсезлек. Ниләр генә булмасын, ул Галиәкбәрнең инфарктган егылуын ишеткәч тә, больницага килеп җитәргә тиеш иде.

Әлфия хәзер аның тинтәк хатыныннан барысын да көтү мөмкин дип уйлый иде.

Ул әтисенең артык авыр итеп, күкрәк читлеген артык кабартып сулыш алуын күргәч, уянып киткәндәй булды. Карт йокыга талган иде. Әлфия аяк очларына гына басып ишек янына барды, коридордагы өстәл артында утыручы сестрага язуын бирде дә, яңадан әтисе янына килеп утырды. Башта әтисе турында гына уйланды, әмма, сиздермәстән генә, астыртын гына, тагы Фәрит турындагы шомлы уйлар аны били башлады.

## 14

Фәритнең каядыр китеп югалуына һәм Галиәкбәрнең йөрәк белән егылуына инде өч тәүлек узган иде. Фабрика директоры сынаулар барачак корпусның цех башлыгын үз кабинетына чакыртты.

Бәләкәй генә буйлы, ләкин кәлтә еланыдай елдам һәм сөйләшергә бик оста цех начальнигы килеп кергәндә директор селекторда склад мөдире белән сөйләшә иде. Ул кабинетында цех башлыгын күргәч, гадәтенчә, ишарә белән генә аңа утырырга кушты.

— Син бүген сынауларның соңгы көне икәнлеген беләсеңме? — диде ул селектордагы сүзе беткәч.

— Бик беләм.

— Белгәч, нигә соң дәшми-тынмый гына йөрисең?

Цех мөдире үзенең нечкә тавышы белән кеткелдәп көлеп куйды.

— Мин югарыдан әмер көтәм.

— Нинди әмер тагы. Сынаулар бит синең цехыңда уздырылды.

— Сынаулар баш зоотехникның хас үз карамагы астында уздырылды, — диде мөдир һаман күтәренке рух белән көлемсерәгән хәлдә.

Гатауллин авыр итеп сулап куйды. Ул Фәритнең югалуында үзен дә гаепле саный иде. Вөҗданы каршында ни кадәр акланырга тырышмасын, ул моны булдыра алмады һәм аяк астыннан килеп чыккан бу бәла өчен чын күңелдән җәфа чигә иде.

— Фәрит Зариповичның юкка чыкканлыгын белмисеңмени син? Менә өч көн инде аның поселокта күренгәне юк.

Цех мөдиренең дә ябык, очлы борынлы йөзенә җитдилек йөгерде.

— Анысын ишеттем. Тик мондый хәбәр дә йөри тагы, имеш, аны кичә безнең саклык кассасы янында күргәннәр.

— Күргәннәр. Ләкин ул фабрикада күренмәде. Һәркөнне иртә белән өенә шалтыратам, хатыны кайтмады, ди. Ә бит ул китте дип, эшне туктатып булмый, дус кеше. Шуңа күрә хәзер читлекләрне бушатып сынаудагы чебиләрне реализациягә озатырга кирәк.

— Яхшы, — диде мөдир, кузгала башлап.

— Инде болай, бу эшнең җаны булган профессор да больницада ята бит. Син беләсеңме?

— Беләм, ишеткән идем.

— Белсәң, менә аларның методика хикмәтләрен бозып куймас өчен эшне безгә Эльвира Хәкимовна белән бергә башкарырга кирәк булыр. Алар анда ниндидер мәгълүматлар теркәячәкләр, эчәкләр, бүтәкәләр белән кызыксыначаклар. Мин аның белән сөйләштем, аның бүгенгә монда калуын үтендем. Аннсыз берни дә эшләмәскә!

Мөдир ризалыгын белдереп, сүзсез баш иде һәм:

— Ә теге чибәр егет белән нишлибез, аңа эш бетте, димәк, — дип сорады.

— Ах, да, — диде Гатауллин, Рәмзине хәтерләп. Ул селекторга кулын сузды. — Кем бу? Синме, егет? Менә хәзер үк минем янга кер әле. Ничек, син минем директор икәнлегемне дә белмисеңмени әле? Менә шулай, хәзер кереп җит.

Рәмзи конторага килгән арада алар цех хәлләре турында, андагы эш, артымнар һәм үлем-җитем һәм башка шундый мәсьәләләр турында сөйләшеп утырдылар.

Ниһаять, ишектә Рәмзи күренде. Гатауллин аның җилкәсенә җитә язган кара куе һәм очлары бөдрәләнеп торган чәчләренә күз ташлады һәм ирексездән елмаеп куйды. Хәтәр иде бу яшь зоотехник, чәч тә заманча, мыек та. Билләһи, Гатауллин аның яшендә булса, болай йөрергә оялыр иде. Ул эчтән шулай уйланды, ләкин сер сынатмады, үз иткән булып, егеткә өстәл янындагы буш утыргычка утырырга кушты.

— Ну, эшләр барамы?

— Пока бара, но бит мин бер үзем калдым, — диде Рәмзи ачынып.

— Нишлисең, дөнья ул, — диде Гатауллин, — пока синңа аларны алыштырырга туры килер.

— Фәрит абый белән профессорныммы?

— Шүрлисеңмени?

Рәмзи кулларын җәеп куйды.

— Курыкмыйм да, ничектер уңайсыз.

— Менә сиңа цех мөдире ярдәм итәчәк. Аннан тагы доцент Эльвира Хәкимовнаны беләсеңме син?

— Ну.

— Менә шул ярдәм итәчәк. Кыскасы, син элеккечә үк эшләячәксең, начальствоң гына алышына. Учет алып барудан туктамадыңмы?

— Учет бара.

— Кара аны! — Гатауллин бүген үк читлекләрне бушата башларга кирәклеген аңлатты. — Ә аннан соң сиңа бик зур җаваплы эш тапшырырга уйлыйбыз. Без кеше тапканчы, син әлеге зур экспериментка хәзерлек эшләре алып барырга тиеш буласың. Гыйльми җитәкчең Эльвира Хәкимовна.

— Ә ул бүген кайтып китә, дидегез түгелме? — дип куйды мөдир.

— Ничава, институт белән үзем сөйләшермен, бер атна бездә торырга каршы килмәс дип уйлыйм.

«Уһу, зур йөк тагарга җыена бу пеләш баш миңа» — дип уйлап алды Рәмзи. Әйтмичә түзмәде.

— Мин бит, иптәш директор, әле җүнләп штатка да кертелгән кеше

түгел. Зарплатасы да... Ничегрәк соң мондый ответственный эшләр йөкләргә җыенгач...

Бу сүзләр Гатауллинга ошамады. Ул гомумән кул астындагы кешеләренең дәгъва кылуларын өнәми иде, чөнки ул һәр вакыт: «Барысын да үзем белеп эшлим, — дип уйларга ярата иде. Бу юлы да Рәмзигә каты гына бәрелергә уйлады, хәтта шул уңайдан егетнең ачу китергеч бөдрәләренә дә, кара мыегына да таш атып узмакчы иде, тик тыелып калды. Егетнең үз кабинетына беренче тапкыр гына керүен, аңа чыннан да житди эш тапшырылачагын уйлап өлгерде. Ә Фәритнең эшләре ничек булып бетәсен кем белә әле! Эшен, балаларын ташлап китү дәрәҗәсенә җиткән кешедә өмет бар микән! Инде тагын бүген поселокта булып та үзендә эшли торган җиренә кереп чыгарлык та көч тапмагач, ай-һай, бик зур катастрофаның башы булуы мөмкин бу!

— Ярар, анысын карарбыз, — диде ул Рәмзигә, — бездә әле моңарчы бирәү дә үзен кыерсытылган санамады.

— Мин киттем алайса, — диде Рәмзи.

Ул каты басып кабинеттан чыгып китте.

— Менә хәзерге яшьләр, — дип калды аның артыннан Гатауллин, — җүнләп эшли башламый, давай аңа әйбәт эш хакы, ә?

— Гомумән егет тырыш, — диде мөдир директорны тынычландырырга теләп, — бер дә алай эштән курка торган түгел, корпуска кайчан керсәң дә шунда. Әле контрольдәге чебиләрне үлчи, әле читлекләрен тазарта, эшсез тормый.

Директор сүз дәшмәде, ул Фәрит турында милициягә шалтыратыргамы, әллә яңадан бер-ике көн көтәргәме, дип баш вата иде.

Рәмзи исә үзен зур кеше итеп сизгән хәлдә, юлында очраган кызларга төрле шуклыклар аткалап, территория буйлап үзе эшли торган корпуска таба китте. Аңа Фәрит вакыйгасы минуты-сәгате белән килеп ирешге. Урамда Фәһимә оештырган җәнҗал вакытында цехтагы кыз эшкә бара торган булган, шул барысын да түкми-чәчми иптәшләренә җиткерде. Башта Рәмзи ул кызның сүзләренә ышанмады, тик бу искиткеч хәбәрне башкалар да раслагач, ул ышанырга мәҗбүр булды.

Рәмзи ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр нинди дер мәхәббәт дигән төшенчәләргә корылган булуына хәзер бөтенләй ышанмый иде. Хатынның ошавы бар, ошамавы бар, татлы, иркә булуы бар, бакадай салкын, җансыз булуы бар. Аныңча хатын-кыз бары шундый ике төркемгә генә бүленә. Кайчандыр яшьлектә Гөлсинәне сөеп йөрүләре, аның өчен ут йотып, гыйшыкның татлы газапларын кичереп яшәгән көннәрнең куанычы хәзер хәтердә бик тоныкк сакланган, алар бик еракта калган һәм кабатлануы да мөмкин булмаган бер хатирә булып кына күренә иде. Алай гына да түгел, алар барысы да балалык, хәзер көлеп кенә искә ала торган вакыйгалар иде, аныңча.

Ләкин менә хәзер, үзеннән ни кадәр генә куарга теләмәсен, һәм кеше хакына керергә ярамый димәсен, Әлфия үзенең барлык гүзәллеге белән аның күз алдында җанланудан туктамады.

«Менә ышан син аларга, — дип нәтиҗә ясады ул, — чынлыкта шул кыз Фәрит Зариповичның сөяркәсе, имеш». Ләкин Рәмзи шундый бер тойгы кичерә иде ки, әйтерсең лә Әлфия аныкы һәм аны Рәмзидән тартып алганнар. Аның әле мондый хәлдә калганы юк иде. Ул моңарчы кызларга ниндидер бер әйбергә караган кебек кенә карады. Һәм ул әйбер җәлләүдән дә бигрәк, аңарда тизрәк ашалырга, бетерелергә тиешле нәрсәгә карата булган бер кыргый тойгы гына тудыра иде. Ә Әлфия исә ничектер, элек булмаганча, яңа бер сәер тойгы кузгатты. Ул хәзер Фәритнең бөтенләй кайтмавын, ә Әлфиянең гомергә бирелә үзе белән калуын тели иде.

Рәмзи хәзер Әлфиянең Чаллыда авыру этисе янында икәнлеген хәтерләде. Картның хәле начар диләр, ул тиз генә кайта да алмас бәлки,

дип уйлады ул. Әтисе өчен бик борчыла булыр чукынган кыз. Әллә больницага бер барып кайтасы инде. Ләкин ул анда барып та берни эшли алмый кайту ихтималын да чамалый иде. Җитмәсә хәзер кызу эш башланачак, ул чебиләрне тапшырачак, хәзер бит барысы өчен дә ул җаваплы, баш зоотехник өчен дә, профессор өчен дә.

Рәмзи, иң хәерлесе хәзер тапшырылган эш белән шөгыльләнү, дигән карарга килде. Башкача мөмкин дә түгел иде. Чөнки ул корпуска кергәндә Эльвира Хәкимовна анда иде инде, ул аны күптән көтеп торганын әйтеп каршы алды. Рәмзи бүген суелачак чебиләрнең контроль группасын үлчәргә әзерләнә башлады.



## 15

Фәрит кунакханәнең үзенә бирелгән бүлмәсен эчтән бикләде дә, портфель тотырып кибеттән алып кайткан әйберләрен өстәлгә чыгарып тезде. Бүлмә җыйнак, матур, якты, бер кешелек кенә. Нәкъ Фәрит теләгәнчә булды. Аулак, тыныч. Монда беркемнең беркемдә эше юк. Фәрит теләсә ни эшли ала. Ләкин уйларыннан, тойгыларыннан аулак бүлмәдә бикләнеп кенә котыла аламы соң ул? Әйе, үз-үзеңнән качып котылу мөмкин булмаганлыгын ул яхшы аңлый. Ул сынамады түгел инде, бердәнбер юл, ул исерткеч белән юану. Шул, гадәттә, Фәрит бөтенләй ярамаган, кешенең кешелеген бетерә, аны хайванның да иң начарына әйләндерә торган кабахәт нәрсәгә сыену.

Ул кире Фәһимә янына кайта алмый, ул аннан котылу өчен балаларын күрми яшәргә дә риза, ә инде гомерендә беренче тапкыр чын мәхәббәт утлары кабызган Әлфия янына да күчә алмый ул. Әйе, әйе, Фәрит моны бик анык аңлады инде. Юк, булмый, ул нидәндер курка, ни өчендер аның вөҗданы газаплана башлый, озын кара керфекле күзләрен тутырып аңа балалары текәләләр. Я, хода, булса да була бит миндәй җүләр, көчсез ихтыяри зәгыйфь бәндәләр. Әйе, бердәнбер юл, хәзергә исерткечкә таяну, ә аннан күз күрер. Белмәссең, бәлки Фәһимә булмады инде дип, кайтып китәр. Ә Әлфия? Шунда Әлфия белән кавыша аламы соң әле? Моңа аның көче җитәрме? Җитәр, җитәр, әгәр тегеләр күз алдында булмасалар, җитәр.

Фәрит кибеттән әле генә сатып алып кайткан әйберләрен өстәлгә чыгарып тезгән арада күңеленнән шулай сөйләнде.

Ул Чаллыга иртә белән үк килеп төшкән иде инде. Яңа шәһәрнең киң төзек урамнарында озак йөрде ул, йөри-йөри бик нык арыды. Аның йокысы да килеп китте. Тукта, дип уйланды ул, паспорт үз янымда, кунакханәгә урнашыйм әле. Акчам бар, кирәм шунда, яшим. Чыннан да, бәхеткә каршы, кунак өендә урын да булды. Җитмәсә, аерым бүлмә, тыныч, аулак. Фәрит урнашу белән чишенеп йокларга ятты. Шунда гына, менә инде ничәнче төнен саташулы сай йокы белән, ә кайбер төннәрне бөтенләй йокысыз уздырганын хәтерләде. Ул ап-ак җәймә, күпереп торган мендәр өстенә ятты да, шундук йокыга талды. Ул дүрт сәгатькә якын йоклагач кына уянды. Торып юынды, чәчен тарады һәм, портфелен алып, кибетләргә чыгып китте. Әле исә аның кибетләрдән төянеп кайтып керүе иде.

Өстәлдә аракы, минераль су шешәләре. Берәр чынаяк чәй дә кирәк иде. Фәрит коридорга чыгып дежурныйдан бер таш чәйнеккә тутыртып чәй алып керде. Ә шикәр, икмәге, хәтта закускалары да җитәрлек аның.

Фәрит каударланып шешәне ачты, пәке белән ашыга-ашыга икмәк, колбаса кискәләде.

Тәмсез ачы аракыны эчеп җибәргәч, ул комсызланып ашарга кереште.

Лэкин ни өчендер аракы алмый иде Фэритне. Тойгы-кичерешләр отыры куерак, кискенрәк булып киткәндәй иде. Фәритнең хәзер елыйсы килде. Аңа чарасыз бер хәлдә калуы һәм көчсезлеге өчен үзе кызганыч иде. Аңа Фәһимәнең зәһәрлек белән тулган күзләре күренгәндәй булды. Ул тетрәнеп китте. Утырган җиреннән артка чигенде. Шундук аңа балалары Марат белән Ләйлә моңаеп карап торалар кебек иде. Әнә, тагы зур моңлы күзләрен текәп Әлфия дә аңа төбәлде. Бу күзләрдә үпкә, тәнбиһ, моңсулык чагыла. Фәрит түзмәде, балалар кебек учлары белән күзләрен каплады да тавышланмаска тырышып, шыңшыйшыңшый елап җибәрде.

Табын шул килеш калды. Фәрит караватка барып капланды.

Әмма шулай да бераздан Фәриткә сәрхушлек гамьсезлеге барып житте. Ул шыңшуыннан тукталды, ничектер хисләргә артык бирешмәс бер хәлгә килә башлады. Бик катлаулы тоелган нәрсәләр хәзер гадиләшкәндәй булды, һәм, әйтерсең лә сүз үзе турында бармый, ул Фәрит исемле кешенең хәлен читтән генә тикшереп, хөкем итеп ятучы. Ул тагы өстәл янына барып утырды, баягы йомшаклыгы өчен үзеннән көлеп куйды һәм тагы шешәгә үрелде. «Кешеләр минем хәлдә бер дә аптырап калмыйлар, — дип фикер йөртте ул, — төкереп тә бирмиләр. Хатыннарын яратмыйлар икән, артларына тибәләр дә, куып чыгаралар. Алалар икенчесен, инде анысы да барып чыкмый икән, алалар өченчесен. и табалар үзләренең бәхетләрен. Интеллигентлык чире, үз-үзеңдә казгану, чокыну, төртену, демагогия белән шөгыльләну, идиотлык, чәнчелеп киткере! Инде нишләргә, дигән сорау куябыз алга, ягъни мәсәлән. Ягъни мәсәлән, кәжә суйган Әпсәләм, тотабыз да өйгә кайтып Фәһимә нәгаләткә әйтәбез, давай мотай, алдыңнан артың матур, дибез. Аерылышабыз дип, мәсьәләне кабыргасы белән куябыз. Ә үзебез инде җаным бәгырем Әлфия янына күчеп китәбез. Менә бит бөтен эше шул! Ә мин нишәк мөрите баш ватып, ух та пух килеп юкны бушка әйләндереп, стакан эчендә зилзиләләр ясап йөрим». Ә теге көнне Әлфия яныннан чыккач нәрсә булды соң? — дип дәвам итте уйларын Фәрит. — Барлык төзегән планнар җилгә очтымы? Очты. Мин куркак куянга әверелдем, өйгә кайтып аждаһа янында кунмавыма вөжданым газаплана башлады.

Ә бүген соң? Бүген дә бит мин исереклектән генә шундый уйлар белән юанам.

Юк, дип нәтиҗә ясады ул. Булмый, буласы да юк. Аның соңгы көннәрдә тәмам теткәләнгән нервылары сыкрана иде. Нишлим, нишлим, дип сорады ул тагы илереп. Әлеге хыянәтчел елау тагы буа башлады аны. Аның, эчәргә күнекмәгән кешенең, икенче көн дәвам иткән агулануга түзә алырлык көче калмаган иде. Ул, үзе дә сизмәстән, гадәтенчә, куллары белән күзләрен каплады да аяк астындагы әйберләргә сөртенә-сөртенә әрле-бирле йөренергә тотынды. Бераздан кран астында баш түбәсенә су агызырга тотынды. Су чиркандырып муенга, муеннан аркага агып төшә иде. Фәрит җиңеләя төшкәндәй булды. Иң яхшысы йоклап алырга, дип уйлады ул. Ә бәлки урамга чыгып һавада йөрергәдер. Юк, юк, юк. Анысы булмас. Фәритнең мондый хәлдә бер кемгә дә күренәсе килми.

Фәрит ятагына ауды да кичкә кадәр йоклады.

Өч көн буена ятты Фәрит кунакханәдә. Шул өч көн эчендә бары ике тапкыр урамга чыгып керде, анда да аракы алу өчен генә. Соңыннан ул тәмам арыды, миңрәүләнде. Хәзер аңа барыбер иде. Хәзер аңа бер кем дә юк иде. Нервылар сыкрануы да кимеде хәзер. Әз генә айный башласа, аның тагы исереклек гамьсезлегенә чумасы, онытыласы килә иде.

Дүртенче көнне номер ишеген шакылдаттылар. Булмәгә дежурный хатын белән кунакханә администраторы килеп керде.

— Бу нинди эш? — диде юан гәүдәле, пенсне күзлек кигән администратор. — Сез безнең кунак өен әллә эчкечелек урыны дип белдегезме? Бөтен шәһәрдә алкоголизмга каршы көрәш бара, ә сез безнең гостиницаны шул эшнең оясына әйләндерәсез!

— Сезнең миндә эшегез юк, — диде Фәрит.

— Ничек юк, җыештыручыларны кертмисез, урын-җирне пычратып бетергәнсез.

— Бетерсә,мин аның өчен түләгәнмен. Мин номерга бөтен шартын туры китереп, акчасын алдан өч көнгә түләп кердем. Шуңа күрә сез миңа бәйләнә алмыйсыз.

— Сез монда дүртенче көн торасыз бит инде.

Фәрит хәйран калып күзләрен шарландырды.

— Дүртенче көн?

— Сез инде, күрәсең, көннәрне дә оныткансыз.

— Әйттегез, рәхмәт, мин хәзер үк түли алам.

Фәрит чалбар кесәсеннән йомарланып беткән кәгазь акчалар чыгарды.

— Акчагызны аста кассага түләрсез, — диде администратор, — ә хәзер әйберләрегезне җыегыз да номерны бушатыгыз.

— Нигә, ни өчен? Мин бит сезгә әйтеп торам, түлим, бер көнгә генә түгел, биш көнгә түлим. Хәзер бераз рәтләнәм дә төшәм. Мине калдырыгыз зинһар.

— Сез өегезгә кайтырга тиеш. Сезне эзлиләр.

Фәритнең йөзе җитдиләнеп китте.

— Кем эзли мине, хатыныммы?

— Хатыныгыз түгел. Сез кош фабрикасында эшлисез бит?

— Ну, эшлим.

— Директорыгыз шалтыратты. Ул сезне хәзер үк өегезгә озатырга кушты. Бер сәгатьтән кайтмасагыз, үзем килəм, диде.

— Директор шулай әйттеме?

— Әйе, директорыгыз, иптәш Гатауллин, шулай әйтте.

Фәрит, мондый тозактан ничек котылырга икән инде, дип авызын ачкан хәлдә, түшәмгә карап уйланып торды. Күрәсең, ул бераздан җаен тапты, аның йөзенә ярарга тырышу мескенлеге күренде.

— Аңлашылды,— диде ул,— барысы да тәртиптә булыр, иптәш... Мин хәзер битне генә юам да...

Фәрит таушалып беткән пинжәген салды да юынгычка таба атлады. Краннан агызып салкын суда битен чылатты. Кулларын тырнап алган сакал-мыекларына игътибар итте. Кырынасы иде бит дип уйланды, аннан, монда кырыну әсбаплары булмавын хәтерләп, урамга чыккач парикмахерга керергә булды.

Аның бүлмәне бушатуын һаман көтәләр иде әле.

— Хәзер, хәзер, — диде Фәрит, — әйттем ич, борчылмагыз.

Ул кун пальтосын киде, башына ямьшәеп беткән эшләпәсен утыртты. Карават астында яткан портфелен эзләп тапты да, чыга башлады.

— Ходаем, — дип куйды дежурный хатын, — карап торырга җүнле генә кеше кебек үзе. Менә ничек әдәм мәсхәрәсенә калдыра нәгаләт аракы ир-атны.

Фәрит аста, вестибюльдә яңадан бер көнгә акча түләде дә урамга чыкты. Ул урам буйлап иртәнге суыктан бөрешкән, куырылган бер хәлдә автостанциягә таба юнәлде. Тик ул билетны поселокка түгел, ә Азнакайга алды. Аның да сәбәбениндидер максат аркасында түгел, ә бары автобус шунда китәргә торганга күрә генә иде.

## 16

Ике көн ятканнан соң Галиәкбәрнең хәле бераз яхшыра башлады. Аның йөзенә нур кунды, ул күзләрен ачып, сөйләшкәндә сүзен дә шактый ачык итеп әйтә башлады. Сафура эшли торган җиреннән рөхсәтне ике көнгә генә алган иде. Узган ике тәүлектә Әлфиянең әтисе янында утырырлык хәле калмаган чакларда Сафура кизүлек итте. Инде хәзер кризис узды булса кирәк, шуңа күрә Әлфия апасына, Эльвирадан калмасын дип, билетлек акча бирде дә Казанга кайтарып җибәрде. Әледәнәле телефон аша сөйләшеп хәбәрләшеп торырга булдылар.

Менә бүген Галиәкбәрнең инфаркттан егылуына алтынчы көн киткән иде инде. Әлфия кулларын, битен юып керде дә, әтисен кашыктан ашатырга кереште.

— Азрак каптырсаң да ярый, кызым, — диде Галиәкбәр, — кашыгың бик зур, ахры.

Әлфия әтисе күбрәк кабып, күбрәк ашаса, тиз арада хәлләнеп, терелеп китәр дип уйлый иде, тик әтисенең сүзен тыңламый булдыра алмады. Ул манный боткасын кашык очына гына әләктереп ашата башлады.

— Тозы азрак, ахры, — диде карт.

— Сиңа тоз ярамый.

Карт дәшмәде. Аның фабрикадагы хәлләрне бик беләсе килә иде.

— Фәрит күренмиме? — диде ул Әлфиянең йөрәген әрнетеп.

— Күренми, әти.

— Кичә теге читлектәге чебиләрнең срогы узды. Нәтиҗә ниндирәк икән?

— Әти, зинһар тыныч кына аша әле. Сиңа сөйләшергә ярамый, онытма. Сынауларың искиткеч нәтиҗә биргәннәр. Кичә син йокыга киткәч, төнлә директорның өенә шалтыратып белештем. Әтиегезгә бөтен коллектив исеменнән рәхмәт тапшырыгыз, тизрәк терелсен дә теге олы сынауларга керешсен ди.

Галиәкбәрнең күзләре нурланып китте. «Ярый, яхшы», — дип пышылдады ул.

Әлфия әтисенә үзенең поселокка беренче тапкыр килеп төшүе, поселокны башта һич яратмавы, хәзер исә аркан белән тарттырсаң да мондый гүзәл урыннан китмәячәге турында сөйли башлады. Тик аны Галиәкбәр бүлдерде.

— Ә Эльвира Хәкимовнага мин әйткәннәрне тапшырдыңмы?

Әле ул зур сынау ким дигәндә бер айдан соң башланачак иде. Бу арада, Әлфиянең ышануынча, әтисе терелергә, яңадан поселокка кайтып эшкә керешергә тиеш иде. Картның әле васыять буларак яңгыраган сүзләрен яңадан хәтерләве Әлфиягә сәеррәк тоелды.

— Мин аңа барын да төкми-чәчми әйттем, тик син нигә аны искә төшерәсең әле. Сынаулар башланганчы терeләсең син.

— Син шулай дип уйлыйсыңмы, кызым? — диде карт, Әлфиягә күз кырыйлары белән генә карап.

— Әлбәттә.

Карт дәшмәде, тагы нидер уйлап ята башлады.

Галиәкбәр бу авырудан исән калса да, хезмәткә, яну-көюләргә яраклы кеше булмасын сизенә иде. Ул ерак юлга чыгасы кеше әйберләрен барлаган кебек, узган гомерендәге эш-гамәлләрен барлап ята иде. Үзеннән соң яшәячәк кешеләргә ниләр калдыра ул? Нәрсә дә булса берәр файдалы хәзинә бүләк итәме? Әллә, юкса, аның михнәт һәм мәшәкатьләр белән түшәлгән тормыш юлы бушка гына уздымы?

Галиәкбәр озын һәм хәтәр, сәер һәм кызыклы вакыйгаларны чагылдырган кинофильм тасмасындагы кадрларны яктылыкка куеп карагандай, узган юлын берәмтекләп тикшереп ятты. Монда нинди генә

кадрлар юк иде. Ятим баланың бер сынык икмәк өчен жанын кызганмый тырышып, көчәнеп жир сукалаулары да, ачлык һәм бөлгенлектә узган дәртле яшьлек, уку еллары да, белгеч булгач, әле күп тапкыр аптырашка калып, уку йортында алынмаган белемнәрне тормыш өермәләреннән өйрәнү, акыл туплау еллары да, ниһаять, озак еллар буена төннәрен төшләренә кереп шомландырган, шашынып уяныргa мәжбүр иткән дәһшәтле сугыш еллары да, инде бөтен акыл көчен туплап, гүзәл максатлар белән янып яшәлгән, фән өчен хезмәт дәрьясында йөзгән сугыштан соңгы чор да... Юк, бу кадрларның берсе дә Галиәкбәрнең йөзен кызартырлык түгел иде. Ул беркайчан да намусына хыянәт итмәде. Әйе, бәлки ялгышлар булгандыр, ләкин алар нинди дер мәкерлек, начар ният белән эшләнгән хаталар түгел. Аңлашылмау яки эшнең асылын белеп бетермәү аркасында килеп чыккан хаталар.

Яки менә аның гаилә тормышы. Ул да намуслылыкка һәм якынының хөрмәт итүгә корылды бит. Гомерлек юлдашы аннан разый булды. Ул үлгәндә дә: «Мин синнән риза бәхил, арсланым»,— дип үлде. Ә менә кызлар?

Галиәкбәр ыңгырашып куйды.

— Нәрсә, әти, әллә тагы...— диде куркынып Әлфия.

— Юк, кызым,— диде Галиәкбәр һаман түшәмгә ярым йомык күзләрен төбәгән килеш,— мин бары сиңа, синнән бик разый икәнлегемне генә белдермәкче идем. Әгәр үлә-нитә калсам...

— Әти бәгырем!— диде илереп Әлфия. Аның күзләрен яшь элпәсе каплаган иде.— Юкны сөйләмә әле, зинһар. Син терелсәң, синең хәлең көннән-көн яхшыра. Зинһар өчен, зинһар өчен...

Әлфия артык бер сүз дә әйтә алмас булып яшьләренә буылып тынып калды.

— Борчылма, минем өчен үз-үзеңне бетермә, кызым,— диде карт,— бер миннән генә калмаган. Әниең дә, әнә, нинди яшьләй...

— Сөйләмә, сөйләмә андый сүзләрне, әти. Үлем турында уйларга тиеш түгел син, ул сиңа килешми. Аңлыйсыңмы, әти, ярамый.

— И, кызым, мин әз генә дә курыкмыйм. Мин гомеремне бушка уздырмадым. Газаплар, михнәтләр бушка китмәгән, мин әле шуның турында уйлап яттым. Шуңа күрә миңа жиңел дә. Барыбер килми калмый ич ул... Бик зур үтенечем шул: Сафура апаңны ташлама. Көчсез ул. Аны кызган, аңа ярдәм кулыңны суз... Аннан Лиана... сары песнәгем...

Әлфия әтисен юатырлык хәлдә түгел иде, ул чыланып беткән яулыгына капланып тынып торды.

Ә Галиәкбәр үзенең соңгы сәгатьләре якынлашканын сизенеп сөйләнгән икән. Кичкә таба аның хәле кинәт начарланды. Кетмәгәндә, уйламаганда йөрәк кискен рәвештә авырта башлады. Әйтерсең лә ана пычак тыгып каерып-каерып боргычлыйлар. Галиәкбәр барлык буыннарының хәлсезлектән камыр кебек йомшарып калуын тойды. Аның кызганыч рәвештә ыңгырашуын ишетеп сестралар, врачлар йөгереп килде. Тиз генә йөрәген тикшерергә тотындылар, шундук укол артыннан укол кададылар. Ләкин бернинди чара да ярдәм итмәде.

Галиәкбәр аяк һәм кул бармакларының суынып китүен, сизгерлекләрен югалтуын тойды. Мондый сәер өшү һаман югарыга таба, йөрәккә таба үрмәләде. Йөрәк хәзер файдасызга тыпырчына иде. Әйтерсең лә буш куыкны һава белән өреп тутырмакчы булалар, ләкин ул куык тишек, шуңа күрә, никадәр тырышмасыннар, хезмәте бушка китә.

Кичке сигездә, шәфәкъ кызыллыгы тәрәзә аша бүлмәгә төшкән чакны, Галиәкбәр вафат булды. Әлфия аның күкрәгендә сулыгып елыйелый озак вакыт ятты. Инфаркт икенче тапкыр йөрәккә үзенең хәнжәрен кадаган иде.

Галиәкбәрне үзебезчә итеп, дус-иш, күрше-күлән ярдәме белән поселокның урман читендәге каберлегенә күмделәр. Бу аның соңгы теләге буенча эшләнде. Карт ничектер бер, үлсәм дә Әлфиям янында каласым килә. Азапланып мәетемне ташып йөрмәгез, дигән иде. Җеназада халык күп булды, мәгәр казанлылар да, профессор белән бергә эшләгән кешеләр дә бар иде. Күмүдә хәтта институт ректоры белән трест башлыгы да катнашты. Сафура гына килә алмады, телефоннан хәбәр итүенә караганда, ул ангина белән чирләп ята икән. Әлфиягә дуслары, фабрика эшчеләре, директор Гатауллин һәм тагы бик күп кеше ярдәм итте. Аны бер генә минутка да ялгыз калдырмадылар, күңелен табып юатырга тырыштылар, хәсрәтеннән айнырга, онытылырга ярдәм иттеләр. Ләкин бу тырышлыклар никадәр генә изге теләкләрдән чыгып, саф күңелдән эшләнгән булса да, Әлфия элекке халәтенә кайта алмады. Ул хәзер котчыккыч ялгызлык, рухи ялгызлык авырлыгын кичереп газаплана иде. Аңа ял бирергә дә булдылар. Теләсәң, ял йортына путевка бирәбез, диделәр. Ләкин Әлфия бер кая да китәргә теләк белдермәде, путевкадан баш тартты. Ул бар көчен куеп, үҗәтләнеп вакытын үзенең лабораториясендә уздырды. Әтисенең вакытсыз үлеме аның өчен әйтеп бетергесез зур фаҗига иде. Өстәвенә, өйгә кайтып баш-күз алгач, инде менә кайчаннан бирле Фәритнең кайтмавын искәрде ул. Бу хәл аны тагы да тетрәтте. Тәртипсез тормыш, үз-үзеңне белештерми эшләү аның матур ак йөзенә җыерчыклар салды. Күзләре ничектер нурсызланды, тәмам суырылып калды ул. Әлфия хәзер күңеле белән соңгы ышанычы, соңгы өмете булган Фәритнең кайтып керүен көтә иде.

Беренче май бәйрәме якынлашып килә иде инде. Поселок урамнарын 22 нче апрельдә шимбә өмәсендә себерделәр, тәртип урнаштырдылар. Инде бәйрәмгә дип кешеләр затлы азык-төлек, эчемлек тә әзерли башладылар. Никадәр авыр булмасын, көннәр тәрәлеп тормады. Галиәкбәрнең үлүенә ун көн вакыт узды да китте. Әһавалар искиткеч матур. Бройлер фабрикасы язгы кыр эшләрен төгәлләү алдында тора. Шундый көннәрнең берсендә, эштән соң, Әлфия кошлар сайравын тыңлап, фабрикадан өенә кайтып кергәч, почта әрҗәсеннән Фәриттән килгән хат тартып чыгарды. Әлфия таушала төшкән конверттагы хатны кулына алып аның кемнән икәнлеген аңлау белән, шатлыгыннан бөтенләй телдән язды. Шатлыкның ни икәнен оныткан иде бит инде ул! Аның күзләреннән яшь атылып чыкты, аскы ирене дерелди башлады.

Гүя кемдер кызның бу көтелмәгән куанычын тартып алырга тора иде. Әлфия йөгереп баскычтан менде, күз ачып йомганчы ишек йозагын ачып бүлмәсенә керде, утыргычка тезләре белән чүкте дә, конвертны өстәлдә яткан кайчы белән сак кына ачты. Хат гади дәфтәр битенә язылган иде. Кәгазьнең артык таушалган булуына Әлфия игътибар итми калмады. Ләкин эш андамени әле! Нилэр язган соң аның Фәрите? Ә Фәрит тигезле-тигезсез хәрефләр белән язган күрәсең, хат бик ашыгыч язылгандыр. Анда:

«Әлфия! Хәзер мин синнән бик еракта. Мин бөтенләйгә син яшәгән поселоктан киттем. Ни өчен шулай әллә кайларга, ят-чит җирләргә киттем мин? Үзем дә аптырыйм. Уйланам, уйланам да очына чыга алмыйм. Тик шуны беләм, мин бәхетсез бер качкын. Мин хәзер исерек вакытны гына үземне кеше итеп сизәм, ә юкса мин акылсыз бер дивана.

Әйе, нинди сәбәпләр аркасында соң мин шундый көнгә калдым? Яраткан абруйлы эшемне югалттым, дусларымны югалттым, балаларымны югалттым. Нидән килеп чыкты бу, ни сәбәптән, кем гаепле монда? Монда син гаепле, Әлфия, бары син, син, син! Син минем тормы-

шымны җимердең, син мине үзеңә каратып, газап утларына ташладың. Чөнки син минем балалар атасы булуымны белә торып та, миңа килеп сыландың. Нәләт төшсен сиңа, гүзәл елан! Әйе, елан син, чөнки син мине генә харап итмәдең, минем балаларымны да ятим калдырдың. Менә шул! Бу соңгы сүз сиңа. Мине эзләмә, минем алдымда акланырга тырышма. Фәрит».

Әлфия бу таушалган кәгазьдәге числосы да, урыны да куелмаган хатны үз күзләренә ышанмыйча укып чыкты. Башта андагы сүзләр аның аңына барып җитмәдә булса кирәк, кызны кызыксыну тойгысы гына биләгән иде, ниһаять, бераздан хаттагы сүзләр аның аңына барып кадалдылар. Әлфия тетрәнеп күзләрен зур итеп ачкан хәлдә хәрәкәтсез калды. Бераздан ул сыгылып хат өстенә өстәлгә ауды, әтисе үлгәндәге минутлардагыдай үз-үзен белешмичә еларга тотынды. Аның күз яшьләре мул ага, хатны чылата. Әлфия аның саен өстәлдәге хәтфә япманы ике кулы белән йомарлап елый-елый: «Фәрит, Фәрит», — дип кабатлый иде.

— Нишләдең син, Фәрит, нишләдең? Нигә син миңа дөньяда булмаган гаепләр тагасың, кадерлем? Мин бит сине бары яраттым гына, бары яраттым гына! Ә син соң мине яратмадыңмыни? Син дә яраттың мине, Фәрит кадерлем, багалмам! Ник соң тормышыңдагы шундый җаваплы бер минутта син көчсезлек күрсәттең? Әллә син без кичергән бәхетле минутлар тагы кире кайта ала дип уйлыйсыңмы? Фәрит, Фәрит, мине мәхәббәтем өчен әрләмә! Мин гаепле түгел, син гаепле монда, чөнки мәхәббәтең өчен көрәшергә теләмәдең. Ай, җаным, ай, җаным!

Әлфия артык тетрәнүдән тәмам алҗып, хәлсезләнеп тынып калды. Маңгаен беләгенә салган килеш байтак вакыт шулай берни уйлый алмастан, фикер йөртергә тәмам сәләтсез бер хәлдә ятты. Бары бер нәрсә ачык иде аңа, ул да булса, соңгы өмет җепләре, куанычка, бәхеткә булган өмет җепләре шартлап өзелгән иде. Бераздан аңа һава житмәгәндәй тоелды. Ул торып утырды, башын артка ташлап, иркен итеп сулыш алырга теләде. Ә хатны ул игътибарсыз калдырды. Әйтерсен лә анда күз яшьләренә манчылып беткән кирәксез бер кәгазь генә ята иде. Хәзер Әлфиягә барыбер, аны хәзер илтифатсызлык халәте биләп алды. Әмма һаман тын алулары авыр, иркен сулау өчен бүлмәдә һава һаман житми иде әле. Әлфия башына ак челтәр пәрәвез җебедәй юка шәлен каплады да, ишеккә таба юнәлде. Аңа хәзер барыбер, барыбер. Ул хәтта ишеген дә япмады, ярым ачык килеш калдырып, баскычтан түбән төшә башлады.

Кемнәрдер аның юлында очрады, кемнәрдер зурлап сәлам бирде, мәгәр Әлфия аларның берсен дә күрмәде дә, ишетмәде дә, ул поселок урамы буйлап кулларын пальто кесәсенә тыккан хәлдә салмак кына атлап баруында булды.

Поселок кибетенә житәрәк кыз каршысына кемдер аркылы килеп басты. Ул кычкырып: «Исәнмесез, Әлфия Галиәкбәревна», — диде. Әлфия: «Исәнмесез», — диде, аңа барыбер иде ул кеше кем булса да. Ләкин кеше нәкъ Әлфиянең каршысында, аңа юл бирми. Әлфия ирексездән күтәрелеп бу таза кешенең йөзенә карады... «Ә, Рәмзи, — дип уйланды ул шул ук гамьсезлек томаны аша, — д'Артаньян!»

— Болай бик уйланып кына кая барасыз, Әлфия Галиәкбәревна?

Кая бара соң әле ул Әлфия? Ә, барыбер түгелмени! Әнә кибеткә, ахры.

— Кибеткә.

— Нәрсә алып кайтырга соң исәп?

Нәрсә алалар соң әле кибеттән? Әйдә, барыбер түгелмени!

— Лимон.

Рәмзи бик аптырады.

— Лимон?
— Лимон.
— Соң лимон юк ич безнең кибеттә. Ул Чаллыда да сирәк була.
— Шулаймыни?
— Теләсәгез, мин сезгә үзем бирә алам. Мин узган елны Чаллыдан аны бер дистә алып кайткан идем. Теләсәгез, мин сезгә бирәм. Кирәкме?
— Кирәк, билгеле.
— Кирәксә, әйдәгез, минем өйгә керәбез. Минем квартира монда гына бит!
Әйдә, миңа барыбер ич, дип уйланды Әлфия Рәмзигә ияреп.
Алар пыяла тәрәзәләрен ялтыратып торган зур таш кибет яныннан узып алга киттеләр.
— Менә монда саграк, карабрак басыгыз, язгы гөрләвекләр асфальтны җимергән, — диде Рәмзи. — Беләсезме, мин бит хәзер цехның законный начальнигы. Менә озакламый яңа квартира да вәгъдә итте Гатауллин. Теге зур сынауның практик эшен миңа тапшырдылар. Хәзер минем эшләр худта.
— Тәбрик итәм, — диде Әлфия салкын гына. Аңа әле һаман барысы да гамьсезлек пәрдәсенә төрелгән иде.
— Менә минем сарайга килеп тә җиттек, — диде Рәмзи, — рәхим итегез, узыгыз.
Алар ике катлы таш өйнең икенче подъезды алдында торалар иде. Кинәт Әлфиянең башына гаҗәп ачык булып гади бер сорау килде. Тукта, нигә ул мине үзенең өенә сөйри? Әлфия уянып киткәндәй булды. Әтисенең «сез әле каласы кешеләр, сезгә мин нәрсә калдырам соң?» дигән сүзләре колакта яңгырагандай булды. Ә Рәмзи исә аны үзенең өенә сөйри иде.
— Туктагыз әле, — диде кинәт бөтенләй айнык, кырыс бер тавыш белән кыз. — Мин кереп тормыйм. Сез лимоныгызны монда гына чыгарыгыз!
Рәмзи матур авызын җәеп, ак эре тешләрен балкыткан хәлдә, көлеп җибәрде.
— Миндә лимон юк. Мин сезгә шаяртып кына әйттем.
— Нигә соң мине монда алып килдегез?
— Минем сезнең белән бер сөйләшеп утырасым килә. Миндә альбом бар. Бик кызыклы. Аны миңа бер иптәш бүләк иткән иде.
Әлфия Рәмзинең эре чалымлы матур, ләкин оятсыз йөзенә текәлде.
— Әйтегез әле, сез минем фаҗигамнән файдаланмакчы буласызмы?
Рәмзинең йөзенә аптырау һәм шундук ачу йөгерде.
— Ничек инде? — диде ул.
— Менә шулай! — диде Әлфия Рәмзинең кулын үзенең беләгеннән кискен бер хәрәкәт ясап ычкындырды да шактый кызу адымнар белән китеп тә барды. «Туктале, ни өчен соң миңа барыбер булсын, — дип уйланды ул. — Минем әле яшисем бар, эшлисем бар, кемнәрнедер шатландырасым, кемнәрнедер үзем белгәннәргә өйрәтәсем бар. Нигә миңа барысы да бетсен дә, нигә мин барысына да гамьсез генә карап яшәргә тиеш?!»
Ни өчендер аның күз алдына этисе онытмаска кушкан Лиана килеп басты. Аны, әлбәттә, әнисе үзенең җилкуарлыгы аркасында юньләп карамаячак та, юньләп тәрбияләмәячәк тә. Аны мин үземә кызлыкка алам, дип уйлады ул.
Әлфия адымнарын кызулатканнан-кызулатты, каядыр ашыгырга кирәк кебек иде. Әйе, дип кабатлады ул үз-үзенә, бер нәрсә дә, бер нәрсә дә миңа барыбер түгел. Барыбер — ул үлем, дигән сүз, ә мин әле үләргә теләмим. Теләмим, теләмим!

## ЭПИЛОГ

Камада агымга каршы өскә күтәрелә торган теплоходлар яр буендагы кош фабрикасы турысына җиткәч, ярга шактый якынаялар. Менә шушы турыда, әгәр палубага менеп игътибар беләнрәк карасаң, куе урманлык эчендәге бәләкәй аланны һәм андагы каберлекне күрергә була. Әгәр инде биноклең булса, бу каберлектәге профессор Галиәкбәр Максудовның да каберен күрергә мөмкин. Чөнки ул нәкъ Кама киңлекләренә төбәлгән.

Әлфия акча кызганып тормады, зыярәт кылучылар игътибар итсен дип, әтисенә шактый матур мәрмәр таш куйдырды, кабергә чардуган ясатты, кабер өстенә кәс җәйдерде.

Шулай ук профессорның сынаулары да аның өчен матур истәлек булып калды. Әйе, зур сынауны үзенә уздырырга туры килмәде аңа. Ләкин бу эшне Эльвира Хәкимовна нәкъ ул әйткәнчә уздырды. Фабрикада еш-еш үзе булды, үзе булмаганда Казаннан аның ярдәмчеләре килеп тордылар. Ул арада фабрикага Фәрит урнына яшь зооинженер да табылды.

Фәрит яңадан поселокка кайтмады. Көтеп-көтеп тә иренең кайтуыннан ваз кичкән хатын Марат белән Ләйләне ияртеп, яңадан әнисеннән мирас булып калган үз өенә кайтып китте. Фәһимә белән Фәрит арасы ни белән беткән, моны анык беркем дә белми иде. Бары имеш-мимешләр генә йөри. Озак вакытлар Фәрит әтрәгәләм булып, эчеп, читят җирләрдә йөргәннән соң, яңадан гаиләсенә кайтып егылган дигән хәбәр бар. Фәрит тәмам эчкечелеккә сабышкан икән, дәваланып та караган, тик файдасы булмаган, ә гаиләдә тынычлык, татулык һаман тумаган, ир белән хатын дошман булып гомер уздыралар, дип тә сөйлиләр.

Батырлык һәм егетлекне үзенчә аңлаган Рәмзи дә күңелсезлекләргә дучар булды. Без капчыкта ятамы соң? Рәмзи ни кадәр генә аңлатмасын, Соня бала табу бәхетеннән ваз кичәргә теләмәде. Бәби дөньяга килде, һәм аннан качып котылырга теләгән Рәмзи турында Соня фабрика җитәкчелегенә әйткәннәрен шаһитлар белән раслап, хат язды. Бу эшнең ахыры ни белән беткәне бик ачык инде. Бәхетле идеме соң д'Артаньян? Мондый сорауга җавап бирүе авыр түгел. Олы саф мәхәббәтне инкарь итә торган кеше бәхетле була аламы соң!

Шулай ук Сафура да бәхетле гаилә кора алмады. Бу яшь хатынның үз рәхәте өчен генә яшәргә ашкынуы, миннән акыллырак, миннән гүзәлрәк кеше дөньяда юк дип уйлавы яшь гаиләне һәлак итте. Алар Дмитрий белән аерылыштылар. Квартираны икегә бүлделәр. Галиәкбәрнең өч бүлмәле бер квартирасы урнына берәр бүлмәле аерым ике квартира булдырдылар. Аларын да бер-берсеннән ераграк урыннардан таптылар. Берсе Казанның Дербышка поселогында, икенчесе Казанның Мәскәү районында.

Ә Лиана терелеп, шактый үсеп санаторийдан кайтты. Ул өйдә юк чакны Сафурага җиңелрәк иде. Нәни Лиана кайтып Сафураның аяккулын богаулап куйгандай итте. Шуңа күрә Сафура, берничә ай бәләкәч белән изаланганнан соң, аны, Әлфиянең күптәнге үтенечен искә алып, Кама буена озатты. Сафура бәхетлеме соң? Җан рәхәте өчен түгел, бары тән рәхәте өчен генә яшәгән кеше бәхетле була аламы соң? Әйе, ул әлегә матур, үзе тапкан акчасын модадан калышмау өчен генә тота, һаман ир-атның күзен кыздыра, флирт оештыра. Ул һаман министрның секретаре булып хезмәт итә, һаман министрның үзенә

күзе төшүен көтә, ләкин ул барыбер бәхетнең нидән торганын белми иде.

Ә Әлфия үзенең олы фаҗигасе, авыр хәсрәте белән бергә яши, эшли, тормышның көндәлек бәләкәй шатлыкларына юана, үзендәге авыр хис-тойгылардан арыну өчен көрәшә. Хәзер аның хәле шактый җайланды. Чөнки аның янында Лианасы бар. Әйе, Лианасы, сары песнәге, көмеш кыңгыравы. Әлфия аны бөтенләйгә үз кызы итеп алырга ниятләнә. Фикеренчә, Сафура моңа каршы килмәс, чөнки аның кыз кеше булып бик-бик озак еллар яшисе килә бит!

Әлфияне бәхетле кеше дияргә була. Нигә, ул чын, олы һәм саф мәхәббәт ширбәтен эчеп карамадымени? Әти-әнисен өзелеп яратмаган, хөрмәт итмәгән кешемени? Ул хезмәтеннән тәм тапмыймыни? Юк, ул фаҗигале булса да, бәхетле кеше!

Алар буш вакытларда еш кына Галиәкбәрнең каберенә баралар. Андагы бәләкәй эскәмиягә утырып, карт профессорны искә алалар. Әлфия Лианага үзенең әтисе турында сөйли. Әйе, Лиана үзен бик, бик яраткан «давати»сен әле бик яхшы хәтерли, ул да, нәкъ Әлфия кебек үк, аны сагынып яши.

Камада ярга якын гына узган аккошлардай купшы теплоходлар Галиәкбәр яткан каберлек яныннан узганда ни өчендер сузып-сузып кычкырталар. Гүя алар шулай күңелләргә аерылышу моңсулыгын салып, Галиәкбәрне искә алалар.

1978

## ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА




КОНКУРСКА КИЛГӘН ОЧЕРКЛАРДАН

**Рәмзи Максудов**

# КАМАДА АК ПАРОХОД



Идел дулкыннары, көн-төн дулап хәлдән тайган сыман, иренеп кенә киләләр дә ярга сугылалар. Шул дулкыннарда салмак кына тирбәлеп, яр читендә кечкенә пароход тора. Исеме — «Смоленск». Ул бер кая да китәргә дә җыенмый, ахрысы: бер төшендә дә сәфәр чыгу алдыннан була торган ыгы-зыгы сизелми.

Киң җилкәле ир уртасы кеше, яр буйлап ашыкмый гына атлап килде дә, шул пароходның трабына менеп басты. Палубаны җыештыргалап йөрүче матрос, аны күрүгә:

— Старпом, сезне капитан көтә,— дип кычкырды.

Трап буйлап пароходка кергән әлеге кеше, тавыш бирүче матроска таба борылып, аңладым дигәндәй, кул изәде. Адымнарын кызулый төшеп, пароход башлыгының каютасына юнәлде. Өстендә күн тужурка, ул шуның итәкләрен тарткалады, билендәге каешын рәтләде һәм капитан каютасының ишеген шакыды.

— Керегез,— диделәр эчтән калын тавыш белән.

Старпом эчкә үтте. Капитан, урыныннан торып, аңа кул сузды:

— Әйдә, әйдә, Николай Михайлович, көтәбез.

— Ашыгыч эш чыктымы әллә? — Старпомның борчулы карашы пароход башлыгына төбәлде.

— Хафаланырлык нәрсә юк,— диде капитан.— Тик якорьны күтәрергә туры килер сиңа, Николай Михайлович. Сине комиссар чакыра. Менә, иртүк телеграммасы килеп төште.

— Кая?.. Кем чакыра?

— Монда барысы да язылган.— Капитан аңа телеграмма сузды.— Губком боерган.

Николай Михайлович Глазунов бланкны кулына алды: «Ашыгыч. «Смоленск» пароходы капитанына. Старпом Глазуновны «Красная звезда»га җибәрегез».

Глазунов та, «Смоленск» пароходы капитаны да «Красная звезда»ның Идел буйлап сәяхәткә ни өчен чыгуын бик яхшы беләләр иде. Россия, бигрәк тә Идел буйлары авыр хәлдә. Бу төбәкләр әле күптән түгел генә аклар золымыннан азат ителде. Урыннардагы җитәкче кадрлар шундый кыен шартларда — таркалган хуҗалыкларны аякка бастыру, политик тәрбия эшен җайга салу юлларын белеп җиткермиләр. Вакытның болганчыклыгыннан файдаланып, кирегә ишәргә маташучылар да юк түгел. «Красная звезда» пароходында төрле комиссариат вәкилләре, совет хөкүмәтенең агитаторлары һәм инструкторлары бара. Алар һәр урында эшчеләр, крестьяннар белән очрашалар, җитәкче оешмаларга булышалар. Пароход Нижний-Новгород шәһәреннән кузгалып китә. Халык аны «Йөзмә ВЦИК» дип зурлый. Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты, ягъни.

Шундый зур эшләр белән чыккан пароход 1919 елның июль аенда Казан пристанена килеп туктый. Монда аны партиянең губерна комитеты һәм башкарма комитет вәкилләре, эшчеләр каршылый. Шәһәр хезмәт ияләре В. И. Ленинның дусты һәм көрәштәше Надежда Константиновна Крупская белән очрашалар. Митинглар үткәрелә. «Йөзмә ВЦИК» губерна җитәкчеләренә күп кенә четерекле мәсьәләләрне хәл итүгә булыша...

Глазунов боларны газеталардан укып белә иде. Тик менә үзен шул пароходка ни өчен чакыруларына төшенеп җитә алмады. Телеграмманы дүрткә бөкләп куен кесәсенә тыгып куйды да, капитан тәкъдим иткән кечкенә катерга утырып, Кама тамагына китеп барды.

— «Красная звезда» кайчан үтте? — дип сорады ул андагы шкипердан. Ә ул, «нигә кирәк булды әле сиңа бу?» дигәндәй, Глазуновка каш астыннан гына карап куйды. Тиз генә тел ачарга исәбе юк иде шикелле. Николай Михайлович аңа телеграмма сузды. Шкипер Глазуновны причалда торган зуррак катер янына алып килде. Анда ике-өч матрос кайнаша иде. Шкипер шуларның өлкәнен чакырып китерде дә:

— Менә, комиссарны «Красная звезда»га илтергә кирәк, хәзер үк кузгалыгыз. Губком боерыгы! — диде.

Ун-унбиш минуттан катер кузгалып та китте. Глазунов, бәлэкәй палубага баскан килеш, каршыга йөгергән дулкыннарга күз салды. Күңелен сәер хис биләп алды. Карасана, кызык кына икән бит бу пассажир булып бару дигәне! Шул Иделдә күпме йөреп, мондый хәлдә бер чакрым ара да узганы юк иде әле. Башта елга пароходында матрос булды. Ә матроска кайда да шөгыль-мәшәкать җитәрлек! Кечкенә генә суднода ничәмә-ничә ел тир түккәннән, Иделдә бик күп җил-давыл кичергәннән соң гына капитанның өлкән ярдәмчесе итеп күтәрделәр. Бу хезмәт гади матрос мәшәкатьләреннән йөз кат авыррак. Бөтен команда өчен җавап бир. «Пассажирның эше рәхәт икән! — дип уйлады Глазунов.— Аңа дулкын ни дә, томан ни».

Николай Глазунов команда белән уртак тел табып эшләде. Аны гадилеге, туры сүзле булганы өчен яраттылар. «Смоленск» командасы һәм якын-тирәдәге пристань эшчеләре аны, зурлап, «комиссар» дип атый.

Комиссар!.. Глазунов, үткәннәрне хәтерләп, елмаеп куйды.

Совет республикасын төрле яктан чит ил интервентлары һәм акгвардияче генералларның армияләре уратып алган чак иде. Унтугызынчы елның дәһшәтле, республика өчен гаять хәвефле язы. Идел буйларында сугыш уты дөрли. Илгә икмәк җитми. Балалар ачлыктан интегә. Икмәкнең һәр кыерчыгы алтыннан кадерле. Шундый чакта ул, Николай Глазунов, дошман гаскәрләре уты астыннан 500 мең пот ашлык алып чыкты. Ашлык төялгән баржалар кәрванын Казанга илтеп җиткерде. Ә аннан инде Мәскәүгә, Петроградка.

Ул елны яз бик сүлпән килде. Иделдә боз соң кузгалды. Глазунов хезмәт итә торган пароход Спасста (хәзерге Куйбышев поселогы) кышлаган иде. Монда тагын пароход димәсәң дә хәтере калмаслык берничә судно торды. Пристань эшчеләре шуларны ремонтлап, язга әзерли башлады. Ә тирә-яктан хәвефле хәбәрләр килә. Якында гына Колчак туплары гөрселди... Ул Чистайга якынлаша дип сөйлиләр...

Беркөнне елгачылар янына шәһәр политкомиссары Миронов килеп чыкты. Пристаньда эшләүчеләрне җыеп, чын хәлне ачыклап бирде.

— Илебез бик хәтәр көннәр кичерә, иптәшләр,— диде ул.— Колчак гаскәрләре Иделгә таба ябырылып килә. Дошман бу якларга җитә калса, судноларны нишләтергә икән безгә? Шул хакта киңәшергә килдем. Гади көймәне дә дошманга калдырырга ярамый.

Комиссар әйтеп бетермәде. Елгачылар аны сүзсез дә аңладылар. Барлык пароходларны сүтәргә карар иттеләр. Кирәк икән, үз куллары белән батырачаклар да...

Суднолардагы двигательләрне сүтәргә, кайсын-кая яшерергә дип тотынганнар иде — елгада боз кузгалды. Казанда шуны гына көткәннәр диярсең — телеграмма килеп төште. Теләсә нинди шартларда һәм бик ашыгыч рәвештә Чистайга буксир пароходы җибәрергә. Анда ашлык төялгән баржалар тора. Һәркайсында махсус отрядларның җаны-тәне белән җыйналган икмәк. Шул баржаларны алып чыгарга һәм Казанга җиткерергә кушылган иде. Бу җитди һәм җаваплы эшне сәләтле большевикка тапшырырга — губерна комитетының әмере шундый.

«Чистай янында гына колчаклар мәш килә ләбаса... Ничек инде дошман уты астына буксир судносы белән барып керәсең?» Телеграммада язылган сүзләр аңга барып җиткәч, беренче уйлар шундый булды. Елгачылар икеләнеп калдылар. Ләкин боерыкны үтәргә, ярты миллион пот ашлыкны саклап калырга кирәк иде. Тик кемне җибәрергә? Губком бу эшне сәләтле большевикка йөкләргә кушкан. Димәк...

— Затонда бердәнбер коммунист син, иптәш Глазунов,— диделәр аңа. Әйдә, команданы бир. Әмереңне көтәбез.

Глазунов кырыс кына итеп:

— Дүрт сәгатьтән юлга чыгабыз, иптәшләр. Якорьне күтәрергә әзер булыгыз,— диде.— Штурвал рубкасын калынрак тимер белән тышларга кирәк. Ком тутырылган капчыклар әзерләргә! Бөтен командага коралланырга.

Буксир судносы шулай хәрби корабка әверелде, ә старпом Глазунов капитан булып китте.

Иделдә боз бетмәгән иде әле. Кама тамагына кадәр үтү бик авыр булды. Шактый еш очраган зур-зур боз өемнәре белән бәрелешмәс өчен, судноны әле уңга, әле сулга бора-бора беләкләр калмады. Төнгә каршы инде буксир пароходы Кама тамагы пристаненда тора иде, ул чагындагы аталышы — Богородская. Монда буксирга Кама елгасының холкын яхшы белгән лоцман утырды. Бозлар

сирэгэйде. Тагын берничэ сэгатьтэн алар бөтенлэй күренми башлады. Пароход Камага чыкты. Глазунов җиңел сулап куйды.

Лаеш та артта калды.

Мурзиха пристаненда «Чердынь» пароходы тора иде. Капитаны — Глазуновның күптэнге танышы. Николай Михайлович аңардан Чистай турында сорашты.

— Хэзергэ тынлык,— диде «Чердынь» капитаны.— Тик пароходлар барысы да сүтелгэн. Бүген-иртэгэ Колчак флотилиясе күренер дип уйлыйлар. Атыш тавышлары шэһэргэ якында гына ишетелэ...

Глазунов команда белэн киңэшеп алды. «Ничек тэ өлгерергэ! Ашлыкны дошман уты астында булса да алып чыгарга!» — дигэн карарга килделэр.

Ул елларда Мурзиха тирэлэрендэ Кама үтэ тар, Чистайга кадэрле диярлек шундый иде. Көчле агым пароходны кирегэ сөйри. Лэкин кечкенэ булса да ярыйсы ук куэтле судно, каршы агымга үҗэтлэнгэн шикелле, бөтен гайрэтенэ үкереп, алга бара. Глазунов штурвал рубкасына баскан, кулында бинокль. Энэ, Чистай элеваторының башнясы да күренде. Бинокль пыялалары пристань ягына төбэлде. Эһэ, баржалар тора!.. Николай Михайлович аларны санарга керешге: бер, ике, өч... Алтау. «Барысы да исэн!» — дип куанды Глазунов. Берсе янында кечкенэ генэ судно кисэге дэ бар. «Колчак разведкасы булмагае»,— дип уйлый Глазунов. Команданы коралга бастыра. Ни дисэң дэ,— ун винтовка, ун сугышчы матросы бар бит!

Егетлэр, мылтыкларны шул пароход ягына төбэп, ком тутырылган капчыклар артында ята. Буксир баржаларга якынлаша. Карасалар, элеге пароходның «кабыгы» гына калган икэн. Машиналарын сүтеп алганнар. Арттарак тагын өч-дүрт пароход тора. Алары да шундый ук хэлдэ. Машиналары сүтелгэн, бөтен эчке җиһазлары алынган.

Җансыз пароходлар арасына исэн-имин судно килеп кергэч, баржаларның берсендэ кырыс йөзле, алыптай гэүдэле кеше күренде. Трюмнан килеп чыкты, ахрысы. Глазунов судносы аңа гудок бирде.

— Нэрсэгэ сызгыртасың, бабаңның нэлэт орган оныгы! — дип сүгенде баржадагы «Алып».— Пристань буш, пароходлар үлгэн. Бэбэклэрегез чыкмагандыр бит... Ишетмисезмени — гөрселди...

Двигатель тынып калды. Элеге «Алып» янында тагын берничэ матрос пэйда булды. Кайберлэре кораллы.

— Сез кайдан? — дип сорады алып гэүдэле матрос. Күрэсең, ул монда өлкэн кешедер. Глазунов җавап бирде. Э ул аны бөтенлэй ишетмэгэндэй, үзенекен сукалады:

— Энэ, аклар килэ... Барысы да шунда китте. Э безне...— ул янындагы матросларга ымлады,— бирэдэ калдырдылар. Баржаларны батырырга куштылар. Боерык!

— Батырырга?! — дип кычкырып җибэрүен сизми дэ калды Глазунов.— Кем кушты? Кем боерыгы бу?..

— Кушкан кеше еракта, э монда без хуҗа,— диде баржадагы матрос.— Нэрсэ, акларга калдырырга дисеңме эллэ бу байлыкны? Егетлэр! — ул үз янындагыларга эндэште.— Ачыкларга кирэк боларның кемлеген. Ни шайтаныма йөрилэр мондый чакта? Бэлки контрлардыр!..

Баржадагы матросларның мылтыклары буксирларга төбэлде. Глазунов елмаеп куйды да үз командасына боерык бирде:

— Сез дэ күренегез, егетлэр!

Кулларына мылтык тоткан ун матрос торып басты. Баржадагылар моны көтмэгэн иде булса кирэк. Алай да аптырап калмадылар. Алып гэүдэле матросның калын тавышы тагын яңгырады:

— Ни өчен судногыз ходта?
— Тыңлагыз! — дип кычкырды Глазунов рупор аша. — Без мене шушы баржаларны алып китәргә килдек. Губком кушуы белән. Кайсыгыз монда җаваплы итеп калдырылды? Өяз комитетыннан берәрсе юкмы?
— Барыбыз да башлык, — диде теге кеше. — Кемнең кулында мандат — шул әмер итә. Вакыты шундый...
— Алайса, менә сезгә мандат, — Глазунов кулларын алга таба сузды. Уңында пистолет, сулында телеграмма иде. Матрос алгарак чыкты.
— Син бу алтатарыңны җыеп куй, ә монысын укып карыйк, — ул Глазунов кулыннан телеграмманы алып, күз йөртеп чыкты да бармакларын авызына кабып, сызгырып җибәрде.
— Палундра-а!.. Үзебезнекеләр! Баржаларны әзерләргә!..
Каяндыр тагын берничә матрос килеп чыкты. Глазунов командасы да эшкә тотынды.
Кырыс күренгән әлеге матрос Глазунов янына килде дә:
— Болай каршылавыбыз өчен гафу ит, туган! — диде. — Югыйсә, аклар кармагына кабуың да ихтимал.
Батырырга әзерләнгән баржаларны яңадан буксирга тагарлык хәлгә җиткергәнче, көн узды. Кәрван төнгә каршы гына кузгалды. Атышлар шәһәргә тагын да якынлаша төшкән иде инде. Ике снаряд пристань янына ук төшеп шартлады.
— Утларны сүндерергә! — дип боерды капитан.—Машина бүлеген томаларга.
Язгы төннәр караңгы булучан. Елгада берни күренми диярлек. «Монысы безнең файдага», — дип уйлады Глазунов һәм лоцманга:
— Бу тирәләрне яхшы беләсезме? — дип эндәште.
— Соравыгыз урынсызрак.
— Сукыр килеш барасы булганга сорыйм.
— Тыныч булыгыз!
Лоцман кәрванны маяксыз-нисез урыннардан Иделгә таба алып китте. Лаеш яныннан узып барганда, яр буеннан суднога ата башладылар. Баш өстеннән сызгырып пулялар очты. Рупор аша:
— Әй, буксир! Туктагыз! — дип кычкырдылар.
Акларымы?... Кызылларымы?.. Кем булса да тукталмый гына узасы иде. Глазунов командасына боерык бирде:
— Тулы тизлек!.
Тик яр буендагылар да моны абайлап алдылар булса кирәк.
— Хәзер үк туктагыз! Сезгә туплар төбәлгән!
«Ни булса — шул, туктарга», дип карар итте Глазунов. Томан юк, ай яктырткан елга өстендә буксир һәм баржалар ап-ачык булып күренә. Ярдан туплар ата башласа, беренче снарядлар ук кәрванны пыран-заран китерәчәк.
Буксир туктады.
Озак та үтмәде, көймә килеп җитте. Берничә кораллы кеше. Кызылларымы, акларымы — ачык түгел, көймәдәгеләр аста — судно күләгәсендә торып сөйләшә иде. Глазунов аларның сорауларына мөмкин кадәр «шомарак» җаваплар бирергә тырышты.
— Кая юл тотасыз? — дип сорадылар.
— Кушылган җиргә, — диде капитан.
Көймәдән ачулы тавыш ишетелде:
— Кушылган җир хәзер бер генә! Чистайга ярдәм кирәк! Глазуновның эченә җылы керде. Чистайга булгач, кызыллар, үзебезнекеләр, Казаннан килешләредер. Шулай да, шиген бетерергә теләп, ул үзе дә:
— Ни телисез? — дип сорады.

— Полкны Мурзиха ягына чыгар!.. Шул гына...

Шул гына, имеш! Буксир пароходы белән полк хәтле полкны ничек чыгарып бетерәсең ди.

Шул арада кайдандыр ерактан дизельләр авазы ишетелгәндәй булды. Кайсы яктан?.. Әһә, Кама тамагы ягыннан икән. Димәк, суднолар Казаннан килә. Үзебезнекеләр!..

Глазунов тревога белдерергә боерык бирде. Каршы яктан килүче суднолар туктады. Болар — Идел хәрби флотилиясе кораблары иде. Хәрбиләр Николай Михайловичның аңлатуын тыңладылар да рупор аркылы болай дип боердылар:

— Идел хәрби флотилиясенең комиссары сөйли. Гаскәрләрне Мурзиха ягына чыгару кичектергесез бурыч. Баржаларны Лаешта калдырып торыгыз. Чистайга ярдәм кирәк, полк шунда ашыга. Бу хакта Ленинннан телеграмма бар. Ә баржаларыгыз өчен борчылмагыз. Дошманны Иделгә кертмәбез.

Флотилия китеп барды. Глазунов егетләре хәрби комиссар боерыгын үтәргә керeште. Полкны күчерү тәүлектән артыкка сузылды...

Хәрби боерык үтәлде. Кызыллар командованиесе судно матросларына рәхмәт белдерде. Николай Михайлович Глазуновка командующий боерыгы белән бүләк тапшырдылар: кызыл йолдыз тагылган күн фуражка, күн тужурка һәм күн чалбар. Комиссарларга гына бирелә торган нәрсәләр. Шуңадыр, күрәсең, бүләк киемнәрне өстенә киеп чыккач, матросларның берсе:

— Комиссар булуыгыз белән котлыйбыз, Николай Михайлович! — дип, аның кулларын кысты.

...Ул хәзер шул ук урыннардан уза. Аны «Красная звезда» пароходына чакырткannar. Нигә? Кем дәштергән? Николай Михайловичка мәгълүм түгел.

«Красная звезда» пароходын алар Глазунов өчен бик-бик истәлекле урында — Чистай пристанендa куып җиттеләр. Николай Михайлович, катердан төшеп, туп-туры шунда китте. Трап янында торган бер матроска телеграммасын күрсәтте. Матрос аңа:

— Комендантка керегез, — диде. Ул күрсәткән ишекне ачып керүгә, Глазунов бер мәлгә югалып калгандай булды. Аның алдында иске танышы — Спасстагы элекке политкомиссар Миронов басып тора иде. Ул аңа рапорт бирергә теләп:

— Иптәш комендант, рәсми чакыру белән... — дип сүз башлаган иде, Миронов аны бүлдерде.

— Ярар, Николай Михайлович!.. Саумы, якташ? Килеп җиттекме?

Күрешкәч тә комендант аны Надежда Константиновна каютасына алып китте.

— Әйдә, рапортны аңа бирик без, иптәш комиссар.

— Нинди комиссар ди мин, иптәш Миронов?

— Революция комиссары, — диде Миронов. Аның тавышы җитди иде.

Алар беренче класс салонына үттеләр. Бер-берсенә каршы куелган кәнәфиләрдә ике хатын-кыз утыра иде. Миронов белән Глазунов кергәч, чал чәчлесе урыныннан торып, аларга таба атлады.

— Сезнең карамакка җибәрелгән елгачы Глазунов...

— Куегыз сана, — дип кул селтәде Надежда Константиновна. — Утырыгыз, әйдә, утыр!..

Крупская сораштыра башлады. Ничек килеп җиттегез? Спасста нинди үзгәрешләр бар? Гаиләгез борчылып калмадымы? Өйдәгеләрегезгә әйтеп киткәнсездер бит?

— Өлгерә алмадым шул, — диде Глазунов. — Капитан әйтәчәк...
Крупская комендантка борылды:
— Сез, иптәш Миронов, Спасска телеграмма суктыра алмассызмы икән?.. Иптәш Глазуновның гаиләсенә. Ул «Красная звезда»-да диегез. Борчылмасыннар...
— Эшләрбез, Надежда Константиновна.
— Иптәш Глазунов тамак ялгап алсын иде. Юл килгән кеше бит, ачыккандыр, — диде Надежда Константиновна һәм Николай Михайловичка шундый игътибар белән карады, әйтерсең әнкә кешенең улына каравы.
Миронов аны ашханәгә алып китте. Барып җиткәнче, аның «Красная звезда» пароходына чакыртылу сәбәбен аңлатты.
— Гади пароход кына түгел бу, комиссар. Агитация-инструктаж мәктәбе. Монда Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетының җаваплы работниклары һәм төрле комиссариатларның вәкилләре бара. Төнебез юлда уза, ә көндез шәһәрләрдә яки авылларда туктап торабыз. Надежда Константиновна — Халык мәгарифе комиссариатының инструкторы. Бик зур эш алып бара. Пароход Нижнийдан кузгалды. Пермьга хәтле барачак. Төп таянычыбыз — коммунистлар. Ләкин команда составында партиялеләр күп түгел. Вакытның нindилеген беләсең, Николай Михайлович. Пароход үтәсе төбәкләр әле яңа гына аклар золымыннан азат ителгән. Төрлесен көтәргә мөмкин. Безгә бик ышанычлы коммунистлар кирәк иде. Казанда Надежда Константиновна губкомнан пароход командасына ярдәмгә тәҗрибәле елгачы бирүен үтенде. Партияле иптәш булсын, диде. Синең кандидатурага тукталганнар. Мин дә якладым. Чистайдан ашлык чыгаруыңны искә алдым...
Ашханәдән чыккач, Глазунов Надежда Константиновнага:
— Сез ышанып тапшырган эшне башкарып чыга алырмынмы икән, Надежда Константиновна? — диде.
— Без сезгә ышанабыз, иптәш Глазунов.
Пароход Чистайда ике көн торды. Партия Үзәк Комитеты, ВЦИК хезмәткәрләре шәһәрдә һәм өяздә совет оешмаларының эше белән таныштылар, җитәкче работникларга киңәшләр бирделәр. Соңыннан Надежда Константиновна Чистай хакында көндәлегенә мондый юллар яза:
«Өяз шәһәре. 35 мең кеше яши. Зур гына, матур гына. Иң башлап, безне коммунистлар клубына алып бардылар. Ул аклар белән качкан нindидер сәүдәгәр йортына урнашкан... Башкарма комитетның кечкенә генә утырышын үткәреп алдык...»
Икенче көнне шәһәрдәге интеллигенция белән очрашу-митинг үткәрелде. Монда Крупская совет властеның интеллигенциягә мөнәсәбәте, аны тәрбияләү һәм үстерү юнәлешендәге эшләр турында доклад сөйләде.
Кичкә табан «Красная звезда»ны тагын бер пароход куып җитте. Анда ике мең ярым кеше — кызылармеецлар иде. Алар яр буена чыгып сафларга тезелделәр. Шәһәр гарнизоны да килде. Сугышчыларга эшче отрядлары өстәлде. Бик зур митинг булды. «Красная звезда» агитаторлары һәм инструкторлары докладлар, речьләр сөйләде. Башкалар белән бергә, Глазунов та аларның һәркайсын йотылып тыңлады. Сүз яр буенда тезелешеп утырган солдатлар һәм эшчеләргә бик кадерле булган нәрсәләр — илдә тынычлык урнаштыру, сугыш җимергән хуҗалыкны аякка бастыру, совет властен ныгыту турында барды. Ораторларны хуплап, алкышлар яңгырады. Сугышчылар совет властен соңгы тамчы кангача якларга ант иттеләр. Эшчеләр үз төбәкләрендәге заводларда яхшы эшләргә сүз бирде. Монда һәр сүз, һәр хәрәкәт — барысы да совет власте белән хезмәт халкы арасында-

гы бердәмлекне раслый иде. Ораторлар тынуга, кызылармеецлар «Интернационал» җырлый башлады. Аларга эшчеләр, пристаньда торган пароходларның матрослары кушылды. Тын елга буенда «Интернационал» яңгырады.

Глазунов Надежда Константиновнаның йөзе көләчләнүен күрде. Меңләгән кешенең сугышчан җырына ул да кушылган, илһамланып җырлый. Онытылмаслык митинг. Ул Глазуновның хәтеренә гомергә уелып калды.

Пароход Чистайда торган чакта, Надежда Константиновнага Мәскәүдән хат килеп төште. Ильичтан. Ленинның ул чакта Крупскаяга ни язганын Глазунов күп еллар үткәч кенә белде. Аның бу хаты Ильичның китабында басылып чыкты. Аны укыган чакта, Николай Михайлович «Красная звезда» пароходының иркен салонын, шул салондагы кәнәфине һәм шуңа утырган килеш хат укучы Крупскаяны күз алдына китерде. Надежда Константиновнаның йөзендә арганлыкның эзе дә калмаган иде. Күзендә нур. Ә кәгазьдә мондый юллар:

«Кадерле Надюша! Крестинскийның Пермьга баруыннан файдаланып, сиңа хат язам. Бәлки, куып җитәр.

... Йөрәк авыртуың кабатланган икән, шуны белдем. Димәк, син чамасыз күп эшлисең. Кагыйдәләрне ныграк сакларга һәм врачны яхшырак тыңларга кирәк.

Югыйсә, кышка синең хезмәткә сәләтең бетәчәк! Моны онытма!

...Көнчыгыш фронтларда хәл бик әйбәт. Бүген Екатеринбургның алынуы турында белдем. Көньякта — борылыш бар, ләкин яхшы якка үзгәреш әлегә күренми. Булыр дип ышанабыз...»

Ильичның үзе кебек үк, Надежда Константиновна да чама белән генә эшли алмый иде шул. Глазунов аны бик яхшы аңлады. Иртәнге сәгатьләрдә Крупская пароходтан бик дәртләнеп чыгып китә. Көннең-көн буе учреждениеләрдә, культура учакларында йөри, митингларда чыгышлар ясый. Кичке сәгать тугызлар тирәсендә арып-алҗып кайта. Ләкин монда да ял итәргә мөмкин түгел — аны пароходта ничәмә-ничә кеше көтеп тора.

Җәйге төннәр кыска. Пароходта төнге уннарда-унберләрдә тынлык урнаша. Барысы да ял итә. Ә Надежда Константиновна каютасында ут яна. Кечкенә генә өстәлгә иелә төшеп, ул нидер яза, укый. Бәлки, көндәлекләренә көндезге тәэсирләрен терки торгандыр. Бөтен команда аның көндәлек язуын белә, кичләрен аңа комачауламаска тырыша. Тик матрослар арасында яшьләр дә бар. Алар, билгеле инде, төннәрне йолдыз санап үткәрәләр, таңнарны палубада каршылыйлар. Тын гына йөрсәләр бер хәл иде, юк бит, гармун сыздырып җибәрәләр, җырлыйлар. Төнге авазлар ерак-еракларга яңгырый. Глазуновның эчен пошырган нәрсә дә шул. Яшьләрнең уен-көлкесе Надежда Константиновнага комачаулаганын күреп тора. Дөрес, Крупскаяның бу хакта тел тибрәткәне юк. Ләкин аны төнге шау-шулардан коткарырга кирәк, дип уйлады Глазунов. Матрослар янына төште дә:

— Киңәшәсе бар, егетләр,— дип сүз башлады.— Надежда Константиновнаны ялдан мәхрүм итәбез бит болай...

Иртәгәсен тәрәзәгә күз салуга, Надежда Константиновна аптырап кала. Балкон ябык, каюта янынннан үтү юлына аркылы диван куелган. Крупская шул диванга карап тора да, каютасыннан чыгып палубада йөри. Күзенә Глазунов чагылгач, йомшак, ягымлы тавышы белән:

— Нинди баррикада корылган анда, иптәш Глазунов?—дип сорый.

— Яшь-җилкенчәк сезне борчымасын дип эшләдек, Надежда Константиновна.

— Кирәкмәс иде... Яшьләр күңел ачарга тиеш. Аларга киртәләр кормыйк.

Пароход Алабуга пристанендa да шактый озак тукталып торды. Аннан Тихая горага килде. Бу инде — революцион рухлы Бондюг заводы! «Красная звезда»ны каршыларга меңнән артык эшче чыккан. Кызыл байраклар җилфердәтеп, «Интернационал» җырлап каршы алдылар. Крупская үзе дә эшчеләр арасына күтәренке күңел белән, дәртләнеп чыкты. Барысы бергә Бондюг заводына бардылар. Митинглар үткәрелде. Надежда Константиновна алар турында күңеленә дә куанып язган:

«Коммунистик клуб каршында иҗтимагый мәсьәләләргә багышланган бик яхшы китаплар тупланган китапханә эшли. Театр-коммуна бар, анда төрле җыелышлар уздырыла. Техник курслар ачарга телиләр, монда андый курсларга ихтыяҗ зур. Укый-яза белмәүчеләр юк диярлек, грамотага өйрәтү мәктәпләре кирәк түгел. Укытучылар — коммунистлар һәм аларның карашларын яклаучылар. Бигрәк тә мөселманнардан ике коммунист — укытучы әйбәтләр.

... Хатын-кызлар митингысы үткәрдек, аңа яшь һәм күкрәк балалары белән килделәр, ике йөзләп кеше җыелды. Бондюг заводында эшләүчеләрнең яртысы — татарлар. Митингка килүчеләрнең дә күбесе татар хатын-кызлары иде. Мин сөйләгән речьне аларга тәрҗемә итеп тордылар...»

Һәр тукталышта шундый киеренке эш алып барды Надежда Константиновна. Халык алдында беренче булып ул чыга һәм, нинди генә авыр булмасын, хакыйкатьне сөйли иде.

Пароходта тагын Воскресенский, Александров кебек күренекле агитаторлар да бар иде. Аларның һәркайсы көненә дүртәр-бишәр очрашуда була, халык алдында чыгышлар ясый.

Николай Михайлович «Красная звезда» пароходындагы инструкторлар һәм җаваплы работникларның эше гаять катлаулы һәм тыгыз булуын хәтерли. Теге яки бу пристаньга килеп җитү белән, халык комиссариатлары вәкилләре төрле оешма, учреждениеләргә китә. Андагы эшләрне тикшереп, җитәкчеләрне пароходка чакыралар. Монда йомгаклау утырышы була.

Глазунов «Красная звезда» пароходында ай ярым булды. «Йөзмә ВЦИК» 1919 елның 11 августында Пермьгә килеп җитте. Ә өч көннән Надежда Константиновна пароход командасы белән хушлашты. Ул минутларны гомергә онытмады Глазунов. Крупская аның кулын кысып:

— Рәхмәт сезгә, иптәш Глазунов! — диде.

Николай Михайловичның күңеле тулды. Ул үзен иң якын кешесе белән хушлашкандай тойды.

— Хушыгыз, Надежда Константиновна!

* * *

Күп еллардан соң, инде пенсиягә чыккач, Николай Михайлович Глазунов шул ук маршрут буйлап тагын бер тапкыр узды. Шул ук «Красная звезда» пароходында. Бу чакта инде пароход музей ителгән иде. Аның таныш палубасына баскан килеш, Глазунов кадерле урыннарны — Идел һәм Кама буйларын, шунда үткән гомерен кабат күздән кичерде.

Күңелендә куанычлы хисләр яңарды. Бәхетле ул — елгачы Глазунов! Тикмәгә генә яшәмәде. Тормышта эзе, ил тарихында кечкенә генә булса да үз урыны бар. Утлы-давыллы еллар аша узганда фидакарь хезмәте белән салынган эз.

Дәрья суларында пароходларның эзе калмый.

Тормыш дәрьясында кешеләрнең эзе кала.

## Сибгат Хәким

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

●

Гаҗәпсенмәгез, тапсалар
Айда гамәл дәфтәре,
Чыккалый кунып бурычка
Анда Галләм яшьләре.

1978

●

Галәмдә йөзгән корабль
Карны ярып бара кук,
Корабльдәге космонавт
Карындагы бала кук.

1978

●

Текәлеп карап торганда
Рифма эзләп «йөрәк»кә,
Әнкәсе охшатты кызын
Мыскалдагы ефәккә.
Мин инде ачтым дигәндә
Сүзләрнең тирән серен,
Ул әйтеп салды яңадан
«Кунмаган балга чебен».

1979

●

Яшьлек, хезмәт, эштә тырышлык —
Бик күп нәрсә бизи ватанны,
Матур картлар бетте авылда
Кирәк сакал, горур, вәкарьле.

1978

●

Кайда җыр — кереп шул якка
Китәм онытылган кебек,
Җырлый егетләр авылда
Китап укыган кебек.

1978

●

Борчый, газаплый күңелне
Үтәлмәгән вәгъдәләр,
Шуңадыр туган якларда
Томанлы тәрәзәләр.

1979

●

Иске тегермән таллары
Таныр күк, абайлар күк;
Тегермән чираты көтеп
Утырган агайлар күк.

1979

●

Кулымда чәнчә бармакта
Эзе бар урагымның,
Бик ерактагы очы күк
Ул шигырь юлларының.
Кемлегем онытып җибәрсәм,
Карыйм шул чәнчәгә мин,
Хезмәттән, халыктан башка
Бу җирдә нәрсәгә мин.

1979

## Акбай

Зират коймасы буенда
Тау-тау тимер-томырлар,
Шоферлар артык-пыртыкның
Барын шунда тондырган.
Кайберсе эшкә ярарлык
Төзәткәләп бакканда;
Шунда иске мичкәләр дә,
Шунда иске баклар да.
Дөньясы муен тиентен
Тимергә баткан кебек,
Ә Акбай? Кышкы тын кояш
Карый күк бактан көлеп.
Ә балалары? Аларның
Җырлары җырланмаган,
Әйтерсең тормыш шул баклар
Эчендә йомарланган.

Ап-аклар, йодрык-йодрык кар,
Йомшак кар, юеш карлар,
Туктаусыз бураннар уйный,
Бураннан елышканнар.
Агыла моң Акбай күзеннән,
Тилмергән карашыннан,
Танавы гына елтырый
Тимерләр арасыннан.

1979

●

Елтыр-елтыр утлар яна,
Бездә түгел, конторда.
Безнең күңел зурда түгел,
Бер кечкенә матурда.

Халык җыры.

Ялгыз кабер. Кабере аның үрдә.
Үрне төшкәч, чеби болыны,
Иксез-чиксез оркестрга охшап,
Үз-үзеннән чыңлый болыны.
Чебиләрен очратмадым никтер,
Бала чакта җыйдым кузгалак.
Хәзер дә мин ялга кайткан саен
Шул тирәдән йөрим узгалап.
Кай яклардан килеп чыккандыр ул,
Контордагы кызны яраткан.
Яратканы өчен нигә әле
Кабре аның читтә зираттан?
Үзенә кул салган, мордар[1] киткән,
Азмы җирдә корбан-мордарлар,
Хыянәтне беркайчан да гафу
Итми торган кырыс моңнар бар.
Хыянәткә протест кебек ята,
Миңа шуннан матур урын юк;
Кәтүчеләр шунда, шәфәкъ шунда,
Мәңгелек ут төсле горурлык.

1979

●

Гаҗәп сәер төшләр керә кайчак,
Авылым кыры, авылым зираты,
Зират яны, кырда бодай утыра,
Иренеп кар ява, җир каты.
Бодай кыры. Әнкәй каберенә
Бик күп булса шуннан ун адым,
Үпкә белән авылдашларына,
Алып әнкәй әлгән урагын,
Зәһәрләнеп урып китәр төсле...
Бөтен якны каплап, ягалап,
Ак кар ява, зират коймасына
Ябалак кар ява, ябалак.

1978

[1] Мордар киткән — дин-шәригать законнары буенча үлмәгән кеше. Динсез киткән, шуна зиратка күммәгәннәр. С. Х.

•

Урман, төпләр, төп өстендә Казан,
Әйтерсең лә гудрон Казаны,
Солдатка аш пешә, бераз читтә
Үз Казаным, гомрем Казаны.
Ике иңдә ике калын такта,
Ак такталар — ап-ак канатлар
Басып иңне, җиргә салынып төшкән,
Урман, төпләр, солдат, бараклар.
Урман шәрә, язмышым дә шәрә,
Килдем үтеп мин күп җирләрне,
Фронт — ерак, бер кырыйга посып,
Карый күзгә тик мүк җиләге.
Карый күзгә сугыш ятиме күк,
Казан белән Йошкар-Оланың
Уртасында солдатларым белән
Таптыйм көн дә яшь кар аланын.
Һич каргамыйм авыр язмышымны,
Миңа барыбер якын шушы җир,
Көзге урман һәм наратлар шавы,
Мүк җиләге үскән Суслонгер.

1978

## Рәшидә сукмагы

Кочаклап алырдай булам
Берьюлы яшел ямен,
Бар безнең авылда үзенең
Сукмагы Рәшидәнең.
Сукмак һәм инеш... Икесе
Ике ахирәт кебек,
Рәшидә инештә үскән
Озын ак тирәк кебек.
Эзеннән, артыннан аның
Язгы су, карлы суда
Шушы сукмак буйлап килгән
Сугышның кайгысы да.
Кадерле, якты хисләрен
Батист яулыкка төйнәп,
Юеш, тын инеш читеннән
Фермага атлый тирәк.
Өй белән ферма арасы...
Узмаган зря гомер,
Ул тоя: шушы сукмакта
Җылысы йөрәгенең.

24 январь, 1979

# ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА




## Кадыйр Сибгатуллин

•

Кешеләрнең барын танып йөрим,
таянганым бары — ышаныч.
Вакыты белән мин алар көк горур,
вакыты белән мин дә кызганыч.

Бер эшкә дә кайчак кулым җитми,
бар эштә дә ләкин хакым бар.
Башкалар кук мин дә я гаепле,
башкалар кук мин дә хөкемдар.

Күрми диеп кайчак уйлыйлардыр,
кызганычка каршы, күрәм мин.
Һәрбер туган белән туа торам,
Һәрбер үлгән белән үләм мин.

Шуңа күрә мин бер бәхетледер,
үтмәгәнгә гомер әрнелеп.
Шуңа күрә, бөтен кеше кебек,
бу тормышта мин дә мәңгелек.

### Мәчет мәйданы

Үткән заман төсе.
Карт һәм иске.
Түбәсендә кыйшык манара.
Хәтеренә сеңгән
бу авылда
булып үткән барлык манзара.

Тутык Айлы башын кырын салып,
түбән карый,
гүя үткәнгә.
Үткәннәрдә бар язмышы,
хәзер
кирәк түгел Җиргә, Күкләргә...

Бер карасаң изге җир бу мәйдан.
Бер карасаң олы гөнаһлы.
Заманалар узган гауга салып —
мәчет манарасы гуаһы.

...Кичке шәфәкъ яна.
Яна офык.
Яна бер йорт мәчет каршында.
Ялкын белән тарткалашып яна
кызыл байрак түбә башында.
Әллә янгын,
әллә байрак балкый,
әллә шәфәкъ,
әллә ил каны...
Совет йорты яна,
ялкынына
чумып ята мәчет мәйданы.

Китерәләр сөйрәп мәйдан аша...
Уттан чыгып исән калганнар.
Икенче кат үләр өчен баса
Заһид, Салих, Нури, Солтаннар...
Кан төсендә һава.
Сөрем.
Төтен...
Кояш яңа баеган чак була.
Стенага терәп ата аклар,
михраб ягы,
кыйбла як була.
Өч большевик кала чират көтеп:
Шириаздан, Касыйм, Габдулла.
Соңгы залп яңгырар мизгелендә
килеп җитә йөгереп карт мулла.
«Әфәнделәр!
Мәчет...
Кыйбла ягы...
Туктатыгыз тәңре хакына!»

Мәчетен яклап басып торган мулла
өч большевик белән атыла.

Күкрәкләрне тишкән шул ук ядрә
тишеп үткән мәчет тактасын.
Большевиклар — дошман,
ә мулланы,
ә мәчетне нигә аткан соң?!

Кыйбласына аткан,
мулласына...
Шушы мәйдан яхшы белә аны.
Алласын да атар,
анасын да,
вәхшиләрнең шундый иманы!

Мәчет мәйданында мәрмәр һәйкәл.
Башын ияр һәрбер замана.
Айлы башын кырын салып тора
уйлы, моңлы иске манара...

## Бер эздән

Бер эз салып үтте кыр казлары.
Тыным бетте алар үткәндә:
бердәм булсаң,
бер эз буйлап кына
йөреп буладыр күк күктә дә.
Таралсалар юлда
мин гаепле,
ник санадым икән, ник баздым?!
Егерме каз үтте,
камылларда
күләгәсе калды бер казның...

Чаңгычылар ерак юлга чыкты.
Күз күреме — офык.
Ак дала.
Чаңгылардан кала бары бер эз,
сулышлардан җылы пар кала.
Сызгыра кар офык сызыгында,
китә офыклардан авышып.
Зур походта чаңгычылар байтак,
тик бер генә чаңгы тавышы.
Чыгып бергә, офыгыңа бергә
барып җиту кирәк,
бик кирәк.
Чаңгы юлы буйлап ишетелә:
ак далада тибә бер йөрәк.

Аякларын аерып баскан ирләр.
Чалгычының эзе бер генә.
Язылмаган,
ләкин тиеш түгел
бер сөям дә читкә керергә.
Селтәнәсең бергә.
Кистер бергә.
Аерым-аерым арма, талма да.
Учка төкер бергә.
Җана бергә.

Узарга да базма,
калма да.
Чаңгычылар ничә дистә булыр,
болыннарның бигрәк киң чагы.
Күзне йомып тыңлыйм:
бар болынны
яңгырата бары бер чалгы.

Чаңгычылар,
чалгычылар кебек
бер була ала Җирдә мең кеше.
Шуны көтеп буыннарга күчә
дөньяларның мең дә бер эше.
Кыр казлары кеше көнләшерлек.
Чылбыр-чылбыр итеп кем тезгән?

...Төшләремә керә кайчакларда:
бара, имеш, дөнья бер эздән.

## Роза Халиуллина

### Бәби мунчасы

Әби бәбине
Иллә чаба соң.
Сөембикәсе
Ник бер еласын!

Елатмый әбкәй,
Белә йоласын.
Каен себеркең,
Мунчаң чыдасын:

«Аю баласы,
Бүре баласы,
Йөрәк парәсе,
Күзем карасы...

Ата баласы,
Ана баласы,
Аю баласы.
Бүре баласы.
Ары барасы,
Бире барасы.
Барысын күреп
Бире каласы.

Идел илемнең
Илле баласы,
Илле ананың
Илле ярасы.

Дошманнар илгә
Коткы салмасын,
Бүре баласын
Утка салмасын.

Аю баласы,
Бүре баласы.
Кара мунчамның
Күркәм баласы.

Кендеген кистем,—
Җирдә каласын.
Кендек тамырын
Җирдән алгансың.

Аю баласы,
Бүре баласы,
Үсәр монысы,
Туар яңасы».

Әбкәй бәбкәен
Әмма чаба соң.
Бәби еламый
Күргәч чарасын.

«Нигә еласын
Аю баласы...
Нигә әрнесен
Бүре баласы —
Төзәлгән инде
Кендек ярасы.

Сөяр атасы,
Сөяр анасы.
Шушылай кайнар
Сөяр җанашы.

Аю баласы,
Бүре баласы,
Сине матурлар
Кыйбла тарафы.

Ары барасы,
Бире барасы.
Мондый асылны
Кайдан табасы?

Кара мунчамның
Якты баласы,
Кардәшләремә
Ихлас карасын.

Аю баласы,
Бүре баласы,
Ай шуны бирәр
Күреп каласы...

Аю баласы,
Бүре баласы,
Үсеп җиткәнче
Йоклап аласы.

Башыңа көмеш
Кыршау саласы.
Көмеш акыллар
Йөретсен башы.

Аю баласы,
Бүре баласы,
Белсен йоланың
Канда каласын.

Толымы булсын
Сакчы еландай.
Алга омтылсын
Яхшы боландай.

Буй-сыны булсын
Ак каен сыман,
Күктәге яшь ай —
Кашкае сыман.

Билләре талдай
Сыгылып торсын.
Хәләле ул дип
Өзелеп торсын.

Күзләре — ике
Йолдыз — нур сипсен.
Карашы илне
Тоташ нур итсен.

Аю урманы,
Бүре урманы,
Кызлы булганым,
Уллы булганым».

Мунча кертүче
Гайшә-Фатыйма
Мөнәҗәт әйтә
Йола хакына.

Аю баласы —
Бәби хакына —
Ыру башлыгы
Бүре хакына.

... Яшәр халыкта
Фатыймаларның
Илләргә биргән
Фатыйхалары.

# ШАМИЛ РӘКЫЙПОВКА 50 ЯШЬ



*Соңгы елларда документаль жанрның активлашып, нык әдәбиләшеп китүе татар әдәбиятын тагын да үстерә, камилләштерә баручы күпләгән күркәм күренешләрнең берсе. Һәм, әйтергә кирәк, шактый нык күзгә ташланганы булды. Соңгы ун-унбиш елда бу жанр элеккеге публицистик һәм очерк халәтеннән чыгып, әдәби-сәнгатьчәлеккә табан зур адым ясады, әдәбиятыбызда мөстәкыйль бер тармак булып формалашты. Хәзер инде бездә документаль жанрны үзенең иҗади тормыш юлдашы, хәтта иҗади язмышы буларак кабул иткән аерым язучылар бар. Шуларның берсе — язучы Шамил Рәкыйпов.*

*Иҗатын нәни хикәяләр һәм кечкенә күләмле сәхнә әсәрләре белән башлаган автор үзенең 50 яшьлек бәйрәменә әдәбият сөючеләр арасында киң танылган, хәрби темага язылган документаль повестьлар белән килде. Әдипнең «Чәчәкләр сөйли бела», «Таңнар һаман матурмы?», «Кайдан син, Жан?», «Кызлар-йолдызлар» һәм «Кипарислар җыры» дигән повестьлары, бер яктан Бөек Ватан сугышы геройларының әле без белеп бетермәгән батырлык сәхифәләрен ачып күрсәтүче әсәрләр булсалар, икенче яктан алар татар әдәбиятындагы документаль жанрның әдәби-сәнгати мөмкинлекләрен киң ачып күрсәттеләр. Бу повестьлар Ш. Рәкыйповның сәләтле әдип, ватандарлыкны, илгә, халыкка бирелгәнлекне, бөекләрнең бөек эшләренә һәм көрәшләренә соклану хисләрен җырлаучы әдип булып җитешүен раславылар. Югарыда санап кителгән повестьларның барысы да диярлек рус теленә тәрҗемә ителеп, кайберләренең йөзәр меңле тираж белән басылуы, авторның берничә күләмле әсәре чуваш һәм белорус телләрендә дә дөнья күрүе әнә шул турыда сөйли.*

*Ш. Рәкыйпов, соңгы елларда документаль повестьлар язу белән бергә, халкыбызның әлегә киң билгеле булмаган батырларын барлау, популярлаштыру, алар турында яңадан-яңа мәгълүматлар табып, кыска-кыска нәсерләр, публицистик мәкаләләр һәм очерклар рәвешендә укучыга җиткерү өлкәсендә дә актив эш башкарды. «Казан утлары» журналында, коллектив һәм аерым җыентыкларда урын алган бу мәкаләләр һәм очерклар Ш. Рәкыйповның киләчәктә язылачак зур күләмле повестьларының нигезедер, яңа зур әсәрләргә разведка ясавыдыр кебек.*

*Авторның иҗат эше аның җәмәгать эше белән тыгыз бәйләнгән. Ул Совет Армиясендә хезмәт итүчеләр белән даими элемтәдә тора, алар белән языша, алар ал-*

*дында язучы буларак чыгышлар ясый. Ш. Рәкыйпов Татарстан Язучылар союзы идарәсе каршында оештырылган хәрби-патриотик комиссиянең председателе.*

*Бу айда язучы Шамил Рәкыйповка 50 яшь тула. Без аны Татарстан Язучылар союзы идарәсе, «Казан утлары» журналы редколлегиясе һәм мәңләгән укучылар исеменнән кайнар котлыйбыз. Язучы үз юбилеена яңа әсәр белән килә. Журналыбызның бу санында укучыга әдипнең шул әсәрен тәкъдим итәбез.*

## Шамил Рәкыйпов

# КАЙДАН СИН, ЖАН?

Пролог урынына



Күршеләрдән алып кайткан ахактай күмерләр белән учак тергезеп җибәргән Ирина Лукинична чандыр гәүдәле, җиткән сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле улы Ваняның аркасыннан сөйде:

— Их, Иванушка, безнең яклардагы гореф-гадәтләр! Кияү каршылау, килен төшерүләр үзләре генә дә ни тора!

Өстенә кат-кат күлмәк кигән, башына очлары чучка колакларыдай тырпаеп торган, төсе уңган керле яулык бәйләгән Глафира карчык, почмакта борын сызгыртудан кисәк туктап, артыш таягын идәнгә төя-төя:

— Сөйләмәсәнә юкны! — диде.— Нигә алар бу йолкышка? Ходай сүзен сендер син аның калебенә, ходай сүзен!

— Юк, иң әүвәл үз халкы турында хәбәре булырга тиеш аның. Үз халкын тирәнтен олылаган адәм үлемне җиңә!

— Җиңә пычагым!..— диде Глафира, иреннәрен мыскыллы бүлтәйтеп.— Үлемне җиңгән бәндә юк. Булмас та!..— Артыш таяк кабат идәнне төйде, керфексез чепи күзләрдә карчыганыкыдай зәһәр усаллык чагылды.

Ваня, гаҗәпләнеп, әле әнисенә, әле үзен күзәтеп торган карчыкка карады. Ана гадәттәгечә мөлаем, ә артыш таяк хуҗасы баз бакасыдай салкын, шөкәтсез иде. Малай әнкәсенә сыенды. Бу хәл Ирина Лукиничнаны бер мизгел эчендә әллә нишләтте: чакма ташыдай нык, бөркеттәй мәгърур иде ул хәзер. Үз тормышының дәвамы булган әнә нинди багалмасы бар бит аның. Ул корымасын, татлы җимеш бирсен өчен тамырларның туган туфракка тирәнгә җибәрелүе шарт. Димәк, Ваня ыру-нәселе, ватандашлары турында бөтен нечкәлегенә кадәр белергә тиеш.

Ирина Лукинична улын үз янына, учак каршысына утыртты.

— Менә берзаман үсәрсең...— Ирина Лукинична, «өйләнерсең» дияргә базмады. Ләкин, фикер җебен өзәргә теләмәде, яшь чакларын исенә төшереп, татлы хисләргә бирелде: — Әйе, берзаман өйдә би-ик тәмле ипи пешерербез. Җиде басуда үскән бодайның оны, җиде

---

Шул исемдәге повестьның икенче кисәге.

чишмәдән алынган су, ун сыерның мае һәм йөз илле күкәй салынган булыр ул ипекәйнең камырына. Камыр өлгергәнче үк мичне кабызып җибәрербез...

— Бүгенге кебекме?

— Тагын да әйбәтрәк иттереп, Ванюша. Утыннар менә шулай күңелле итеп янарлар. Мич кызган арада каты камырдан әвәләп зур ипи өстенә ат, кош сурәтләре ясарбыз, кырыена яшь килен толымы кебек үрелгән камыр ябыштырырбыз. Ә уртага куяр өчен, нәсел агачына ишарәләнгән, һәркайсы икешәр-өчәр тармаклы, кабыгы суелган чыбыклар хәзерләрбез. Ул чыбыкларны юка камыр тасмалар белән чолгап пешерербез. Мичтәге утын янып бетүгә, хуш исле нарат ылыслары белән ахактай күмерләрне себереп өярбез дә, ипине мичкә тыгарбыз. Өсте кызарып пешкән, кәгазь чәчәкләр белән чолгап алынган искиткеч тәмле, хуш исле ипине түргә чыгарып куярбыз да, өстенә нәсел агачы тармакларын кадарбыз. Һәр тармак — бай нәселнең уллары, кызлары икәнлеккә ишарә булыр. Кияү белән киленне ипи тирәсеннән җыр җырлап әйләндереп йөртерләр... Юк, гади икмәк кенә булмас ул, балам, бу түгәрәк ипи — туендыручыбыз җир-ана үзе, тагын да түгәрәкләнә төшкән бәхет, тормышның дәвам итүе булыр...

Ваня әнисенә сыенган килеш тора бирде. Үзен уенга чакырырга килеп, инде әллә ни гомер тәрәзә катында торган Сары сандугач кушаматлы, озын сыйраклы Яшканың ымлауларын да күрмәде.

Йөзе алсуланган Ирина Лукинична хикәятен дәвам иттерде.

— Ә моңа чаклы, Иванушка, кәләш өендә нинди ыгы-зыгы кубуын күрсәң! Ахирәтләре кәләшне киендерәләр, бизәндерәләр, чәчләренә ямь-яшел нәни тармаклар тезәләр... Урамда туйчылар күренә. Кияү өр-яңа, чем-кара костюм кигән, аның артында — иңнәренә аркылы-торкылы сөлгеләр бәйләгән боярлар, ягъни кияү егетләре. Аларны киленнең ата-анасы каршы ала. Ул үзе киявенең чигүле сөлгесен чишә. Шул чак, Иванушка, күктән гәрәбә явамыни,— кияү һәм кәләшне уч-уч алтын бөртекләр белән коендыралар...

— Ә ипи, ипи нишли, әни? — диде Ваня иренен ялмаштырып.

— Никахлашып балдаклар алмашып кайткач, өстәлдәге ипигә чират җитә. Беренче телем — кияү белән кызның ата-анасына. Кунаклар җыр башлый. Аннары кәләшнең ахирәтләре:

> — Хорошо тебе, калина,
> В лесу оставаться,
> Как же мне несладко
> С мамой расставаться!

— дип моңлы көй суза.

Боярлар ыгы-зыгы кила, стенадагы картиналарны, караваттан чук чәчәкле җәймәне алалар, яман да чинатып, дуңгыз баласы күтәреп керәләр — яңа җирдә, Иванушка, тормыш өчен һәммәсе кирәк. Өсбашына каурый ябышкан егет, чырылдата-чырылдата, чуар тавык тотып керә. Тавыкны каккалыйлар, чәчәкләр, мәрҗән-төймәләр белән бизиләр. Чөнки иң зур бирнә — шул.

«Чегәннәр» — туй шамакайлары бии, шаяра. Хатын-кыз ирләр киеме кигән, эшләпәләрдә күркә каурыйлары тырпаеп тора, бит-баш корымга буялган, аяктагы калошлар алды артка киелгән. Мыеклар чүбектән, сакаллар мунчаладан. Егетләр эре чәчәк бизәкле чаршауларны юбка иткәннәр, кулларына себерке һәм кулъяулыклар, битләренә корым һәм дә кершән якканнар, ирennәрен кып-кызыл иттереп буяганнар. Җиз тәлинкә, таба каккан тавышларга, гармун чыңлавына зерә дә дәртләнеп, «чегәннәр» кулга-кул тотына, шамакайлануның

соң дәрәҗәсенә житеп үрле-кырлы сикерenә, парлап бии, әйләнә, бөтерелә, чүгә... Түләүле тамашаларыгыз, клоун-молауннарыгыз бер якта торсын!..

Әнисенең бу сүзләреннән Ваня рәхәтләнеп көлде. Учакта дөрләп янган утка карап уйга чумды. Нинди соң ул Белоруссия? Нигә әнисе ул якларны һаман оныта алмый? Иванга калгәндә, аңа Казанда да начар түгел. Киресенчә, әйбәтрәк тә әле. Коеныйм дисәң, суы бар, кызыныйм дисәң, комы бар. Дөрес, урманда җиләк, чикләвек яклары гына такыррак. Бу тирәләрдә халык күп яши — тиз җыеп бетерәләр. Шәһәр шәһәр шул инде. Әмма шәһәрнең ниндие! Ленин үзе укыган шәһәр. Быел менә класс җитәкчесе Николай Филиппович аларны университетка алып барды. Володя Ульянов утырган партаны күрсәтте. Сходка башланып киткән залга алып керде.

Җае чыгып Белоруссиягә кунакка кайта алса, андагы малайларга сөйләр нәрсә күп хәзер. Авызларын ачып, тын да алмыйча тыңларлар иде.

Тик кайчан җитәр ул көннәр?

Иван Кабушкинга Белоруссиягә бөтенләй бүтән шартларда кайту насыйп булган икән шул...

## Үткәннәрдән сәхифәләр

...Партизан отрядына «Зур җир»дән самолет килеп китүен ишеткәч, Кабушкин гадәтенчә үзенә хат бирүләрен көтсә дә, өмете акланмады. Күңеле кителде, моңсулык басты аны. Һәр чәчәк, һәр яфрак, һәр агач, ниһаять, куе урманның үзе дә ямьле Идел буйларын хәтерләтә иде. Уйга чумган килеш, урман сукмагыннан атлады да атлады ул. Бер ел гына гомер үткән икән әле. Юк, аерым яшәүләрне гомер чутына кертергә ярамыйдыр аны.

...Кабушкин Казанда озак кунак булмады. Ялы бетәргә шактый иде әле, хәрби комиссар җибәргән чакыру кәгазе килде.

Иван сизенде: Тамараның әтисе чакыра. Зур гәүдәле, салмак хәрәкәтле, үткен карашлы, киң күкрәгендә ике ордены балкып торган хәрби җитәкче иде ул.

Повестканы күрүгә Кабушкинны нинди дер сәер тойгы биләде. Чак кына курку идеме ул, янсә гаҗәпләнүме — аеруы кыен. Ни дип чакыра икән соң аны хәрби комиссар? Тамарага булган мәхәббәтне сизенде мәллә? Дөрес, куркырлык һични юк шикелле: Иванның мәхәббәте саф, кайнар һәм, шулай әйтергә яраса, мәңгелек иде. Ул әле азрак кына хыялый да түгел микән?!

Ихтимал, хәрби комиссар, ата буларак, кызы сайлаган егетне якыннан күреп-белеп, Тамараны һәртөрле күңелсезлекләрдән саклап калырга телидер? Билгеле инде, теләсә: син, солдат, дары исен җитәрлек иснәсәң дә, минем кызыма тиң түгел, дип кистереп әйтә ала ул. Тамара әле бик яшь, акылга утырмаган, дип әйтүе дә мөмкин.

Хәрби комиссар Кабушкин белән озак сөйләште: Ахырда ул:

— Тамара миңа синең хакта һәммәсен сөйләде, Иван,— диде.— Күрәм, син башлы егет. Сиңа укырга китәргә тәкъдим итәм. Солдат тормышын беләсең. Бер ел дигәндә лейтенант булырсың. Я, килешмәсме?

Бу боерык төсендә яңгырады диярга мөмкин иде. Әмма хәрби комиссарның соңгы сүзләрендә гаҗәеп мөлаемлек, аталарча кайгыртучанлык булып, аның ачык зәңгәр күзләрендә бернинди рыя юк иде.

Хәрби комиссар саубуллашканда Иванның кулын нык итеп кысты:

— Я, укыганда уңышлар телим.

Кыска сроклы хәрби мәктәпне тәмамлаган Кабушкинга интендант хезмәтләре лейтенанты дигән исем бирделәр һәм ул, ике атналык ялдан соң, Минск хәрби округы чик буе гаскәрләре сафында хезмәт итәргә тиеш иде.

Ваня укуын тәмамлавын буласы каенатасына әйтергә һәм Тамараны үзенә хатынлыкка сорарга дип Казанга кайтты. Кызганычка каршы, комиссар белән очрашырга туры килмәде — полковник Петровның үзен дә укырга җибәргәннәр иде. Туйга барыбер кайтты ул. (Туйны, Ирина Лукинична теләгәнчә, Казанда башлап, Белоруссиядә төгәлләргә ниятләделәр). Кияве белән кызын комиссар ихлас күңелдән тәбрик итте, бәхет теләде. Тамараның медицина институтындагы имтиханнарны бер елга кичектереп, Иван хезмәт итәргә тиеш заставага хәзер үк ияреп китәчәген генә ошатып җиткермәде ата.

Сагынуларга күп түзгән Тамара киявеннән бер генә сәгатькә дә аерылырга теләмәде. Киленне каенана яклады. Күп тә үтмәде, алар өчәүләп Белоруссиягә китеп бардылар. Ваня хезмәт итәргә тиешле хәрби часть Ирина Лукиничнаның туган авылы Малаховцы белән янәшәдә генә булып чыкты. Монда Ваня элеккеге танышларыннан майор Кадермәтовны очратты. Майор Казанда чакта үзе янына каткат кереп карантинда яткан Ваня белән күрешү даулаган Тамараны (хәрби комиссар кызы бит!) онытмаган икән. Көлә-көлә үткәннәрне искә төшерделәр.

Ирина Лукинична, туй мәшәкатьләре белән авылга, туганнары янына китте. Тынгысыз армия тормышы башланды. Аннары... сугыш, Тамараны озату һәм — әсирлек... Саташулы куркыныч төш кенә булгандыр ул. Урмандагы бу сихри иртә дә бәлки төш кенәдер. Моннан нәкъ бер ел элек, аякларны көчкә-көчкә сөйрәп, үзе кебек әсирләр сафында тузанлы юлдан Минскига таба атлаганда мондый матур сандугачлы иртәләрне күрермен дип һич тә уйламаган иде ул.

Тамара, Тамара, күңелем кошы, кара күзле чибәрем, кара карлыгачым, кайда икән хәзер син? Онытмадыңмы Ваняңны, син дә шулай өзелеп сагынасыңмы?..

— Сәлам, якташ!

Кабушкинның уйлары кинәт бүленде. Аның каршында карсак гәүдәле, җилдә, кояшта йөреп каралган, тирән җәрәхәт эзе калган киң битле, азрак кына чепи күзле, чем кара мыеклы, егерме сигезутыз яшьләр чамасындагы бер партизан басып тора иде. «Юк, таныш кешегә охшамый бу! — дип уйлады Кабушкин.— Аннары, нигә үзеңне кем җитте шуңа танытып йөртергә? Хәерлегә булмый ул. Сүзләрең көмеш булса да, эндәшмәвең алтын булсын дип, бик белеп әйткәннәр! Бу кеше урманга яңа гына килгән бугай».

Мыек хәйләкәр төстә елмайды һәм Кабушкинның уйларын сизгән шикелле:

— Отрядка кичә генә килеп җиттем әле. Күршедәге урманнан. Озакламый кайтып китәм,— диде.

— Миңа димәгәе, хет бүген китегез. Чит кешеләрнең китү-кайтуында абсолютно эшем юк,— дип, Кабушкин ризасызлык белдерде. Аның зәңгәр күзләре кысыла төштеләр, озын көчле куллары, малай чактагыча үрелеп, нарат ботагын әләктереп алдылар. Ботак зур, таза гәүдәне күтәрә алмады, сынды.

— Без чит кешеләр түгел, Жан. Тамара яратып шулай дип атый иде бит сезне. Хәер, Тамарага чаклы ук шулай эндәшүчеләр бар иде инде. Бала чак дустыгыз Харис, мәсәлән. Аннары, дивизиягезд дә...

— Минем дивизия — партизан отряды, иптәш...

— Вафин,— дип кулын сузды Мыек һәм ярым шелтәле төстә дәвам итте:

— Йомшак хәтерле булырга ярамый, иптәш лейтенант. Иптәш военком кияве!

«Вафин... Вафин... Гумерка Вафин ич бу! — дип, Кабушкин чак-чак кычкырып җибәрмәде.— Тик моның бите... Провокатор түгелме бу? Сайрасын әле, сайрасын...»

Ниһаять, аңлаштылар.

— Чигенә башлагач, үзебезнең Казан егетләреннән кемне дә булса очратмадыгызмы соң? — дип сорады Вафин, уйчанланып калган Кабушкинның үзенә әүвәлгечә битараф каравына үпкә белдергән сыман. Үзең бала чак дусты, үзең хәл дә сорамыйсың дип, рәнҗеп карыйлар иде аның күзләре.

— Яков Лысинны очраттым,— диде Кабушкин.— Дөресен әйткәндә, аз гына да куандырмады ул мине. Искә аласы да килми хәтта... Ә барыбер һәммәсе истә.

— Вәт бу очрашу! — диде Яшка ул чакта.— Болай очрашырбыз дип һич исәпләмәгән идем.

— Сугыш шартларында... яманрагы да булуы мөмкин,— диде Кабушкин.

Алар янәшә атлап киттеләр. Аяк астында чыбык-чабак сына, урыны-урыны белән су лычкылдый.

— Сине интендант хезмәтендә дигәннәр иде,— диде Яшка,— кесәсеннән папирос ала-ала.— Кайда машиналарың? Нишләп асфальттан гына выжлатмадың?

— Машиналарның кайберләрен яндырып калдырдык, кайберләрен тылга озаттык.

— Тамара китеп өлгердеме?

— Өлгерде.

Алда «Кызыл хач» сурәте төшерелгән машина күренде. Аның ачык ишеге янына талчыккан йөзле яшь кенә шәфкать туташы баскан иде. Ул:

— Яралы кызылармеец иптәшләр, ике кешегә урын бар, рәхим итегез,— диде.

Яков көтмәгәндә аксаклый башлады, каты әрнүгә түзгәндәй аскы иренен тешләп, Иванның беләгенә тотынды.

— Мин — яралы, ә син мине озата баручы. Киттек, Кабушкин!..

— Син нәрсә?! Әле генә...— Иван сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, агач башларына тияр-тимәс зәһәр тырылдап дошман самолеты очып узды. Ике-өч җирдә бомба шартлады. Утлы төтен, тузан чүмәләләре күккә томырылды.

— Ложись!..

Элеккегесеннән дә хәтәррәк тавышлар чыгарып, икенче самолет үлем чәчеп узды. Ул ташлап киткән бомбаларның берсе «Кызыл хач»-лы машинага эләгеп, аның урынында пыскып яткан түгәрәк чокыр гына калдырды.

— Димәк, гомер бетмәгән безнең! — диде Яков.— Озак яшәячәкбез.

Кабушкин эндәшмәде.

Чигенүне дәвам иттеләр. Яков сөйләнә-сөйләнә барды:

— Карале, Ваня, һаман үлем турында гына уйларга кирәкмидер. Тормышның һәр ботагына ябыш. Һәр тармакка тешләрең белән...— Ул нәрсәнедер исенә төшереп булса кирәк, беразга тынып калды, аннары мөлаем тавыш белән: — Туенда җиде басуда үскән бодай онынннан, җиде чишмәнең суыннан ипи пешерә алмавыгыз дөресме? — дип сорады.

— Дөрес,— диде Иван.— Туйны әни теләгәнчә, туган авылыбызда үткәрергә теләгән идек тә, сугыш комачаулады.

— Димәк, белорус туй йолаларын өйрәнүдән бер тиенлек тә мәгънә чыкмады. Шулай буласын Казанда чакта ук әйткән идем мин

сиңа.— Яков өметсез төстә кул селтәде,— юллар Парижга түгел, кабергә илтергә мөмкин.

Кабушкин усал итеп Яковка карады.

— Парижга җиткәнче шушы белорус җирләрен узасың бар әле.

— Узып барабыз инде. Ә бәлки шунда тукталыргадыр? Ниһаять, белорусча туй ясый алыр идек.

— Моның белән нәрсә әйтергә телисең син, Яков?

— Бу мәхшәрдә телгә ни килмәс... Кара син тирә-ягыңа: күк күкрәвен хәтерләтеп артиллерия ата, бомба шартлый, үкереп самолетлар оча, танклар ыжгырып өскә килә... Ни белән бетәр болар барысы, ә?

— Ни белән бетәсе билгеле: һәр вакыттагыча котырып килә-килә дә, авыз-борынын җимереп, чалбарын ташлап качып китә. Һаман шулай булган, тагын шулай булыр.

— Бу юлы ул, энекәем, техниканың кәттәсенә утырып килә. Чалбарын ташлап йөгермәс. Гитлер яшен тизлегендә җиңәм, ди бит.

Моннан дүрт-биш ел элек трампарктагы бер сөйләшү кылт итеп Ваняның исенә төште:

— Алаймы? Чебеннән фил ясамадыммы?

— Аңламыйм...

— Аңлыйсың. Мин электроцехта эшләгәндә газета укыгач... Гитлер шантрапа, буш куык кына, фәлән-фәсмәтән, дигән идең.

— Явыз хәтерле син, Кабушкин.— Ул флягасыннан спирт салып эчте, аннары Ваняга агызды.

— Юк, аек хәтерле. Моны борыныңа киртләп куй! — диде Кабушкин.— Кайда синең мылтыгың?

— Нигә ул? Менә пистолет табып алдым. Штабчы ич мин...

Спирт белән тамак чылаткач кәефе күтәрелеп киткән Яшка, иннәренә корал, сугыш кирәк-яраклары күтәреп баручы талчыккан сугышчыларга игътибар итеп тормастан, үткән көннәрен искә төшерә башлады.

— Бар иде яшь чаклар. Харис әйтмешли, кесә тулы борчаклар... Ничаклы кыз кул астында иде. Ә бит мин, Ваня, Светлананы барыбер эләктердем. Тамараң кайткач, ул тәмам җебеде. Иләс-миләс йөрде-йөрде дә... Эчкәли башлады. Эчкәч хатын-кыз үз-үзенә хуҗа була аламени? Тәне шәп иде шайтанның. Ап-ак... тутырган тавык кебек... Мин инде син аны авыз иткәнсең дип уйлаган идем.

— Син исерекме, әллә акылдан яздыңмы, Яшка?

— Менә син ул... ул чакта да җиләк кебек кызны интектереп... Света миңа барысын сөйләде...

— Житте, старшина! Әгәр хәзер үк гәйбәт савытыңны япмасаң...— Кабушкин пистолетына үрелде.

— Бетте, бетте...— дип, Яшка чигенүче сугышчылар арасына кереп шылды.

Язмыш аларны әсирләр лагеренда очраштырды.

Анысы болай булды: яралы килеш мең бәла белән Минскига таба атлаганда әсирләр арасында:

— Килеп алучысы булган белорусларны ирекккә чыгарачаклар икән,— дигән хәбәр таралды.

Кабушкин ышанмады. Ләкин бу хәбәр раска килде: җиңел машинада узган күзлекле офицер, рус сүзләрен вата-сындыра, үзе шулай диде. Иван элек Минск тирәсендә яшәгән бер әсиргә гозерен әйтте.

— Үземне генә эзләп тапсыннар, карарбыз аннары.— диде теге.

Ике көннән соң Кабушкин әсирләр лагеренда кочаклашып, әрнүле төстә елашкан ир белән хатын янына килде, тамак кырды.

Белорус агай айнып киткәндәй булды, йомшап төшүенә уңайсызланып, тиз-тиз күзләрен сөртте һәм: «Таныш бул, Маруся, бу — Жан»,— диде.

Маруся тулы гәүдәле, татарларга хас кара күзле, озын толымлы, сабыр гына яшь хатын иде. Күренеп тора: сер сыя моңа, тешләре сирәк түгел моның.

Тәртип саклап әрле-бирле йөреп торган полицай һәм немецераклашкач, ире хатынына:

— Тап кемне дә булса, Маруся. Коткарыйк егетне кыяматтән,— диде.

Маруся, ризалык белдереп, баш иде. Кабушкин аңа нишләргә кирәклеген аңлатты.

Шул чак колак төбендә генә:

— Миңа да хатын табыгыз. Юкса бу номерыгыз барып чыкмас,— дигән тавыш ишетелде.

Кабушкин кутәрелеп караса, шак катты: каршысында яралы уң кулын канлы чүпрәк белән бәйләп күкрәгенә аскан, ябыгып шактый бетәшкән Яков басып тора иде. Ул яргаланган иреннәрен ялмаштырып:

— Зинһар,— дип өстәде.— Жан, әйт ичмаса бер сүз. Шикләнмәсеннәр. Өйләнәчәкмен мин ул хатынга. Бу тәмугтан коткарсын да терелтсен генә...

Маруся Яковка җирәнгән сыман караш ташлады. Ире исә йомшак кына:

— Тырышып кара, Маруся,— диде.

Маруся, ризалык белдереп, ым какты.

Алар проходнойга таба атладылар.

Яков, гомерлек гадәтеннән аерыла алмыйча җиргә «черт» иттереп төкерде дә, теш арасыннан гына:

— Ышанмыйм мин бу стервага. Сүзендә тормас! — диде.

— Исән булсак, күрербез...

— Синең хатын табылыр. Синең хатын-кызны яраттыра торган сөйкемле сөягең бар. Военком кадәр военком кызының башын әйләндердең. Светлана акылдан шашып йөрде. Минем генә фартым юк.

— Светлананы... үземнеке иттем, диден ич...

— Шыттырдым гына ла...

Бу юлы Кабушкин җиргә төкерде.

— Без бер җепкә тезгән мәрҗәннәр булып чыктык бит әле, Ваня: туйларны белорусча җиде басуның бодай онынннан, җиде чишмәнең суыннан әвәләгән ипи салдырып үткәрмәгәек. Яхшылыгымны онытмассың: өйләнгән икәнеңне әйтмәм.

— Мин икенче кат өйләнергә уйламыйм.

Яков гаҗәпләнеп карады:

— Үзенә өйләнмәгәч, нәрсә дип безне моннан йолып алырга? Ахмаклык бу!

— Юк, фидакарьлек! Үзең теләмәсәң, көчләп өйләндермәсләр.

— Муенга атланачаклар! Һәм бер генә чыелдасаң да немецка тотып бирәчәкләр.

— Не смей алай сөйләргә! Үз аршының белән үлчисең. Парижга юлың уңмадымыни? Белорус җирендәге кешеләр кирәк булды, ә? Коега төкермә, суын эчәрсең, дип борынгылар бик белеп әйткәннәр.

Яков чебен кугандай селтәнеп:

— Тукта, тукта, масайма. Безне алырга этем дә килмәячәк! — диде.

— Миңа килерләр. Сиңа — икеле...

— Әгәр миңа килмәсәләр, моннан ычкынырмын димә, Иван. Комиссар кияве икәнеңне чишәчәкмен. Без — бер җепкә тезелгән мәрҗәннәр дип әйттемме? Үлсәк тә, калсак та бергә. Вот шулай!

— Тәмам эт икәнсең, Яков. Коерыгыңны чабып өзми ялгышканмын...

Алар икесе ике якка атлады.

Әсирләр бу сөйләшүне ишетмәделәр дә, һәммәсе сусаудан иза чигә иде. Чәнечкеле тимер чыбык киртә буенда авыз-борыннарында, җәрәхәтләрен бәйләгән канлы чүпрәкләрдә чебен мыжлаган мәетләр күренә башлады.

Кабушкин күләгәрәк почмакка килеп утырды. Чигәләрен учлары белән кысып, чуалган уйларының рәтенә төшәргә тырышып карады... Башы чатный, фикерләре томанлы иде. Ләкин өметне өзмәскә, биреш мәскә кирәк. Әгәр берәр мәрхәмәтлесе алырга килсә? Ә эт җанлы Яков сатса? Барысы да бетәчәк. Иванга ярдәм кулы сузарга теләгән изге җанны да аяп тормаячаклар. Хәер, эшләр алайга китсә, ул хатын бу кеше минем ирем түгел, ялгышканмын, дип борылып китә ала алуын. Әмма бу инде суга батканда саламга ябышкан кебек килеп чыгачак.

Шулай ни йокылы-уяулы уйланып ятканда әсирләр, дәррәү кубып, проходнойга таба кузгалдылар. Юк, ашарга да, эчәргә дә бирмәделәр. Ишек янында полицайны ияртkән немец, кулындагы кәгазьгә карый-карый, Яков Лысинны чакыра иде.

Яков Кабушкинга күз чите белән генә карап, вәкарь белән генә алга узды.

— Яков Илларионович Лысин?

— Йа, йа,— диде Яков.

— Ду ист белорус?

— Йа, йа...

Немец җиңенә свастикалы чүпрәк бәйләгән, йөзенә карап нинди милләттән икәнлеген аеру мөмкин булмаган озын буйлы, киң җилкәле шөкәтсез адәмгә нәрсәдер әйткәч, анысы Яковка төксе итеп:

— Хатының алырга килгән,— диде.

— Күптән кирәк иде. Мәрхәмәтле немец властьларының приказын сәгате-минуты белән үтәмәгәне өчен кайткач та ярам әле мин аны, стерваны...

— Хатынының исеме ничек?

Һәммәсен күреп-ишетеп торган Кабушкин: «Җор Яшка бетте, капты! — дип уйлады. Гомер күрмәгән кешенең исемен каян белмәк кирәк? Бетте, хәзер ялганы тотыла...»

Ләкин Яшка — Яшка икән ул. Судан коры чыгу әмәлен тиз тапты. Ул, ялагайланып, иреннәрен ялмаштырып:

— Сез кайсысын әйтәсез, яхшы әфәнде? — диде.— Хатыннарым минем, законлысын законсызын санасаң, бишәү...

— Мөселманмы әллә син?

— Юк, христианмын, яхшы әфәндем. Тумышым белән Загорскиның үзеннән. Атакай йорты духовный семинария янында гына...

Эшләрнең куерып баруын һәм куркыныч янавын абайлаган, хәйләмәкергә, күрәсең, Яковтан һич калышмаган, мул күкрәкле, йомры хатын такта ишек артыннан ажгырып килеп чыкты да «иренә» ташланды:

— У-у-у, идол!.. Тирес бит! Чучка танау! Кәнтәйләрең килмәдемени үзеңне йолып алырга? Законлы әшәке Авдотькаң тагын кирәк булдымы?..

— Авдотьюшка! Авдотьюшка! — дип ялварды хатынның исемен белеп өлгергән Яков.

«Ирен» алырга килүченең гел сынап карарга гадәтләнгән комсыз күзләрендә гаҗәпләнү чагылды. Колагындагы алтын алкалар салкын гына җемелдәделәр. Кып-кызыл итеп буялган калын иреннәр гаҗәпләнүдән ярым ачык килеш калды.

Немец белән полицай әле хатынга, әле иргә карадылар.

Мич кадәр бу ханымның пешкән чүрәкәй хәтле генә Яковка кияүгә чыгуы гаҗәбрәк иде шул.

Язмышы кыл өстендә торуын белгән Яков ширбәтле сүзләрен сибепме сипте.

Артык төчеләнү хәерлегә түгеллеген чамалаган полицай «кияүнең» җиңеннән тотты:

— Син үзеңне белорус дисең һәм дә бу хатынга өйләнгән идем дисең?

— Әйе, әйе, яхшы әфәнде,— диде Яков тиз-тиз.— Шартын-йоласын үтәп, искечә туйлап.

— Искечә туйлап?.. Әйт инде алайса, энекәем, кияү егетләрен искечә кемнәр дип атыйлар? Никах көнендә кияү белән кәләш өстенә нәрсә сипteләр? Төп бирнә бүләге ни?

Кайчандыр Кабушкинның анасы улына сөйләгән туй йолаларын Яшка тәрәзә төбендә тыңлап торган булса да, кирәге юк дип, хәтеренә сеңдермәгән иде. Шуңа күрә хәзер ык-мык итте, рәтле җавап бирә алмады. Ә айгырдай хатын, эшнең тугарылуын чамалап, тәртәне шундук кирегә борды:

— Юк-юк, бу бәндә минем ирем түгел. Борыны гына азрак ошаган. Тик аның борыны зуррак иде. Ялгышканмын мин. Гафу итегез...

Полицай Яковны сугып екты. Өнсез гәүдәне каядыр сөйрәп алып киттеләр. Яшка бүтән күренмәде.

Икенче көнне Кабушкинны проходнойга чакырдылар, хатыны эзләп килүен белдерделәр.

Өстенә иске-москы киенеп, олырак күренергә тырышса да, Нюра мөлаем һәм чибәр иде. Аңа күп булса унсигез тулгандыр. Ул үзенең «ире» кем икәнен абайлап алуга, бер дә тартынмыйча, Кабушкинга сарылды. Кибеп ярылган иреннәреннән, сакал-мыек баскан яңакларыннан үпте. Үзе елый-елый такмаклый, үзе «ире» белән очрашуга әйтеп бетергесез шатлана иде.

Тәртип саклап әрле-бирле йөргән кораллы немецның бу күренешкә күңеле йомшады булса кирәк, ул: «Фрау гут, гут»,— дип читкәрәк китте. Ә Нюра шул арада Кабушкинны моннан йолып алу өчен үзләренең паспорт хәзерләүләрен, тик аңа ябыштыру өчен фоторәсем кирәклеген, әгәр Иванның фоторәсемле берәр документы булса, Комсомол урамында яшәүче таныш фотографның булышырга әзер икәнлеген әйтеп өлгерде.

Кабушкинның барлык документларын, башына сугып миңгерәүләткәч, дошман солдатлары алып киткәннәр иде. Бары тик Тамара белән 1940 елда Казанда кышкы киемнән төшкән фоторәсем генә нииндидер кодрәт белән гимнастерка кесәсендә сакланып калган иде. Иван әрнеп шуны Нюрага төртте һәм: «Менә шуннан ни дә булса чыгара алса гына инде»,— дип пышылдады.

— Чыгарыр. Пеләшне дә чәчле итә ул! — диде Нюра.

Чыннан да, кичке якта Нюра бөтен шартын китереп яланбаш төшкән фоторәсемле паспорт алып килгәч, Кабушкинны «хатыны белән өенә» кайтарып җибәрделәр.

Кабушкинның иреккә чыгуы шулай ансат кына хәл ителде дисәк, бу хакыйкатькә туры килеп бетмәс иде. Төксе полицай Жанны да сират күпереннән уздырды.

Кияү егетләренең боярлар дип аталуын, туйда кияү белән кәләш өстенә кушучлап-кушучлап гәрәбәдәй бөртек сибүләрен, иң зур бирнә бүләге итеп чуар тавык һәм дуңгыз баласы бирүләрен — һәммәсен-һәммәсен сөйләде Кабушкин.

Алар проходнойдан Нюра белән култыклашып чыктылар.

Шулай итеп, Иван Жан булып йөри башлады. Иң әүвәл Столовая бистәсендәге кешеләр белән аралашты, яңа тәртипкә карата аларның чын фикерен белде, аннары Минскиның үзеннән иптәшләр әзерләргә керешге. Урманда партизаннар бар, дип ишеттерделәр, ләкин алар үзләрен сиздермиләр иде әле. Тирә-якта да, Минскида да тынычлык хөкем сөрде. Жанның моңа эче поша башлады. Юк, халык өметен җуймаска тиеш, ул дошман белән әчке көрәшкә әзерләнсен, үзенең җитәкчесе барлыгын тойсын. Төнлә самолет ташлап киткән листовкада шулай диелгән. Димәк, эшне башларга кирәк. Вакыт.

Һәм Жан, урманнан кораллар табып алуга, үзенең өч иптәше белән беренче тапкыр ауга чыкты. Шоссе юлның текә борылган җиренә засадага урнаштылар. Менә алдан һәм арттан мотоциклллар сакчылыгындагы «Опель» маркалы җиңел машина күренде. Жан сигналы буенча бердәм ыргытылган өч граната һәм автомат чиратлары фашистларның көлен күккә очырды. Тегеләрнең коралларын һәм документларын алып, урманга кереп сыздылар.

Чираттагы ау Логойск юлында булды. Аннары Стелбун ягына киттеләр. Монысында ягулык ташый торган машиналарны шартлаттылар.

Партизаннар хәрәкәте турында шәһәрдә мең төрле хәбәрләр таралды.

Партия подпольеда эшләргә кешеләр калдырган булып чыкты. Минскида подполье райкомнары оештырылган, алар белән шәһәр комитеты җитәкчелек итә. Хәзер Минск тирәсендәге урманнарда байтак партизан отрядлары бар инде. Алар фашистларга китергән зыянны санап-исәпләп бетерер хәл юк. Дошманның аяк астында җир яна. Элеккеге кебек күккә карап, күкрәк киереп йөри алмый ул хәзер. Һәр адымда үзен үлем сагалаганны белә. Күпчелек урманнарга алар кермиләр — куркалар. Андый урыннарны алар партизан зонасы дип йөртәләр. Анда халык сугышка кадәргечә яши — власть Советлар кулында, мәктәпләрдә укулар дәвам итә.

Укулар дошманның борын төбендә үк хәрәкәт иткән партизан отрядында да тукталганы юк. Әле моннан ике атна гына элек Жан, отряд командиры Ничипорович, комиссар Покровский кушуы буенча, партизан мәктәбендә укучылар өчен карандашлар табып кайтты. Дәфтәр ягы гына кыенрак. Юк, немец дөньясында кәгазь юк. Хәер, укучылар аптырап тормыйлар; урман бай, каен тузына, юкә такталарга язалар. Нинди кызык мәсьәләләр, мисаллар уйлап чыгаралар диген, юеш борыннар! Һәр мисалда шартлатылган склад, күпер, паровозлар, юк ителгән техника, солдат... Сугыш балалар дөньясына да үтеп керә, чыныктыра, җитди булырга, дошманны таный белергә һәм үч алырга өйрәтә. Балалар арасында ятимнәр дә бар. Ләкин отрядта ятимнәр юк, алар турында олылар кайгырта...

Кәүсәсенә кара такта беркетелгән карт имән үсеп торган аланлыкка килеп чыккач, Кабушкин иптәшләренә туктарга ишарәләде.

— Унга борылыйк, дәресне бүлдермик,— диде ул шыпырт кына.— Болай да фашист самолетлары, артиллериясе күп бүлдерә аларны. Землянкаларда юеш булганга, кояшка чыкканнар, нарасыйлар...

Партизаннар әмәлләгән озынча эскәмияләргә утырып, тезләрен өстәл иткән укучылар аларга борылып та карамадылар... Партизан мәктәбендә классларга бүленеш юк. Укучылар абыйлы-энеле янәшә утыралар. Һәркем үзенең ничәнчедә икәнен белә һәм үзенә тиешле заданиене тырышып үти. Бөтен игътибар укытучыда. Каршыда ул басып тора икән, димәк, син үз эшеңдә бул, кайгырма...

Жан күбрәк тапталган сукмакка борылды. Ул штабка илтә иде. Алар каршына өстенә кыска тун кигән, муенына бинокль һәм немец автоматы аскан яшь кенә бер егет — штаб элемтәчесе килеп чыкты.

— Отряд командиры сезне көтә,— диде ул Кабушкинга честь биреп.

Аны отряд командиры полковник Ничипорович борчулы кыяфәттә каршылады. Ул:

— Рәхим ит, түргәрәк уз,— дип, ак кулларын җәеп өстәл янына чакырды. Хәл сорашты, аннары Минскидагы күңелсез хәбәрләр турында сөйләде һәм Жанның бик ашыгыч рәвештә шәһәргә китәргә тиешлеген әйтте.

— Приказ әзер, имза куелган,— диде ул Кабушкин алдына бер бит кәгазь этеп.

Анда түбәндәге сүзләр язылган иде:

«Отрядта медикаментлар һәм сугыш кирәк-яраклары җитешмәүне искә алып һәм шулай ук Логойск партизан отряды белән элемтә урнаштыру максатыннан, боерык бирәм:

1. Отряд штабының икенче бүлек начальнигы өлкән ярдәмчесе лейтенант Кабушкинга һәм сугышчы-партизан иптәш Саранинга аерым исемлек буенча медикаментлар алып кайту, сугыш кирәк-яраклары табу, Логойск кызыл партизан отряды белән элемтә урнаштыру һәм басма хәрефләр белән листовкалар чыгару өчен Минск шәһәренә китәргә.

2. Куелган бурычны үтәү өчен 1942 елның 10 мартында 22 сәгать 00 минутта лагерь урнашкан җирдән чыгып китәргә. Лагерь урнашкан җиргә 1942 елның 16 мартында кайтып җитәргә».

— Аңлашыла,— диде Кабушкин.— Приказны үтәү өчен хәзерләнә башларга рөхсәт итегез.

Командир Жанны кочаклап алды:

— Сак була күр, Жан. Элеккеге кебек барысына да үзең чапма. Син безгә зур эшләр оештыру өчен кирәк... Провалдан соң Минск подпольесы какшады, беләсең.— Отряд командиры авыр сулап куйды, әйтергәме-юкмы дигәндәй, иренен тешләде һәм дәвам итте: — Анда ниндидер провокатор барлыкка килгән. Белергә һәм бик тиз аңардан котылырга кирәк. Юкса...

— Аңлашыла,— диде Кабушкин.— Приказ үтәлер, иптәш командир.— Жан үкчәләрен шыкылдатып честь бирде.— Хушыгыз, Владимир Иванович. Көрешкәнчегә кадәр...

— Уңыш телим, Жан!

Кабушкин белән Саранин төне буе юлда булдылар. Саклык йөзеннән үзара сөйләшмичә (урман — колак, кыр — күз дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр!) бардылар. Таң алдыннан аяк асты туңдырып җибәрде, атларга җиңеләеп китте. Разведчиклар моңардан күбрәк файдаланып калырга исәплиләр иде. Шуңа күрә тукталган җиргә авып йоклар дәрәҗәгә җитеп арысалар да, ял итмәделәр. Наратка сөялеп кенә тамак ялгадылар да аяклардагы тәмам йөрәккә төшә торган әрнүләрне җиңеп, юлны дәвам иттеләр.

Күз бәйләнеп килгәндә, шәһәргә өч-дүрт чакрым калгач, Жан юлдашын туктатып:

— Хәзер икебезгә ике якка китәргә кирәк,— диде.— Шулай ышанычлырак.

Партизан отрядыннан алып кайта торган авыр йөк — шартлаткычларны икегә бүлделәр. Капчык өсләренә дуңгыз мае салдылар.

Жан, әйләнгеч юлларны туры итеп, Александра Константиновна Янулис квартирына кайтырга тиеш иде. Тулы гәүдәле, озын кара толымлы, сирәк елмая торган аз сүзле бу чибәр кызны квартир хуҗасы итеп Жан үзе сайлады. Полиция бирә торган таныклык — аусвайста аталарының исеме туры килгәнгә, тикшерүчеләргә алар үзләрен бертуганнар дип әйтәләр иде. Фамилияләре ике төрле — чөнки

Александра кияүгә чыккан, янәсе. Кияве беренче көннәрдә үк сугышка алынган, хәзер бертөрле дә хәбәре юк...

Кыз подполье таләпләренә тиз күнде. Ул казинода эшли һәм, немец телен яхшы белгәнгә, исереп мактанышкан офицерлардан ишеткән мәгълүматларны подпольедагыларга житкереп тора иде.

Көннәрдән бер көнне Артур Вильке дигән немец капитанының махсус задание үтәр өчен Минскига килүен белеп кайтты. Монысына Жан әллә ни игътибар итмәде: гестапо, абвер, СД агентлары белән мыжлап торган шәһәргә кем килмәс тә кем китмәс?! Әлеге капитанның кобурасында исемле пистолеты бар икән. Аны капитанга Гитлер үзе бүләк иткән...

Жанны аучыларга хас тойгы биләп алды: эх, шул пистолет кулга төшсә?!

Александра гажәпләнеп:

— Нигә ул сиңа? — диде.— Коралың булмаса икән...

— Моны, сугыш беткәч тә, музейга куяр идек. Музейга кергән кешеләр пистолеттагы язуны укып: «Менә бит белорус партизаннары нинди кыю булган, алар Гитлер үзе бүләк иткән коралны да кулга төшерә алганнар!» — дип, безне мактарлар иде.

— Болай да мактарлар, Жан.

— Барыбер сөйлә, Шурочка, нindирәк ул капитан?

Жан атна буе аны сагалап йөрде. Ниһаять, очратты. Капитан бер офицер белән казино түрендәге гөл артында почмакта кәефләнеп утыра иде. Икесе дә ярыйсы ук сәрхүш. Нәрсә турындадыр кызыпкызып бәхәсләшәләр.

Жан алган сырасын эчә-эчә Александраның күзләренә мәгънәле карап алды да тиз-тиз урамга чыкты. Капитан кайсы якка китәр икән? Кич булып килгәндә әллә кая барып йөрмәс, кунакханәсенә генә кайтыр ул. Димәк, «Белорусь»ка. (Жан моны белеп өлгергән иде инде.) Анда таба кайту юлында нинди жайлырак урын бар? Әһә... сәгать буе сыра эчеп утырган немец юлда тукталмый калмаячак, Жан белә: бәдрәф эзләп йөрмәячәк алар.

Капитан казинодан бергә эчеп утырган иптәшен ияртеп чыкты. Кунакханә ягына борылмыйча, туры киттеләр. Жан аларга иярде. Каршыдан искән жил өзек-өзек сүзләрен ишеттерә: бөек Германия, фюрер, аңа биргән ант...

Мондый төче сүзләрне Жан һәр немецтан диярлек ишетә иде. Аерма шунда: бу сүзләр бүген гадәттәгечә тантаналы-горур төстә түгел, күбесенчә зур кырыслык һәм янау белән әйтелделәр. Ни хикмәт? Жан саклык йөзеннән кесәсен капшап куйды. Юк, корал кирәксенеп түгел (көндез ул гомумән коралсыз йөри), немецлар нигә безнең арттан барасың дип бәйләнә-нитә калсалар, берәр хәйлә табар өчен. Кесәдә Александраның көмеш медальоны бар. Жан чылбырны чеметеп тотып:

— Герр офицер, битте, цванциг марка! — диячәк.

Дошман икәү булганда теләсә кемне бер селтәүдә һуштан яздыра торган сул йодрыкка сүз бирелмәячәк. Хәер, жае чыкса...

Болар борылып карамыйча юлны дәвам иттерделәр. Тротуарга жимерелеп төшкән йорт янына житәрәк тиргәшү аеруча көчәйде. Менә капитан, сүгенеп, иптәшенең якасына ябышты, аралыкка төртеп кертте.

— Брудер! Майн брудер! — диде яшьрәге.

Мондый хәлгә гажәпләнгән Жан, хәрабәләргә ышыкланып:

— Ә бу капитан шәп спортсмен! — дип уйлады.— Иптәшен нишләтергә чамалый ул? Брудер абый дигән сүзләре ич ул аларның...

Капитан кулында күгелҗем корычлы пистолет елкылдады, тымызык көнне ботак сынгандай гына шартлау ишетелеп калды.

Ганс Гансны атты! Нәрсә бу? Әлегә хәтле мондый сәер хәлне күрергә түгел, ишетергә дә туры килгәне юк иде аңа. Шик юк, боларның берсе...

Кара киемле капитан, мәет өстенә иелеп, кабалана-кабалана кесә актарырга кереште. Ниндидер кәгазьләрне читкә ыргытты, ә саллы гына бер төргәкне чирканып тотып, як-ягына карана-карана изүенә яшерде дә бирегә таба йөгерде.

Юк, уткәреп җибәрә алмады Жан: аяк чалды. Капитан бакадай җәйрәп барып төште. Жан корбанына ташланган киектәй сикереп, тегенең кулына басты да, немецның пистолетын кобурасыннан алды һәм:

— Папиер! — диде.

Немец төргәкне Жанга сузды, исән котылуга өметләнеп өзек-өзек итеп:

— Флюгшрифт... Листовка... Из Москуа,— диде.

Жан яшен тизлегендә: «Безнең агент микән әллә бу? — дип уйлап алды.— Җайсыз килеп чыкты. Әллә пистолетын кире бирергәме? Аннары маңгаена тераэп атса?..»

— Геноссе... Камрад... Товариш...

— Вег! Йөгер тизрәк! Мин сезне җибәрәм...

— Спасибо.

Яшерен квартирага кайткач, Жан иң әүвәл өстәлгә медальонны, аннары аның янына исемле пистолет белән листовкаларны куйды.

Йөзе ап-ак булган Александра:

— Бу — бик куркыныч эш, Жан! — диде.

— Алай ук түгелдер лә, кадерлем, мөгаен, алай ук түгелдер. Әмма мин коточкыч ахмак хәлгә калдым бугай.— Һәм ул Александрага һәммәсен сөйләп бирде.

Листовкалар, чыннан да, Мәскәүдә басылган иде.

Мәеттән капитан читкә алып ташлаган нәрсә лейтенант Рудольф Вилькеның шәхси таныклыгы иде.

Александра өстәлдә зәһәр кара күзен төбәп яткан коралга ымлап:

— Бу нәмәрсәкәйнең дә хуҗасы Вильке фамилияле булган,— диде.

Жанның фикере яктырып китте:

— Акыллым син минем, Шурочка! Игътибар итүең өчен рәхмәт... Димәк, капитан Артур Вильке, чынлап та, үзенең энесен аткан...

— Син нәрсә, Жан...— Кыз өстәл яныннан чигенеп (әйтерсең пистолет шул мәрхәмәтсезлеккә төп сәбәпче!), Жанның киң күкрәгенә ышыкланды.— Ничек инде — үзенең энесен?..

— Монысы көн кебек ачык. Лейтенант майн брудер дип өзгәләнеп кычкырды да хәтта.

— Абыйсы энесен... Коточкыч вәхшилек! Гитлер бүләк иткән пистолет белән...

— Монысы гаҗәп түгел. Уйла әле: капитан Артур Вильке ни өчен үзенең энесен атты? Менә кайда мәсьәләнең кәттәсе?

— Барыбер түгелмени, Жан? Бер фашист икенчесен дөмектерсә ни дә, икенчесе беренчесен дөмектерсә ни? Урыннарын алмаштырудан сумма үзгәрми.

Жан кызның чәченнән сыйпап, уйчан төстә:

— Үзгәрә шул, кадерлем, үзгәрә,— диде.— Кем үтерелде бүген — дусмы, дошманмы? Бу ике туганның берсе — һичшиксез безгә дус. Кемне кулдан ычкындырдым мин — дуснымы, дошманнымы? Вәт кайда мәсьәлә. Моңа җавапны шушы листовкадан табып булмасмы?

Александра листовканы тәрҗемә итәргә кереште:

«— Әйе, без ант белән бәйле. Аңардан ваз кичү безгә авыр, бик авыр... Явызлык, мәрхәмәтсезлек белән властька килгән Гитлер халыкны һәлакәткә илтә. Халкыбызга булган тугрылык Гитлерга булган тугрылыктан күп өстен...

Нәрсә ул хыянәт? Үз файдасы өчен халкын саткан кеше генә хыянәтче була. Без Ватанны сатучылар түгел, ә коткаручылар... Безнең намус, безнең бәя Гитлерга биргән антыбызны формаль үтәүдә түгел, халкыбызга тугрылыклы булып калуда...»[1]

— Аңлашыла... Бу байлыкны без, Шурочка, адресатларына тапшырырбыз, әлбәттә. Шигем юк, Рудольфның үтерелүенә шушы листовкалар да сәбәпче.

— Ни өчен листовкалар? — диде Александра.— Үтерешмичә, ташлап кына китсәләр?

— Инанган кыйбланны ташлап китеп булмый, Шурочка. Листовкалар Рудольфның эчке кесәсендә иделәр. Димәк, ул аларны кайдандыр алган. Агасына укыткан. Аннары — ике инанган кыйбла бәрелешкән... Тик Артур, энесен үтергәч, ни өчен аның документларын читкә алып ыргытты?

Александра кыюсыз гына:

— Партизаннарга сылтар өчендер, мөгаен,— диде.

— Мин дә шулай уйлыйм. Тик хәзер, Шурочка, шуңа җавап бир: листовкалары кесәсендә килеш энесен гестапога тапшырган булса, моның өчен Артурга рыцарь тәресе бирерләр иде бит?

Каты чикләвек булып чыкты бу мәсьәлә. Аңа төрлечә якын килеп карасалар да, рәтле җавап таба алмадылар.

Җан өстәлдәге пистолетны сүтеп, детальләрне ике өлешкә аерды да, берсен иске чүпрәккә төреп, Александрага сузды:

— Бик ерак яшер, кадерлем. Сугыш беткәч бергә кушып җыярбыз. Шулай ышанычлырак булыр...

Александра ишегалдына чыгып китте. Шактый торып кергәч:

— Карт тополнең уң ягына күмдем,— диде.

— Моны ник миңа әйтәсең?

— Белеп тор. Сугыш беткәндә мин булмасам... килеп алырсың. Мине исеңә төшерерсең...

Җан кызны кочаклады. Сөйләшмәделәр, һәр икесе үз уе белән мәшгуль иде. Урамнан ачы чыйнап патруль машинасы узды, автоматлар тырылдады. Тәрәзә пыялаларын зыңлатып нәрсәдер шартлады да, тирә-як кинәт тынып калды.

Бераздан инде Җан баягы уйларына чумган иде.

— Ни өчен Артур рыцарь тәресеннән баш тартты икән соң? — диде ул листовкаларга карап.

Кыз бу куркусыз егетнең подполье эшенә шул дәрәҗәдә бирелгән булуына сокланып бетә алмый иде. Ул гүя шуның өчен генә яши, аның бүтән бер нәрсәдә гаме юк. Башка хатын-кызлар белән ялгыз калганда да шундый... инсафлымы икән?.. Китегез, ямьсез уйлар! Җан бүтән төрле, яхшы, итагатьле. Әгәр югары белем дә алса, тәмам ачылып китәр иде... Александра Җан килгәндә генә файдалана торган зәңгәр чәчәкле чынаякка чәй агызды, күптән инде саклап тоткан шоколадның ука кәгазен ертты.

— Җан, беләсеңме, Артурның рыцарь тәресеннән ни өчен баш тартуын мин аңладым бугай...

— Ни өчен, кадерлем? Әйт, зинһар!..

---

[1] Антифашист Эрнст Хадерманның 1942 елда республикабызның Алабуга шәһәрендәге хәрби әсирләр лагеренда үткәрелгән офицерлар җыелышында сөйләгән реченнән, ул, немец телендә Мәскәүдә 500 мең данә басылып, төрле юллар белән фашист гаскәрләре арасында листовка итеп таратыла. Берничә данәсе Совет Армиясенең Үзәк музеенда саклана. (Автор).

— Казинода офицерлардан ишеткәнем бар: немец, антын бозып фюрерга хыянәт итсә, аңа үлем җәзасы бирелә.

Жан түземсезләнеп:

— Соң, Рудольф үле бит инде...— диде.

— Моның белән генә эш бетми икән шул: үлемгә хөкем ителгәннең ата-анасын, туганнарын йорт-җирләреннән куып чыгарып, үлем лагерьларына озаталар икән.

Жан кызны күтәреп алды:

— Акыллым син минем! Дөрес! Артур Вильке нәкъ әнә шуңардан курыккан. Энесе Рудольфны гестапо барыбер эләктерер иде һәм аны барыбер үтерерләр иде. Моның кара күләгәсе бөтен кардәш-ыруга төшәр иде. Шул исәптән Артур Вилькенең үзенә дә... Ә болай хәл башка: антына тугрылыклы Рудольфны партизаннар үтерде. Фюрер өчен шәһит китте. Өйдәгеләргә пенсия килеп торачак... Оста уйлаган!— Жан ике кулы белән башын тотты.— Шигем юк хәзер: чын фашистны ычкындырганмын икән. Кызганыч, аһ, кызганыч!..

Шулай да Жан отряд командирыннан Артур Вилькенең безнең яшерен агент түгелме икән дип белешүен үтенде. «Зур җир»дән уңай җавап килмәде. Ахырдан Жан моңа үзе дә ышанды.[1]

*

* *

Партизаннар биреп җибәргән «урман күчтәнәче» берәгәйле булды: тимер юлда мәхшәр башланды. Фашистларның Минскидан фронтка дип озатылган поездлары кайдадыр юлда откоска мәтәлделәр, дошманның ягулык салынган цистерналары шартлады, бик күп сугыш кирәк-яраклары, солдат, офицеры юк ителде. Юлларда хәрәкәт тукталды. Хәрби комендант партизаннар зонасын чистарту, тимер юлны ремонтлау һәм саклау өчен Берлиннан өстәмә көчләр сорарга мәҗбүр булды.

Фашистлар подпольечыларга каршы көрәшне көчәйттеләр. Шәһәрдә агентлар, шымчылар бермә-бер күбәйде. Парольләр, пропускалар әледән-әле алмаштырылып торыла башлады. Тентүләр ешайды, шәһәргә кертмиләр дә, чыгармыйлар да. Урамнарда йөрү куркыныч иде хәзер. Тик өйдә кул кушырып утырып булмый бит. Задание үтәлергә тиеш. Иван өс киемнәрен алыштырды, кырынды, чистарынды һәм, сак кына атлап, чыгып китте. Ары сугылды, бире сугылды — артта «койрык» юклыкка инангач кына ышанычлы кешеләрдән подпольедагы «Звязда» газетасының редакторы Володя Омельянюкның яңа адресын сорап алды. Бу спай егетне ул күптәннән белә иде инде. Володя хәзер олыгаеп киткән: борын төбендә генә мыек калдырган, сакал җибәргән. Өстендә ак күлмәк, муенында ефәк галстук. Чалбары шәпләп үтүкләнгән.

— Ә-ә-ә, Саша-Александр, Жан Базаров-Назаров, Кабушкин-Бабушкин! Сәлам, дускай, сәлам!—дип каршылады ул Иванны, ягымлы елмаеп.— Иң әлек «Зур җирдән» нинди хәбәрләр килүен сөйлә. Ленинград нишли?

— Ленинград кыядай нык тора! Севастопольнең дә бирешергә исәбе юк. Фашистлар Кызыл Армиянең көчен сындырдык дип юкны лыгырдыйлар. Барлык фронтларда каты сугышлар бара. Партизан хәрәкәтләрен, диверсион эшне без көчәйтергә тиеш, Володя!

---

[1] Майор Артур Вильке Минскидагы гестапо башлыкларының берсе була. Ләкин барыбер гадел җәзадан котылып кала һәм соңгы елларда ГФРда укытучы булып эшли. (Автор).

— Әлбәттә! Әлбәттә, Базаров-Назаров, Кабушкин-Бабушкин! Син, дустым, гаҗәпләнмә болай такылдавыма. Гестапода ачкан делода син шулай исәпкә алынгансың ди. Синең баш өчен шактый акча да билгеләгәннәр икән. Шулай булгач, үзеңне эре тотарга тулы хакың бар, дустым.

— Беләсең ич, Володя, вакланып торганыбыз юк: шартлатсак кимендә эшелонны шартлатабыз; дөмектерсәк, ким дигәндә унтер-офицерны дөмектерәбез. Клинок авылы янындагы сугыш турында ишеткәнсездер инде? — Кунак Омельянюк тәкъдим иткән урындыкка утырды да, җавап көтеп, күзләрен дустына текәде.

— Ишеттек, Жан, ишеттек. Шуның шәрәфенә менә мин бәйрәмчә киенгән бит инде! Фашистларның тәмам кирәген биргәнсез сез анда. Бер батальонга якын эсэсчы юк ителгән. Сайлап алынган гаскәр. Һәммәсе югарыгы чин — ял йортында көч тупларга килгән булганнар. Өч көн буе күмделәр, өч көн буе табутларны Германиягә озаттылар. Рәхмәт үзегезгә. Кайткач барлык партизаннарга, бигрәк тә Ничипоровичка партиянең шәһәр комитеты исеменнән кайнар сәлам һәм зур рәхмәт тапшыр.

— Бик рәхәтләнеп, Володя! Ләкин кунак ашы — кара каршы дигәндәй, шәһәр комитетына без дә рәхмәт әйтәбез: алар җибәргән кешеләр арслан кебек сугыштылар ул көнне. Менә дигән партизан алар хәзер.

Омельянюк уйга калды. Бераздан:

— Синең эшләр шәп, Жан,— диде.

— Нигә алай дисең, Володя?

— Кайтасың да гестапога утлы күлмәк киертәсең, китәсең дә эсэсчыларны автомат белән мунча чабындырасың.

— Шуңа күрә мин партизан-разведчик, үзеңчә әйтсәк, Базаров-Назаров, Кабушкин-Бабушкин бит инде.

Алар икесе дә рәхәтләнеп көлештеләр.

— Я, сөйлә, нинди заданиеләр белән кайттың?

Әңгәмә озакка сузылмады. Тәрәзә төбендә автоматын әзер тоткан фашист патрульләре йөреп торганда озаклап сөйләшеп утырырга мөмкинме соң?! Әнә ачы үкереп, ябык машина — «кара козгын» үтеп китте. Аның тавышы басылырга өлгермәде, мотоцикллар тырылдап уздылар.

— Листовкалар басуны оештырырбыз,— диде Володя, саубуллашканда.— Шрифтлар әзер инде, тынычрак урын һәм вак-төяк кенә табасы калды. Элемтә мәсьәләсен дә хәл итәрбез. Озакламый аннан кеше килергә тиеш. Очрашу урынын билгеләрбез. Яңа адреслар менә шушы кәгазьдә. Күз карасы кебек сакла. Янында йөртәсе түгел. Курkыныч туса, шундук юк ит. Ә менә провокатор Давыдов... Моңа үзең керешерсең. Син разведчик кына түгел, оператив группа җитәкчесе дә бит. Эзлә, тап, күзәт. Тик җентекләп тикшерә күр һәм... үзең башкарма. Гестапо синең почеркны тиз таный. Я, хәзергә, Жан...

Ике көннән соң немецлар провокатор Давыдовның җансыз гәүдәсен поляк костелы артындагы төрбәдән табып алдылар...

Шәһәрдә кабалану, ыгы-зыгы башланды.

*

* *

Омельянюк биргән адресларны кайда сакларга? Иң яхшысы — күңелгә сеңдерү, билгеле. Ләкин унга якын бит алар. Капылт кына ничек һәммәсен күңелгә сеңдереп бетермәк кирәк?!

Александра Иванга иске үтүк китереп тоттырды:

— Син электр эшен беләсең, бәлки, төзәтеп куярсың? — диде.

Жанның кабырсып йөрүен кай арада сизеп алган диген. Шунысы җайлы тагын: кызның төпченә торган гадәте юк. Үзең сөйләмәсәң, берни сорашмый. Шуңа карамастан, ни кирәген әллә каян белеп ала. Менә, рәхмәт төшкере, кәгазеңне яшерергә шушы үтүк ярамыйммы диюе бит инде аның.

Жан үтүкне иплә кенә сүтә башлады. Нәни гайкаларда эз калмасын өчен, «карга борыны»на резина кисәге куеп борды. Эчтәге асбестны икегә аерып, адреслар язылган кәгазьне арага салып калдырды. Ахырда Александраны чакырып:

— Бер-бер хәл була башласа, шнурны тоташтырырсың,— диде.

— Ток юк ич...

— Фашистлар тентү ясарга кирәк булган кварталга ток бирәләр.

— Аңлашыла, Жан...

— Син иң акыллым минем.

— Мин шат... Сиңа булыша алуым өчен шат.

— Әти-әниең шундый кызлары белән горурланырлар иде.

Александра, башын аска иеп, акрын гына:

— Әйе, алар юк инде...— диде. Кыз: «Бу дөньяда бердәнберем син хәзер минем!» — дип әйтергә бик-бик теләсә дә, кыюлыгы җитмәде, кызарып, кухняга юнәлде.

Кара-каршы утырып, гөлдерәшә-гөлдерәшә тамак ялгагач һәм беркадәр вакыт сөйләшеп яткач, Жан йокыга талды. Ул бүген өч сәгатьтән соң шәһәр читендәге бистәгә барып кайту өчен яктырганчы ук юлга чыгарга тиеш иде.

Чытырдый-чытырдый янган сукыр лампа яктысында Александра Жанга карап уйланып утырды. «Үзең искиткеч куркусыз кеше син, Жан. Ничаклы хәтәр эш синең җилкәңдә, ничаклы борчылу, хәвеф... Барыбер зарланмыйсың. Син һәр вакыт көр күңелле, ягымлы, кыю».

Кызның йомшак бармаклары битенә тиюгә, Жан уянып китте.

— Вакыт җитте, матурым...

*

* *

Кичке якта Кабушкинны эзләп элемтәче Ирма Лейзер килде.

— Атакай сине бик тиз отрядка кайтырга кушты,— диде ул.

«Алдан килешкән вакыты җитмәгән. Хикмәт нәрсәдә икән соң? — дип уйлады Жан.— Әллә инде без монда ни дә булса карап җиткермәдекме?»

Ул Давыдовны юк итү операциясен вак-төягенә чаклы хәтереннән үткәрде. Бәлки урын дөрес сайланмагандыр? Юк, поляк зираты подпольечыларның яшерен урыны түгел. Анда моңа чаклы бернинди операция дә үткәрелгәне булмады, мөгаен, үткәрелмәс тә. Шулай булмаса, Сайчик алдан кисәтеп куйган булыр иде. Жан заданиене үтәргә керешкәнче үк аның белән киңәште ич. Сайчик ул чакта елмайды гына, аннары:

— Андый сак җанвар бу алдавычыңа кабармы икән? Урыны бигрәк караңгы бит,— диде.

Ә «җанвар» капты, егетләр дә аптырап калмадылар.

Листовкалар үз вакытында бастырылып таратылды. Элемтә тиешенчә көйләнде. Һәммәсе тәртиптә кебек. Черки дә борынын тыгарлык түгел...

Жан әнә шундый уйлар белән урманга кайтты. Отряд командиры Ничипорович землянкасы ишеге төбенә баскан сакчы көтеп торырга кушты. Бу хәл дә яхшы уйлар кузгатмады. Элек болай түгел иде — биредә ул һәр чак көтелгән кунак иде...

Узгынчы жил үткен укларны хәтерләткән чыршы башларын һәм жиздәй наратларның купшы ак түбәтәйләрен чайкалдырды. Агачлар берьюлы шаулаштылар да тындылар. Кайдадыр ябалак кычкырып куйды.

Ниһаять, Кабушкинны землянкага керергә чакырдылар. Анда карангырак һәм салкынча иде. Идәннән әрем исе чыгып тора. Урман эчендәге землянкага хас түгел иде шикелле бу. Бала чакта Ваня үз куяннарына ашатыр өчен үлән жыеп йөргәндә, әрем исе нәкъ шулай борынны әчеттерә иде.

Кабушкин дулкынланмаска тырышты. Ул отрядта лейтенант саналып, штабның бүлек начальнигы урынбасары вазифасын үтәсә дә, аңа буйсына торган берәү дә юк иде. Ул үзенә-үзе солдат, үзенә-үзе командир. Бүгенгә чаклы алар — солдат һәм командир — кушылган һәр эшне менә дигән иттереп үтәделәр һәм шуңа күрә ниндидер шик азрак борчып торса да, Жанның йөзе тыныч иде. Әйбәтләп карасаң, шик тә түгелдер әле ул, бары уйлану гынадыр. Ә уйланудан исә берниндн солдат та, командир да азат була алмый инде.

Отряд командиры, киң жилкәле, озын буйлы кадровый подполковник Ничипорович, өстәлдәге кәгазьләреннән карашын алмый гына башын күтәрде, гимнастеркасын, бил каешын төзәтте дә шат тавыш белән:

— Вольно, лейтенант. Вольно,— диде.— Мин сине, дус кеше, зарыгып көтәм. Я, утыр. Иң әүвәл башкарган эшләрең турында сөйлә. Кыскача гына...

Кабушкин листовкалар чыгару, элемтәгә керү һәм провокаторны юк итү вакыйгаларын сөйләп бирде, егетләрне мактады, һәм яңа заданиене үтәр өчен әзер икәнлеген әйтте.

Ничипорович урыныннан торды. Кабушкин да аяк өсте басты. Командирның акыллы, үткен күзләре кысыла төштеләр, киң маңгаенда жыерчыклар барлыкка килде. Трубкасына ут элдерде дә, күгелҗем алкалар чыгара-чыгара, землянканың шыгырдавык идәне буйлап йөрергә кереште. Үзен нәрсә дә булса берәгәйле дулкынландырса, ул һәр вакыт шулай итә.

Өстәлдә телефон шалтырады, ләкин командир трубканы алмады. Гүя һичнәрсә ишетмичә һаман йөри бирде.

Кәгазь тотып радист керде, аны өстәлгә куйды да кулын чигәсенә тидереп, ике генә сүз әйтте:

— Ашыгыч. Мәскәүдән.

Җавап көтеп тормады, чыгып китте.

Отряд командиры, йөрүеннән туктап, кәгазьне кулына алды, радиограмманы укыды. Йөзендәге уйчанлыгы тагын да арта төште:

— Белсәм икән мин ул көтүченең нинди икәнлеген...

— Иптәш командир, белдерергә рөхсәт итегез,— диде Жан,— көтүче — күренекле фигура, аңа бөтен көтү буйсына. Бәлки мин белә алырмын? Заманында көтүчеләр һәм кәҗәкәйләр белән эш йөрткәнем булды минем. Кирәк икән, хәзер дә...

Командирның күзләрендә шаянлык җемелдәде:

— «Эш йөрткәнем булды» дисеңме? Димәк, майлы кәҗә итен авыз иткәнең бар? Шуңа күрә үткен егет булып үскәнсеңдер әле! Шулаймы, Жан?

— Яшереп тормыйм, иптәш командир, булды андый хәл, булды. Үсмер чакта. Үзебезнең Идел ярындагы болында пикник ясадык. Во!..

Командир жилкә чокырын кашып:

— Ә нәрсә, андый пикникны кабатларга була. Тәжрибәң дә бар икән... Болын-урманга барырга ризалата алмасаң, ресторанда ли-

монлап коньяк эчеп кәеф-сафа корырга мөмкин. Моның гади көтүче түгеллеген онытмагыз. Үзең үк: «Аңа бөтен көтү буйсына», дисең бит...

— Аңлашыла, иптәш командир. Тик кечкенә генә бер детальне ачыкларга рөхсәт итегез: ул «көтүчене» теге дөньяга җибәрергәме?

Ничипорович көлә-көлә:

— Юк, Жан. Бу юлы задание катлаулырак. Аны теге дөньяга җибәрергә ярамый. Ул безгә эшләргә тиеш, — диде.

— Әгәр риза булмаса? — Жан сораулы карашын командирына текәде. Ничипорович җавап бирергә ашыкмады. — Ул немецмы?

— Әйе.

— Алайса эш барып чыкмас.

— Барлык немецлар да фашист түгел, Жан. Аларның күбесе яшен тизлегендә җиңү сугышының бик нык сузылуын һәм Гитлерның ахмак саташуы гына икәнлеген аңлады бит инде. Россияне җиңү тәтемәячәген, киресенчә, үзләрен теге дөньяга җибәрәчәгебезне күреп торалар алар хәзер. Менә хәтта фашист газетасы «Минскер цайтунг» партизаннар кулыннан әҗәлен тапкан мең алты йөздән артык немец шәһәр зиратына күмелде дип яза. Син беләсең бит, Жан, болар әле урта кул офицерлар гына. Зуррак чиндагыларның мәетләре Бөек Германиягә цинк табутларда озатыла.

— Димәк, безнең «көтүче» дә — офицер?

— Әлбәттә. «Зур җир»дә аны шулай атаганнар.

— Бу задание аннанмы?

— Әйе, Жан. Ә синең «көтүчең» — Ганс Штрубэ, «Үзәк» тимер юллар президенты канцеляриясенең башлыгы булыр.

Кабушкинның маңгаена салкын тир бәреп чыкты, лып итеп урындыкка утырды, Штрубэның өстәлдә яткан сурәтенә бакты һәм:

— Иптәш командир, сез шаяртмыйсызмы? — дип сорады.

— Һич юк, лейтенант. — Ничипорович челемендәге көлне баш бармагы белән баскалады, янә көйрәтеп җибәрде дә кабат әрле-бирле йөренә башлады. — Билгеле, бик хәтәр эш бу. Әмма бүтән чара юк. Без сиңа ышанабыз, Жан... Моны син генә булдыра аласың. Бары тик син генә!

Жан аяк өсте басты:

— Сынап карармын, иптәш командир!

— Отлично, Кабушкин. Хәзер кичекмәстән эшкә керешик. «Зур җир» «көтүчегә» ачкыч табарга кирәк һәм моны мөмкин эш дип саный. Тик сак бул, Жан: Штрубэ — акыллы һәм үткен кеше. Хәрәкәт планы болай...

...Шулай итеп, Жан сәүдәгәр булып китте. Александраны казинода гына күргәләде. Алтын тешләр куя торган Лена белән ешрак очрашты, менә дигән өс-баш киемнәре тектерде, шәһәр уртасындагы әйбәт квартирага күчте — эре коммерсант әллә кайда, читтә яшәмәс бит инде!..

Жан Штрубэны ерактан күзәтте. Танышып китеп, максатка ирешү өчен кешене яхшылап өйрәнергә кирәклеген аңлый иде ул. Штрубэның холкы ниндилеген, нидән кәефе күтәрелүен яки төшүен, нәрсә яратуын, характерының йомшак ягы нәрсәдә икәнлеген ачыклап бетергәч кенә эшкә керешә Жан. Әлбәттә, бүтән офицерлар кебек үк Ганс Штрубэ да алтын яратадыр. Бу җимгә кабуы бик мөмкин аның. Тик алтынны ничегрәк тәкъдим итәргә? «Менә сиңа, агай-эне, алтын, ә син моның бәрабәренә Мәскәүгә җибәрү өчен, тимер юлдагы поездлар хәрәкәте турындагы кыйммәтле мәгълүматларны безгә бирә торырсың», — дип шәрран ярып булмый ич инде.

Жан станция тирәсендә ешрак әйләнгәли башлады.

Тимер юлчылар өчен «урак өсте» иде. Төзәтергә чират көтеп, унга якын паровоз депо капкасы янында тора. Бер ишләре чош-пош иттереп сирәк-мирәк хәл ала, ә икенчеләре мәеттәй сап-салкын, тынсыз. Димәк, алар биредә кимендә өч-дүрт тәүлек капка төбен саклый инде! Тышта шул чаклы булгач, депоның эчендә алма төшәрлек тә урын юк дигән сүз.

Жан Сайчик карт табарга кушкан тимер юлчыны күзләде. Аның янына гади киемнән генә килде, билгеле. Әбәт вакытында сыра чөмерә-чөмерә сүз ялганды. Кирәген генә сөйләде аңа тимер юлчы. Соңгы көннәрдә паровозлар депога күбесенчә подшипникларын эретеп кайталар икән.

— Берлиннан җибәрелә торган баббит эретмәсе начар,— диде тимер юлчы.— Шуңа күрә әнә күпме паровоз депо төбендә. Тимер юлчы сынаулы итеп Жанга карады, сакалын сыпырды һәм күз кысты. Ул як-ягына каранып алды, аннары ярым пышылдап:

— Без дә тырышмыйбыз түгел, сынықка сылтавы да булгач, бигрәк тә... Җиңүне якынайтасы килә. Безнең җиңүне!..

— Ә начальнигыгыз Штрубэ әфәнде ничек соң, бик чәпчемиме? Һәммәгезне стенага терәттерәм, дип янамыймы?

— Халык алдында кылчыклы. Ә ялгызы булганда алай бик зыянлы күренми, тыныч.

Штрубэ депода һәр эшкә тыкшынып йөрми икән, килгән чакларында дәшми-тынмый карап әйләнә дә: «Лючше нада рабатайт!»— дип китеп бара. Күбрәк үз кабинетында кәгазь укып утыра икән. Атнага өч тапкыр җыеп киңәшмә үткәрә. Кабул итү көннәре — сишәмбе белән җомга. Кабинет ишеге янында һәр вакыт төзәтенгән-ясанган секретарь кыз утыра.

— Ул кызның исем шәрифләре ничек?

— Раиса Александровна...

— Тәк...кияүгә чыкканмы?

— Юк диләр...

Жан мыегын бөтереп куйды: «Әллә без начар кияүме? Буй-сын — метр да туксан тугыз, авыз-борынны да ходай кызганмаган. Салпы якка салам кыстыра беләбез. Бүләккә саранланмабыз... Барысы да шома тәгәрәсә, чибәр секретуткасы янына нинди шәп кавалер килеп йөрүен шеф-немец күрми калмас... Аннары инде Жан, Штрубэга баш иеп, аның башкода булуын үтенер. Тиздән үткәреләсе туенда урынны иң түрдән бирәчәген әйтер, истәлеккә дип кыйммәтле бүләкләр тәртәр. Берлинда яшәүче фрау Штрубэны да өлешсез калдырмас. Мул яудырыр Жан туй бүләкләрен. Аннары инде җаен туры китереп сүз башларга да була: гонорар түләнде, Штрубэ әфәнде, эшкә керешергә вакыттыр. Шуңа чаклы чибәр Раиса кулыннан үтә торган кәгазьләрдән сөзеп алыр нәрсә чыкмагае әле. Бүләкләрне, әлбәттә, Лена өстәл тартмасыннан алырга туры килер. Анда алтын алка, беләзекләр җитәрлек. Барыбер тоныкланып тик яталар. Лена берсен дә кызганмаячак...»

Пропусклар бюросында эшләүче таныш егет Штрубэ секретаршасының адресын тиз табып бирде.

Жан, сәгате-минуты белән дигәндәй, Раисага шалтыратты, борчакны кушучлап сипте һәм фәлән җирдә көтәрмен диде. Кыз риза булды. Билгеләгән сәгатькә килде, казинога кереп мороженое ашадылар, затлы шәраблардан авыз иттеләр. Александра, тагын нәрсә китерергә боерасыз, әфәндем, дип йөгереп кенә йөрде... Кич Жан кызны өенә чаклы озатып куйды. Икенче көнне дә эштән кайтканын көтеп алды. Йомшак ак кулын үбеп, өенә кертеп җибәрде.

Раиса Александровна чыннан да шәп кыз иде. Жан аны беренче караштан үз итте, кыз да магнитлангандай аңа тартылды. Күзләре

гел жемелдәп, битләре янып торды. Кыйммәтле бүләкләр, шәраб тыйнак кызны тәмам исәрләндерделәр. Ләкин Жан һәр вакыттагыча инсафлы булып кала белде. Бу аңа булган ышанычны тагын да арттыра төште. Кыз, кызарып пешкән җиләк кебек, тәмам өлгереп җитте. Озатып калганда егетнең муенына сарылып, җибәрмичә тора иде. Нәрсәдер әйтергә тели иде... Ә Жан аны нәзакәтле генә үбә дә, кул болгый-болгый китә. Күрше-күлән аларга бүрегә карагандай карый. Раиса, куркып, бүлмәсенә кереп бикләнә. Икенче көнне иртән үк Жанга шалтырата, янына чакыра. Жан, кырык эше кырык җирдә кырылып ятса да, «сөеклесе» янына килә, эре сәүдә компаниясе вәкиленә хас юмартлык белән һәммәсенә бүләкләр өләшә.

— Бәхетле син, Раечка,— дип пышылдыйлар кызның хезмәттәшләре.

Жан Раиса янына утыра, хуш исле сигарасын кабызып җибәрә. Парлап тарталар. Бераздан Раиса, кияү бүләге итеп, бер тартма сигараны Штрубэга кертеп бирә.

Шул арада Жан ике-өч мәртәбә фотоаппаратын чыртлатып өлгерә, газета укырга керешә. Кыз чыккач, аның күзләренә карап йотыла, чын кавалерларча, бармак очларыннан гына тотып, урынына китереп утырта.

Билгеле инде, Жан кәләшенең матур тезләренә тикмәгә генә орынмады: шундый чакларда, «коммерсант» буларак, әле яңа гына шеф биреп чыгарган эш кәгазьләренә дә күз салгалап алды ул.

Берлинга җибәрә торган телеграммаларында Штрубэ, гәрчә баббитның начар сыйфатлы икәнлеген белеп торса да, күләмне арттыруны гына сорый иде. Әйтерсең лаборатория анализлары бөтенләй юк. Шеф аларны гүя күрми. Президент канцеляриясенең начальнигы Ганс Штрубэ ни өчен болай эшли? Анализ нәтиҗәләренә басым ясап күрсәтсә, Берлинда шундук баббитның сыйфатын яхшырту өчен чара күрә башларлар һәм, билгеле инде, бу кыйммәтле чималга кытлык кимер иде. Подшипниклар яхшы сыйфатлы баббиттан коелган булса, паровозлар депода ремонт көтеп ятмаслар иде. Жан моннан шундый нәтиҗә ясады: Ганс Штрубэ, мөгаен, үзенә әшнә булган сәүдәгәрләрнең товарын, начар сыйфатлы булуын белгән көенчә, үткәрә тора, ул шуны тели. Кул кулны юа, табышның бер өлеше Ганс кесәсенә керә. Төп максат табыш алу гынамы икән? Башка бер ният юкмы икән? Ярар, немец безнең җиңү өчен тырышмасын дип юрыйк. Алай булганда да, Штрубэ, начар сыйфатлы баббитны алып ятып, тимер юлда тәртипсезлек дәвам иттерелүгә күз йомучы булып чыга бит.

Бу инде уен-муен түгел, Штрубэга каршы Жан кулындагы берәгәйле козырь!

Жан отряд командиры Ничипоровичның: «Штрубэ акыллы, үткен кеше»,— дигән сүзләрен исенә төшерде.

— Карап карыйк,— диде ул үз-үзенә,— бу карт чуртан саңагыннан эләктергәч нишләр икән?

Ә шул арада чибәр Раисаның гыйшкы һәрбер таныш-белешенә хәтле билгеле булды. Көяз бай кияүне кызның шефы да күрми калмады, әлбәттә. Һәм ошатты ул безнең Жанны, ошатты.

Туй ясарга да вакыт җитте шикелле: Раиса кияүгә чыгарга риза. Тик Лена гына Минскида юк. Ул атакай заданиесе белән йөри, менә-менә кайтырга тиеш. Ләкин юк та юк. Ә вакыт көтми. Пешкән җимешне өзелеп төшәр чагында кабуың хәерле. Юкса бозылуы ихтимал. Һәм Жан эшне ялгызы гына башкарып чыгарга булды.

Менә бер көнне Раиса, шат елмаеп, икесенә дә кагылышлы бик мөһим бер мәсьәләне хәл кылу өчен, кияүен шефы янына кертеп җибәрде.

Ганс Штрубэ кырык-кырык биш яшьлэрдэге, ак чырайлы, калын муенлы, алтын кысалы күзлек кигэн, бүкэндэй нык гэүдэле кеше, күн белэн тышланган йомшак кэнэфигэ кырын ятып, тэмле кофе чөмерэ иде. Өстэлдэге мэрмэр шэрэ хатын-кыз сыны алдында калын сигара төтенлэп ята. Жанны күрүгэ симез биттэ елмаю чагылды:

— О-о, кияү килэ! Пажальсто! На свадьбу приглашаль, эйеме?

— Туй булмый, начальник эфэнде,— диде Жан.

— Ничек булмый? Була! Бик була! Раиса сказаль... Ул бит во,— Ганс симез бармакларын иренэнэ тидереп үбү галэмэте ясады:— Пешкэн җилэк, то-есть, кап та йот...

Жан өстэл янына килде:

— Туй булмый. Чөнки мин өйлэнгэн кеше,— диде ул Штрубэга кырыс карап.

— Өйлэнгэн? Өйлэнсэ, война спишет. Тагын өйлэн.

— Ярамый.

— Аңламыйм. Нэрсэсе ярамый? Кем соң сез? Мэзэкчеме?! — Штрубэ түшэмгэ карап хихылдады: — Ха-ха! Раиса янында мэзэкче... Булмый бу! Ул синнэн акча таптыра. Только акча! Күп-күп акча! Бүтэн берни булмый!..

— Була! — Жан кулын кесэсенэ тыкты, кэнэфигэ якын ук килде һэм, Штрубэнең төссез күзлэренэ текэлеп карап, өзек-өзек итеп: — Мин — совет разведчигы. Мэскэү заданиесен үтэү өчен килдем,— диде.

Немец калтырамады да, агарынмады да. Гажэплэнде генэ:

— Маскау? Задание? Менэ мэзэк — кияү!..

— Юк, Штрубэ эфэнде, мэзэкче түгел мин. Минем белэн мэзэк хэерле түгел. Кабатлап эйтэм: Мэскэү заданиесе белэн килдем мин сезнең янга. Сез я безгэ эшлисез, я...

Штрубэ гажэплэнеп Кабушкинга карады. Чынаягыннан кофе кабып алды да, ак телефонга ымлап, тыныч кына:

— Я, хэзер үк гестапога шалтыратам,— диде.

— Исегезгэ төшерим: сезнең ул гестаподан килеп җиткэнче, мин үзегезне өч тапкыр теге дөньяга җибэрергэ өлгерэчэкмен. Шулай түгелме? Тик моның белэн генэ эш бетми эле.— Жан телеграмма копиялэрен һэм лаборатория анализлары кэгазьлэренең берничэ копиясен Штрубэга тоттырды.

Ганс бу кэгазьлэргэ телэр-телэмэс кенэ күз йөртте, симез битендэ борчылу пэйда булды.

— Сез кыю разведчик. Үткен зиһенле. Шулай да... Провокатор түгеллегегезгэ гарантия кайда?

— Кичке алтыда гестапо белэн янэшэдэге аптекага керегез. Лэкин кисэтеп куям: гестапога шалтыратасы түгел. Койрык белэн килсэгез, бу кэгазьлэрнең төп нөсхэлэре, тиешле аңлатмалар белэн ныгытылып, кирэкле җиргэ озатылыр. Анда да үткен зиһенлелэр табылыр. Нэтиҗэ чыгара белерлэр. Күнсэгез, буш булмассыз. Алтын дисез икэн — алтын булыр...

— Яхшы, уйлап карармын,— диде Штрубэ.

Жан баш иде һэм бүлмэдэн чыкты. Билгелэнгэн вакытта очрашу урынын күзэтэ-күзэтэ: «Килерме яки килмэсме?» — дип барыбер борчылды ул.

Э Штрубэ килде...

Һэм берничэ көннэн соң «Үзэк» тимер юллар президенты канцеляриясе начальнигы Ганс Штрубэ язмалары буенча Белоруссия урманнарында төзелгэн түбэндэге яшерен радиограмма Мэскэүгэ очты: «28 тэүлеккэ йөк уздыру. Гаскэрлэр — 2653 вагон, танклар — 851, автомобильлэр — 2877, патрон һэм снарядлар — 969 вагон, ягулык —

770 цистерна, төрле калибрдагы туплар—301 вагон, азык-төлек—5650 вагон».

Озакламыйча Ганс Штрубэ тимер юл буйларына урнаштырылган күп санлы ныгытмаларның төгәл планын подпольечыларга бирде. Бу планда барлык дзотлар, бункерлар, траншеялар, зенит һәм кыр артиллериясе туплары һәм шундагы хәрби частьларның номерлары ачык күрсәтелгән иде. Моның өстенә Минскида мина һәм шартлаткыч җайланмалар куелган бик күп объектларның исемлеген, аннары сызымнарын да китерде ул. Бу кыйммәтле мәгълүматлар да ашыгыч рәвештә Мәскәүгә озатылды. Аларны Җан, фронт линиясе аша чыгып, Совет командованиесенә үзе тапшырды.

## Дошманга тынгы юк

«Зур җир»дә булып кайтканнан соң Җанга урмандагы иптәшләре арасында рәтләп ял итәргә туры килмәде: кабат Ничипорович чакыртты.

— Ашыгыч эш чыкты, лейтенант,— диде ул.— Минскида безнекеләрнең хәле мөшкел. Гестапо «көтүче»безнең эзенә төшкән. Асканнар, имеш...

— Баббит өченме әллә...

— Шул бугай.

— Алай булса бу ярты бәла генә...

— Һәммәсен ачыкларга кирәк. Һәм сак була күр, Җан. Чамадан тыш тәвәккәлләмә. Азрак медикаментлар тапсаң, шул җитә хәзергә.

Җан Минскига җитәргә унбиш чакрымлап калгач кына аттан төште.

Александра бүлмәсендә өс-башын тәртипкә китергәч, кибеткә юнәлде. Ишек янында кат-кат йөткереп, кибетче белән күзгә-күз караштылар да тыныч якка үтте. Җан артыннан ук кибетче дә керде. Тәмам төсе качкан иде аның.

— Нинди яңалыгың бар?

— Күпләрне эләктерделәр. Хәтта Раисаны да... Депода комиссия дә ревизия. Штрубэ нык торган. Барыбер... эшенә салкын караганы һәм взятка алганы өчен...— Кибетче, муенына элмәк салу галәмәте ясап, тынып калды.— Сайчик та капты. Качып барганда атып яралаганнар.

— Хәзер кайда?

— Беренче больницада.

Җан мәгънәле итеп кибетчегә карады. Тегесе тиз аңлап, башын чайкады:

— Палата ишеге янында гөрзиле хәсис тора...

Өлкән яшьтә булуына карамастан, подпольечылар өчен күп эш майтарган горком члены Сайчикны Җан яхшы белә иде. Карт аңа һәр вакыт әйбәт киңәш бирде, ярдәм итте. Әнә хәзер үзе ярдәмгә мохтаҗ...

— Ничек тә йолып аласы иде бит...

— Син тотынсаң, уйлап карарга була,— диде кибетче.— Ярдәмчеләр тәкъдим итә алам.

Кабушкин кирәкле кешеләр белән очрашты. Сайчикны больницадан качыру өчен әллә ничә төрле хәйлә корды. Ниһаять, берсенә тукталып, аны гамәлгә ашырырга ниятләде...

Менә барысы әзер. Җаен туры китереп, Сайчикның үзенә белдерәсе һәм аның палатадан бәдрәфкә дигән булып чыгуын көтеп аласы кала. Әйтү ансат, моны гөрзиле хәсис сизмәслек итеп башкарырга

кирәк бит. Уйлаша торгач, җае табылды. Сайчикны саклаучы хәсис җилбәзәгрәк нәрсә икән. Димәк, сөйләштереп торыр өчен чибәр Лена-ны больницага кертергә кирәк. Янәсе, сеңелесе янына килгән. Егетне ошаткан, шуңа аңардан күзләрен ала алмый. Аның назлы елмаюлары шәрабсез исертергә тиеш.

Менә Кабушкин белән Лена урамда шартлы сигнал көтәләр. Больницаның икенче катындагы тәрәзә төбенә чәчәкле гөл куелырга тиеш. Бу: Сайчик һәммәсен белә, операцияне башларга мөмкин дигән сүз.

Жан немец офицеры булып киенгән иде, авызында кыйммәтле сигара, борын өстендә калын кысалы күзлек, кулында әйбәт планшет. Янындагы Леночканың киемнәре аеруча бай, купшы. Өстендә билләре өзелеп торган, ак челтәр якалы бәрхет тышлы тун, ачык муенында алтын чылбырлы медальон, башында шәмәхә каурыйлы мех бүрек, аякларында биек үкчәле әйбәт итекләр.

Кинәт тимер юл буенда көчле шартлау гөрселдәде. Күккә ялкын бөркелде. Бер-бер артлы салмаграк гөрселдәүләр башланды — болары вагоннар шартлавы иде. Жан канәгать төстә Леночкага карады. Елмайды. Тегесе баш какты. Күзләрендә шатлык җемелдәде. Тирә-юньдә сиреналар үкерде, машиналар ду килеп вокзал ягына ашыкты.

Урамдагы халыкның ябык чыраенда тыелгысыз куаныч балкый иде. Кешеләр, вокзал ягына ишарәләп, бәйрәмдәгечә кул кысышалар, күр сөйләшәләр. Тик алар Лена яныннан үткәндә кинәт кырысланалар, күзләрендәге мәсхәрәле караш, усаллыктан кызның тәненә чирканыч йөгерә иде.

Узгынчыларның берсе, теш арасыннан гына:

— У-уу, өстерәлчек! Тукта, синә да килеп җитәр алар!—дип китте.

Лена, куркак яшь боландай тетрәнеп, Кабушкинга сыенды. Ул кай-нар итеп:

— Миннән җирәнәләр! — дип пышылдады.

Жан аны тынычландырырга ашыкты:

— Игътибар итмә, Леночка. Алар синең хакта бер нәрсә дә белмиләр бит. Матур этикеткаңа гына карыйлар.

— Ягъни киемнәремә димәкче буласыңмы?

— Әйе, кадерлем...

Алар, ашыкмыйча гына атлап, менә икенче кат инде больница янына килделәр. Шартлы сигнал һаман юк иде.

Ниһаять, тәрәзә пәрдәсен тартып куйдылар: чүлмәккә утыртылган гөл яктыга үрелгән иде.

— Жан...

— Нык бул, Леночка!..

Лена больница капкасыннан кереп киткәндә Жан бераз гына хәвефләнеп тә алды: кыз югалып калмасмы? Ни генә әйтмә, партизанка булса да, хатын-кыз бит ул. Дөрес, аның кебек меңнәр җәзалаулар, үлем белән янауларга карамастан, теләсә нинди заданиене үтәргә баралар. Әнә күршедәге аллеяда гына фашистлар сугышның беренче атналарында ук медсестра Шербацевичны уналты яшьлек улы белән янәшә аскан иделәр. Биредәге фонарь баганаларында исә егерме алты подпольечы ун көн буе җилдә тирбәлеп торды. Совет урамындагы бакчада ике йөздән артык кеше атып үтерелде. Халыкны куркытыр өчен мәетләрне штабельләп өеп атна буе тоттылар. Тик дошманнан үч алучылар саны барыбер кимемәде. Димәк, халык белән үлемсез идея идарә итә. Димәк, халык бу идеяне дөньядагы бар нәрсәдән өстен саный. Шуңа күрә җиңеп чыга. Бу Ленага да көч бирер.

Больница тәрәзәсендәге шартлы сигналны кабатлап, ак пәрдәне төшереп куйдылар. Жан сәгатенә карап алды һәм бакча артындагы тыкрыкка ашыкты. Бераздан ул Сайчикны машинага утыртып алып китте.

Икенче көнне Жан Александрага су җылытырга кушты. Су җылынып чыккач, аның кулына кәгазь кап тоттырды да:

— Миңа бу нәмәрсәкәй минем чәчне чегәннекедәй кара итәргә тиеш, — диде.

Өйдән кара бөдрә чәчле кеше чыгып китте. Ул тыныч тыкрыклардан шәһәр уртасындагы мәйданга юнәлде. Элек Хөкүмәт йорты дип йөртелгән зур бина каршында — аптека. Жан шунда юл тотты. Бозланган пыяла ишекне ачып керде. Күзлекле аптекарь, күшеккән кулларына өрә-өрә, кәгазьләр актарып утыра иде. Дару алырга килүче соңгы кеше чыгып киткәч, Жан ике рәт тамак кырды, ике рәт йөткерде. Аптекарь күтәрелеп карады да, түрдәге ишеккә ымлады. Бераздан ул Кабушкинны бәләкәй тәрәзәле келәткә кертте.

Исәнләштеләр. Жан гадәтенчә шаяртып алды, партизан отряды хәбәрләрен сөйләде. Аннары төп эшкә күчтеләр.

— Медикаментлар кирәк. Мөмкин чаклы күбрәк булсын, — диде Жан.

Аптекарь ике стена арасыннан капчык тартып чыгарды.

— Менә барысы шунда.

— Нибары шулмы? Бер түмәр белән землянка җылытып буламыни. Ә мамык? Бинтлар?

— Кырып-себереп киттеләр, — диде аптекарь. Ул тәрәзәгә ымлады. Анда, ишегалдындагы склад янында, солдатлар зур йөк машинасына әрҗәләр, капчыклар төйиләр иде.

Кабушкин:

— Кая илтәләр? — дип сорады.

Аптекарь җилкәсен генә сикертте.

— Машина Борисовтан килде, димәк, шосседан кайтачаклар...

— Сөйлә, сөйлә, — диде Жан. — Ошый миңа бу уең. Кызыктыра бу уең!

— Немецлар ташландык чиркәү янындагы бәләкәй ресторанга туктаячаклар, әлбәттә. Анда чатан Глафира карчык офицер әфәнделәр өчен ниндидер хуш исле үләннәр һәм борыч салып, самогон әзерли...

— Нинди чатан карчык? Каян килгән ул? Аны безнең чанага җигәргә мөмкин түгелме?

— Икеле. Сугыш башланыр алдыннан гына килеп чыккан иде ул. Ниндидер изге Варвара чиркәвен торгызу өчен хәер җыя. Чиркәү җиһазларын да ерактан ук китергән диләр.

— Болары чепуха... — Жанны бу минутта ниндидер Глафира карчык һич кызыксындырмый иде. Яралы партизаннар өчен медикаментлар кирәк. Шуңа кайтты ич ул Минскига. Командирның приказы үтәлергә тиеш.

— Рәхмәт, дускай сиңа. Бу капчыгыңны урынына яшер. Соңгы запасыңны алырга кулым күтәрелми. Бәлки җан биргәнгә җүнен бирер...

* *

Юлларда һәм тротуарда кар эри башлаган иде инде. Каралып торган хәрабәләр өстендәге кар бүрекләре кояшта алмаздай җемелди. Вакыт-вакыт түбә кырыйларыннан борынгы гаскәр сөңгеләрен хәтерләткән бозлар челтерәп төшә. Җимерек өй карнизларыннан, моң тулы рамсыз тәрәзә төпләреннән тамчылар тама.

Яз килә. Нинди булыр һәм ни алып килер ул буйсынмас Белоруссия халкына? Фашистлар үзләрен шәһәрдә чын хуҗалардай хис итәләр. Әнә икесе алпан-тилпән атлап, туйдан кайткандай җырлый-җырлый килә. Шәп табыш инде бу исерекләр! Кесәләрендә партизаннарга бик

тә кирәкле увольнение кәгазьләре дә бар инде боларның... Ләкин урам чатыннан, салмак атлап, өч автоматчы чыкты. «Патруль!» — дип сагаеп калды Жан. Тәненә салкын кырмыскалар йөгергәндәй булды. Читкә борылыргамы? Дөрес, куркыр урын юк, документлары тәртиптә Кабушкинның. Шулай да... Тышкы кыяфәте бернинди шик-шөбһә уятырлык түгел, бүген ул кабат көяз парикмахер булып киенгән иде — өстендә җәй-көз кия торган әйбәт пальто, ефәк күлмәгенең ак якасына кара күбәләк-галстук кунаклаган, башында шундый ук чем-кара эшләпә, кулында кыйммәтле хушбуйлары һәм хушбуй сиптергече булган кечкенә күн сумка.

Юк, бу юлы туктатмадылар. Ә исерек немец солдатларын тыныч тыкрыкта эләктерергә соң иде инде. Төяүле машина менә-менә юлга чыгарга тиеш. Чатан карчык янына барырга кирәк, анда күз күрер...

Бер танышы торган өйдән Жан авыл агае булып киенеп чыкты. Аны хәзер танырлык түгел иде: өстендә кат-кат ямаулы иске бишмәт, катып беткән сырган чалбар, аякларында тузган итекләр, аркасындагы киндер капчыкта чүпрәккә төрелгән тоз һәм ике кисәк балчыктай кап-кара сабын. Янәсе ул бу байлыкларны базарда дуңгыз мае бәрабәренә алмаштырып алган да, хәзер үз авылына кайтып бара. Мондый җир кортына алла йорты алдына тукталып чукыну фарыз һәм юлга чыгып киткәндә диндар карчыкның сихәтле бер касә хәмерен каплап кую да гөнаһ түгел.

Карчыктан самогон сатып алып, шәһәр читендәге контроль өе янында теге машинаны көтеп торырга кирәк иде. Часовойлар кәгазь тикшергән арада, юл уңае белән авылга чаклы утыртып кайтсын өчен, шоферны «салдырырга» да, урманга кергәч, фашистларны дөмектереп, машинаны агай-эне торганрак сукмакка борырга исәпли иде Жан.

Сөйләшенгәнчә, Саранин белән чиркәү янында очраштылар. Кыйшайган чиркәүгә карап бил бөгә-бөгә чукынырга туры килмәде: урам чатыннан ютәлли-ютәлли иске йөк машинасы килеп чыкты.

Жан ачынып: «Эх, шайтан алгыры! Өлгереп булмады!» — дип уйлады.

Йөк машинасы кайчандыр монахлар тамак туйдыра торган йорт каршысына тукталды.

— Бәлки безгә офицер әфәнделәрдән үзләре белән алып кайтуларын сораргадыр? — диде Жан Саранинга. — Салып утырганда юмартрак булмаслармы...

— Сынап карыйк... Тульке икеле...

Жан пычрак пивнушкадан аермасы булмаган тәтенле бүлмәгә үтәргә чамалаган иде дә, ишек янында ук туктаттылар.

Кызмача немец якага ябышып:

— Вшивый сабака! — дип акырды. — Век!..[1]

Грузовикка эләгү турында уйларга да юк иде.

Жан Саранин янына килде.

Шулчак артта берәү кызганыч тавыш белән:

— Бәгырьләрем, алла йортын төзәтү өчен ярдәм итсәгез лә! — диде. — Чиркәү җиһазларын бә-әк ерактан — Казаннан ук китергән идем. Саранланмагыз, бәгырьләрем. Теге дөньяга барасыбызны уйлагыз...

Жан кисәк борылып карады. Артыш таягына таянып, карчыганыкыдай кәкре борынлы, җыерчыклы битле, күзлекле бер карчык, сәдака сорап, кулын сузды.

— Тамак чылатырга дисәгез, сезгә катырагын да табармын, боерган булса.

Кабушкин күзләрен зур ачып:

---

[1] Ычкын моннан! (нем.)

— Глафира Аполлоновна! — дип чак кына кычкырып җибәрмәде. — Теге чакта Пелагея Андреевна өендәге тимер сандыкның нигә бушап калуы аңлашыла хәзер! — дип уйлап алды. — Алтын тәреләр, көмеш савытларны бу үләт козгыны очырган икән! Инде менә бирелдәге чиркәүне торгызырга йөри... Жан әчке кесәсеннән ике немец маркасы алды да, як-ягына карый-карый, карчыкка сузды.

Глафира Аполлоновна, комсызланып, акчаны эләктерде, аннары алъяпкычы астыннан яртыны чыгарды.

— Әчегез, күгәрченкәйләрем, исәнлеккә-саулыкка! Сихәтле булсын өчен, нинчә төрле дару үләне генә салдым.

— Безгә нәкъ шундые гына кирәк, әбекәй. Киттек, Христофор. Юл кешесенең юлда булуы хәерле.

Алар тикшерү өенә таба киттеләр.

— Өлгерербезме икән? — дип пышылдады Саранин.

— Өлгерергә тиешле...

Көн кичкә авышкан иде инде. Каршыдан ачы җил исә. Кар себертә. Болар бик кулай булачак. Тактадан кормаштырган кечкенә өй стенасына ышыкланып җылынып алырга, шунда узгынчы машинаны көтеп торырга сәбәп чыга. Глафира түти турындагы уйлар Жанның кабат хәтерендә яңарды. Хәйләкәр тиктормас карчык. Коточкыч диндар. Элек нинди булса, хәзер дә шул ук. Ләкин бик бетәшкән. Күпкә түзмәс, аягын сузар...

Тикшерү өе янына дәшми-тынмый гына килделәр. Каршыга автоматлы ике сакчы чыкты. Өченчесе эчтә калган икән — анда нәрсәдер дөбердәп куйды.

Жан: «Күбрәк шул», — дип уйлап алды.

Рөхсәт кәгазьләрен тикшерергә керештеләр. Озын чандыр немец һәм кып-кызыл чырайлы полицай кичкырын сәфәр чыккан юлчыларга шикләнеп карыйлар иде.

Кызыл чырайлы полицай:

— Ни шайтаныма дип төнгә каршы юлга чыктыгыз? — диде.

Немец та ризасыз төстә мыгырдады.

— Менә-менә грузовик килеп җитәргә тиеш, әфәнделәр, — диде Жан. — Килешенгән — утырып кайтачакбыз... Җил нинди әче... Бәлки сездә касә-фәлән бардыр, ә? — Кабушкин куен кесәсеннән шешәсен тартып чыгарды. — Сабый күз яшедәй чистасы, әфәнделәр. Борычы да салынган. Калада авыз итәргә вакыт тимәде. Хәзер менә юл аягына җылынып аласы иде...

Полицай, иренен ялмаштырып, часовойга карады.

Тегесе:

— Шнапс?.. Гут, гут, гут! — диде дә өйгә керергә чакырды. — Битте...[1]

Жан белән Саранин күзгә-күз карашып алдылар.

Өй эчендә салмак кына итеп өч тапкыр ату тавышы ишетелде... Медикаментлар төягән йөк машинасы юлга аркылы куелган киртәгә килеп төртелгәч, документлар тикшерергә өйдән икәү чыктылар. Жан, исерек шоферга күз кырые белән генә карап, аның юл кәгазьләренә текәлде. Саранин, автоматын әзер тотып, кузовка менде.

Жанның сул кулында сәмруг кош сурәте төшерелгән кәгазь, уң кулы исә кесәсендә. Кузовтагы юлдашы тамак кыруга, Жан кесә аркылы гына шоферга атты. Аннары янәшә утырып йокымсыраган немец авып төште.

Йөк машинасы, эче төтен бөркеп, җай гына кузгалып китте.

Жан, Казанның Восстание бистәсендә автомобиль йөртергә өйрәнгән чакларын исенә төшереп, елмаеп куйды.

---

[1] Аракымы? Яхшы, яхшы. Рәхим итегез!

Күпләп кулга алулардан соң Минск подполье үзәге урманга күчте һәм, шуннан торып, дошманнан үч алучы халык көрәше белән идарә итәргә керешге. Шуңа күрә Жанга хәзер шәһәрдә ешрак булырга туры килә иде. Бу вакытта вграк партизан отрядлары, эре берләшмәләргә оешып, илбасарларга ярыйсы гына зыян китерә башлаганнар иде инде. Башында Гитлерның урынбасары гаулейтер Вильгельм фон Кубе торган Белоруссия Генеральный комиссариаты, партизаннар белән көрәшү өчен, Берлиннан өстәмә рәвештә гаскәр сорарга мәҗбүр булды. Кырык мең кешелек механикалаштырылган эре хәрби берләшмә белорус урманнарын «тарарга» җибәрелде. Әмма партизаннар оста хәрәкәт иттеләр: төп көчләрдән бик читләшеп, җәза отрядларына һич көтелмәгән төбәкләрдә кыю һөҗүмнәр ясадылар.

Партизаннарга «Зур җир» булыша торды. Самолетлар төн саен диярлек корал, сугыш кирәк-яраклары, медикаментлар китерделәр. Үч алучыларның аяусыз көрәше Минскида көчәйгәннән-көчәйде. Жан һәм аның иптәшләре, киек кенә йөри торган урман сукмакларыннан килеп, калага үттеләр, подпольедагы дусларына корал һәм мина китерделәр. Төнлә казармаларга ут капты, хәрби складлар, фронтка ашыгучы тимер юл составлары күккә очты.

Мондый тәвәккәл эшләр өчен илбасарлар җирле халыкны мәрхәмәтсез төстә җәзага тарттылар. Ләкин бу хәл патриотларны куркытмады. Геббельснең Совет властена тупас яла ягуны күздә тоткан үгет-нәсихәте дә көткән нәтиҗәне бирмәде. Ниһаять, белорус халкының аңын милләтчелек чире белән агуларга керештеләр. 1941 елның ахырында сатлык җаннардан төзелгән «Белорус халык ярдәмләшүе» дигән нәмәрсәкәй, гитлерчыларның мәкерле күрсәтмәсенә таянып, «аңлы белорусларны» полиция оборона корпусына язылырга чакырды. Бер үк вакытта фашистларның яшь белорусларны совет йогынтысыннан арындырып чиста ареецларга якынайтуны күздә тоткан «Белорус яшьләре союзы»н төзү хәстәре алып барулары да билгеле булды.

Подпольедагы партия комитеты халык арасында аңлату эшләрен көчәйтә төшәргә һәм Белоруссиянең баш җәллады гаулейтер Вильгельм Кубены, өлкә комиссары Людвиг Эренлейтерны, өлкә жандармерия башлыгы Карл Каллны, зондерфюрер Иоганс Эркаченконы, милләтче-фашист житәкчеләре Акинчиц, Козловский һәм башка хыянәтчеләрне юк итәргә дигән карарга килде.

Жан, оператив төркем житәкчесе буларак, белорус халкы исеменнән Вильгельм фон Кубены җәзалап үтерергә задание алгач, бу кабахәт җанны теге дөньяга олактыру өчен җай эзләргә кереште. Белоруссиянең иң явыз хакимчесе һәвәскәр әдәбиятчы да икән — ул бәдбәхет бер үк каләм белән чиле-пешле кәмит тә язган һәм һич гаебе булмаган меңнәрчә кешене җәзалап үтерү өчен көн саен бирелә торган боерыкларына боргалап үз имзасын да салган. Бер көнне Жан аны олы урамнарның берсендә, күп санлы нярченнәре һәм көчле сак астында барганда күреп алды. Ап-ак бияләйләр кигән гаулейтер ата-аналары белән бергә концлагерьларга озатылучы сабыйларга учлап-учлап конфет сибә иде... Шулай да бу ерткыч җәллад халыкның үзенә карата булган ярсулы ачуын сизеп тора һәм шуңа күрә бер квартирадан икенчесенә туктаусыз күчә, шәһәргә чыкканда бер үк төрле машиналар китертеп, төркем эчендә машиналарны әледән-әле буташтырып барырга куша. Ул яшәгән йортка билгесез кешеләрне үткәрмәс өчен, әйләнәтирәгә катлаулы тикшерү постлары куелган иде. Боларга өстәп, тәүлек буе атлы һәм җәяүле патрульләр, шәһәр халкы кебек гади киенгән пар-пар яшерен сакчылар йөренеп тора.

Күп мәшәкатьләрдән соң Жанга фон Кубе кәнизәкләренең берсе белән танышырга мөмкин булды. Кыз аңа гаулейтерның үз врачы тикшермичә торып, өстәлгә куелган ризыкка һәм эчемлекләргә орынып та карамавын сөйләде. Кубеның бүген-иртәгә Смолевичига барып речь сөйләргә җыенуын да шул кәнизәк әйтте. Юлда барганда аны уннарча мотоциклчылар, броневиклар саклаячак икән. Смолевичига берәүне дә җибәрмиләр, ә юлга ике яклап часовойлар куелган.

Жан ничек кенә булса да Смолевичига барырга карар итте. Моның өчен сатлык җан Козловский чыгара торган пычрак газетаның фотохәбәрчесен файдаланырга кирәк дип тапты. Ресторанда француз шәрабларыннан җитәрлек авыз иткәч, теге көнде. Алгы пыяласына махсус пропуск кәгазе ябыштырылган редакция машинасы иң әүвәл Лена торган квартир алдына туктады. Сайчикны больницадан качыруда зур тәвәккәллек күрсәткән иде бу кыз. Жан аңа шәһәр уртасыннан тыныч бер фатир табып бирде һәм Лена, биредә яшәп, подпольечыларның төрле заданиеләрен үти иде.

Кыз бүлмәсендәге өстәл ярыйсы ук мул итеп хәзерләп куелган иде. Чибәр, яшь хуҗабикә назлы елмаеп кыстый башлагач, ничек инде «юл аягына» бераз төшереп алмаска?! Мәзәкләр сөйләп ике-өч бокал күтәргәч, фотохәбәрче тәмам изелеп төште.

— Кичкә чаклы уянмас, — диде Лена. — Ике доза йокы даруы эчте.

Исерекне диванга күтәреп салдылар. Аның шәхси таныклыгы вакытлы рәвештә Жан кесәсенә күчте. Борын төбенә мыек ябыштырып куйгач, ишекне бикләп, чыгып киттеләр.

Тантанага катнашу өчен махсус рөхсәт кәгазе булган машинаны бернинди тоткарлыксыз үткәреп җибәрә тордылар. Кунак сыйлаганда шәраб авыз иткән Лена, ваемсыз көлә-көлә, чырт та чырт иттереп фотога төшереп узды. Смолевичига җитәрәк кенә туктатып документларны тикшерделәр, багажникны ачып карадылар. Әмма арткы утыргычта янәшә яткан фотоаппаратларны карарга башларына килмәде...

Тикшерү Ленаны айнытып җибәрде.

— Жан, фотографны... җыештырырга туры килерме безгә? — диде кыз.

— Ник? — диде Жан, машинаны кызулап, — туйганчы йокласын әйдә. Кубены рәсемгә төшергән өчен безгә рәхмәт кенә әйтәчәк ул.

— Соңгы тапкыр рәсемгә төшергән өчен, — дип өстәп төзәтеп куйды кыз. Жан кызның кулын сыйпады.

— Бүтән нәрсә турында уйла, кадерлем...

— Ә син үзең ни турында уйлыйсың?

— Үрдәк итеннән пешерелгән өчпочмак турында...

Кыз аны шаярта дип белеп, иренен бөрештерде:

— Нәрсә ул «өчпочмак»?

— Бик тәмле кайнар ризык.

— Кайда пешерәләр аны?

Жан, әңгәмәнең тирәнгә китү ихтималын чамалап, шаяртып котылырга теләде:

— Париж, Токио рестораннарында.

— Мин ул кайнар ризыкны пешерергә өйрәнәчәкмен!

— Мин сиңа үрдәк сатып алып кайтып бирермен. Тик аның эченнән алтын тәңкә чыкмас шул инде, Леночка. Чыкмас...

— Ул мал миндә җитәрлек, — дип масайды кыз. — Исән генә калыйк. Жан, вакыт-вакыт мин бик куркам... Әллә... соңга калганчы кирегә борылабызмы?..

— Тынычлан, Леночка. Син фәкать мин әйткәнне генә эшлә. Фәкать мин әйткәнне генә! Югыйсә... — Жанның тәвәккәл кырыслыгы шаян

елмаю белән алмашынды, — югыйсә, кайнар өчпочмагыңны авыз итеп булмас.

Смолевичига керделәр. Машина отель ягына борылды. Гестапочылар һәм полицайлар күзәтүе астында балта осталары отель каршындагы мәйданда трибуна әмәлләп бетереп киләләр иде инде.

Жан кызга:

— Мине машинада көтеп тор, — диде һәм арткы утыргычтагы фотоаппаратларны (аларның берсе куәтле мина иде) алып иңенә асты. — Баш төзәтеп килим әле...

Отельнең күңел ачу залында ул үзенә өстәл хәзерләргә кушты. Аннары папирос алырга кергән бер балта остасын янына чакырды. Берәмберәм бүтәннәре дә сыйланып чыктылар. Тагын ярты сәгатьтән әзер булган трибунаны Жан сурәткә төшерде.

Футлярдан алып иске бияләй эченә тыгылган мина трибуна баскычы астына куелган иде инде. Ул шунда үз корбанын көтеп ята бирде. Ләкин Кубе килмәде...

Билгеләнгән вакытта Жан машинасы, текә борылып, китеп барды. Ул шәһәр читенә житүгә, көчле шартлау ишетелде. Трибунаның күккә очуы иде бу.

Лена, авыр көрсенеп:

— Кызганыч, ораторсыз гына күккә очты, — диде.

— Зыян юк, Леночка,—диде Жан,—икенче юлы ычкына алмас...[1]

*
* *

Декабрь башларында көчле бураннар котырып, бик күп кар яуды. Партизаннар караңгы урманнарга киттеләр. Шуңа күрә Жан ике атнадан артык шәһәрдә күренмәде. Декабрь урталары узгач кына тушалып, ябыгып кайтты ул. Партизаннар хәрәкәте турында хәбәрдар булган Лена аны көтә иде инде. Алда хәрби әсирләрне лагерьдан качыруны оештыруга кагылышлы кичектергесез күп эшләр тора. Лена лагерь белән янәшәдәге буфетка эшкә күчте. Буфет складына әсирләр өчен кием-салым, корал китереп куелды. Онлы капчыкларның берсенә исә Матбугат йортыннан мең бәла белән алып чыгылган, листовкалар басу өчен гаять кирәкле эре кургаш хәрефләр салынган иде.

Лена Жанны шатландырачак бу хәбәрләрне әйтергә ашыкмады. (Хәбәрләрнең бик хәвефлесе дә юк түгел иде шул). Иң элек аңа каршы йөгереп чыкты да, муенына асылынып, өзелеп-өзелеп сагынуын такмаклады. Күрше бүлмәдә генә яшәүче күршеләрдә шик уятмас өчен шулай эшләргә тиеш иде ул. Алар өчен Лена белән Жан «кияү» һәм «кәләш» иделәр бит...

— Чишен, кадерлем, — диде Лена. — Кулларыңны ю, аннары чәй эчәрбез. Жылынырсың.

— Рәхмәт, матурым.

Жан өстәл янына килеп утырды. Чәй эчә-эчә эш турында сөйләштеләр. Жанның зәңгәр күзләре кысыла төште, киң маңгаенда җыерчыклар калыкты. Ул үзе очрашырга тиеш кешеләрне, аларга нинди эшләр йөкләргә кирәклеген уйлады, көрешү өчен шик тудырмый торган урыннар сайлады.

— Эре хәрефләр китерделәр диденме, Лена? — диде ул, жанланып .— Күпме?

— Шактый.

[1] Озакламыйча гаулейтер Вильгелм фон Кубены подпольечы патриоткалар Е. Г. Мазаник, М. Б. Осипова һәм Е. В. Троян, магнитлы мина шартлатып, үз квартирында дөмектерәләр. Бу батырлыклары өчен патриоткаларга Советлар Союзы Герое исеме бирелде. (Автор).

— Әйбәт. Бүген үк үз урынына озатырга кирәк булыр. Мин «кәләшем»не куркыныч янаудан сакларга тиеш.
Кызның күзләренә яшь тулды:
— Ә үз-үзеңне сакламаска тиешме? Керләреңне кемгә юарга бирдең? Күлмәк кесәсендә нинди кәгазь калдырдың?
Ах, шайтан! Ашыгычлык белән нинди дуамаллык эшләп ташлаган бит: Рудольф Вилькеның шәхси таныклыгы кесәдә киткән!.. Газраиллларга эләксә, беттең, әлмәк киертәчәкләр. Эш өчен булса икән әле. Бер гаепсезгә расходка чыгарачаклар... Жан үзен бик тиз кулга алды:
— Андый куркыныч нәрсә юк, кадерлем... Керләр турында кайдан белдең?
— Ник аларны чит кешегә бирдең... «кәләшең» була торып? Бу хәл шик уятмыймыни?
— Сиңа андый кара эшне куша алмыйм мин, Леночка!.. Теш технигы һәм пычрак керләр...
— Ирем минем, карт ябалак, техник иде. Урыны оҗмахта булсын. Үзбаш эшләргә дә, яшәргә дә өйрәтеп калдыра алмады. — Кыз Жанга буйсынучан төстә карап елмайды. Аның затлы иннек сөрткән матур иреннәре дерелдиләр иде. — Үз «киявемнең» керләрен үзем юарга тиештер ич мин. Шик уятмас өчен генә булса да...
Жан Ленаның тулы ак беләген сыйпады:
— Моның нәрсәсеннән шикләнергә? Киресенчә, бу адәм үзенең яшь чибәр бикәчен бик ярата, шуңа күрә бик тырышып саклый диярләр. Ә нәрсә, Леночка, ул хатын бирегә килдеме әллә?
— Килде. Миннән алтын даулады. Юкса, киявеңне фонарь баганасында күрерсең, диде.
— Ә син бирдеңме? Алтынны дим.
— Хәзергә юк. Сатылган хатын булырга охшый ул, Жан.
— Зыян юк, Леночка. Мин үзем аның белән исәп-хисапны өзәрмен. Ә хәзер киттек, кадерлем.
— Кая?
— Йөреп керик.
— Юлдан кайтып арыгансыңдыр ич. Ял ит.
— Зыян юк. Рәтлерәк киемнәреңне ки әйдә.
Лена өс-башын алмаштырды. Алар култыклашып чыгып киттеләр. Ял көне иде. Ваттырылмый калган чиркәүдә чаң кагалар. Тавышы ла тавышы. Күңелләрне әллә нишләтә. Моң да бар, ниндидер тылсым да бар кебек бу авазларда.
Йомшак карлы бүрек кигән хәрабәләр әкиятләрдәге торараташ булып каткан баһадирларны хәтерләтәләр. Тамчылар тама, чыпчыклар чыркылдаша. Мондый кояшлы көннәрдә элек яшьләр кар атышып уйный, урам саен кар бабайлар әвәләп куя торган иде. Бүген андый хәл юк. Башын аска игән кешеләр базарга агыла.
— Жан, утырыйк әле менә шунда. Карале, көн нинди матур!
— Син бүген тагын да чибәрләнгәнсең.
Кыз, оялып, читкә карады.
Жан кирпеч, таш ватыклары арасыннан такта сыныгы тартып чыгарды, аны элек нигез булган җиргә куйды һәм эскәмия сыман нәрсә барлыкка килде.
— Рәхим итегез, чибәрем!
Лена янәшә утырды. Дулкынланган иде ул. Жанны беренче тапкыр очраткан көнен исенә төшерде, ахры.
— Белмим, ни белән генә бетәр инде болар, — диде ул.
— Җиңү белән. Безнең җиңү белән.
— Мин ул хакта түгел... Син бу юлы озак кайтмый тордың, ә мин көтәм... хәвефләнеп... зарыгып... Син һаман шаяртасың...— Кыз моңаеп, тынып калды.

Жан аның зәңгәр күзләренә карады:
— Зарыгып көтәргә тиеш бит син. Чөнки кәләшем ич син минем. Юкса, күршеләр ни уйлар?
— Мин чынлап зарыгам, — диде кыз, еларга җитешеп. — Беләм, тиң түгеллегеңне дә беләм... Тик барыбер... Шатлыгым, бәхетем син минем... Сиңа буйсыну рәхәт... Синең белән элек татымаганны татыдым. Пакьләнеп киттем шикелле... Беләм, сизәм, син рухи яктан миннән әллә ни чаклы бай, өстен... Китәрсең дә бер... — Кыз, моңаеп, туктап калды, учына йомарлаган җепшек карны кысты. Бармак араларыннан күз яшьләредәй тамчылар тамды.
Жан, күзләрен зәңгәр офыкка текәгән килеш, яшьлек хатирәләренә чумган иде. Әйе, Светлананы хәтерләтә бу яшь ханым. Шундый кайнар тойгылы, һәммәсенә әзер... Әнә ничек моңаеп, сагышланып калды. Юк, моңа юл куярга ярамый. Моң, сагышка бирелгән кеше күпкә түземи, мәлҗери ул. Ә немец белән көрәшер өчен чакма таштай нык булу кирәк!
— Телисеңме, Леночка, күңелеңне ачам? Телисеңме?
— Ничек?
Жан, кулларын селки-селки, эфсен укыгандай итеп:

— Тарый-барый, тарый-барый...
Мин тылсымчы хәзер шундый,
Кодрәтемә чик юк! Дөнья — фани,
Гыйлем — бакый! Тьфү! Тьфү!..

Лена иренен турсайтты:
— Син һаман көләсең...
— Юк! Һич юк, — диде Жан юлда берәүне күреп. — Сүзләремә ышанмасаң, сынап карасаң да ярый. — Жан узгынчыга таба кулларын сузды:

— Шушы чибәр кызның
Теләген үтә, әй син, абый!
Елмаеп кил бирегә,
Кил һичнигә карамый!

Амин! Там-тара-ра-рам!.. Хәзер син, Леночка, аның янына барып: «Мин сине яратам!» — дигән тылсымлы сүзләрне әйт. Һәм ул, синең иркеңә буйсынып, бирегә килер. Килер! Әйткән иде диярсең, килер!
Лена, шаяртуның мәгънәсен аңлап, узгынчы артыннан йөгерде.
Кырык яшьләр тирәсендәге ярлы киемле агай, гаҗәпләнеп, борылып карады һәм, Жанны танып, кызга рәхәтләнеп елмайды да.
— Мин дә сине яратам. Кушсаң әгәр, чибәрем, җир читенә дә барам! — диде.
Хәсән Мостафович иде ул. Тиз-тиз Жан янына килде, нәзакәтле итеп исәнләште дә:
— Сезне исән-сау күрүемә бик шатмын, — диде.
— Рәхмәт, Хәсән агай... Леночка, бар әле буфетыңны ача тор. Бу агайга алай карама, дүрт баласы бар аның...
— Бишәү, әфәндем, — диде Хәсән Мостафович, елмаеп.
— Яхшы — биш диик. Шул сыбызгы борыннарга теге оннан өлеш чыгарыйк. Авыр капчыктан, Леночка, яме? Без хәзер барып җитәрбез.
Кыз, чаттан борылуга, Жан наборщикка шәһәр комитетының листовкалар чыгару турындагы карарын аңлатты.
— Фашистлар хәзерли торган мәкерле эшләрне халыкка аңлатырга кирәк, — диде ул. — Подпольечылар сафын да ишәйтәсе бар...
— Хакны әйтәсең, туган, хакны, — диде Хәсән. — Сафларыбыз сирәкләнде. Нинди кешеләребез һәлак булды бит. Омельянюк, Рубец, Короткевич...

— Күп шул! Көрәшне без дәвам итәргә, террорга террор белән җавап бирергә тиеш!

Алар Лена артыннан киттеләр. Юлда Жан дошманга булышлык күрсәтүче милләтче кабахәтләрне хурлык белән тамгаларга кирәклеген аңлатты. Ә инде редактор Козловский, бургомистр Ивановский, милләтчеләр башлыгы Акинчиц кебек сатлык җаннарның муеннарын борып ташларга вакыт, диде. Беренче булып теге калай этәч зондерфюрер Иоганс Эркаченко юк ителергә тиеш. Подпольечылар күптән ауларга йөри инде аны...

Хәрефләр ышанычлы кулларга тапшырылгач, кич Жан кер юучы хатын өенә китте. Юып үтүкләнгән киемнәрен түләп алгач, ишек бавын тоткан килеш:

— Миңа әйтер сүзегез юкмы сезнең? — дип сорады.

— Бар шул... Утырыгыз әле бераз, — диде хатын боргаланып һәм түгәрәк иңбашларын сикерткәләп. — Бераз күңел ачып алыйк дисәм, баш тартмассыз бит? — Ул назлы итеп карады, керфекләрен түбәнгә таба сирпеде, тавышы акрынайды. — Мин хәзер шул хәтле бәхетсез, шул хәтле бәхетсез!.. Япан кырда үскән кыяк сабагыдай япа-ялгыз... Сез дә шундый бугай. Ялгышмасам, сез дә кемгәдер сусыйсыз... Кер юучы итеп кенә карамагыз сез миңа, зинһар. Сугыш булмаса, консерватория бетерә идем инде мин. Барысы турында да сөйләшик әле бер рәхәтләнеп. Яхшы кешеләр хәзер шундый сирәк, шундый сирәк... Ахирәтемнән капкаларга гына алып керәм дә... Төн — безнеке! — Хатын, кабалана-кабалана башына шәл урарга керешкән иде, Жан:

— Юкка мәшәкатьләнмәгез, — дип ишекне томалап басты. — Беренчедән, мин эчмим. Икенчедән, бу кәмитне туктатырга вакыт.

— Аңламыйм...

— Хәзер аңларсыз. Минем гимнастерка кесәсеннән катыргы тышлы кәгазь алмадыгызмы?

— Юк, күрмәдем.

— Алайса, юылган булса да, ул шундадыр әле, — диде Жан хатынга текәп карап.

— Белмим...

— Ә мин беләм. Өченче көн кем янына килүегезне дә, әлеге катыргы өчен аңардан нәрсә соравыгызны да беләм. Шуңа күрә өчкә чаклы саныйм...— Жан пистолетын киндердәй агарынган хатынга төбәде: — Бер... Ике...

Хатын, елап, идәнгә тезләнде:

— Үтермә генә!.. Катыргыңны да бирәм... Сөйлим дә! Барысын-барысын сөйлим!..

— Сөйләгез! Тиз!..

— Көяз офицер... зондерфюрер...

— Ну!..

— Листовка... Сезнең өчен җитмеш биш мең...

— Катыргылы кәгазь аңардамы? Кайда?

— Әнә өстәл җәймәсе астында...

Жан ике атларга өлгермәде, хатын, утка пешкәндәй сикереп торып, ишеккә ташланды:

— Коткарыгыз!.. Назаров-Базаров үтерә!..

Жанның атмый чарасы калмады. Таныклыкны эләктерде дә, бусагага аркылы егылып җан биргән хатын-кыз гәүдәсе өстеннән чыгарга базынмыйча, кырыйдан яны белән үтеп, урамга чапты. Теге көнне күрсәткән саксызлыгы өчен үз-үзен тиргәде. Ярый әле бу төбәктә сакчылар йөрми диярлек. Алар килгәндә Жаннан җилләр искән булыр инде!..

Комендант сәгате башланган иде. Хәзер урамда очраган һәр кешене алып китәләр. Иң яхшысы төнге берләргәчә сабыр итү. Анда газра-

иллар йөрүдән туктап, я кәрт сугарга керешә, я йокы симертә башлый. Җылы өннәрен ташлап чыкканнары икешәрләп яки өчәрләп олы урамнарда гына тәртип күзәтә. Кышкы төндә алар, без хәзер менә биредә дигәндәй, шагыр-шогыр атлап, ярты чакрымнан сәлам бирәләр.

Җан бомба җимергән зур таш йортның чарлагына менеп посты. Һәм нәкъ вакытында: теге хатын өенә таба выжлап ике машина узды. Арттагысы җиңел машина иде. Таныды аны Җан. Гестапоның аеруча җитди эшләр белән шөгыльләнүче тикшерүчесе үзе вакыйга урынына килгәч, алар ул хатынга зур өметләр баглагандыр, күрәсең.

Ә бәлки алай түгелдер? Курыкканга куш — койрыгы белән биш, диләр ич... Күзәтик, аннары нәтиҗә чыгарырбыз...

Тыкрыкта эсэсчыларына әмер биргән зондерфюрерның нечкә тавышы яңгырады.

«Шул үзе, — дип уйлады салкыннан калтырый башлаган Җан. — Димәк, бу көяз офицер Назаров-Базаров белән нык лап кызыксына башлаган булып чыга. Кер юучы — шул корган тозак. Моңа хәзер шик юк. Ә бит ул хатынны подпольечылар тәкъдим итте. Кем? Родзянко! Очраклы хәлме бу? Хәзергә шулай дип уйлыйк. Ләкин шунысы бәхәссез: гестапо Җанны ауларга бик нык лап керешкән. Ул, үз максатына ирешү өчен, һичнәрсә белән санашып тормаячак... Нишләргә соң? Горкомга белдерсәң, иртәгә үк урманга озатачаклар. Аннары шәһәргә кайтулар бетте. Ә Җан алай яши алмый. Аңа көн саен, сәгать саен тәвәккәллек тулы хәрәкәт кирәк. Җан шәһәрдә күбрәк файда китерәчәк. Димәк, куркыныч янавын горкомга сиздермәү әллә ни зур гаеп булмаячак. Билгеле, Җан уяулыкны, саклануны арттыра төшәр. Шулай да... иң яхшы саклану чарасы — һөҗүм итү дип, Суворов әйткән түгелме?

Җан төнге икеләрдә генә Лена квартирына кайтты. Үз ачкычы белән ачып керде. Ленаны уятмас өчен, аяк очларына баса-баса мич янына раскладушка җәя башлаган иде, караваттан Александраның гадәттәгечә:

— Шөкер, исән-сау икәнсең, — дигән тавышы ишетелде.

Җан бер мәлгә аптырап калды. Нишләп әле Янулис монда? Әллә Җан квартираларны буташтыра башладымы, югыйсә?

— Гаҗәпләнмә, — диде кыз ярым пышылдап, — мин сине засадага эләкмәсен дип кисәтер өчен килдем. Өйдә тентү булды, кизү дә калдырганнардыр.

Җан гәүдәсен турайтты:

— Ә үтүк? Үт-үтме?..

— Юк ла, — диде Александра, — борып куелган лампага гөлт итеп ут кабынуга, син әйткәнне искә төшердем.

— Молодец, акыллым! Аннары?

— Аннары ишекне бикләп, төтенләнгән үтүкне тотып, чыгып йөгердем.

— Аннары?

— Утын сарае артына ышыкланып ике машинаны үткәреп җибәрдем дә... зондерфюрер ишекне ватып керергә кушкач бире килдем.

— Кара төстәге җиңел машинадан чыктымы ул зондер?

— Әйе, — диде Александра.

— Аңлашыла...

Үзенә сүз башларга җай көтеп яткан Лена тынлыктан файдаланып

— Син, егет, бәлки ашарга телисеңдер? — дип сорады.

— Булса, мишәйт итмәс иде, — диде Җан.

Лена чаршау эченнән чыкты, салкыннан бөтен гәүдәсе белән калтырап куйды һәм, узып барганда, үзенең сылу гәүдәсенә күз төшсен дипме инде, тәрәзә пәрдәсен күтәреп куйды. Төнге аяз күктә тулган ай елмая иде. (Әйтерсең бу яшь ханымның наянлыгыннан шулай көлә!) Лена,

мич буена яткан Жанның кочагына ташланырдай булып килде дә, ахыр чиктә генә тыелып, аның куенына кулын тыкты, битен сөйде.

— Тәмам туңгансың, Жан. Жылытмый булмас үзеңне...

— Рәхмәт, — диде Жан. — Бүген эчмим дигән идем инде. Һаман-һаман баш тартырга ярамас шул. Бигрәк тә синең кебек су кызы кыстагач...

— Француз ромы... Биш бәясенә сатып алдым. Жылыну өчен түгел, кайнарланырга дип ясаганнар аны ясавын...

— Ну тел үзеңдә, Леночка!..

— Тел генә шул. Монашкага әверелеп беттем инде тәмам.

— Аларның да төрлесе булган бит.

— Алайса, шуларның берсе сыйфатында... — Бәллүр касәләргә аккан шәраб тавышы өй эче тынлыгын бозды. — Шурочка, безнең компаниягә кушыласыңмы?

Мендәргә йөзтүбән капланып яткан Александра:

— Юк, юк! — диде.

Касә чыңнары тынып, бераздан Лена:

— Тагын теләмисеңме? — дип сорады.

— Житте, рәхмәт. Жилекләргә кадәр төште, — диде Жан. — Күнекмәгәнгәдер...

— Эх син... — Лена авыр гына кузгалып, үз урынына менеп ятты.

Өй эчен ай алтын нурлары белән коендыра. Гүя йокламаска өнди: әй, адәм балалары гомерегезне әрәм үткәрмәгез, дөньяның матурлыгын татып калыгыз! Нинди кире кайтмаслык гүзәл төн! Нинди тылсымлы төн! Тик мәңгелек бу чакыруга колак салучы юк иде шул бүген. Һәммәсе уйга талган, һәммәсе нидер көтә...

Чаршау артында пышылдашып алдылар. Һәм кайсыныңдыр рәхимле ак кулы мич ягына юрган ыргытты.

Жан, рәхмәт әйтеп, башыннан ук бөркәнеп ятты. Ләкин барыбер жылына алмады ул.

Кызлар тагын пышылдаштылар. Жан турында ихлас кайгыртырга күнеккән ике яшь ханымны тәкатьсез каршылыклы хисләр биләгән иде. Ул, ул әнә, дөньяда иң кадерле, сөекле кеше, жылына алмыйча калтырап ята!.. Ә ничаклы кайнарлык бу күкрәкләрдә?! Бәлки... Бәлки кем дә булса хәзер торып китәргә тиештер? Кем? Кем аны көтеп калырга тиеш? Торып китү ул—мин сезнең якынлыкны беләм инде дигән шикелле килеп чыга бит әле житмәсә!.. Уен-муен түгел бу. Аннары ничек инде үз иркең белән көндәшеңә... Юк-юк!.. Эссе. Икесенә дә эссе. Ә ул жылына алмыйча калтырап ята...

Ниһаять, Жан юрганын ачып жибәрде:

— Мин нәрсә, якмаган өйдә болай туңып ятырга ахмакмыни?! — дип, чаршаулы караватт янына килде.

Кызлар икесе дә сулаудан туктадылар.

— Ягез әле, сылукайлар, ике арагыздан урын бирегез! — дип икесенә берьюлы эндәште Жан.

Читенсенмәделәр. Берсе уң ягына, икенчесе сул ягына әйләнде. Жан исә чалкан ятты. Ник бер тиешсез хәрәкәт ясасын. Шаярып сөйләшүләр бетте.

Ә ай зәңгәр патшалыгыннан һаман нур сибә, һаман елмая...

Мич алдына өеп куелган утын әрдәнәсе, ерактагы шартлау өйне селкеткәнгәдер, ахры, идәнгә ишелеп төште.

Александра йоклаганга салынып ята. Ләкин кая ул йокы! Мондый сәер хәлгә очраганы юк иде әле аның. Бер мендәргә икәү — егетең яки ирең белән баш кую табигый, ә өчәү... Өченче артык дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр ич инде. Дөрес, бу чибәр Еленага ул үзен Жанның сеңлесе мин дип таныштырды. Тик бу мут хатын моңа ышанмады, ахры. Күзләрендә зур кызыксыну жемелдәде. Алайга китсә, Александраның кү-

целендә дә көнләшү дигән нәрсә юк түгел үзе. Тере җан ла ул. Яратуы да ким түгел. Киресенчә, бәлки әле көчлерәк һәм... мәңгелектер. Ленага аңа ни: мөгаен, бүген Жан, иртәгә Роман... Жан шуны аңламый микәнни? Аңлыйдыр. Ул бик тә, бик тә сизгер һәм нечкә күңелле егет ич. Егет... Хатыны бар егет... Александра өчен ул шундый. Булсын. Жан хатынын ярата. Яратсын. Суынып: андый чибәрләр сугыш вакыты дип тормыйлар... Менә шундыйларның берсе янәшәдә генә. Жанны ирем дип лагерьдан йолып алган да булсын, алтыннарын түгәргә дә әзер торсын. Ләкин болар иң-иң мөһиме түгел. Иң-иң мөһиме—пакьлек, сафлык. Жан шундый кызны гына мәңге сөя ала. Җиңү көннәре генә житсен... Юк, болар турында уйларга иртә әле, иртә! Шулай да... нигә хыялланмаска? Бергә. Гомергә бергә. Бәлки шуңа күрәдер... Жан өчен һәммәсен эшлисе килеп тора. Ул булдыра алмыйм дигәненне дә эшләтә. Аның өчен «юк», «ярамый» дигән төшенчәләр гамәлдә юк! Һәм Жан өчен һәммәсен эшли Александра. Рәхәтлек бирә бу аңа... Тәне жылынып килә инде. Шәп итте соң ике арага ятып. Әгәр ул Лена белән генә яткан булса, бу төнне Александра гомере буе ләгънәтләр иде. Ә янәшә яту рәхәт... Менә шулай тигез генә, тыныч кына ятып торулары да рәхәт икән шул, Жан, синең белән!..

Лена Александраның тизрәк йокыга китүен тели иде. Үч иткән шикелле, утыннар дөбердәп тынычлыкны бозды... Кыз тәмам ойый башлаган иде югыйсә. Кирәк бит кайчан дөбердәргә. Жаннан сорыйсы иде пышылдап кына: син дә яратасыңмы, бәгырь? — Юк, ярамый, сеңелесе ишетүе бар!.. Сеңелесе... Беләбез без андый сеңелләрне! Жан турында сүз башлауга кысладай кызарып чыга. Ник? Мәхәббәт билгесе бу. Мондый аз сүзле йомыкый кызлар бик бирелеп ярата алар. Үзләре операция ясаучы хирург кебек салкын канлы булалар, үзләре пациентны һич читкә җибәрмиләр. Печән өстендә яткан эт кебек инде менә.

Лена апаң белән тартышырга борын астың кипмәгән әле, жаным. Йокла әйдә, тизрәк...

Бөтен тән онытылып наз көтә. Аякларны сузып җибәрәсе килә. Жан, бәгърем, аз гына башыңны борып, нигә инде муеннан бер үбеп алмыйсың? Эссе... Нигә инде интектерәсең?.. Синең тәнең генә түгел, жаның да туңган, хөрмәтле Базаров-Назаров! Җиләк күк ике хатын арасына кереп яттың да, намусыңа көч килгере нәрсә, оясындагы аю кебек, йокы симертәсең! Йоклый, имеш! Белмәгән без синең ничек гырлавыңны!! Алайга китсә, Елена апаңда да горурлык житәрлек. Керфеген дә селкетмәс! Һичкайчан селкетмәс! Һичкайчан!! Жан... Мәрхәмәтсез Жан...

Жан, азрак жылынып, йокыга китә башлаган иде, парашют фабрикасы янында сәгатькә көйләнгән мина гөрселдәде. Бөтен өй селкенде. Хәтта утын әрдәнәләре ишелеп төште. Төшсен. Йокы ястык сорамый диләр. Ә биредә әле ястыкның шәбе. Ястык кынамы әле!.. Төрек солтаны шикелле, ике хур кызы арасында ята ич ул! Менә әкәмәт, дөньяда мондый хәлләр дә булгалый икән. Кызык бит. Кем уйлаган шулай туры килер дип. Кызлар гаепле түгел. Яхшылык кына тели алар. Жан үтенгәч, ни генә эшләмәде алар? Ничә тапкыр үлем белән күзгә-күз очраштылар. Куркудан тетрәп, калтырап тынычлана алмый йөдәделәр. Жан юата белде, шаярта белде һәм алар, кирәге чыгу белән, кабат подпольечылар йомышын үтәргә киттеләр. Икесе ике төрле холыклы: Александра сабыр, Елена кайнар канлы. Уртак сыйфатлары да юк түгел: эчкерсезләр, юмартлар. Юктан гына күңелләре була, юктан гына хәтерләре кала. Менә Лена хәзер аның кочаклавын көтеп ятадыр, мөгаен. Моны эшләп була, уң кулны гына суза төшәргә кирәк... Лена ул кулны үбеп, күкрәгенә куячак. Бәлки шулай йоклап та китәр... Йоклар-

мы икән? Керүеңнән алда чыгуыңны уйла диләр түгелме? Кызмача Лenaның дөрләп кабынуы мөмкин. Бу инде тыйнак Александраның саф тойгыларын мәсхәрә итү, аның алдында түбәнгә тәгәрү дигән сүз. Әллә Александрага сул кулны бирергәме? Нишләр, битенә куярмы? Моны үткен Лена шундук сизеп алачак. Юк, инде, сылукайларым, сез миңа икегез дә кадерле, сез миңа икегез дә кирәк, әлбәттә, иң беренче чиратта, уртак эшебез өчен кирәк! Татулыкта, бердәмлектә безнең көч. Димәк, мин йокларга тиеш! Фәкать йокларга тиеш!!

Һәм күп тә үтмәде, Жан татлы йокыга талды.

Иртән кызлар һичнәрсә сиздермәделәр. Жан тыныч күңел белән шәһәргә чыгып китте.

*
* *

Кичке якта Жан аеруча яшерен эшләр белән шөгыльләнүче зондерфюрер Иоганс Эркаченко турында дусларыннан өстәмә хәбәрләр алды. Алардан Жан шундый нәтиҗә ясады: Эркаченко коньяк һәм кызлар ярата икән.

— Мин иснәнеп белдем инде, — диде Толик Левков, — өченче каттагы иң кырый бүлмәдә ниндидер бер кыз янында кунгалый ул. Элек дәүләт китапханәсе булган йортта. Урамнан патрульләр еш йөри йөргән, шулай да тәвәккәлләргә мөмкин.

— Һәм бүген үк, Толик, — диде Жан. — Әйдәле, күрсәт миңа ул хур кызы яшәгән бүлмәне...

Караңгы төшеп килә иде инде. Урамда шәһәр халкыннан адәм заты күренми диярлек. Аның каравы, кызмача, шат немец солдатлары адым саен очрады.

Патрульләр туктамады, ашыга-ашыга атладылар да атладылар. Чәнечкеле тимер чыбык киртә белән әйләндереп алынган Йозак һәм Татар урамнары яныннан үттеләр. Анда хәзер гетто — еврейлар лагеры. Сугышның беренче көннәрендә шушында фашистлар сиксән мең еврейны тереләй чокырларга күмделәр. Иртән алар өстендә җир селкенеп торды. Танклар килеп туфракны тыгызладылар...

Кинотеатрда кәпрәюле хәрби музыка уйный, дөньяны балкытырдай булып утлар яна: немец кәеф чигә бела!

Жан юлдашына:

— Менә кайда куеп калдырасы иде безнең бер кәнфитне! — дип пышылдады. — Тик эрерәк балыклар йөзеп килгән мәлне сайларга кирәк булыр...

Нәкъ төнге сәгать икедә, урамнан узучы патрульләрнең дагалы итек тавышлары тынгач, Жан янгын баскычы буйлап түбәгә менде. Аннан торбага тотынып балконга төште. Чүгәләп тирә-юньне тыңлады. Шылт иткән тавыш та юк. Коридорда тонык кына булып ут яна. Жан балкон ишеген тартып карады, юк, ачылмый. Монда күптән чыкмаганнар, күрәсең. Кем чыксын соң — элек бу йорт китапханә иде, хәзер... Тәрәзә пыяласын ватсаң, ишетәчәкләр. Әһә, әнә форточка чак кына ачык. Тәрәзә рамы нык, күтәрер. Сыеп булса... Немец, каһәр, тәртип ярата: бәдрәфне тәүлек буе җиллэтеп тота. Жан, патшалар җәяү йөри торган җирнең таш идәненә, яшь чагында сальто-мортале ясагандай, учлары белән килеп төште. Юлбарыстай сикереп аякка басты. Төзәтенде. Ишекне сызык кына ачып тыңлап торды. Астагы каттан йокымсыраулы җыр ишетелә, чишмә чылтырагандай итеп кызлар көлә. Янәшәдә юыну бүлмәсе, ахры. Анда кемдер суда чупырдый, рәхәтләнеп пошкыра, борын эченнән генә нидер көйли.

Жан, аяк очларына гына баса-баса коридорны үтеп, кырый бүлмәгә килде, ишекне ачты. Эчтән затлы хушбуй исе бөркелде. Утлар сүндерелгән, мул ризыклы өстәлдә тетрәнә-тетрәнә ялгыз шәм яна, ә өстәл янында шәрә аркалы, юеш чәчле яшь чибәр кыз тәмләп кенә шампань шәрабе чөмерә иде.

Түшәмдәге тамчылы бәллүр абажур уты кабызылмаган, киң караватта тулы тәнле мендәрләр таралышып ята...

Калын имән ишек шыгырдап ябылды.

Яшь чибәр ханым борылмыйча гына:

— Иоганс, кадерлем, зарыктырдың ич, — диде. — Кил тизрәк... Кил яныма!

Жан якын ук килде:

— Менә килдем,— диде, үткен хәнҗәрен тегенең алсу яңагына тигезде. — Нәрсә, көтмәдеңмени? — Нык кысылган кулдагы корычның салкын җемелдәве ефәк халаты ачылып киткән кызның тәмам котын алды. Аны очкылык тота башлады.

— Тынынны чыгарасы булма! — диде Жан хәнҗәренә ымлап. — Кайда Иогансың? Юынамы?

Кыз, әйе дигәндәй, баш какты.

Жан аңа кием шкафына керергә ымлады, шунда тик кенә утырырга кушып, ишекне тиз генә бикләде дә, зондерфюрерның чөйдәге пистолетын эләктереп, юыну бүлмәсенә ашыкты.

Сызгырып аккан эре су тамчылары тирән җәрәхәттән аккан кан эзен бетереп юа бардылар...

Зондерфюрерны күмәргә килүче күп булды. Фашист итеген ялаучы Козловский кабер өстендә нотык тотты. Ахырдан ул:

— Хуш, кадерле Иоганс! Авыр туфрагың җиңел булсын. Без синең эшне дәвам иттербез, синең юлың белән барырбыз! — диде.

Бирегә көчләп китерелгән халык арасыннан берәү усал итеп: «Бүтән юл юк сезгә. Һәммәгезне шунда олактырырбыз!»—дип пышылдады.

Чыннан да, озакламыйча «спандар» Козловскийны, үч алучылар пулясы үзәк урамга урнашкан сатлык газета редакциясендә эләп тапты. Аннары подпольечылар карагруһ милләтчеләрнең башлыклары булган Акинчиц, Рябушка, бургомистр Ивановскийны һәм бүтән шундый хыянәтчеләрне теге дөньяга озаттылар.

Белорус халкының гадел үченнән немец өлкә комиссары Людвиг Эренлейтер, хөкүмәт инспекторы Генрих Клозе, жандармерия начальнигы Карл Калл, өлкән жандарм Карл Вундерлих һәм башка эсэсчы офицерлар да котыла алмады.

Баш имәс белорус халкы фашистлар корган мәкерле провокациягә әнә шулай кире какты. Партизаннарга каршы белоруларны җибәрергә һәм туганны туганы белән сугыштырып үз гаскәрләрен фронтка озатуны күздә тоткан хәйлә барып чыкмады, ул төтен булып күккә очты.

## «Мин кайтырмын, әнкәй!»

Яңа ел алдыннан партия подполье комитеты Кабушкин белән Сайчикны, гитлерчыларның Барановичи тирәсендәге хәрби көчләре турында мәгълүмат туплау өчен, ашыгыч рәвештә разведкага җибәрергә булды.

Билгеләнгән очрашу урыннарының берсендә шәһәр партия подполье үзәге җитәкчесе Исай Казинец[1] белән күрештеләр. Ул фашист

[1] И. Казинецка үлгәннән соң Советлар Союзы Герое исеме бирелде. *(Автор)*

гарнизоннарының ничек һәм күпме коралланган булуларына аеруча игътибар бирергә кирәклекне әйтте. Малаховцы авылы янындагы аэродром белән Зур җирнең кызыксынуын белдерде.

— Сайчик шул якта туып үскән кеше. Аңа һәр авыл, һәр хата таныш. Туганнарыма кунакка кайтам дип әйтә ала... Рөхсәт кәгазьләрен пропусклар бюросындагы Зориктан алырсыз, — диде Казинец, саубуллашканда.

Кабушкин елмаеп куйды: «Сайчик шул якта туып үскән... Туганнарына кайта. Ә Иван?» Аның әнисе, әнисенең туганнары нәкъ менә Малаховцыда яшиләр бит инде. Тик бу хакта һич кемгә сөйләгәне юк иде аның. Сөйләмәс тә. Ник дигәндә, Иванны электерә-нитә калсалар, фашистлар, һичшиксез, әнисен һәм туганнарын аның күз алдында җәзалаячаклар. Үләргә тек, башкаларны яшәтер өчен үләргә кирәк.

— Нәрсә, Сайчик ошамыймы? — дип Казинец Жанның елмаюын үзенчә юрады.

— Ошый, нигә ошамасын. Сайчик — күңелле картлач.

— Обстановкага карап эш ит, Жан.

— Әлбәттә.

Алар икенче көнне таң беленгәч тә юлга чыктылар. Зәһәр җил чыгып җәяүле буран сыдыртканга һәм өстендә иске-москы гына булганга, Сайчик чанадагы печәнгә күмелеп ятты, атны юырттырып барырга кушты. Эх, бу разведчик язмышы... Шушы буранда адәм рәтле киемнәреңне өйдә калдырып, чыгып кит инде менә! Кабушкин-Бабушкинга аңа рәхәт: чиертсәң каны чыгарлык таза, өстәвенә үзе өр-яңа полицай киемендә.

Шулай да Сайчик зарланмады, гадәттәгечә шаяртуында булды.

Кабушкинның картка хөрмәте зур иде. Ул аңарда Казандагы зурайтып эшләгән фоторәсем буенча күзаллаган әтисе образын күргән кебек булды. Бу бәлки, еллар буе җыелып килгән, күңелне моңайтып, кимсетеп торган ачы юксыну нәтиҗәседер?

Сайчик, чана башына тотынып йөгерә-йөгерә дә, азрак җылынгач кабат печән эченә чума, кабат шаярта башлый. Ә күзләре һаман тирә-юньне айкыйлар.

— Тагын бер аю өне, — ди ул, юл кырыенда авызын ыржайтып, сизелер-сизелмәс кенә пар чыгарып торган ДОТка ишарәләп. — Унҗидәү булды, Жан.

Авылларда чәй эчеп, ашап чыгу сылтавы белән, гарнизон урнашкан тирәгәрәк тукталдылар, күзәттеләр, санадылар, исәпләделәр...

Барановичида төн кунарга тиеш иделәр. Биредә, чиркәүгә борыласы тыкрыкта гына, аларны партизан отряды элемтәчесе комсомолка Галина хәзерләгән йортта каршыладылар. Жан ул кызның фамилиясен белми. Аны белүнең хаҗәте дә юк иде. Эшен җиренә җиткереп башкарса, «койрык тагып» йөрмәсә, шул җиткән. Бу мәсьәләдә Галина ут кыз булып чыкты. Әле менә күптән түгел генә гестапоның тәҗрибәле тикшерүчесен кәкре каенга терәп киткән. Урманнан кайтып, кирәкле кешеләрне күреп йөргәндә нәкъ ау эте сыман эзгә төшә бит теге. Бастырып куа килә. Кызның күлмәк эче тулы листовка. Эләктеңме — беттең. Көпә-көндез кая барырга? Чиркәү якында гына. Халык арасына кереп югалырга мөмкин. Якшәмбе бит, анда картлар, карчыклар җитәрлек. Шулай да гыйбадәт кылучылар бүген ишле түгел икән шул. Галина үзенең бодай арасындагы борчак күк бик тиз күзгә чалынасын уйлап, чуен рәшәткәле ишектән поп янына үтә.

— Мине фашист куа килә. Әгәр сатсаң, беренче пуля сиңа, атакай, — ди кыю разведчица.

Ары сугыла, бире сугыла гестапочы — кыз юк. Поптан да сораша. Ләкин, җан кадерле бит, әйтми теге. Тора-бара разведчица аны тәмам

үз кубызына биетә башлый. Поптан шикләнмиләр. Поп кушканны вакытында үти. Менә фатирда һәммәсе әзер...

Икенче көнне иртән үк кузгалмыйча базардан кайтучыларга кушылуны кулайрак санадылар. Жан базарда йөрде, тегесен-монысын сатып алды, сөйләшүләргә колак салды. Халык кыйммәтчелектән зарлана, «яңа тәртип»не сүгә иде. Подпольечылар информбюро хәбәрләрен кулдан язып та, бастырып та тарата гына торалар икән. Бу кешеләрне өмет белән яшәтә, берләштерә, көч бирә. Мондый шартларда попның элемтәчене тоттырмавы гаҗәп түгел шул, дип уйлады Жан. Кайтуга чиркәүгә керде, шәмнәрнең тонык кына януын күзәтте, үгет-нәсихәт тыңлады. Ишек яны әйбәтрәк яктыртылган. Шиклерәк кеше күренгәндә генә фюрер һәм аның гаскәрләре хөрмәтенә мактау сүзләре әйтелә...

Әбәттән соң сәфәрне дәвам иттеләр. Бераздан ат ике юл чатына туктады. Моннан Сайчик җәяүләп үз районына китәргә тиеш иде.

— Бәлки энә каракларын санарга мин барырмын, Жан? — диде ул аерылышыр алдыннан. — Ни генә әйтмә, минем кода-кодагый шактый бу якта. Туган-тумачаң булмагач, нишләп йөрисең дип сиңа бәйләнмәсләрме дим?

— Кайгырма, картлач. Кыз яраширгә килдем, диярмен. Начар кияүмени мин?!

— Рисвай шәп. Киемнәрең дә кияүләрски... Сиңа кыз биргән җүләр булыр!

— Бирмәсен шул! Икенчесенә китәрмен, аннары өченчесенә...

— Ак юл, кияү!

— Сиңа да, картлач!

Жан Малаховцыга кечке якта килеп житте. Атын да тугарып тормастан, йөгереп өйгә керде. Ирина Лукинична мич тирәсендә кайнаша иде, ишек шакып, рөхсәт сорап кергән ягымлы тавышлы яшь кешенең полицай икәнлеген күргәч, гаҗәпләнеп тукталып калды.

— Самогон кайнатканым юк, кукәй, дуңгыз мае бетте, — диде ул.

— Әнкәй, сөеклем!..

Ирина Лукинична кулындагы табагын идәнгә төшереп җибәрде. Табак түгәрәк ясап әйләнде дә, кылдыр-кылдыр итеп, тәмам каушап калган ананың хәлсез аяклары янына килеп тәрәлде.

— Ваня!.. Ванюша! Сине дә күрер көнем бар икән! — Ана улының киң күкрәгенә капланды, күзләренә яшь тулды, күгәргән иреннәре тетрәнделәр. Ябык куллары, бу өнме, төш кенә түгелме дигәндәй, кабалана-кабалана газизенең битен, муенын капшадылар, чәчләреннән сыйпадылар .Аның шатлыгы чиксез, юк, шатлыгы гына түгел, бәхете тулып ташыган иде бу минутта. Ирина Лукинична, яшьле күзләрен дә сөртмичә, күгәрчен күк гөлдерди-гөлдерди, чыңаяк тәлинкәсендә яткан гильзалы мамыкка ут кабызды, утын баш өстенәрәк күтәреп, улын баштан-аяк күздән кичерде. Сөенече шундук юкка чыкты, зур коңгырт күзләрендә кырыслык, моң чагылды.

— Син дә яңа тәртип урнаштырып йөрисең икән, — диде ул һәм эскәмиягә барып утырды, бүртенгән тамырлы кулларын алъяпкычы астына яшерде. — Нәрсә тешләреңне ыржайтып торасың? Шатлыгың зурмы?

— Зур шул, зур, әнкәй! — Ваня кабат әнисен кочаклап алды һәм, ана йөрәгенең өметләнеп, сабырсызланып үзенә тынычлык китерә торган сүз көтүен аңлап, дәвам итте: — Киемгә карама син, әнкәй. Партизан мин. Тик бу икебезнең арада гына калсын. Аэродромны күзәтү өчен җибәрделәр мине бирегә...

— Һай, Ванюша, бик хәтәр эшкә алынгансың. Безнең халыкны анда якын да җибәрмиләр. Сине генә инде, бәлки бу киемнәрең белән...

— Юк, ярамый. Шикләнүләре мөмкин. Төпчәнә башларлар. Сезне куркыныч астына куясым килми минем. Белмәсеннәр...

— И бала, бала! — дип, Ирина Лукинична улының башын күкрәгенә кысты, малай вакытындагыча бармаклары белән чәчләрен тарады, уйга чумды. — Тамараң кайда, исәнме, хәбәре бармы?

— Исән булырга тиеш. Сугышның беренче көнендә мин аны Казанга озаттым.

— Хат яз үзенә. Борчылмасын.

— Икенеме, өчнеме язып салдым.

— Тагын яз. Казанга китте дисең... Буенда юк идеме?

— Белмим шул...

— Нәсел агачыбыз корымасын иде. Узган булса, бәләкәчне бик тырышып сакласын иде...

— Әни! Әнкәй!.. Бүген яшәвем белән сиңа бурычлы мин. Син минем зиһенемне яктырттың! Хәтереңдәме, туй йолалары турында сөйләгән идең, хәтереңдәме? Туй калачы, боярлар, кияү белән кәләш өстенә кушучлап-кушучлап бөртек сибүләр...

— Онытмагансың...

— Рәхмәт, әнкәй!..

— Үзеңә дә рәхмәт, сынка! Утыр, әйдә, тамагың ачыккандыр.

— Хәзер атны тугарып, күчтәнәчләрне алып керим дә...

Ул борылып кергәндә, Ирина Лукинична бәрәңгеле чуен янәшәсендә бая бетте дип зарланган дуңгыз маен һәм авызы чүпрәк белән томаланган шешәсен дә куеп өлгергән иде инде. Улы кулыннан бүләк-күчтәнәчләр алгач, ана кабат ачылып китте. Ашый-эчә үткәннәрне искә төшерделәр...

Иван әнисе янында өч көн булды. Һәр көнне иртән таңнан торып, ишегалдында кыштырдады, абзар-кураны рәтләде. Өй авыл читендә генә булганга, фашист очучылары аэродромга шушы турыдан үтәләр иде. Кабушкин һәр төркемне күздән кичерде, чиннарын исәпкә алды, экипажларны ачыкларга тырышты. Һәм озакламыйча каты гүләп һавага күтәрелгән самолетларны санады. Кичке якта күңел ачарга дип чыккач, сүз җаен туры китереп, аэродромга илтә торган юллар, андагы сакчылар турында сорашты. Шик уятмас өчен кызлар артыннан чапкан булды, староста белән самогон чөмерде.

Һәм, ниһаять, дүртенче көнне иртән әнисенә китәсен әйтте.

Ирина Лукинична елап ук җибәрде, тагын берничә көн кунак булырга кыстаса да, улының үз сүзеннән кайтмаячагын аңлап, аны юлга хәзерли башлады. Ана йөрәге давыллы диңгезгә эләккәндәй шомланып, куркып китте. Ваняны акфиннарга каршы сугышка озатканда ул бүгенгедәй борчылмаган, кайгырмаган иде. Ул чакта аның дуслары, иптәшләре янында иде. Алар аңа терәк булдылар, бәлагә тарса, йолып алдылар, шатлыгын, хәсрәтен уртаклаштылар. Бүген ул берүзе йөри, иптәшләре аның кем икәнлеген, кайда икәнлеген дә белмиләр. Шулай тынычрак, хәвефсезрәк, ди. Шулаен шулай да, язмышның соңгы сәгате сугып, ул-бу була калса, кайчан, ничек, нинди үлем белән дөньядан китүе дә карт әнкәсенә килеп ирешмәячәк. Ул үзенең бәгырь кисәген көтәр дә көтәр...

— Улым, күз нурым... Бүтән әллә күрешә алабыз, әллә юк... Кил, зинһар. Саклан. Туры юлыңнан чыкма. Әшең хак, намусың пакь булса гына югалмассың! Илаһым, үзең сакла шул газиземне!.. Ганимәтбайлык өчен түгел, дан-шөһрәт өчен түгел, ил-халык бәхетен яулар өчен китә ул бу хәтәр ут эченә! Әгәр инде...— Ирина Лукинична, күз яшьләренә төелеп, үксеп елап җибәрде.

— Кирәкми, әнкәй, — диде Иван, әнисен үбә-үбә, — алай елама. Хуш! Көт мине! Мин кайтырмын, әнкәй! Барыбер кайтырмын! Кайтырмы-ын!..

Өч көн буена ял иткән җирән кашка, урман артыннан күтәрелеп килә торган кояшка карап, кышкы юлда зилзилә бураннары туздырып, җан-фәрманга чабып китте. Ямаулы тунын киеп капка алдында кул болгап нәрсәдер кычкырып калган бичара ана тавышы ындыр артыннан ук башланып киткән аэродромдагы самолетлар гөрелтесенә күмелде. Күп тә үтмәде, канга сусаган карчыгалар кебек җирдә шомлы күләгәләр калдырып, дошман очкычлары күккә күтәрелә башлады. Агач буе менеп өлгергән кояшның алтын кылычлы нурлары күзләрен сукырайтты булса кирәк — очкычлар төньякка таба борылдылар.

— Муеныгыз сынсын иде, бәдбәхетләр! Канатларыгыз каерылсын иде! — дип каргады аларны капка төбендәге карчык.

Анын каргышын ишеткән кебек, озакламый җил чыкты һәм өч көн буена буран котырды.

Ә дүртенче көнне Ирина Лукиничнаны бик яман шартлаулар йокысыннан сискәндереп уяттылар. Кызыл йолдызлы самолетлар гүләп очып узган саен җир селкенде. Аэродромдагы көчле янгын җирдән энә табарлык итеп тирә-юньне яктырткан иде. Таң алдыннан атышлар басылды, янгын исә кечкә чаклы сузылды.

Ана йөрәге бәла-каза якынлашуын алдан сизенгән булган.

Кабушкинны 1943 елның 4 февралендә кулга алдылар. Партизан отрядыннан килгән элемтәче Ирма Лейзер белән очрашырга дип барган иде. Өйалдына керүгә, алты-җиде гестапочы берьюлы аңа ташланды. Посып сагалап торганнар. Җан ике-өч тапкыр гына селтәнергә өлгерде, идәнгә ектылар, кулларын артка каерып бәйләргә керештеләр. Кабушкин әзмәвердәй ике гестапочының эченә типте, тегеләр чыйнап, коридордан урамга мәтәлделәр. Өйдән яңалары атылып чыкты. Алар, Җанны качырмас өчен, анын өстенә өелделәр, аякларын боргычлап бәйләделәр. Мәет исен сизгәндәй, ике «кара козгын» килеп җитте. Берсенә, аһ-ух итеп тирләп-мышнап, Кабушкинны этеп керттеләр һәм ишекне шартлатып бикләп куйдылар, икенчесенә үзләре төялделәр.

Халык хуҗалыгы институты бинасына гестапо үзәге урнашкан иде. Машиналар шунда кайтып керделәр. Биредәге юеш подвалларда Җан белгән уннарча подпольечылар җәфа чигә. Моннан исән чыгучы бик сирәк. Гестапочылар исән калдыру бәрабәренә «бөек Германиягә» чын күңелдән бирелеп хезмәт күрсәтү, ягъни туган илгә хыянәт тәкъдим итәләр. Белов кебек кайберәүләр, җәзалауларны вакытлыча туктатып, «эшлекле сөйләшүләргә» күчүгә, байлыкка алданып, гестапоның яшерен агентына — пычрак сатлык җанга әверелә. Аны кабат җәзалыйлар, үгетлиләр, куркыталар. Ул кичәге сугышчы иптәшләренең исем-фамилияләрен, адресларын әйтә, очрашу урыннарын, корал складларын күрсәтә, намуслы совет кешеләрен сата. Аны мактыйлар, аракы эчерәләр, матур кызлар, чит ил банкларына салына торган зур байлык вәгъдә итәләр.

Әлбәттә, мондый җимне, чиертмәсме дип, Кабушкин алдына да ташлаячаклар.

Ул ялгышмады. Гестапоның иң тәҗрибәле, иң мәкерле тикшерүчесе Фройлик Кабушкинны ишек төбенә чыгып, әдәпле кыланып каршылады.

— Сезнең белән очрашуыма бик шатмын, Җан! — диде ул. Һәм бу күңелсез хәлгә ачуланган төсле итеп гестапочыга: — Чишегез Җанның аякларын! — дип боерды.

Бульдог кебек җирәнгеч танаулы гестапочы Кабушкинның боргычлап бәйләгән аякларын чиште. Җан аңа шундый итеп тибеп җибәрде, теге йомшак җирен тотып, чын-чынлап эт кебек чыйнап карга мәтәлде.

Башкалары, Фройликка чират житмәгәе дип, автоматларын Кабушкинга төбәделәр.
— Арестованныйны минем кабинетка! Живо!
Фройлик Гитлер портреты астындагы киң өстәл янына керeп утырды. Кабушкинның кулларын чиштерде, коньяк китерергә боерды.
«Башлана!» — дип уйлап, мыскыллы төстә елмаеп куйды Жан.
Аның бу елмаюы тикшерүче игътибарыннан читтә кала алмады. Ул:
— Юкка ирония белдерәсез, Жан, — диде. — Без, бөек нация вәкилләре, эшлекле һәм сәләтле кешеләргә һәр вакыт хөрмәт күрсәтәбез. Безгә сезнең җинаятьләр барысы билгеле. Ләкин, һәр ике якка файда булсын өчен, без сезгә ул җинаятьләрне йолу мөмкинлеге бирәчәкбез. Әгәр бөек фюрергә чын күңелдән хезмәт итсәгез...
— Тикшерүче әфәнде, ни өчен мине кулга алдыгыз?
Тешләрен каты итеп кысудан Фройликның яңак сөякләре калкып чыкты, иреннәре калтырады. Кабинет ишеге янына керeп баскан гестапочыга: «Лейзерны алып керегез!» — дип боерды һәм, сабырсызланып, бармаклары белән өстәлдә барабан кагарга тотынды.
Тавышсыз гына ишек ачылды. Ике гестапочы бүлмәгә Ирманы алып керделәр. Ул танырлык та түгел иде: күз төпләре кара янып чыккан, иреннәре, яңаклары җилсенгән, шешкән, чәчләре тузгыган.
— Танйисызмы?
— Юк.
Култыгыннан ычкындыргач, Ирма егылып китте, аны күтәреп торгыздылар.
— Жан, мине гафу ит, — диде Ирма. — Мин барысын да сөйләргә мәҗбүр булдым... — Ул, өзгәләнеп, үксеп елап җибәрде.
Фройлик сакчыларга ишарәләде, кызны алып чыктылар.
— Я, хәзер нәрсә әйтерсез, Жан? Бәлки, бүтән киреләнеп тормыйча эшкә керешербез, ә?
— Ни өчен мине кулга алдыгыз? Мин бу кызны белмим. Минем бернинди гаебем юк!
— Кара син нинди гөнаһсыз фәрештә икән! — Фройлик шытыр-шытыр иттереп сейф тоткаларын борды, аның авыр ишеген ачты һәм кайчандыр Омельянюк искәртеп куйган калын делоны шапылдатып өстәлгә ташлады.
— Александр Бабушкин-Кабушкин, Назаров-Базаров! Соңгы тапкыр яхшылык белән сорыйм...
— Кабат әйтәм: минем бернинди гаебем юк!
— Әһә, син шулаймыни әле! — Фройлик Кабушкинның авызына сугып җибәрде.
Жан чайкалып куйды, ләкин егылмады. «Мин шулай!» — дип кизәнеп, тикшерүченең танавына ямады, теге, бүредәй улап, креслосына ауды.
Өерләре белән гестапочылар бәреп керделәр. Берсенә урындыкны алып томырды, икенчесенә аяк чалды һәм, өстәлне аударып, тәрәзәгә сикерергә чамалаганда гына арттан килеп кулларга ябыштылар. Тибеп җибәргән иде, резин тукмак белән башка суктылар, аннары аякларга тышау салдылар. Типкәләп-типкәләп кыйнау башланды. Дөнья зың-зың итеп әйләнде-тулганды да тынды, барысы онытылды...
Юеш цемент идәндә аңына килде. Караңгы. Унга кул сузсаң да таш стена, сулга орынсаң да. «Таш капчык дигәннәре шушы икән!» — дип уйлады Иван, кан төкереп.
Богау чылтыравын хәтерләтеп ишек ачылды. Кабат сорау алырга өстерәделәр. Яңагына пластырь ябыштырылган Фройлик бик үк якын килмичә генә җикеренергә тотынды. Ә ике якта резин тукмакларын әзер тотып, җиңнәрен сызганган сакчылар тора.

— Кем синең иптәшләрең? Алар кайда яши?
— Мин берәүне дә белмим.
— Ялганлыйсың, бандит!
— Гаебем юк...
— Лагерьдан хәрби әсирләрне качыруны кем оештырды?
— Белмим...
— Кем аларга кием, корал бирде?
— Мин түгел...
Аны кыйный-кыйный, җәзалау өчен махсус җиһазландырылган бүлмәгә сөйрәделәр.
— Сайчикны больницадан качырырга сиңа кем булышты?
— Мин бернинди Сайчикны да белмим!
— Әһә, белмисеңме, камчы татыгач, бәлки исеңә төшерерсең!
Озын тар өстәлгә бәйләп, ялангач тәнгә ике яклап чыжлатып камчы белән сугалар. Сугалар да сорау бирәләр, җавап булмагач, тагын селтәнәләр.
— Профессор Клумовта ничә яралыны яшердең?
— ?..
— Медсестра Виктория Габец нинди дарулар бирде?
— ?..
— Татарин Хәсән белән кайда листовкалар чыгардыгыз?
— ?..
— Давыдовны кем үтерде? Кемнәр ярдәмчеләрең?
— ?..
Гестапочылар Кабушкинның телен чишә алсалар, дистәләрчә подпольечыларны һәм урманнан кайтучы элемтәче-партизаннарны эләктерәчәкләрен аңлыйлар иде. Тик Кабушкин дәшмәде, түзде.

Ниһаять, аны электр урындыгына алып килделәр. Монысы һәммәсеннән дә газаплырак, коточкычрак икән. Аяк-кул тамырларына эретеп кургаш салгандай булды, бөтен тәнгә хисапсыз күп утлы энәләр кадыйлар сыман. Дерелдәтә, калтырата, сулап булмый, йөрәкне гүя пычак белән телгәлиләр.

Трамвайда эшләгәндә аның берничә рәт токка эләккәне бар иде. Ток сугып үлгән кешеләрне дә күрде. Ә болар кинәт кенә үтермиләр, соңгы чиккә җиткереп җәфалыйлар, газаплыйлар. Башта хәзер бер генә фикер калды: «Түзәргә!.. Түзәргә!..» Кабушкин күңеленнән әнә шул сүзне кабатлый. Бүтән нәрсә кирәкми, бүтән нәрсәнең әһәмияте юк.

Гестапочы, ток бирүне һаман арттыра барып, күзләрен елтыратып, корбанын күзәтә. Бу тәмуг газабына түзүчеләр сирәк. Хәзер, хәзер менә... Ләкин Бабушкин-Кабушкин дәшми, Бабушкин-Кабушкин телсез.

— Сөйлә! Сөйләсәң, ток бирүне туктатабыз! — ди Фройлик, Жанның калайлана башлаган күзләренә карап.
Тагын шул ук сораулар, тагын көзән җыеру, утлы энәләр, ике як яңактан елга булып агып төшкән тир...
«Түзәргә!.. Түзәргә!.. Түзәргә!..»
Буяулы стеналар каядыр артка чигенделәр, Идел таңнарына охшап, күксел томан төшкәндәй булды. Ул гүя упкынга егылды... Тән авыртмый да, бер нәрсә сизми дә. Тынлык...
Кабушкин башына салкын су сибүдән аңына килде, комсызланып бер-ике йотым су эчәргә өлгерде.

— Сусадыңмыни, егет? — диде Фройлик. — Су хикмәтле нәрсә, суда тереклек, суда көч... Сорауларыма җавап бирмәсәң, ундүрт көнгә судан мәхрүм ителәчәксең. Кеше шуннан артыкка түзми. Бәлки син?.. Юк, бу экспериментны тәкъдим итмим. Шундый сәләтле разведчик өчен

сусыз тилмерү... Нигә тилмерергә? Эшләргә кирәк, яшәргә кирәк. Гомер ике килми... Сөйгән кызың, әти-әниең бардыр, әлбәттә.

— Әти юк...

— Ә соң кайда ул? Әйе, аңлыйм, 1941 елда...

— Юк, 1914 елда.

— Патша армиясендә хезмәт иткәндә? — Фройлик, әрле-бирле йөренүеннән туктап, Кабушкинга текәлде. Ул, ниһаять, Жанның теле чишелә башлады, инде әңгәмәне иплән кенә дәвам итәргә кирәк, дип шатлана иде.

— Тагын бер кат юк, — диде Кабушкин усал итеп. — Сезнең итек астында калырга теләмичә семьясы белән Россиягә качканда Могилев янында... Сез әйткән хикмәтле нәрсәне эчеп һәлак булган.

— Ә Магильюф... Магильюф... Син үзең... кайдан син, Жан? Без синең кайдан икәнлегеңне белә алмадык. Җинаятьләрең безгә билгеле. Иң каты җәзага лаек син. Шул хакта туганнарыңа хәбәр итәргә кирәк булачак. Белми калмасыннар. Кайдан син, Жан?

Кабушкин үзен мәрхәмәтсез төстә җәзалый башлаганнан бирле беренче тапкыр елмаеп куйды.

— Шәп, шәп... Кәеф күтәрелә, — диде Фройлик. — Димәк, эшкә...

— Белмәсәгез, белегез, тикшерүче әфәнде! Советлар Союзыннан мин!

— Бала булмагыз, Жан.

— Сез дә олы җанлы булып кыланмагыз! Әйдә, башлагыз өр-яңадан. Һәм мин кабатлап әйтәм: минем берниндә дә гаебем юк. Юк! Юк!

Фройлик ишек төбендә басып торган сакчыларга ымлады:

— Аерым бикләгез. Ашарга да, эчәргә дә бирмәгез!

Тагын таш капчык. Урамда көнме-төнме икәнлеген дә белеп булмый. Коридорда дагалы итек тавышлары, сүгенү һәм ыңгырашулар чиратлашып тора. Ара-тирә ишек бикләвечләренең зыңгылдап ачылуябылулары, җикеренүләр ишетелә. Һәм күпмедер вакытка кадәр кабат барысы да тына.

Кабушкинны гүя бөтенләй онытгылар. Дүрт көн инде менә ана берни бирмиләр. Әмма барыбер, немецларга хас төгәллек белән, һәр көн иртән коридор буйлап бәдрәфкә алып баралар. Жан кулларын артка куйган килеш алдан бара, кораллы сакчы арттан. Коридордан йорт ишегалдына чыгарга да мөмкин икән. Анда әнә эшләп йөрүче ирләр күренә. Алар нибары утыз-кырык адымда... Шушы араны йөгереп узар өчен ниләр эшләргә икән соң? Иң әүвәл ирекгәгеләр белән элемтә урнаштырырга һәм көчне сакларга. Тәнгә су кирәк хәзер, су... Жан, юыну сылтавы белән краннан су эчәргә чамалаган иде, гестапочы, мона әмер юк дип, аркага резин таяк белән тамызды.

Бәдрәфтән кайткан арада Фрида исемле чибәр генә яһүд кызы Жан камерасының идәнен юып чыгара. Кайбер көннәрдә кыз әле эшен бетермәгән була. Жан, иреннәрен ялап, комсызланып сулы чиләккә һәм, суының идәнгә күбрәк түгеп калдыр дигәндәй, идәнгә ымлый, аннары кызның матур соры күзләренә ялварып карый. Күзләре тәгәрәп төшәрдәй булып карый. Кыз бөгелә-сыгыла идәнне корыта һәм Жанга күз ташлап, аңладым дигән кебек ым кагып куя.

Гестапочы бер бәйләм ачкычы арасыннан Жан камерасыныкын аралап ала. Жан ачкычның балтасын хәтеренә сеңдерергә тырыша: ике генә киртләче бар, озынлыгы сантиметр ярымнан артык түгел...

Кыз, башын оҗмах кошыдай горур тотып, үтеп китә. Жан бусагадан караңгыга атлый, тимер бикләвечнең зыңгылдавы тынар-тынмас, цемент идәнгә ташлана. Ишек артындагы почмак азрак батынкы икән, анда тавык эчәрлек кенә дым сизелә. Жан ятып идәнне ялый, шулай сусавын басарга тырыша.

Вакыт бик акрын үтә. Уйламаган нәрсә, искә төшермәгән вакыйга калмады бугай инде. Уйлар түшәмнән саран гына ут яктысы төшеп торган шушы кысан камерага әйләнеп кайталар да, үзәк өзгеч моңсу булып китә. Шулай ук барысы да беттеме инде? Иректәге иптәшләре аның турында уйламыйлармы икән? Юк, кул кушырып утырмаслар. Элемтә урнаштырыр өчен җай эзлиләрдер. Кыз геттога кунарга кайта... Аның янына кич Александра килә ала...

Эчәсе килә, тел кипкән, бәгырь яна... Үч иткән төсле, мөлдерәмә тулы бер стакан су һаман күз алдында тора. Стаканның тышына кадәр тирләгән. Менә ул, менә, үрел дә ал... Чүкеч белән төеп гарипләндерелгән бармаклар стакандагы суның салкынлыгын тоялар сыман. Ирennәрдә су тәме, авызда су тәме... Йотасы гына инде. Тик нишләп йотып булмый соң?.. Җан авырлык белән генә күзләрен ача. Сулы стакан әллә кая югала, ә керфекләр авыраеп йомылу белән ул тагын мөлдерәп күз алдына килә. Эчәсе иде, бер йотым гына эчәсе иде. Кайдадыр чишмә чылтырый түгелме? Әйе, тау чишмәсе бу! Малаховцы янындагы чишмә түгелме икән әле ул? Кышын да туңмый, чылтырый да чылтырый...

— Бабушкин-Кабушкин, допроска!

Ишек бикләвече генә шулай чылтыраган икән лә...

Кабушкин, кулларын артка куеп, алпан-тилпән атлап икенче катка юнәлә. Озын коридор буйлап үткәндә тагын йорт ишегалдына күз сала. Известьле мичкә тирәсендә кайнашалар, бүлмә агартучылардыр, ахры. Акшарлы киемнәр табу әллә ни авыр булмастыр инде, шәт... Җан үзенчә уйлый, ә Фройлик, кабахәт җан, үзенчә. Кабинет тәрәзәсенә тимер рәшәткә куйдырган... Җан моннан сикерә алмаячак шул инде... Кара син аны: адәм рәтле кешеләр кебек исәнләшеп маташкан була бит. Ә өстәленә графин белән су куйдырырга, стаканга салырга онытмаган...

— Магильюф янында... Мең тугыз йөз ундүртенче елда су агуланган булган, Җан. Самолеттан сиптергәннәр. Әтиең агуланып үлгән булырга тиеш.

— Рәхмәт куанычлы хәбәрегез өчен.

— У-у, син юморлы кеше икәнсең әле. Тик мин мәзәк сөйләргә чакырмадым. — Фройлик кулына сулы стаканны алды. — Бу суда агу юк. Менә... — Ул иләмсез төстә голт-голт иттереп суны эчеп куйды. — Сорауларыма җавап бирсәң...

— Мин бер нәрсә дә белмим.

— Су тәмле нәрсә... Бигрәк тә эчәсе килгәндә аннан тәмле нәрсә юк. — Фройлик бу юлы нәзакәтле итеп су капты. — Су тереклек бирә. Су — тормыш...

Бу — азгын мәченең тычкан белән уйнавы шикелле бернәрсә иде. Җан читкә борылды.

— Юк, — диде тикшерүче, — читкә карама, чөнки бүген агуланмаган суның көче турында сүз бара. Теге чакта агуланган булган — үтергән. Бүген... Су чиста, әмма ул барыбер бөек Германиягә хезмәт итә, ул тоттырмас Җанның телен чишә. Төлке кебек хәйләләп озак йөрде — без аны барыбер тоттык. Балык кебек өнсез — без аны барыбер сөйләштерербез! — Фройлик ишек төбендәге гестапочыга нидер ымлады, теге тиз-тиз килеп, Җанның аякларына тышау-элмәк салды, һәм күз ачып йомган арада Җан башы түбән килеш һавада асылынып калды. Авызы янына гына сулы стаканны китереп куйдылар.

Күпләр, бик күпләр чиста суның исе юк диләр. Ялгышалар алар. Чиста суның борынны кытыклый алырлык дымык исе бар. Әнә ничек эчәсене китереп, тәмле итеп аңкый ул.

— Әйт, кемнәр синең иптәшләрең?

Жан башын чайкады, күзләрен йомды, хәер, барыбер эндәшә алырлык хәлдә түгел иде ул.

— Бездән ансат кына котылырмын дип уйлама. Без сине тиз генә үтермәбез. Акрын-акрын менә шундый берсеннән-берсе коточкычрак газапларда дәмегерсең син. Дәмеккәч тә тынычлык булмас... Туганнарыңның күзен ачырмаслар: гестапо агенты иде дигән мәгълүмат таратырбыз. Әйт, киреләнмә! Ник син генә җәфа чигәргә тиеш? Кемнәр өчен, нинди шатлыклар өчен?..

«Әнә нәрсә турында кайгырта. Димәк, гитлерчылар Россияне җиңә алуларына үзләре дә шикләнеп карый башлаганнар! Түзәргә! Түзәргә! Түзәргә!» — дип уйлады Кабушкин.

Яшьрәк чакта Иван аякларын күтәреп кул өстендә торуны бернигә санамый иде. Хәзер... Күзләре атылып чыгардай булды, үпкә-бавыры гүя авызына килде.

Фройлик Жанның адәм баласы түзә алмаслык газапка дучар ителүен күреп тора иде. Кыйналган, күгәреп-янып чыккан хәлсез тәнгә азрак куәт бирергә һәм бер үк вакытта рухы сынмас бу кыю подпольечыны тагын да җәзаларга теләп, стакандагы суны Жанның иреннәренә тидерде. Баштүбән килеш су эчүнең гаҗәп авыр икәнлеген белә иде бу ерткыч.

— Эч, эч, әйдә! Кешечә мөгамәлә ошамагач, хайванча булсын! — диде ул.

Кабушкин соңгы көчен җыеп гәүдәсен чайкалдырды, урындыктагы суны эләктереп алды һәм Фройликның битенә атып бәрде.

— Ах син, бандит! Хәлең бар икән әле. Шул килеш тагын бераз асылынып тор алайса. Үҗәтлегең беткәч, чакырырсың. — Фройлик, хром итекләрен шыгырдата-шыгырдата, кабинетыннан чыгып китте.

Жанның аяклары пычкы белән кискән күк әрни, яна иде. Каеш элмәк тубык итенә тәмам батып кергән, ертык чалбарның телгәләнеп беткән балаклары тезгә чаклы төшкән, балтырдагы тамырлар зәңгәрләнеп-күгәреп чыбыркы сабы хәтле бүртеп чыкканнар.

Үзәк өзгеч бу әрнүләрдән беразга гына булса да котылып булмыймы икән? Жан бөтен гәүдәсе белән селкенеп, таган атынгандай чайкала башлады һәм тикшерүче күчереп куйган урындыкны якынрак китерде, аңа куллары белән таянып, бөтен гәүдәсен күтәреп торган аякларын бераз ял иттерде.

Юк, ничаклы гына җәзаласалар да, иптәшләрен сатмас ул. Гестапочы, Жан баштүбән килеш асылынып торуга озак түзә алмас дип, үзен чакырганны көтәдер. Көт, көт... Менә кайчан ярап куйды ул яшь чакта иренмичә күнегү ясаулар! Хәзер аякларны элмәктән чыгарырга тырышып карарга кирәк. Әгәр ычкынып булса... Кабинет бикле, сакчылар ишекнең теге ягында. Урындыкның башына ныклабрак тотынып өскәрәк күтәрелсәң, бау бушарга мөмкин. Хәзер аякларны кыймылдатырга... Менә шулай. Сул аяк ычкынмый гына! Уң аякның баш бармагы ни өчен? Һоп!.. — Жан, ит түшкәсе кебек ларсылдап, идәнгә килеп төште. Инәләргә баскан күк булды, күз алларында яшелле-зәңгәрле түгәрәкләр биеште. Тәрәзәне тартып ачарга ниятләп, алпан-тилпән бер-ике атлауга, тәрәзәләрдәге тимер рәшәткәләргә күзе төште. Әх! Ничек элегрәк күрмәде соң ул бу нәмәрсәкәйләрне?! Бәлки менә икенче ишектән чыгып сызарга мөмкиндер? Тукта, иң әүвәл туйганчы су эчәргә! Әнә графин өстәлдә генә... Су!.. Аннары ни булса булыр... Су!.. Су!..

Жан үтә күренмәле графинны кулына алды. Өстәлдәге берәр яшерен нәрсәгә кагылдымы яки графин шулай көйләп куелган идеме — коридорда сирена гүли башлады, боерык биргән, йөгерешкән тавышлар ишетелде. Икенче ишеккә омтылмады Жан, битенә, муенына су

агыза-агыза, йотлыгып эчүендә булды. Ләкин туйганчы эчәргә туры килмәде, кабинетка бәреп кергән гестапочылар, графинны тартып алып, Жанны типкәли-типкәли кыйнарга тотындылар...

Әни, сөекле әнкәем! Нигә инде син авыру улыңа чиләктән алып салкын су бирмисең? Чиләк әнә анда, ишек катындагы ыргакта гына иң. Ваня бүтән беркайчан да синең сүзеңнән чыкмас. Беркайчан чиркәүгә дә кермәс... Тик чиркәүдә җен сукмады аны. Явыз карчык Глафира Аполлоновна таяк белән сукты. Шуңа менә башы авырта. Эссе... Ә Глафира Аполлоновна хәзер Минскида... Самогон сата... Юк, Ваняга самогон кирәкми, су кирәк, су... Бер кружка гына... Алайса бер йотым... Әни, бер йотым...

Ә бит аның әнисе хәзер... Казанда түгел, Малаховцы авылында, сугыш алдыннан шунда күчкән иде. Ваня, авыл янындагы кышын да туңмый торган чишмәгә барып, бозлы кытыршы сукмак буйлап ике чиләк су алып кайтып бирде...

Нигә аның мендәре бу тикле укмашкан соң? Әх, Тамара, мендәрне әйбәтләп күпертергә иде...

Жан саташа бугай шул. Сәгатьләр шулай йокылы-уяулы узды. Коридорда сакчылар алмашты, тагын алмашты, тагын... Жан онытылды, тынды. Юк, бөтенләйгә түгел. Менә ул шешкән күзләрен ачты, икенче ягына әйләнергә теләп селкенеп куйды һәм, авыртуга түзә алмыйча, идәнгә йөзтүбән капланды. Ыңгырашты, аннары сөйрәлеп, канлы уч төпләренә таяна-таяна почмакка үтте. Цемент идәннең батынкы җирендә азрак су булса, җыештыручы кыз бирегә кереп чыккан дигән сүз... Су бар иде. Иван кипкән, яргаланган иреннәрен дымык цементка тидерде. Ике-өч йотым су...

Аннан Жан тагын саташты. Бу юлы улын күрде ул.

Улым, кыю арсланым, оялма, якынрак кил миңа! Мин әле сине бер мәртәбә дә күргәнем юк шул. Күрмәм дә инде... Мине, бәгырькәем, фашистлар асачак... Мин мәет инде. Әтием кебек мәет... Ул теге чакта немецлар агулаган суны эчеп үлгән. Чиста су үз улларына калсын өчен эчкән ул агулы суны. Ә хәзер чиста су дошман кулында. Теге чакта әтиемне агулаган немецларның уллары хәзер миңа эчәргә су бирмиләр инде. Сугышчан иптәшләремә хыянәт итсәм генә кулыма су тоттырачаклар. Моңа бара алмыйм мин! Юк!.. Әтиемне күрә алмадым дип миңа рәнҗемә. Мин дә үз әтиемне күрә алмадым бит. Язмыш... Дошман сәбәпче моңа! Барысы өчен дә түләттерербез без фашистлардан. Сиңа яшәү җиңелрәк булыр. Сугыштан соң... Ә без барыбер җиңәчәкбез, улым. Тик безне онытмагыз, фашистларның ерткычлыгын онытмагыз!

Сынган кабыргаларым авырта, чүкеч белән төелгән бармакларым әрни, резин таяк дөмбәсләгән табаннарым сызлый...

Тәпи йөреп киткән улым, газиз әткәңнең ничек үлүен әнкәңнән сорашырсыңмы син? Ә нәрсә дип җавап бирә алыр инде ул сиңа? Кайгылы хәбәр аңа барып җитмәс шул — мин үземне Жан дип кенә йөрттем бит. Чын фамилиямне һичкем белми... Әмма Жан Кабушкинның тикмәгә генә яшәмәве барыбер илгә билгеле булыр!

Улым, васыять итеп ни калдырам мин сиңа?

Изге җиребезне, ирекле Ватаныбызны.

Ватанны саклау һәм бәдбәхет дошманнан аяусыз үч алу теләге бөтен куәтемне гүя бер йодрыкка туплады. Үч алдым мин явыз дошманнан!

Шулай да, улым, үч алынып бетмәде: күнелемдә һаман самолетлар гүләве, миналар чинавы, йортларның гөрселдәп ишелеп төшүе, ут, төтен... Аналар, хатыннар наләте... Куркытыр өчен, тез чүктерер өчен

асулар, кисүләр, тереләй җиргә күмүләр, газда тончыктырулар, мичләрдә яндырулар...

Менә ул фашистлар алып килгән «яңа тәртип»!

Шул вәхшәткә, ерткычлыкка чик кую өчен үзеңнең күпмедер эш башкарган булуыңны тою үлемнән курку тойгысын тәмам юкка чыгара ала икән. Шуңа күрә, балам, мин тыныч һәм яңа газапларга теш кысып түзәргә әзер...

Жанның хыялындагы улы һәм үз-үзе белән булган әңгәмәсен ишеткәндәй, камера ишеге шартлап ачылды. Кара киемле ике сакчы кереп, Жанны кабат сорау алуга алып киттеләр. Аягында чак-чак басып торса да, кулга ялтыравык богау салып, чылбырын ике яктан үзләре тотты.

Жан: «Тагын бер яңалык», — дип уйлады.

Бу юлы бөтенләй бүтән бүлмәгә алып керделәр. Яшел постау җәелгән киң өстәл янында кара киемле, җиңенә фашист тамгасы бәйләгән майор кәгазьләр актарып утыра иде. Ул, Жанны баштанаяк күздән үткәргәч, тыныч тавыш белән:

— Кирәгеннән артык тырышканнар икән, — диде. Урындыкка ымлады. Үзе, кулларын артка куеп, ялтыравык итекләрен шыгырдата-шыгырдата, ишек яныннан бер әйләнеп килде һәм югарыдан карап:

— Мин сезгә тырнак очы белән дә чиертмәячәкмен, — диде.

— Рәхмәт. Мин барыбер дәшмәячәкмен...

— Беләм. Мин сезнең делоны ярыйсы ук шәп өйрәндем. Азиат кирелеге бар сездә.

Тикшерүче Жанның кайсы төбәктән булуын әнә шулай эрактан әйләнеп ачыкларга тели иде, күрәсең. Ләкин аның бу хәйләсе барып чыкмады: Жан елмайды гына.

— О-о!.. Жан елмая. Это — хорошо! Давай кәгазьсез генә сөйләшик. — Майор өстәлдәге делоны шапылдатып ябып куйды. — Менә хәзер әйтегез әле: сез ни өчен киреләнәсез? Сезгә күп акча, алтын, имение, чибәр фрау тәкъдим иткәннәр. Яшә, типтер, рәхәтлән генә! Бөек Германиягә эшләргә ник күнмисез? Ни понимай... Ни сәбәп?

— Дөреслекне белергә телисезме, майор әфәнде?

— Конешно!..

— Бурыч, майор әфәнде.

— Нинди бурыч? Акча бирәбез — түләрсез. Күп, күп акча...

— Ил алдындагы бурыч ул.

— Чепуха!

— Чепуха булса, мине моннан качуны оештырыгыз. Күп, күп акча, алтын алырсыз.

Майорның күзләрендә ачу кабынды, ләкин ул шундук әүвәлге хәленә кайтты:

— Алтын? Кайдан килсен ул сезгә?!

— Анысы өчен кайгырмагыз, — диде Жан. — Сораганыгызны китерерләр. Я, килештекме?

— Бу... Бу фюрерга хыянәт итү була...

— Алдынгы фикерле немецлар фюрергә хыянәтне Ватанга хыянәт дип бәяләмиләр, герр офицер. Алар: «Безнең намус, безнең бәя Гитлерга биргән антыбызны формаль үтәүдә түгел, халкыбызга тугрылыклы булып калуда», — диләр түгелме? Мәсәлән, Эрнст Хадерман шулай дигән иде бугай...

Тикшерүче чыраенда гаҗәпләнү катнаш кызыксыну барлыкка килде:

— Интересно, Жан... Ошень интересно... Мин уйлыйм... Сезнең тәкъдим турында да уйлыйм. — Ул, усал елмаеп, өстәл читендәге кызыл төймәне басты.

Жан, тәмләп су эчкән гестапочыга карамаска тырышып: «Шулай ук алтын балык кабармыни? — дип гаҗәпләнеп уйлады, күзләрен йомды. — Булмас, күзләре мәрхәмәтсез. Шулай да... ятып калганчы атып кал, диләр. Бәлки сары шайтан булышып та куяр...»

Жан сак астында ишектән чыгуга, майор Артур Вильке, ярдәмчесен чакырып, хәрби әсир Эрнст Хадерман рече басылган листовканы табып бирергә кушты. Ярдәмчесе борылып кергәнче, йомшак кәнәфигә кырын авып, озаклап сигара тартты. Уйланды. Минскига килгән көннәрен исенә төшерде. Аннары сөмсерсез күзләрен листовкага төбәде. Сөзәргә теләгәндәй карап торды. Иягенә таянды, мундир якасын ычкындырды, бермәл иренен чәйнәде һәм, корт чаккан кебек урыныннан сикереп, ишекле-түрле йөрергә кереште.

— Доннер-виттер... Коточкыч ил бу! Коточкыч ил... — Майор сүгенеп куйды һәм телефонга ябышты.

Бүлмәгә Ирма Лейзерны керттеләр. Кыз теләгәнчә җавап бирмәгәч, моны киреләнү дип аңлап, аның усак яфрагыдай калтырап торган ябык гәүдәсен урындык аркасына, кулларына озынча тар өстәлгә бәйләп куйдылар.

Кайчан гына әле кына төшерелгән матур тырнаклар астына энәләрне майор үзе кадады.

— Немецча листовкаларны таратуда Жанга кем булышты?

— Аның квартир хозяйкасының адресы, исеме ничек?

— Үтерелгән лейтенант Рудольф Вилькенең шәхси удостоверениесе кемдә?

— Жан трофей пистолетларын кайда саклый? Аңа кемнәр булышты?

Җавапсыз калган һәр сорау өчен тырнаклар астына энә батырылды...

Озакламыйча медсестра Виктория Габец, профессор Клумов һәм Жанның кыю ярдәмчесе Бәләкәй Толикны кулга алдылар. Гестапо яшь егеткә өмет баглый иде. Һәм энәләр аның тырнак астына кадала башлады. Аңын җуйгач, өстенә су сиптеләр, ниндидер укол ясадылар, исерттеләр, электр урындыгына утырттылар...

Өч көн дигәндә бүләк пистолетның бер өлеше тикшерүче өстәлендә иде инде.

Чират янә Кабушкинга житте. Бу юлы майор кыланып тормады:

— Үзегез теләп сөйләрсезме, ярдәм итәргәме? — Ерткычныкыдай кан баскан күзләрендә зур усаллык чагылды. — Беренче сорау... — һәм өстәл тартмасында яткан бүләк пистолетның көмешәле өлеше өскә чыкты.

— Моның язулы тоткасы кайда?

Жан башын чайкады.

— Кайда?

— Кызганыч... Ах, кызганыч!..

Жанны чаршау артына сөйрәделәр. Ирмага һәм Толикка бирелгән сораулар кабатланды, энәләрне исә утта кыздырдылар...

Жан аңга килгәч, фашист сулы стаканны кулына алды:

— Әйтсәң, эчәрсең...

— Мин бернәрсә дә белмим!

— Беләсең! Бик күпне беләсең! — Майор итче кебек симез ярдәмчеләренә җикерде: — Хәтерен яңартыгыз!..

Көн саен шулай... Мондый рәхимсез җәзалауларга түзү авырайганнан-авырая бара. Кара янган, тирән җәрәхәтләр белән тулы тән азрак

ял өметләнеп, Жан аңсыз чакта авыздан Александраның адресы ычкынса? Хәзер тән үзенә, ан үзенә аерым яши сыман... Аң каршы торырга чакыра, тән бирешә бара. Начар фал иде бу. Хыянәтче булганчы үлүең мең артык. Ләкин ничек үләргә? Юк, моңа вакыт җитмәгән әле. Ирекътәгеләргә хәбәр итәсе нәрсәләр бар. Элемтә урнаштырмый калмаслар... Әх, сусауны баса алсаң икән...

Иван ишек артына почмакка таба шуышты. Идәндәге батынкы җирдә азрак су бар иде. Бөтен эче, бәгыре уттай янган кешегә тавык эчәрлек су сумыни ул! Тышта хәзер гөрләвекләр агадыр, боз кузгалгандыр... Ә аңа бер йотарлык су бирмиләр!

Кемдер җырлый түгелме? Гестапо подвалында, тоташ җәзалаулар, әрнү, газап эчендә җыр... Мөгаен, Иван яңадан саташа башлагандыр. Юк, кызлар тавышы бу. Төрмә җыештыручысы Фрида җырлый икән. Ул бәлки Иванның игътибарын үзенә җәлеп итәр өчен җырлый-җырлый идән юадыр?

Җыр тынды. Кабердәге кебек тын һәм ямансу булып китте.

Көтмәгәндә камера ишегенең кәгазь генә сыярлык ярыгында ак нәрсә күренде.

Иван тетрәнеп, калтырап кәгазьне кулына алды, ашыга-ашыга укып чыкты. Берничә сүз... Ә ничаклы көтте аларны Җан! Әгәр ышанырга яраса, бу хатны ирекътәге дуслар язган булырга тиеш. Алар Фриданың үз кеше икәнлегенә ишарәләгәннәр. Нәрсә кирәклеген сораганнар, җавап язу өчен, хатның бер почмагына карандаш үзәге кыстырып җибәргәннәр.

Җавап язаргамы, бу — серне алу өчен эшләнгән хәйлә генә түгелме? Тәвәккәлләргә, ләкин ирекътәге дусларга зыян китерерлек бер сүз дә язмаска!

Кабушкин кыздан идән юганда суны күбрәк түгүен, чүпрәк белән корытып алмавын үтенде. Әгәр мөмкин булса, нечкә резин көпшә табып, аны камерага ташларга, коридорны юганда сулы чиләкне ишек янына ук китереп куярга кирәклеген әйтте.

Икенче көнне Кабушкин чиләктән туйганчы су суырды. Аннары салам тутырылган мендәр астыннан хат, шоколад һәм бер телем икмәк табып алды.

Хат бу юлы да ирекътәге дусларыннан иде. Алар подпольеның кыен булса да хәрәкәт итүен, Җанны качырыр өчен хәзерлек алып баруларын, әгәр бу барып чыкмаса, адвокат яллау яки тикшерүчене сатып алу өчен Лена үзенең алтыннарын бирәчәген сиздерделәр.

Бәләкәй Толикның кулга алынуын раслаганнар. Ә Җан шикләнеп йөргән Зур Толик, урманга китүчеләргә кирәк дип, яшерелгән коралларның кайда саклануын төпчеңә икән...

Кабушкин, кәгазен бусагага куеп, ишек ярыгыннан төшкән яктыда хат язарга керепте:

«Кадерлеләрем!

Мин сау-сәламәт. Хат язганда үз исемнәрегезне куймагыз һәм дуслар белән еш чуалмагыз. Мине бернинди дипломатия дә, бернинди алтыннар да коткара алмый, моны истә тотыгыз...

Мар. Пет.дан белешегез, ни дә булса бирмәдеме икән? Аңа әйтә күрегез: телен тешләп, өендә генә утырсын, һәртөрле «Т»ларны һәм аның кебекләрне, кадак та бирмичә, артларына тибеп чыгарсын, юкса алар «китүчеләр» иңртеп килерләр һәм бу миңа өстәмә газап кына китерәчәк... Тизрәк кыймылдасагыз иде. Миңа шундый ачкыч табыгыз...»

Җан үз камерасын бикли торган йозакның ачкычы сурәтен кәгазьгә сызды.

Аннары өстәп болай дип язып куйды: «Заславский районыннан качкан дезертир Войчковский монда кешеләрне сата.
Кулыгызны кысып калам».

Кабушкин тернәкләнә башлады. Моны гестапочылар да күрми калмады, әлбәттә. Кабат допроска чакырдылар, кабат һуштан язганчы төрлечә җәзаладылар.

Беркөнне сорау алганда Бәләкәй Толик белән күзгә-күз очраштырдылар. Аны «танымагач», ярсып бик каты кыйнап ташладылар. Агалы-энеле Евдокимовлар, профессор Клумов һәм медсестра Виктория Габец белән көрешкәч тә шундый ук хәл булды.

Ниһаять, барыбер файда юк дип булса кирәк, җәзалауларны күпмегәдер туктаттылар. Башка тоткыннар белән беррәттән ашарга-эчәргә бирә башладылар. Подвалда тоткыннар шактый иде хәзер. Арада хыянәтче булмагае дип, Җан алар белән бәйләнешкә кермәде. Аны һаман ялгызын бикләп тоттылар. Ул һаман качу турында уйлады. Сораган әйберләрне ирекtәгеләр тиз табып китерделәр. Алар хәзер Фрида карамагында. Кыз, җайлы вакыт табып, камера ишеген ача алса... Җан шул турыда Фридага кат-кат язды. Тик кызның әллә тәвәккәллеге җитмәде, әллә җае чыкмадымы икән? Моннан ычкына алса, гитлерчылар бөтен ачуны Фридадан һәм аның әнкәсеннән алачакларын уйлап, Җан, эш эшләнгәч тә, бер минут кичекмәстән аларны дусларыннан партизан отрядына җибәрүне үтенде. Боларның барысын бер вакытка туры китерү бик үк җиңелдән түгел иде шул. Бераздан исә төрмә подвалының баш сакчысын алмаштырдылар, аңа яңа ярдәмче билгеләделәр. Яңа себерке һәр вакыт яхшырак себерә бит ул. Селкенергә дә җай калмады. Күзләре тик тормаган Кабушкинны бүтән камерага күчерделәр. Юк сәбәпне бар итеп көн саен үтергәнче кыйный башладылар. Качу түгел, кош теледәй хат кертү дә кыенлашты. Ләкин барыбер ирекtәгеләр белән элемтә бөтенләй өзелмәде.

Җан үзенә агу кертүләрен сорады. Түзәрлек бер әмәле дә калмаган иде аның. Ләкин дуслары агу кертергә ашыкмадылар. Җан ялвара-ялвара гозерен кабатлады.

Александра: «Кадерлем, түз. Әле өметне өзмик», — дип язды.

Кайдадыр югалып торган майор сорау алырга тагын үз бүлмәсенә китертте. Тәм табып, тешләрен шыгырдата-шыгырдата җәзалагач, Җан менә-менә аңын җуяр чакта бүтән һичнәрсә белән кызыксынмаячагын, бу соңгы соравы икәнен әйтте.

Иван калкынып куйды: соңгы сорау, иң соңгы сорау бит... Җавап бирүгә, бу әрнүләр, бу газаплар барысы бетә. Бетә!..

Каян килгәндер — күзләреннән яшь тамды. Моны фашист тоткынның рухы сынды, теле чишелер сәгате сукты дип бәяләп, юхаланып, кулына сулы стаканын тотып якын ук килде:

— Фәкать бер сорау... Бердәнбер сорау: бүләк пистолетның икенче өлеше кайда?

«Тополь төбендә...» Бу сүзләр тел очында гына тора. Шунда ук Җан айнып киткәндәй була: тополь төбен казыганчы ул Александраны кулга алачаклар. Мөлаем, сабыр Александра...

Кабушкин җан ачысы белән:

— Мин бернәрсә дә белмим! Белмим! — дип кычкыра.

— Беләсең! Ну, әйт, ну...— Майор утта кыздырылган энәләрне якын китереп, еландай ысылдый: — Юкса...

— Аһ, кызганыч!..

— Нәрсә кызганыч? Кем кызганыч?

— Теге чакта үз пистолетыгыз белән маңгаегызга атмавым кызганыч!..

— Мин дә сине кызганам... казино янында атмаган өчен! Но моңа өлгерәбез әле! Ә хәзергә полущай энәләрнең кайнарын... азнат шашлыгы урынына!...

Жан, хәл жыя-жыя:

— Әгәр тагын кагылсагыз... бүләк пистолет токсасы янына энегез Рудольфның шәхси удостоверениесен дә куеп, аның кем тарафыннан һәм ни өчен үтерелүен бөтен нечкәлеге белән язып тиешле җиргә тапшырачаклар. Аннары майор Вилькега гына түгел, Берлиндагы барлык Вилькеларга капут! — диде.

Фашистның күзләре акайды. Бер мәл өнсез торгач, Кабушкин делосының тышына ашыга-ашыга нәрсәдер язды да янә кызыл төймәне басты.

Жанны бүтән чакырып борчымады.

Беркөнне безнең самолетлар дошманның хәрби объектларын бомбага тотарга керешкәч, сирена үкерүе һәм көчле сак астында тоткыннарны бер тирәгәрәк җыйдылар. Бомба төшеп шартлаган саен җир селкенә иде. Гестапочыларның чырае караңгыланганнан-караңгылана барды. Тоткыннар исә бомбаларның ишегалдына төшеп шартлавына да риза иделәр: ничаклы фриц теге дөньяга олагачак! Әнә ничек тетрәнеп-тетрәнеп куялар.

Фрида исә бу ыгы-зыгыдан бик оста файдаланды һәм озакламыйча Жанның тагын бер хаты иректәге дуслары кулына килеп иреште.

Жан анда үзен дә санаганда ун көрәшченең төрмәгә эләгүе, кәефенең шәп булмавы турында язган. Хатын болай дәвам иткән: «Ә хәзергә минем хакта — тынлык. Мин болай фикер йөртәм: алар миннән берниндә яңа нәрсә ала алмадылар, барлык җәзалаулары җилгә очты, шуңа күрә, мөгаен, халыкка бүләк итеп 1 Майга асарга ниятлиләрдер. Башкача ничек булсын соң? Алар миннән бер кешё фамилиясен дә әйттерә алмадылар бит, ә миңа каршы 1941 елдан алып материал тупланган һәм ул шактый җитди.

Миңа нәрсә эшләргә кала? Бөтен гомеремне барлык прогрессив кешелек дошманнары белән көрәшкә, халкым өчен, Ватан өчен көрәшкә багышлыйм дип ант иткән идем бит мин! Һәм кинәт тормыш белән саубуллашырга туры килгәч, сатлык җанга әверелергәме?..

Без әле аз эшләдек һәм гомерне саклап калырга кирәк, дисез сез. Ә бүтән юл калмаган булса һәм киләчәктә бәхетле кешеләр тарафыннан минем исемем хурлык тамгасы белән билгеләнмәсен дисәң, нишләргә? Минә мәсьәләне шулай куярга кирәк — үләргә икән — музыкасы янгырап торсын!.. Бүтәннәр зыян күрмәсен өчен барысын да эшлим һәм эшләрмен...»[1]

Фрида икенче көнне Жанга дип язган үз хатын һәм подпольечылардан килгән хатны тапшырды. Җавап алырга өлгермәделәр...

Сәгать бишләрдә Жанны кораллы сакчылар каядыр алып киттеләр. Ул пальтосыз, ялан баш иде.

Тышта апрель кояшы елмая, хәрабәләр астыннан баш калкыткан куаклар яфрак яра, чәчәккә бөреләнә.

Жан, башын горур тотып, ничаклы гына җәзаласагыз да рухымны сындыра алмассыз дигәндәй, чак кына көлемсерәп атлады.

Һәм шул китүеннән кайтмады.

Ничек үтерелүе дә, кабере дә билгесез...

---

[1] И. К. Кабушкинның фашистлар төрмәсендә язган соңгы хаты. Төп нөсхәсе Белоруссия Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының партия тарихы институты архивында саклана. (Автор).

*
* *

Буяулары ялтырап торган 24 нче трамвай депо ишегалдына һәр көн үз вакытында кайтты. Аны кулына ялтыравык ачкыч тоткан берәү каршылый иде. Ул — Жанның яшьлек дусты, трамвайларны депога көндәлек ремонтка кертүче, дошманны үз өнендә кыйнап, өч орден һәм медальләр тагып туган якларга исән-сау әйләнеп кайткан танкист Харис Бикбаев. Харис, гәүдәсен төз тотып, 24 нче трамвайга керә, тукталып тынып кала, йөртүче кабинасының стенасына кадакланган тутыкмас ак корычка язылган, инде күңеле күптән ятлап өлгергән кадерле сүзләрне укый: «1933—34 елларда бу трамвайны Советлар Союзы Герое Иван Константинович Кабушкин йөртте».

Яшьлек еллары исенә төшә Харисның, үткен карашлы, һәрвакыт шат Иван күз алдына килә. Ул, әүвәлгечә, киң елмаеп депо ягыннан килеп чыгар да, әйдә рейска киттек, Харис, безне халык көтә, дип әйтер төсле тоела иде.

Моторлар гүли, моторлар Жанның үлемсезлеге турында мәңгелек җыр җырлый сыман иде.

*
* *

Аның кайту хәбәрен олысы-кечесе ишетте. Ул кайтты да, читтә озак йөрүенә уңайсызланган кебек, басу капкасы янында тукталып калды: кардәш-ыру, күрше-күлән һәм карт әнкәсе аңа рәнҗемиме, туган нигезгә баш иярга рөхсәтме, янәсе.

Үзен күптәннән бирле бик зарыгып көтсәләр дә, Герой-солдат баскан урыныннан кузгалмады. Һәм аны каршыларга бөтен авыл халкы басу капкасына җыелды. Дошман гаскәрләре турында кыйммәтле мәгълүматлар туплаган Жан, нәкъ утыз өч ел элек, җилдәй җитез атта шуннан узып киткән иде. Аның: «Мин кайтырмын, әнкәй! Кайтырмын!» — дигән көр тавышын юл чатындагы көяз чыршылар һаман хәтерлиләр сыман әле. Кулга-кул тотынышкандай тезелеп басканнар да, талгын җилдә чак кына селкенеп, шул хакта серләшәләр кебек.

Чыршылар яныннан ук басу башлана. Офыкка кадәр җирдә инде тәмам өлгереп саргая башлаган бодай дingезе чайкала. Җете көяшлы зәңгәр күктә җитез тургайлар җыр суза. Алар җыры гынамы бу? Юк икән: сулда, ташлардан-ташларга сикереп, эреле-ваклы чишмәләр челтери. Иген исе, бал исе, хозурлык әйләнә-тирәдә. Дөнья гаҗәеп тылсымлы көй белән тулы. Тыңлый белеп тыңла гына!

Челтерәп аккан чишмәләр тавышына, көмеш телле тургайлар сайрашына яхшы пар атлар муенындагы җиз кыңгырау чыңнары да кушыла икән: туй килә бирегә таба! Туй! Шулай, томырылып, тузан туздырып, сөлгеләр, кулъяулыклар җилфердәтеп, дирбияләренә-гә җиз тәңкәләрен җемелдәтеп Мир авылыннан Малаховцыга туй килә.

Оркестр уйнап җибәрде. Галибанә тантаналы авазлар тынарга өлгермәде, олы юл чатына баскан мәһабәт һәйкәл өстеннән ак ефәк пәрдә акрын гына шуып төште. Халык диңгезе икегә аерылып, һәйкәлгә таба омтылучы чал чәчле анага юл бирде. Аякларының җегәре юк, еш-еш сулый; ләкин һични белән исәпләшмичә, үзенә булышырга теләүчеләрдән баш тартып, ул һаман алга атлады. Барып җитте, тез-

ләнде, калтыраган ябык куллары белән һәйкәлнең шома нигезен сыйпарга кереште. Тоныкланган мөлдерәмә яшьле күзләр таш сынның битенә текәлде, күм-күк юка иреннәрдән әрнүле хәлсез өн сытылып чыкты:

— Сынка... Иванушка наныем!.. Бик озак көттем мин сине, бәгырь кисәгем. Менә кайттың. Белдем, белдем мин синең кайтасыңны!.. Шуна күрә үлмичә көттем дә көттем мин сине!..

Ана хәлсез генә үкседе дә үкседе.

Бу манзараны авыр кичергән шикелле, кояш болыт артына китте. Тургайлар тынды. Игеннәр, авыр көрсенеп, җиргә таба иелделәр, чишмәләр дә агудан туктады сыман... Кайдандырерактан иң нечкә кыллар гына суза алган, бәгырьне теләтторган илаһи моң агыла башлады. Аңа бүтән кыллар кушылды, һәм үзәк өзгеч аһәң яңа хөр бизәкләр белән баеды. Алар үсте, тирә-юньне иңләде, биеккә — күкләргә ашты һәм кояш чыкты.

Шул чак һәйкәл янына кияү белән кыз килде. Алар, аяк очына чәчәкләр куеп, һаман әле таш сынның нигезен сыйпаган анага бил бөгеп баш иделәр. Кемдер бодай тулы коштабакны сузды. Ана ябык гәүдәсен турайтты, зиһене түнгән авыр халәттән мәңгелек чын тормышка кайтты: күрде, сизенде ул җир улларының үзеннән фатиха көтүен. Ана гәрәбәдәй тук бөртекләрне кушучлап-кушучлап кияү белән кыз өстенә сипте.

— Бәхетегез мул булсын. Үзегез дә, балаларыгыз да күрмәсен без күргән каһәр сугышны!..

Олы юл чатында һәйкәл тора. Аның янында кешеләрне тирәнтен уйландырган тантаналы моң тора.

Ике яклап сафка баскан мәңге яшел чыршылар монда хакимлек иткән галибанә тынлыкны саклыйлар.

Бодай басуы чайкала да чайкала, чишмәләр чылтырый да чылтырый...

Минск — Казан

## Аяз Гыйләҗев

# БЕЗ УНИКЕ КЫЗ ИДЕК...

ДРАМА 2 БҮЛЕКТӘ[1]

КАТНАШУЧЫЛАР:

Наилә — секретарь-машинистка.
Зилә — артистка.
Рабига — врач.
Нәҗия — балалар бакчасында мөдир.
Диләрә — кибет мөдире.
Ләрия — ательеда кием тегүче.
Өлфәт, Мәрдән, Габбас — боларның һәммәсен бер артист башкара.
Чулпан — Наиләнең кызы, 5—6 яшендә.

Вакыйга бүген дә, иртәгә дә очрарга мөмкин.

### БЕРЕНЧЕ КИСӘК

Бүлмә. Тәрәзә пәрдәләре төшерелгән. Ярым караңгы. Биш хатын — бишесе биш җирдә. Музыка. Музыка тавышы акрынлап тына. Сәгать суга.

Зилә. Бишне суктымы?
Рабига. Санамадым... Дөресрәге, ишетмәдем.
Диләрә. Бишне.
Зилә. Ә тышта дөм караңгы диярлек...
Рабига. Көз бит. Иртә караңгылана. Көне дә шундый салынкы.

Ут яндырырга тели.

Зилә. Кирәкми.
Ләрия. Караңгыда утыру әйбәтрәк инде.
Рабига. Яктыда бер-беребезне күрә башларбыз дип куркасыңмы, Ләрия?
Зилә. Алай булуы да бар, Рабига. Яктылыктан куркуыбыз да бик ихтимал.

Пауза.

---

[1] Әлмәт татар дәүләт драма театрында 1977—1978 ел сезонында куелды.

Д и л ә р ә. Шулай да, таралырга вакыт җитмәдеме икән? Без бригада булып эшлибез. Бүген смена тапшыра торган чуалчык көнебез. Кибетне япканчы, миңа кайтып өлгерергә кирәк.

Л ә р и я *(Диләрәгә, шыпырт).* Әйбәтрәк колбаса юкмы сездә? Габбасым мин пешергәнне яратмый башлады.

Н а җ и я. Колбаса да булдымы ризык?

З и л ә. Дөнья сүзләрен куеп торыгыз.

Л ә р и я. Бетте, бетте, Зилә җаным. Шулай да, Диләрә кайтып китсен. Кайтсын, кайтсын. Гади сатучы гына түгел ич ул, мөдир. Акча тапшырасы да бардыр. Монда нишләп утырсын? Әле килә алуына мең рәхмәт.

Р а б и г а. Үзеңнең кайтып китәсең килә синең, Ләрия.

Л ә р и я. Минемме? Кояштыр, юк. Сездән аерылырга ашыгам диме, язмаганны?..

Н а җ и я. Туктагыз!

Зилә сәхнәнең бер кырындагы телефонга бара. Икенче якта, авансценада диярлек, икенче телефон. Зилә телефонга барганда авансценага Ир кеше чыга. Аның йөзе күренми дә диярлек.

З и л ә. Алло, театрмы? Алло, алло, театр!

Ө л ф ә т. Театр тыңлый, Зилә ханым. Бу сез бит!

З и л ә. Мин идем, Өлфәт абый.

Ө л ф ә т. Ни булды, Зилә ханым?

З и л ә. Өлфәт абый, сез мине кичерә күрегез зинһар, бүген кичке спектакльдә уйный алмыйм.

Ө л ф ә т. Авырыйсызмы?

З и л ә. Соң хәбәр итә дип ачуланмагыз, уйный алмыйм. Без әлерәк кенә дустыбыз Наиләне җирләп кайттык. Аның өендә утырабыз.

Ө л ф ә т. Кайгыгызны уртаклашам. Зилә ханым. Борчылмагыз, әле вакыт бар. Адресыгызны әйтсәгез, машина җибәрермен.

З и л ә. Машина? Минем кайгымны төяп китәргәме?

Ө л ф ә т. Сез нык ихтыярлы, көчле рухлы артистка. Бүген аерата минем спектакль икәнен дә беләсез.

З и л ә. Беләм.

Ө л ф ә т *(шаяртырга теләп).* Көчле икәнегезне дә беләсезме?

З и л ә. Сезнең һәр очракта ни әйтәсегезне беләм.

Ө л ф ә т. Профсоюзларның өлкә конференциясеннән кунаклар килә. *(Шыпырт.)* Хуҗалар булачак! Чит шәһәрләрдән вәкилләр күп. «Бүген Зилә Сәмирханова уйныймы?» дип өзлексез шалтыратып торалар. Бүген сез уйныйсыз! Сез! Шуның өстенә шәп тә уйныйсыз!

З и л ә. Үз гомеремдә беренче тапкыр уеннан баш тартам.

Ө л ф ә т. Утыз тугыз градус җәр белән сәхнәгә чыккан Зилә бит сез.

З и л ә. Юк, Өлфәт абый, булдыра алмыйм. Башка бер спектакль булса икән!.. Мәрзия ханым өйдә, әйдә, бүген ул уйнасын.

Ө л ф ә т. Түрәләр була дисәң, Мәрзия ханым үрмәләп тә килер анысы.

З и л ә. Наилә безнең иң якын дустыбыз иде. Иң якыны! Уникe кыз бергә үскән идек без, Өлфәт абый. Иң чибәребез, иң юмартыбыз, иң акыллыбыз ул иде... Менә ул бүген салкын кабер куенында.

Ө л ф ә т. Кайгыгызны тагын бер кат уртаклашам, Зилә ханым. Телефоногызны әйтегез дә... Каян шалтыратасыз?

З и л ә. Юк, Өлфәт абый!

Трубканы куя, баягы музыка яңгырый, кинәт өзелә.

Пауза.

**Ләрия.** Зилә, Зиләйлүк! Яңа спектакльдә ана ролендә сине искиткеч диләр.

**Зилә.** Нигә килеп карамыйсыз соң?

**Нәҗия.** Газеталарда да мактадылар. Балалары ташлап киткән ятим ананы уйныйсың икән.

**Зилә.** Ишетеп, белеп торасыз, карарга килмисез.

**Диләрә.** Вакыт юк, Зилә.

**Рабига.** Ялгызлык кемгә дә куаныч түгел... Аналар ялгыз калса да аяныч, балалар ятим калганда да читен!

**Ләрия.** Ялгызлык дигәннән, өйгә шалтыратып алыймчы бер.

**Рабига.** Түзәрсең.

**Ләрия.** Я инде, бер генә сүз әйтәм.

**Нәҗия.** Син, Диләрә, бригада булып эшләгәч, хафаланма артык, синнән башка да сменаңны тапшырырлар. Минә минем хәлләрем җайсызрак.

**Ләрия.** Җайсыз? Дүрт тулдымы детсадыңда бер бала калмый! Хәзер әниләре балаларны чамасыз иркәли, ятьрәк үз яннарына алу ягын карыйлар.

**Нәҗия.** И-и, төрлесе була, Ләрия иркәм. Ваемсыз ата-аналар аз дисеңмени? Ата, анага ышана да, сыра эчәргә китә. Ана, этисе барып алыр әле ди дә, өч-дүрт сәгать чәч бөдрәләтеп утыра. Утыр аннары ярты төн авышканчы аларның газиз балаларын саклап!

**Ләрия.** Мөдир ич син! Ташла да кит! Син, Нәҗия, ул детсадыңда чыр-чуга ничек чыдыйсыңдыр. Өйдә бер бала белән җык күрәм.

**Рабига.** Синең балаң бер генә түгел.

**Ләрия.** Авызыңнан җил алсын.

**Рабига.** Габбасың бит бала урынына тора.

**Диләрә.** Зилә, кибет ябылганчы кайтып җитә алмаммы дигән идем. Минем хәлгә керегез инде.

*Зилә ут яндыра, сүзсез генә барысын да карап чыга.*

**Рабига.** Зилә кайтып китмәгәндә, андый сүзне ничек әйтә аласыздыр.

**Ләрия.** Зилә теләсә ни эшли ала! Атказанган артистка. Театр директоры белән ничек сөйләште. Әгәр мин ательебыз директоры Йосиф Маркович белән бер генә тапкыр шулай сөйләшә алсам... Ой, куркыныч. Гомумән, ирләр белән сөйләшергә кыймыйм мин.

*Пауза.*

**Рабига.** Уйласаң, гел чабып, гел ашыгып үтә икән гомер.

**Зилә.** Әҗәл белән очрашуны абайламый да каласың.

**Нәҗия.** Менә Наиләне дә югалттык.

**Рабига.** Бәлки без әллә кайчаннан бирле Наиләсез яшәгәнбездер инде?

**Ләрия.** Авызыңнан җил алсын!

**Зилә.** Быел җәй башында гына, гастрольгә киткәндә, безне озатырга пароходка төшкән иде. Бер кочак чәчәк күтәргән. Бер кочак!

**Ләрия.** Чәчәкнең берсе-берсе өч тәңкә чакта!..

**Зилә.** Кызын җитәкләгән... Исем-һушым китте: санап карасак, күрешмәгәнгә әллә ни гомер икән! Кызы үсеп беткән!

**Диләрә.** Бер шәһәрдә яшәп тә очраша алган юк диярлек.

**Зилә.** Хәлең ничек, Наилә, дим. Көлә! Тормышың ничек, дим. Искиткеч, ди. Чәчәкләре арасыннан нурлы йөзе балкып тора. Айһай чибәр ханым дип, безнең ирләрнең күзе янды.

**Ләрия.** Артист халкын беләбез, калфак кидертсәң, кәҗәгә дә гашыйк булалар.

**Рабига.** Берэр заман телен тыярмы бу кеше?!

**Лэрия.** Шаяртып күңелегезне күтэрим дигэн идем, ямьсез сүз ычкынды. Кичерегез берлеккэ.

**Рабига.** Сез китеп атна-ун көн уздымы икэн, больницага, минем янга килде. Гел елмая үзе, э күзлэрендэ сагыш-моң. Абау, Абау!.. Күзлэренэ күтэрелеп карарга читенсенэм бит! Гаебем бар төсле. Тирэн моң.

**Лэрия.** Күзлэр бар иде инде анда!

**Зилэ.** Озата төшүенэ шул тиклем сөендем, кочаклап еладым, ышанасызмы? Сезон ачылуга билетлар җибэрермен дигэн идем, онытканмын.

**Дилэрэ.** Нишлисең, иң эйбэт вэгъдэлэр дэ онытыла.

**Рабига.** Анысы мэгълүм. Нигэ онытыла соң ул вэгъдэлэр?

**Нажия.** Тормыш мэшэкатьлэре алып узадыр. Эллэ син тормышка баш бирмисеңме, Рабига?

**Рабига.** Ничек баш бирмисең ди? Менэ кичке биш... Бу вакытта, гадэттэ, мин обход ясарга керешэм. Җидедэ эшем тэмамланырга тиеш. Җидедэ бетэме минем эш? Туры килэ бер җан көеге, зарлана-зарлана үзеңне чиргэ сабыштыра. Халатыңны салып ыргытып, биткулыңны юасың да кибеткэ чабасың!

**Дилэрэ.** Кибеттэ оҗмах дип белэсеңме? Менэ безне алыгыз... Микрорайонда бер кибет. Халык эштэн кайта башласа, дер калтырап торабыз. Атылып кереп тулалар, идэннэр тетри. Ашыгалар, ашыктыралар...

**Рабига.** Кибеттэн аны-моны элэктерэсең дэ детсадка чабасың...

**Нажия.** Э бездэ, бездэ... Берсенең биялэе югалган, анасы җир астыннан таптыра!. Икенчесе ыштан балагын таба алмый, исерек этисе чабаклап аңы елата... Өченчесенең... Эй, кым-кырыч килэбез. Утырып тамак туйдырган да юк.

**Рабига.** Эле шуннан парикмахерга, ательега чапкан буласың. Кеше төсле киенэсе, йөрисе килэ.

**Лэрия.** Мин үзем бөтен җиргэ чиратсыз керэм.

**Рабига.** Кыскасы, театрга барырга вакыт та калмый, Зилэ.

**Зилэ.** Э менэ Наилэ вакыт таба иде. Озатырга төшкэн бит! Кочагында чэчэклэр!

**Лэрия.** Таптың чагыштырыр кеше! Наилэнең бит анын...

**Рабига.** Юк ла! Габбасыма гына шалтыратып алыймчы?

**Зилэ.** Алай, кысыр тавык сыман кытаклап торыр булгач, шалтырат.

Лэрия телефонга бара, Рабига аны туктата.

**Рабига.** Кая?

**Лэрия.** Зилэ рөхсэт итте, үзеннэн сора. *(Акланып.)* Күкерт минем Габбасым. Көнче күбэлэк.

**Рабига.** «Тизрэк кайт!» дип эйттерэсең килэ инде.

**Лэрия.** Алайса шалтыратмыйм. Кайткач үтерсен! Яратмыйсыз сез мине. Бер чакта да яратмадыгыз. Гел-гел кактыгыз.

**Дилэрэ.** Турсаймыйча, зурга җибэрмичэ генэ шалтырат эйдэ.

**Рабига.** Тын гына утырыйк эле.

**Нажия.** И-и, гомерлэр диген. Яшь чагында шулай тезелешеп утырыр идек тэ җырлар идек! Җырламаган җыру калмас иде.

**Лэрия.** Шуннан котырынырга тотыныр идек!

**Рабига.** Наилэ такмак эйтеп уен башлар иде...

Җыелган хатыннар бер генэ минутка яшь чакларына кайталар.

**Зилэ.**

Без-без идек!
Без уникe кыз идек!
Келэткэ кердек — бал ашадык!
Базга төшеп май ашадык!..

Рабига.
Без-без идек,
Унике сылу идек,
Унике елга идек:
Кушылдык та таралдык!
Кемне каян табарлык?

Нажия. Кирәкми, Зилә.

Диләрә. Уятма күңелнең йоклаган почмакларын! Яшьлек — яшел яфрак кебек, саргая да коела ул күзен. Кирәкми!

Ләрия. Яратмыйсыз сез мине, үз итмисез!

Пауза.

Зилә. Әгәр элегрәк белгән булсам... Профессорларга күрсәтеп караган булыр идек!

Рабига. Кем дә коткарып кала алмас иде, Зилә. Йөрәге җитмеш яшәгәннеке төсле таушалган аның!

Пауза.

Зилә. Кызы ни хәлдә?

Рабига. Әлегә үзебезгә алып кайттым. Сабый бит! Әнкәсез калганын да аңламый.

Ләрия. Суйган да каплаган Наилә икән. Безнеке мена, Габбасымны әйтәм, кызым үземә охшамаган дип көне-төне табалый!

Зилә. Әти кеше күмәргә дә килмәде.

Ләрия. Киләме соң! Килсә, кем икәне беленә ич аның! Беленгәч кызны үзенә алырга кирәк, тәрбияләргә! Һич югында, алимент түләсе була. Наилә ул серен дә кабергә алып китте. Их, беләсе иде!

Рабига. Тагын нинди серен?

Ләрия. Беләсең ич инде, Рабига!

Рабига. Белмим шул, белмим.

Зилә. Унике кыз идек бит! Алтыбыз кошлар очып җитмәс җиргә китеп гаип булды.

Нажия. Беребез Сахалинда.

Диләрә. Айсылу Германиядә.

Ләрия. Ире полковник икән аның хәзер.

Рабига. Кифая Алжирда... Тагын бер срокка калган.

Зилә. Үсеп җиткәч таралыштык кош балалары кебек... Таралышканнар да бер заман кайтыр... «Наилә кайда?» дип сорарлар... Ни диярбез?

Рабига. Таралыштык.

Нажия. Монда булып ни кыра алганыбыз бар? Елга бер күрешәбез, анда да ашык-пошык, кайгы-хәсрәт килгәндә... Йомыш төшкәндә...

Диләрә. Чирләсәк, Рабига янына барабыз.

Нажия. Затлы колбаса теләнеп Диләрәгә сугылабыз.

Зилә. Кием тектерер чак җиткәч, Ләрияне юксынабыз.

Ләрия. Белешләргә контрамарка сорап, сиңа шалтыратабыз!

Рабига. Ә гомер үтә!..

Диләрә. Дөнья куабыз!

Зилә. Артыгын дөнья да кумады безнең Наилә. Нигә беренче булып гүргә иңде соң?

Рабига. Йөрәге җитмеш яшәгәннең йөрәгенә әйләнгән диделәр патанатомнар.

Нажия. Тәмам янган икән бичара.

Диләрә. Артык зур кайгы да кичермәде шикелле болай...

Рабига. Әллә кайгысын күрсәтмәдеме?

Зилә. Уйлашыйк! Күбебез капыл-копыл кияүгә чыкканда, ул ялгыз яшәп калды. Башкалар дәрәҗә артыннан чапканда, ул һаман секретарь-машинистка булып эшләвеннән тәм тапты. Бүтәннәребез өчәр-дүртәр мәртәбә фатир алыштырып өлгергәндә, ул һаман барак почмагындагы чиста, җыйнак бүлмәсендә яшәп ятты. Без чит ил мебельләре, келәмнәр, хрустальләр артыннан көн-төн чапканда, аның түрендә гади генә өстәл, шарлы тимер караватъ торды...

Ләрия. Аныкы кешечә булмады инде!

Рабига. Бәлки ул нәкъ менә кешечә яшәгәндер? Без әллә нинди комсыз малтабарларга, каруннарга әйләнеп бетмәдекме икән?

Зилә. Нигә безнең сыман тормышын җайламады, җайлашмады? Ашыгып ир канаты астына сыенмады. Күңелле чаклар барыбызның да хәтерендә. Тик тормыш тоташ бәйрәмнәрдән тормый бит! Урта мәктәп тәмамлаган төнне ак алъяпкычлар бәйләп, мәңгелек вәгъдәләр бирешеп, Идел буенда йөрү ансат иде, анда без дус идек! Ә аннан соң? Тормыш — тоташ хезмәт ул. Уртак булдымы безнең хезмәт? Тигез күтәрдекме без хезмәт йөген? Вак-төяк ыгы-зыгыларны җиңә алдыкмы? Ахыр чиктә, тормышыбызның кайсы баскычында бер-беребезне күздән ычкындырдык, бер-беребезгә битараф булып калдык? Шуны ачыкларга кирәк безгә. Шуны белмичә мин моннан чыгып китә алмыйм. Сез дә шул сәбәпле калдыгыз дип уйлыйм. Наилә вафат, дигәнне ишеткәннән бирле мине бер сорау газаплый: аның үлемендә безнең гаеп тә юкмы икән?! Кайчан башланды безнең таркалу? Ничек күрми калдык без аны?

Пауза.

Ләрия. Нигә миннән сорыйсыз аны?

Зилә. Нигә синнән генә сорыйк ди?

Ләрия. Нигә барыгыз да миңа текәләсез? Теләсәгез нишләгез, миңа кайтырга вакыт. Габбасым өйдәдер... Кызым да сырхаулап тора... Нигә миңа ябырыласыз? Мин гаепле димәкче буласызмы әллә?

Диләрә. Габбасың да борчылгач, кайтып кына кит, Ләрия.

Ләрия. Кайтырмын да шул!.. Ә сез?

Зилә. Без калабыз әле, Ләрия.

Рабига. Күреп торасың ич.

Наҗия. Без калыйк әле.

Рабига. Барыбызның да күңелен борчыган сорауны Зилә тел белән әйтеп бирде. Ә без... кайсыбыз кыймагандыр, кайсыбыз теләмәгәндер дигәндәй...

Зилә. Кайчагында бик бәләкәй генә күренгән сәбәпләр дә еллар узгач, тау кадәрле бәла китереп чыгаралар. Наиләнең иртә дөнья куюына ни сәбәпче булды соң? Кем сәбәпче!

Рабига. Йөрәкне хәсрәт туздыра.

Зилә. Дөрес! Кешене эш картайта диләр. Ялган! Яраткан хезмәте кешене яшәртә!.. Кеше гомерен шәраб кыскарта диләр. Шәраб — кояш җимеше, чамасын белсәң, ул да әҗәлне ашыктырмас... Әйе, Рабига җаным, кешене хәсрәт картайта.

Рабига. Каян килә диген кешегә шул хәсрәт-явыз!

Ләрия. Эзләсәң табыла ул.

Зилә. Уйлаганыңны әйтмисең әле син, Ләрия. Дөнья — шатлык белән туп-тулы. Тормыш — гаҗәеп зур могҗиза бит ул! Туу, яши алу, хезмәт итү үзе нинди зур сөенеч!

Рабига. Без исән. Димәк, безнең кайгы-хәсрәт азрак булган.

Зилә. Әллә без ансатрак юл сайладыкмы?

Наҗия. Бәлки безгә Наиләнең кайгысын бүлешеп алырга кирәк булгандыр?

Рабига. Бүлешеп аласы урынга, башка тарафлардан килгән кайгысын уртаклашасы чакта, без аңа кайгы өстәмәдекме икән?

Зилә. Торналар җылы якларга очканда, алга иң көчлесе чыгып, хәлдән тайганы артка, җиңелрәк урынга күчә икән.

Ләрия. Нигә карыйсыз сез миңа?

Рабига. Карыйбыз икән, сәбәпсез түгелдер, Ләрия. Аз салмадың син дә Наилә йөрәгенә хәсрәт!

Ләрия. Нигә алай дисең? Ничек оялмыйсың?

Зилә. Менә мин сәхнәдә балалары ташлап киткән ана ролен уйныйм. Яхшы уйный диләр. Тик мин хәзергәчә җавап таба алмыйм: әйбәт, ягымлы анадан нигә шундый нурсыз балалар туган? Сәбәп нидә? Сәбәпсез яфрак та селкенми, Ләрия.

Сәгать суга.

Наҗия. Сәгать алты.

Диләрә. Вакыт уза.

Наҗия. Кирәкмәс чакта вакыт чаба.

Ләрия. Габбасым мине эт итәр инде.

Диләрә. Утырмасана эч пошырып, кайдалыгыңны белмәсә бер хәл иде!

Рабига. Габбас белә... Күпне белә, Габбас! Элегрәк елларда Наилә сезгә керергә бик ярата иде, Ләрия.

Зилә. Менә бу турыда мин берни дә белмим диярлек.

Диләрә. Син Мәскәүгә, ГИТИСка укырга киткән еллар иде ул, Зилә.

Рабига. Ләрия-Ләрия, Гөлләрия-ләрия, дип җырлап кына йөри иде безнең Наилә.

Зилә. Ләрияне аерата якын иткән икән, аның сәбәбе нәрсәдә?

Рабига. Үзе монда. Сөйләсен.

Ләрия. Нишләп мин сөйлим ди аны? Мине виноват ясамакчы буласызмы әллә? Нигә бергәләшеп мине чукыйсыз?.. Ательега барып сорашыгыз, күршеләрдән, мин намуслы хатын!

Рабига. Нигә гаеплик?.. Зиләнең ачыклыйсы килә. Без дә белик.

Зилә. Үзең дә аңлап кал.

Пауза. Читтәге телефонга ир кеше килә. Бу юлы ул Габбас. Бүлмәдә телефон шалтырый.

Габбас. Квартирамы бу?

Зилә. Әйе.

Габбас. Миңа Ләрия кирәк иде.

Зилә. Сине сорыйлар, Ләрия.

Ләрия. Юк, юк! Мин монда юк. Чыгып китте, диген.

Зилә *(трубкага)*. Хәзер чакырам. Монда Ләрияң, монда!

Ләриягә трубканы бирә.

Габбас. Нигә өйдә түгел? Сәгать ничә икәнен беләсеңме?

Ләрия. Безнең кайгылы көн... матәм...

Габбас. Ис китәрлек кеше күммәдегез әле! Кыз бала анасына анда тагын ни калган?

Ләрия. Хәзер Габбасым, хәзер. Чыгып бара идем.

Рабига. Бир әле миңа! *(Трубканы алам дип тартыша. Ләрия бирми, Рабига ала).* Ләрия моннан кайтып китә алмый, Габбас.

Габбас. Кем чыгарган фәрман бусы тагын?

Рабига. Кызганычка каршы, беребез дә кайтып китә алмыйбыз.

Трубканы элә.

Габбас. Алло, алло!

Шалтырата, әмма бүлмәдәгеләр телефонны алмыйлар.

З и л ә . Бар кайт, Ләрия.

Л ә р и я. Кайтмыйм. Чыгып китүгә, гайбәтемне чәйнәргә тотыныр идегез бугай. Минем гаебем юк!.. Әллә мине үзен-үзе яклый алмас дип беләсезме? Ягез, башлагыз!.. Кайсыгыз хөкемдар?

Р а б и г а. Гаепләргә җыенмыйбыз. Шулай бит, ахирәтләр? Тик башта ук әйтеп куйыйк: Наилә белән ара бозыклыгы синнән башланды.

Л ә р и я . Ялган! Яла!

Р а б и г а . Элегрәк тә сөйләшә идек без бу турыда. Тик үтеп барышлый, сүз арасында гына сөйләшә идек. Башкача кирәк булган!

З и л ә . Сөйлә, Ләрия.

Н а җ и я . Шулай кирәктер инде, җаным.

Р а б и г а . Кемдер сүз башларга тиеш. Шул кемдер безнең өчен бүген син, Ләрия.

З и л ә . Синең сүзең бар бит! Минем дә бар! Йомгакның очы шулай да синдә.

Л ә р и я . Нишләтәсез сез мине?.. Гомеремдә берни башлап йөрмәдем. Без бит дүрт бала үстек, абыйларымны беләсез. Тукмаштыралар иде алар мине. Башта «әләкче» дип кыйнадылар. Соңыннан «астыртын» дип дөмбәсләделәр. Шуңамы, кешеләргә кыеп дәшәргә базмый үстем. Кыюсыз, басынкы идем. Башлап сүз әйткәнем булмады. Бүген сезгә ни әйтим?.. Әйе, Наилә белән арабызның җете чаклары булды. Соңыннан керми үк башлады безгә, читләште. Мин сәбәпче димәкче буласызмы? Безнең тормыш юллары аерылды. Сәбәп шул гына.

З и л ә . Кайчандыр без бер-беребез өчен үлеп тора идек. Рабига унынчыда авыргач, өч ай янынннан китмәдек. Көндәлек дәресләрен калдырмадык. Диләрәнең әтисе үлгәч, ниләр генә кыланмадык, әнкәсенә күпме ярдәм иттек.

Н а җ и я . Ул чаклар кайтмас инде, Зилә.

Д и л ә р ә . Иртән күрешмәсәк, кичкә кадәр зарыгып саргаеша идек.

Р а б и г а . Шулар барысы да эзсез күмелеп калдымы?

З и л ә . Хәтерлә, Ләрия.

Сәхнәдә яктылык кими, музыка. Башкалар арткы планга күчә. Алгы планга өстәл, урындык чыгаралар. Ләрия вакыты мөмкинлек биргәнчә, киемен-салымын үзгәртә, җырлый-җырлый бәрәңге әрчи. Н а и л ә керә.

Н а и л ә . Ләрия-Ләрия, Гөлләрия-ләрия! Саумы, аппагым.

Л ә р и я . Кайчандыр Гөлләрия идек тә, хәзер ләр-ләрия булдык да калдык. Уз, Наиләкәй, уз! Бәрәңге пешерергә җыенып йөрим.

Н а и л ә . Кая, тагын бер пычагың бармы?

Л ә р и я . Бәрәңгесен алып кайтышканың өчен дә рәхмәт. Җитешә генә алмыйм бит. *(Тукталып.)* Һай, күлмәгең!

Н а и л ә . Үзем кистем, Үзем тектем.

Л ә р и я . Люкс ательеда эшләп, шушындый затлы кием кия алганым юк.

Н а и л ә . Килешә дисең инде?

Л ә р и я . Су кызы булгансың! Фәрештә!

Н а и л ә . Актык мактап күз тидерә күрмә. Кызың өйдәме? Мин аңа шундый тәмле торт алып килдем. Кештердәп тора. *(Бирә.)*

Л ә р и я . Тортың бик тәмле күренсә дә, кызым өйдә юк бит. Энеләрдә.

Н а и л ә . Мин кергәндә, нигәдер, гел өйдә булмый башлады.

Л ә р и я . Шулаймыни? Тортыңны ал.

Н а и л ә . Кучтәнәчне кире алмыйлар.

Лэрия. Кызны артык иркәләмәсен ди Габбасым.

Наилә. Учларым рәхәтләнгәнче тупырдатып сөярмен дигән идем үзен.

Ләрия. Бәбәй сөясең килсә, газапланма, кияүгә чык.

Наилә. Шул сүзне син дә әйтәсеңме?

Ләрия. Сүзнең ни гаебе бар?

Наилә. Эштәгеләрдән, күрше-күләннәрдән, туган-тумачадан нигә читләшкәнемне беләсең, Ләрия. Дөньяда яучыларның күпмелеген соңгы ике-өч елда белдем. Кеше бары тик кияү, хатын дип кенә яшимени? Дөнья шул кадәр кызык ич! Сәнгать, музыка, спорт, театрлар, эш-хезмәт бар. Тормыш хәзинәләреннән чынлап торып файдалана алмаган мәми авызлар тоталар да бик белдекле булып: «Кайчан кияүгә чыгасың? Тормышыңны кешечә кайчан корасың?» — дип җан кыйныйлар. Кызың янына шул тинтәкләрдән качып та керәм мин. Шуларның барысыннан да акыллырак ул бала. «Кар нигә ак?» — ди ул. «Суган нигә ачы, алма нигә татлы?» — ди. Менә син карның нигә ак икәнен беләсеңме? Белмисең! Суган нигә ачы? Анысын да белмисең... Ә минем кияүгә чыгарга тиешме, түгелме икәнен белгән булып кыланасың.

Ләрия. Кеше учагында җылынып яшәүнең яме бармыни аның? Шулай да, суган ачы, алма татлы, нигә чыкмыйсың син кияүгә?

Наилә. Хуш. Мин киттем.

Ләрия. Бу сораудан син мәңге котылачак түгел.

Наилә. Ахирәт дуслардан беренче булып син сорадың.

Ләрия. Башкаларга караганда эчкерсез шул мин, күңелемдәге — телемдә.

Наилә. Мин киләсен белгәч җибәрәсең син кызыңны әниләреңә!

Ләрия. Бәлки шулайдыр да.

Наилә. Нигә алай итәсең? Ник җәберлисең мине?

Ләрия. Сиңа кара да, миңа бак! Бәрәңге әрчегәндә, бала чүпрәген юганда болай кәттә киенеп йөреп булмый. Ә син гөлдәй балкып киләсең дә керәсең. Бала «Наилә апа!» дип уяна. «Наилә апам нигә килмәде бүген?» дип нәүмизләнеп йокларга ята. «Аннан тәмле ис килә», ди. Киноартисткаларның кәртечкәсен күрсәтеп: «Әнә, Наилә апам шул инде»,— ди.

Наилә. Габбасыңнан көнләшәсең син.

Ләрия. Габбас бала түгел, теле белән әйтмәсә дә, күзе белән ашаганын күреп торам!

Наилә. Кирәкми миңа Габбасың, ялгыш уйлама.

Ләрия. Габбасымның кайсы җире начар? Нигә яманлыйсың аны?

Наилә. Җүләр, минем арттан менә дигән егетләр йөри.

Ләрия. Мактанчыкларның кай җире ачык дилэр әле?

Наилә. Йөриләр, Ләрия, ышан. Тик мин чыкмыйм. Беркемгә дә чын мәхәббәтем юк.

Ләрия. Безнең яшьтә нинди мәхәббәт ди ул тагын? Әле мин синнән күпме иртәрәк чыктым, анда да баш ватып тормадым. Берәрсеннән ким яшимме?

Наилә. Яратмыйча кияүгә чыкмыйм. Дөньяда шундый бөек хис барын белеп тор да, шуны сынамыйча кал, имеш!

Ләрия. Күзгә карап мине гаеплим диген! Габбаска яратмыйча чыкты дисеңме?

Наилә. Сөйләшмик бу хакта, син борчыласың.

Ләрия. Яратмыйча чыксам да менә дигән яшибез. Берегездән дә ким түгел. Чөнки ул мине ярата! Сиңа Габбас төсле уңган, затлы егет эләксен иде әле, әкият сатып утырмас идең. Җир читенә ялан-

аяк йөгереп барыр идең. Ә ул мине җиде «Волга» белән килеп алды! Я, гаепләп кара тагын бер!

Наилә. Бик беләсең килсә, әйтәм: Габбасың башта миңа тәкъдим ясады.

Лэрия. Сиңа? Минем Габбасыммы?

Наилә. Ризалыгымны бирмәдем. Ошамый иде ул миңа.

Лэрия. Булмастайны, юкны сөйлисең. Мине яратып алмады дип әйтергә телисеңме?

Наилә. Нигә алай усалланыйм? Мин, Лэрия аппагым, сине дә, аны да, үземне дә гаепләргә җыенмыйм. Син үз юлыңны сайладың, минем юлым башка: йөрәгем атылып тормаган кешегә пар булмаячакмын.

Лэрия. Йөр инде, йөр тилереп. Кемне көткән буласың? Генералнымы, лауреатнымы?

Наилә. Җан сөйгән кешемне!

Лэрия. Иремне азындырырга йөрисең син! Әйтмәм дигән идем, чыдарлыгымны калдырмадың. Күршеләр дә әйтеп тора: «Әй, диләр, Лэрия, диләр... Габбасыңнан колак кагасың, өегезгә үк килеп йөри», диләр... Мин гадилегем, беркатлылыгым белән берни уйламый йөрим.

Наилә. Миннән шикләнергә нинди дәлилең бар?

Лэрия. Үз тормышын кора алмаган хатын-кыз ару тормышлыдан көнләшә торган була. Әйе! Юри җибәрәм кызымны әниләргә! Син бозып бетердең аны, син! Килмәсәң көйсезләнә! Мин синең исемеңнең безнең йортта, Габбасым алдында гел-гел кабатлануын теләмим. Тапкан бер сүз! Мәхәббәт, мәхәббәт!.. Кем ышана бу дөньяда мәхәббәткә?.. Хәзер кешеләр акыллы. Мәхәббәт җүләрләр эше.

Наилә. Рәхмәт. Булды. Аңлашылды. Мәгәр мин сезнең араны бозарга кермәдем. Син минем яшьлек дустым. Хатын-кыз дуслыгы ифрат нәзек бит ул, ефәк җеп төсле. Ирләр дуслыгы кырыс, ул яуда, сугыш кырында сынала. Ә хатын-кыз дуслыгы кайчан һәм кайда сынала? Минемчә, бу дуслык — кызлар кияүгә чыгып, аерым-аерым дөнья көтә башлагач сынала. Кияүгә чыгып, кыз икенче кешегә әверелә. Әле кыз чак дуслыгы — ул иртәнге томан. Томанда бар нәрсә дә үзгәреп, серле булып күренә. Рәхмәт! Узган кергәндә кызың Гөлгенә «алма нигә түгәрәк?» дип сорады. Алманың нигә түгәрәк икәнен беләсеңме?

Лэрия. Тәгәрәп китәргәдер...

Наилә. Мин дә белмим.

Телефон шалтырый.

Лэрия. Габбас, синме? *(Наиләгә.)* Чыгып кит тизрәк! Габбасым кайта!

Габбас *(авансценадагы икенче телефонга бара, шактый кызмача).* Лэриям, матурым... Гөлгенәм, бер генәм өйдәме? Юк?.. Мин чак кына, печтек кенә соңарып кайтам. Ярыймы? Нигә дәшмисең?

Лэрия. Тагын ни булды, Габбасым?

Габбас. Институтта бергә укыган егетне очраттым. Командировкага килгән. Өч ел күрешкәнебез юк иде. Өч ел! Шуның белән гостиницада утырабыз.

Лэрия. Кайсы гостиницада тагын?

Габбас. Синең өчен барыбер түгелмени?

Лэрия. Хәзер үк кайт! Бер минут торасы булма.

Габбас. Алайса, бүген мин бөтенләй кайтмыйм.

Лэрия. Ике көн рәттән?

Габбас. Төпченмә, тавык баш!

Лэрия *(Наиләгә).* Бар инде, җәфа! *(Трубкага).* Юк, юк, Габбасым, җаным. Теләгәнеңчә утыр. Сүзем юк. Кунакны өйгә алып кайтсаң да риза.

Габбас *(хихылдап).* Кунак синең янга сыя торган зат түгел! Хуш!

Ләрия трубканы куя. Пауза.

Наилә. Хуш!

Ләрия. Син барын да ишеттеңме? Ишетеп тордыңмы?.. Шул, шул, Габбасым... Кем шалтыратса да ишетелеп торырлык итеп сөйләде.

Наилә. Ишетмәдем, Ләрия, берни ишетмәдем. Хуш.

Ләрия. Тагын керерсеңме? *(Ялынып.)* Кайчан керәсең? Чәй дә куймадым. Хәзер Гөлгенәне алып кайтам. Кара аны, ташлама! Кереп йөр! Болай да барыгыз да читләтәсез мине, ят итәсез!

Наилә чыгып китә, Ләрия ахирәтләре янына барып утыра.

Зилә. Наилә яңадан сезгә кермәдеме?

Наҗия. Берни белми яшәгәнбез икән.

Рабига. Ул үзе бу вакыйга турында телгә дә алмады.

Ләрия. Габбас ул көнне бөтенләй кайтмады. Ике көн рәттән! Белә идем, кемедер барын сизенеп йөри идем. Эзләп таптым. Өсләренә барып кердем. Үземчә, дөбердәтеп алып кайттым. Икәүләшеп утырып елаштык та, кочаклашып чәй эчтек.

Зилә. Ачуың да килмәдеме бер дә?

Ләрия. Үтмәс пычак белән тунар идем!.. Тик ирем бит ул минем, ирем! Хатын-кыз ни кыра ала? Күкрәктә үч кайнады кайнавын!

Зилә. Әйе, көчлеләрдән үч ала алмаганда, без үчнең агулы укларын көчсезләргә, гадәттә, гаепсезләргә юнәлтәбез.

Диләрә. Артык каты әйттең, Зилә. Бәлки Ләриянең алда бер гаебе дә юктыр?

Рабига. Ләрия үч утын үзендә сүндерә торган зат түгел.

Диләрә. Син дә белгән күк утырмасана, Рабига.

Рабига. Мин врач... Мин аның йөрәген күрдем! Бусын әйтмәм дигән идем.

Наҗия. Шулай таланган идеме йөрәге?!. Алайса... мин дә сөйлим инде...

Ләрия. Миңа кайтып китәргә ярыймы инде?

Наҗия. Тукта, тыңла... Күптән күрешкәнебез юк иде, бер көнне безгә Ләрия килеп керде. Хәзер аңладым — нәкъ шул вакытта булган икән бу хәл. Байтактан очрашканыбыз юк иде, башта гаҗәпләндем...

Башкалар сәхнә түрендә утырып кала, Наҗия алгы планга күчә, бераз өс-башын үзгәртә. Ләрия аның янына бара.

Ләрия. Ни хәлләрең бар, Наҗиякәй?! Абау, күз тимәсен, тәмам артистка булгансың. Наилә матур диләр — тьфү! Зилә чибәр диләр — тьфү! Менә син чибәр ичмасам!

Наҗия. Тәмле телеңә рәхмәт, Ләрия.

Ләрия. Ахирәтләрем арасыннан аерата сине яратам, Наҗия.

Наҗия. Алай да Наилә белән Зиләгә сүз тидермә... Күз өстебездәге каш ич алар. Берсе инсафлы, акыллы булуы белән дан тотса, икенчесе шәһәребездә мәшһүр артистка.

Ләрия. Шул инсаф иясе кергәлиме?

Наҗия. Нигә аны сорыйсың? Сирәк-мирәк барыгыз да кергәлисез ич.

Ләрия. Беләсем килеп китте. Нигә ялгыз канат кагып йөри ул?

Наҗия. Кайберәүләргә ялгызлык та килешә. Яшь алалар, тормыш кора беләләр, тереклек итәләр.

Ләрия. Беркатлы шул син, Наҗиякәй. Синең белән дус яшәргә була! Шул холкың өчен яратамдыр бәлки мин сине? Ә Наиләгә кил-

гәндә... Җиде катлы аның җаны! Аздына башлаган ул. Безгә килеп керде исә, Габбасым белән чыкы-чыкы килергә тотыналар.

Нәҗия. Мәрданым да Наиләне ярата. «Акыллы, уйчан, саф хисле кыз», ди.

Ләрия. Минем хакта ни дигән була Мәрданың?

Нәҗия. Аерып әйткәне юк, «кыбырсык» дип һаярткалый.

Ләрия. Син иреңә ышанасыңдыр да әле?

Нәҗия. Иделгә таянма дисең инде, Ләрия. Ышанам.

Ләрия. Көннәрдән бер көнне Мәрданыңнан колак кагасыңны көт тә тор! Мәрданыңның Наилә белән кинодан парлашып чыкканнарын күрдем.

Нәҗия. Күз күрер өчен яратылган. Мәрдан ике билет алып кайткан да, мин бара алмадым, икәү киттеләр.

Ләрия. Кинода тезенә кул салмагандыр дисеңме? Чәчен сыйпамаганмы? Беркөн эштән иртәрәк тайдык та кинога кердек. Яныма бер военный килеп утырды, полковник бугай. Ут сүнгәч, учымны кысып алды да җибәрми бит, чукынчык.

Нәҗия. Үзеңнең ычкындырасың килмәгәндер.

Ләрия. Күр инде бу алъяпкычыңны! Чиш, сал! Карачкыга бәйлә. Кереп йөр яныма, матур күлмәкләр тегеп бирермен, люкс, кыйбатлы ателье дип курыкма, сиңа бушлай тегәм! Әллә Мәрданыңның күзе юкмы? Май җиледәй хуш ис таратып балкып килеп кергән ялгыз хатын белән син юбалгыны чагыштырып карарлык һушы юкмы иреңнең? Архитектор ич синең Мәрданың! Сәнгатькә, матурлыкка табынучы. Беркөн радиодан матурлык турында шулай дәртләнеп сөйләде, ир-атка салкын булсам да, гашыйк була яздым иреңә! Миндәй таш йөрәкне дә кузгатырлык булгач...

Нәҗия. Әллә ниләр белсәң дә, миңа мондый сүзләрне яңадан алып килмә.

Ләрия. Мин белеп сөйлим!

Телефонга Ир кеше килә. Бу юлы ул — Мәрдан. Нәҗияләр янында телефон шалтырый.

Мәрдан. Нәҗия, өйдә икәнсең. Бик әйбәт.

Нәҗия. Тыңлыйм, Мәрдан.

Мәрдан. Мине ике көнлек командировкага җибәрәләр.

Нәҗия. Кая ул алай?

Мәрдан. Еракка түгел, Чабаксарга гына.

Нәҗия. Нишләп алай кинәт? Бер дә әйтмәгән идең.

Мәрдан. Ашыгыч кына хәл иттеләр. Нәҗия, өйгә кереп тормыйм, моннан машина белән китәбез.

Нәҗия. Кемнәр белән?

Мәрдан. Лара Исааковна белән.

Нәҗия. Хәерле юл, Мәрдан. Исән-аман йөр.

Мәрдан. Сау бул! Балаларны кара!

Нәҗия трубканы куя. Пауза.

Ләрия. Лара Исааковна сездә ашта булган яшь, чибәр яһүдәме?

Нәҗия. Искиткеч ягымлы хатын. Теле йомшак, үзе сылу, талантлы.

Ләрия. Шәп! Искиткеч! Шундый сылу белән гулять итәргә мин китмәс идемме? Ташлачы шул алъяпкычыңны!.. Чабаксарга гына түгел, Африкага китәр идем.

Нәҗия. Алар чыннан да Африкага барырга җыеналар.

Ләрия. Арыслан ялын тараргамы?

Нәҗия. Эш белән җибәрәләр.

Ләрия. Икәвесен?

Н а җ и я . Нигә якты көнне шулай каралтасың син, Ләрия?

*Ишектә звонок. Ләрия барып ача, Н а и л ә керә.*

Л ә р и я *(каушаганын сиздермичә).* Ярый, минем китеп барыш. Сау бул, Нәҗия! Исән бул, Наиләкәй!

Н а и л ә. Бер казанга сыймабыз дисең инде? *(Ләрия ахирәтләре янына барып утыра.)*

Н а җ и я. Бәйрәмдер бүген сиңа, күзең генә түгел, кашың, колакларың да көлә.

Н а и л ә . Бүгеннән тутаң ялда.

Н а җ и я. Синең кеше төсле генә буламы? Башкалар җәйнең ямьле чагын сайлап отпускага чыга, Кырым, Кавказга бара, ә ул кыш уртасында ял ала да авызын ерып йөри.

Н а и л ә . Җәй көне урыныма кеше табу кыен. Апаңның дәрәҗәсе зур: начальнигы китә ала, урынбасары ялга чыга ала, ә секретарь-машинистка китсә, завод туктый да кала.

Н а җ и я. Начальниклардан көләм дип, үзеңнән көләсең бит!

Н а и л ә . Ял итә белсәң, кайчан да яхшы ул. Әгәр инде ялны кояшта корсак кыздыру дип кенә аңласаң, башка эш... Васильевога путевка бирәләр, рәхәтләнеп чаңгы шуармын, китап укырмын. Ә мактаулы Кырым-Кавказны яратмыйм.

Н а җ и я. Секретарьлыктан китәргә кирәк сиңа, кызый. Вакыт.

Н а и л ә . Бүгеннән мин ялда, эш турында сөйләшмим.

Н а җ и я. Кирәк булгач сөйләшербез дә. Тукта әле, тукта, син кайчандыр үзегезнең фирмадан зуррак эшкә чакыралар дигән идең түгелме?

Н а и л ә. Чакыралар. Хәзер дә үгетлиләр. Ике бүлмәле квартира вәгъдә итәләр.

Н а җ и я. Дәрәҗәле эшкә дәшәләр алайса сине?

Н а и л ә. Канцелярия мөдире итмәкчеләр.

Н а җ и я. Акча да артамы?

Н а и л ә. Шактый артачак.

Н а җ и я. Туктаусыз эштән котылыр көнең бар икән. Затлы кулмәк алыр өчен дә көне-төне өеңдә машинка тукылдатасың, күршеләреңнән каргыш ишетәсең. Барактан котыласың. Җәйге ялыңны теләгәндә аласың. Квартиры булгач, аның кияве дә ерак йөрми.

Н а и л ә. Тик мин ризалыгымны бирмәдем.

Н а җ и я. Ике бүлмәле квартирадан, акчадан, тынычлыктан, дәрәҗәдән, кияүдән баш тартасыңмы? Акылың бармы синең?

Н а и л ә. Алай акыллы да, алдан күрүче дә булгач, нигә тагын бер соравың юк синең? Яңа урын, яңа квартира бәрабәренә минем ни түләргә тиешлегемне беләсеңме соң син?

Н а җ и я. Ни булса да, ялгызлыктан котыласың ичмасам. Миннән булмый, ирсез, фатирсыз яшәүне күз алдына да китерә алмыйм.

Н а и л ә. Бәйсезлегемне, горурлыгымны гына түгел, саф намусымны да корбан итәргә тиеш.

Н а җ и я. Бәхеткәйләрең булмагач, намус сиңа нәрсәгә?

Н а и л ә. Юк, ышанмыйм, бу сүзләрне син сөйләмисең!

Н а җ и я. Телеграф баганасына ботак булып син генә яшәмәссең инде! Күз сал: башкалар ничек яши? Һәркем үзенчә көйли, көйләнә. Майламаган арба шыгырдый.

Н а и л ә. Ятлар үгет биргәндә, бу сүзләрне көлеп кенә уткәрә идем. Инде син, Нәҗия!.. Юаш, гади хатын. Эчкерсез сердәш!..

Н а җ и я. Кылтаясы юк, дус буласың килсә, безнеңчә, кешеләрчә яшә.

Н а и л ә. Без-без идек,
Без уникe кыз идек!
Базга төштек, май ашадык,
Келәткә кереп бал ашадык!

Бу бит гади такмак кына түгел. Тормышта бер җыр да юкка җырланмый. Бу безнең сүз берләштерү, вәгъдәләребез иде. Юкка ашадыкмы без ул майны? Юкка сыйландыкмы бал белән? Телләребез мәңге татлы, күңелләребез майдай йомшак булсын өчен ашадык!.. Бәлки безнең бабайлар серләрен шулай беркеткәннәрдер?

Н а җ и я. Квартира мәсьәләсен юри миңа төрттереп телгә алдың. Канымны бозар өчен. Беренче хатыны үлгәч, унөч яшь олы Мәрданга шушы зур квартирасы өчен дә чыктым шул. Шушы йортка икенче хатын булып төштем.

Н а и л ә. Матур яшисез, Наҗия. Ирең дә менә дигән уңган кеше.

Н а җ и я. Мактау максатсыз булмый, Наилә. Ач сереңне!

Н а и л ә. Мактар җире барга мактыйм.

Н а җ и я. Гаиләдә ирне мактыйлар икән, хатынны хурлау булып яңгырый ул. Мәрдан әйбәт икән, мин начар булып чыгаммы?

Н а и л ә. Нигә тавык сыман кирегә тырмыйсың син?

Н а җ и я. Гел миңа төрттереп, кадап торганга! Ялгыз хатын гайбәттән, кеше газаплаудан тәм тапмаса, каян ямь тапсын?!

Н а и л ә. Җүләр син. Гомерем буе сафлыкка, тиңсез мәхәббәткә омтылып яшәгән җан буларак, сезнең тигез, тату тормышны күреп сөенмимме мин? Дәлилем сез, бар ул мәхәббәт, бар! дип сөрән саласым килә. Сезгә килгәч, яңарып, яшәреп китәм мин, иртәнге чык белән юынган төсле. Ә син әллә ни сукалыйсың!.. Әллә үз сүзең, әллә гайбәт җиле кагылып киткән сиңа.

Н а җ и я. Ашыкма! Ташлап китмә мине. Әллә ни лыгырдадым. Гафу ит. Кичер!.. Ир бит ул... Күңелгә шик төшми дисеңме? Көнчелек корты яфрагын гына түгел, тамырын кимерә күңелнең! Кичер. Ни булды миңа, аңламыйм.

Н а и л ә. Мин дә аңламыйм. Тик безнең аерма шунда гына: мин аңларга телим, син — киресенчә, бутарга тырышасың.

Наилә чыгып китә. Ахирәтләр тагын бергә җыелалар.

З и л ә. Шуннан соң ниләр булды? Хәтерлисезме?

Д и л ә р ә. Хәтерлисезме дип, бәлки искә төшерәсе килмидер?

Р а б и г а. Мин ул елларны бер дә оныта алмыйм!

Н а җ и я. Онытылганы да бардыр инде, Рабига.

Д и л ә р ә. Көне-сәгате хәтердә калмаган, ялдан кайткан чагы булгандыр дип чамалыйм. Гадәтен бозып, өйгә түгел, кибеткә килеп керде Наилә. Әле мин иске урында эшли идем. Көннәр җылыта башлаган чак иде. Керде дә бер читтәрәк басып тора. Күрештек. «Вакытың тыгыз икәнен күрәм, мәгәр сиңа сүзем бар. Көтимме?» — диде бу.

З и л ә. Ә син?

Д и л ә р ә. Барын да әйтеп бетерсәм, «җүләр баш!» дип көләрсез инде.

Р а б и г а. Сөйлә!

Д и л ә р ә. Гомернең бер яртысы ахмаклык эшләп, икенче яртысы үкенеп уза. «Көтмә, дидем, бүтән чакта очрашып сөйләшербез», — дидем.

З и л ә. Нигә?

Д и л ә р ә. Ревизия вакыты иде бездә. Арабызга яңа кеше алган идек, өч айда бөтен эшебезне тар-мар китерде. Кулы кәкре булып чыкты. Барыбызга да өстәмә мәшәкать килгән чак иде. Кешенеке кештәктә, диләр бит. Бер дә аны-моны уйламадым.

Рабига. Инде җәй башларында минем янга килде ул. Больницага. Хәл белергә кергән дип уйладым. «Әле ярый син сау-сәламәт! Югыйсә, таныш-белешләрне дәвалаудан да читен хәл юк, алар танышлык аркылы чир-чорлардан тизрәк котылырга телиләр!» дип көлдердем үзен. Гел юк-барны сөйләшеп утырдык.

Наҗия. Безне табалыйсың, Рабига, үзең йөрәген дә тыңлап карамагансың!

Рабига. Тыңлатмады. Шаярып кына тыңлап карарга уйлаган идем. «Йөрәк — кирәкле әгъза, әмма йөрәк белән җан арасында күңел дигәне бар аның, менә шуның хәлен белә торган аппаратың булсын иде синең!» — диде актыктан. Кинаясен хәзер генә аңлыйм: минем янга күңел борчуларын җиңеләйтүне өметләнеп килгән икән ләбаса!!.

Зилә. Ялдан кайткач тагын берәрегез күрдеме аны?

Наҗия. Юк бугай. Без бик озак күрешмәдек. Мәрдан аптырап сорашкалый башлады, кая югалды ул кызыкай ди... Мин белмәмешкә салышам, дәшмим.

Ләрия. Бер заман урамнан барам шулай, каршыма ул килә. Борылды да бер ишегалдына кереп качты.

Рабига. Наилә булмаган ул! Качмас иде!

Ләрия. Күрдем инде, күрдем!

Зилә. Миңа Мәскәүгә шалтыратты.

Рабига. Я, я.

Зилә. «Кайтып китә алмассыңмы, Зиләйлүк?» диде. Сездә ревизия, бездә премьера. Иҗат отчетына әзерләнәбез. Ролем барып чыкмый гына бит! Хәзерге драматургларны әйтер идем, чүмәлә китереп өяләр дә, шуны пьеса дип атыйлар. Чүмәлә астыннан бәләкәй генә фикерне эзләп тинтери актер башы!

Рабига. Син читкә сугылдың!

Ләрия. Димәк, сүз аның файдасына түгел!

Зилә. Кайта алмадым. Кайткач, тагын тиз генә очраша алмадык.

Рабига. Күпмедер вакыт узгач, бездә хәлләр тагын куерып китте. Наиләнең үзен күрмәсәк тә, исеме тагы безнең телләргә керде.

Барысы да Ләриягә карыйлар.

Ләрия. Тагын миңа текәләсезме? Минем хакта берни дә белмисез бит! Ничек яшәгән мин ул елларда? Ниләр кичергән? Бәлки мин дә егылып, елап ятканмындыр. Берәрегез кул суздымы миңа? Әгәр мин иртәгә чәчрәп үлсәм, мине җәлләр идегезме? Нигә миңа шулай усалланып карыйсыз?

Рабига. Усалланып димәс идем...

Диләрә. Булды, ахирәтләр, Ләрияне куеп торыйк. Аның тормышы да бал түгел.

Наҗия. Белмим-белмим дип утырмагызсана! Барыбыз да беләбез.

Ләрия. Авызы ачылды... Ә мин моннан болай берни сөйләмим.

Зилә. Синнән гаеп эзләмибез, Ләрия.

Рабига. Без хакыйкатьне табарга гына телибез!

Зилә. Дуслык шулай куша. Без бит дуслар идек. Аңлыйсыңмы? Сөйлә!

Ләрия *(еламсырап)*. Берзаман шәһәрдә хәбәр таралды.

Рабига. Тараттым диген. Сүзнең иясе була.

Ләрия *(елап ук диярлек)*. Түгел, түгел! Алайса артыгын сөйләмим. Нигә мин барын да ачып салырга тиешле? Судмы әллә бу? Гаепле икәнмен, үзегез исбатлагыз.

**З и л ә.** Суд түгел. Кабатлап әйтәм: үткәннәргә акыллы күз белән борылып карау. Судны һәркем үзенчә ясар!

**Д и л ә р ә.** Йолыккаламагыз инде Ләрияне, ялгыз каз түгел бит ул да.

**Н а җ и я.** Берни аңламаган башың белән адвокат булып утырмачы, Диләрә.

**Р а б и г а.** Бәлки ул барын да бездән шәбрәк аңлыйдыр?

**Д и л ә р ә.** Артык акыллы булып киттең, Рабига. Наиләнең йөрәген иртәрәк тыңларга иде! Хәзер акыл сатудан ни файда? Үткәнне кире кайтарып ала алмассың.

**Р а б и г а.** Бу сөйләшү — тереләр өчен. Минем өчен, синең өчен. Дөньяда Наиләләр бер генәме әллә? Бүгенге хаталар иртәгә кабатланмасын.

**З и л ә.** Сөйләмә, Ләрия. Кирәкми. Әйдәгез, таралышыйк.

**Л ә р и я.** Ничек? Без яңадан беркайчан да очрашмабызмыни инде?

**Р а б и г а.** Дөрес, Зилә, сөйләмәсен. Барыбыз да авызга су кабыйк.

**Л ә р и я** *(елап җибәрә)*. Минем ни гаебем бар иде? Габбасымнан ишеткәннәрне генә сезгә тараттым.

**Р а б и г а.** Нигә тараттың? Сәбәбен яшермәскә тырыш. Калганын аңларбыз.

Ләрия алгы планга чыга. Үз өендә ялгызы. Телефон шалтырый. Икенче телефонда Габбас.

**Л ә р и я.** Габбасым, синме?

**Г а б б а с.** Әһә, син башка берәүнең шалтыратуын сагалап утырасың икән! Нигә агарындың? Нигә кулларың калтырый?

**Л ә р и я.** Нахакка җәберлисең мине... Көне-төне рәнҗетәсең...

**Г а б б а с.** Хатын-кыз дигән жанварның эчен-тышын белгәнгә ул!.. Елан мөгезеннән яралган зат бит! Мәкер сандыгы, хәйлә капчыгы, ирләр юлындагы бүре чокыры. Үлгәч, аларның җаннары елан оясында урын табар ди иде минем мәрхүм бабай.

**Л ә р и я.** Нинди капкан? Кайдагы баз? Бусага атлап беркая чыкканым юк. Мәзин бабаңның сөрсегән сүзе белән мине табалыйсың. Безнең заманда ниләр буласын белгәнме ул карт?

**Г а б б а с.** Берәм-берәм бар да килә!

**Л ә р и я.** Тагын ниләр генә булды икән?

**Г а б б а с.** Аңлатырмын. Шуңа шалтыратам да. Әнә, мактаулы, горур, уңган, саф, тәкәббер Наиләгезнең нишләгәнен беләсеңме?

**Л ә р и я.** Машина таптаганмы?

**Г а б б а с.** Камыры кабара башлаган.

**Л ә р и я.** Булмас!

**Г а б б а с.** Алдагы көнеңә программа-максимум! Колагыңа алка итеп так! Сиек миеңә сеңдер. Сиңа үлгәнче бер маршрут билгелим: өй — ателье — базар — кибет! И все! Кара аны, шуннан читкә чыкканыңны күрсәм яки күрсәләр, конвой без предупреждения ата! Мактаулы, горур кыз шулай кыланганны, синең ише майлы күзләр... Кара аны!

Габбас трубкасын куеп чыгып китә, хатын-кызлар тиз-тиз Ләрияне урап алалар.

**Р а б и г а.** Колга, кәнизәккә әйләндергән икән сине ирең.

**Н а җ и я.** Шуңа юньле әтвитең юк идемени?

**Д и л ә р ә.** Телефоны белән башына салыр идем!

**З и л ә.** Юк, дусларым, без хәзер салулап ул якка кереп китмик. Әгәр Ләриянең Габбасын тикшерә башласак!... Аның безнең дуслыкка күпме зыян салганын үлчәсәк!.. Ул икенче мәсьәлә. Габбастан шул хәбәрне ишеткәч, Ләрия нишләгән? Безнең якын дустыбыз, яшьлек дус-

тыбыз, Наиләнең дә бик якын кешесе Лəрия нишләгән ул чакта? Менә нәрсәне белергә кирәк.

Л ә р и я. Барына тылкышып ни кырмакчы буласыз? Әллә Габбасымны монда чакыртып допрослар өйдегезме? «Хатын-кыз дуслыгы — буш әкият», ди ул.

Р а б и г а. Ул әйтә торсын, сүзеңне дәвам ит, Лəрия. Бүлдермәгез аны. Ачуыгызга юл бирмәгез, сабыр булыйк. Гаделлек белән тыңлыйк. Без барысын да дөрес аңларга тиеш. Артмасын да, кимемәсен дә! Габбасың шалтыратты, шуннан син нишләдең?

Д и л ә р ә. Утырып бер елагандыр инде.

З и л ә. Ялгыз хатынга җилнең катысы бәреләдип уфтангандыр...

Н а җ и я. Наиләнең намуслы исемен саклап калырга дип безнең янга чыгып чапкандыр...

Пауза.

Р а б и г а. Я, Лəрия. Без көтәбез. Иренмибез.

Л ә р и я. Исем китеп, һушым таралып озак кына утырдым бугай. Бәхетсезлеккә каршы, Габбасым ул кичне дә кунарга кайтмады. Нигә һаман Наилә исеме белән авыз чайкый бу хайван, дип уйладым. Әллә үзе һаман аның артыннан сөйрәләме дигән фикер килде. Булмас, дидем. Наиләнең ялгыш юлга кереп китүенә хафаланып шалтыратмады бит ул, астыртын сөенеп, тантана итеп шалтыратты. Аның яшьлегенә үзе хуҗа була алмаганга көенеп шалтыратты, көнләшеп! Әллә һаман яратамы ул аны? дип тә көяләндем. Нишли ала идем соң мин ул минутта? Балам авырый, ирем өйдә кунмый... Нишләргә иде миңа?!!

Н а җ и я. Габбаска ышанмаска гына иде!

Л ә р и я. Ничек ышанмыйсың, ул хаклы булып чыкты бит!

З и л ә. Анысын алдарак ачыкларбыз. Син Габбасыңның үчен тагын Наиләдән алырга керештеңме?

Л ә р и я. Бусын... сөйләсәң-сөйләмәсәң, барыгыз да беләсез.

З и л ә. Мин белмим.

Л ә р и я. Нишләдем соң әле мин?.. Нишләдем? Әйе, тораташ булып байтак утырдым бугай... Бала елый, өзгәләнә. Температурасы утыз тугыз. Аннары кинәт сизәм, гәүдәм турылана, турылана, башым күтәрелә... Башымны югары чөеп, телефонга бардым. Кемгә шалтыратырга? Күңелне ничек җиңеләйтергә? *(Горур атлап телефонга бара, номер җыя).* Диләрә, малакаем! Юк, юк, берни дә кирәкми. Рәхмәт. Әле дә, кирәксә-кирәкмәсә, сиңа сыенам. Малакаем, Наилә кияүгә чыкмагандыр бит? Шулай дип беләм мин дә... Әллә туйдан коры калдыкмы дип курыктым. Алайса, ни сәбәптән юаная башлаган ул? Күлмәк кистерергә кергән иде, размеры үзгәргән. Ха-ха-ха! Җилдән инде, җилдән! Искән җилләр дә гел-гел файдасыз түгел икән ләсә! Ә? Шатлана дип, әйтүем генә. Борын чөеп йөргән иде дим! Борын! *(Трубканы куя, тиз-тиз номер җыя).* Наҗияне тиз үк чакырыгыз әле. Наҗия бала-чагаң качмас, ир колы булып гомерең заяга уза инде. Серем бар, башка берәүгә дә ачмыйм, сиңа сөйләми түзәрем юк. Безнең Наилә нишләгән дисеңме? Димисең? Әй, беркатлы шул син, тормыш хәбәрләреннән гамең юк. Тиздән детсадыңда бер җан иясе артачак... Әйе, әйе, беләм. Белмәсәм сөйләмим дә мин аны! Алло-алло! Рабиганы бирегез! Эштән арып кайткан. Уятыгыз! Ал-ло! Почта! Миңа срочно Сахалинны тоташтырыгыз. Германияне бирегез! Алжирны! Кредитка булмагае, чуртка булсын! Тик срочно! Алло!

Трубкасын ташлап хатыннар төркеменә барып кушылам дигәндә, тегеләр дәррәү читкә тайпылалар. Лəрия ялгыз кала. Пауза. Сәгать суга.

З и л ә. Адәм баласы гөнаһсыз икәнлеген нигә үлеме белән генә ышандыра ала икән? Кемнең ничек яшәве турында дөрес итеп үзе гүр

иясе булгач кына сөйләшәбез бит без! Тереләр хакында ачы хакыйкатьне уртага салып сөйләшергә нигә шүрлибез?

Рабига. Нигә алай кискен әйттең, Зилә?

Зилә. Шушы яман хәбәр таралгач берегез дә Наиләне аклап та, яклап та сүз әйтергә батырчылык итмәгән. Берегез дә аны аңларга тырышып карамаган.

Диләрә. Мин Ләриягә ышанмадым!

Наҗия. Мин дә!

Рабига. Авыр операциядән соң төн уртасында гына кайтып яткан идем. Юк, юк, ахыр чиктә, болары дәлил түгел! Тормыш — һәр вакыт тормыш инде. Әш, мәшәкать дип, ваемсызлыкны аклау дөрес булмас.

Зилә. Ләрия миңа шалтыратмады. Хәбәр итүче дә булмады. Нигә миңа шалтыратмадың, Ләрия?

Ләрия. Әйтмим.

Зилә. Мине, актрисаны, Наилә шикелле үк җиңел акыллы, азгын дип санадыңмы?

Ләрия. Барын белеп торгач, нигә тинтерәтәсез мине?

Рабига. Саран Ләрия Сахалинга акча җәлләмәгән. Алжирга! Миңа йөз егерме сум бурычы бар. Әле дә түләмәгән.

Диләрә. Икенче көнне, бурычка акча сорап, миңа килеп җиткән. Бирдем бит, юка баш. Әлек тә бирәчәге байтак иде, бүгенгәчә түләгәне юк.

Зилә. Бурычларны түләмәскә өйрәнеп җиткәнсең, Ләрия. Ләкин кайчан исә бер түләми калып булмый!.. Нигә шулай ашыгып, явыз тантана белән, комарланып чәчтең дөньяга шул яман хәбәрне? Аңламыйм.

Ләрия. Бусын үтерсәгез дә әйтмим. Хәер! Барыбыз да бер иш. Барыбыз да кеше турында әшәке хәбәр чыкканны көтәбез. Әллә сезнең шулай булмыймы? Әллә яшерәсезме? Нигә хәзер миңа карамыйсыз? Нигә күзләрегез идәндә? Әллә сез гелән туры сүз йөртәсезме? Начальникларыгыз алдында ялагайланмыйсызмы? Башлыкларга тәлинкә тотмыйсызмы? Ирләрегезне бер дә алдамыйсызмы? Рабигадән ялган больничный лист теләнеп кермисезме? Диләрәдән чиратсыз-нисез әйбер алмыйсызмы? Эчегездә бер дә яшерен сер юкмы? Әйе шул, мин моны көтә идем! Габбас сүзеннән соң батыраеп киттем. Нигә сезнең телләрдә яманлык сүзе белән янәшә Ләрия исеме генә йөрергә тиеш? Канатландым! Тизрәк ул хәбәрнең башкалар колагына да керүен теләдем. Һәркем үз ишенең күбрәк булуын тели. Бөкре бөкрене күргәндә сөенә, кәрлә үзеннән тәбәнәгрәккә өстән көлеп карый... Нигә миңа карамыйсыз?

Диләрә. Читен, оят, Ләрия. Белеп, аңлап, күз йомып яшәлгән. Шул елны без дача сала башлаган идек. Аның мең төрле мәшәкатен беләсез инде. Баз казыттык, мич чыгардык, мичне кафельладык. Андый дачаны тирә-юньдә таба алмассыз. Аннан машина сатып алдык та гараж салырга туры килде. И-и, гараж салып караганыгыз юк әле сезнең! Күпме вакытлар шул мәшәкать белән узды. Ялына барган буласың, Кырымына китәсең, иртәгә китәргә, диләр, бүген путевкасын тоттыралар. Чаба-чаба аяк табаннарына ут каба. Ялдан кайтасың да эшкә чумасың, онытыласың.

Наҗия. Тормыш, мәшәкать алып узды, Зилә.

Диләрә. Ишетүгә, Ләрия янына барып җитеп, авызын томаларга кирәк булган да бит... хәзер нишлисең, тересәк ерак!

Рабига. Син, Ләрия, монда безгә хәйран гаеп ташладың. Хагы бар, нахагы бар дигәндәй... Шулай да усал синең күңелең! Кара күңел!

Зилә. Ә мин... сәхнә кысасын киң тормыш дип, ярым алданып

яшәдем. Һәр кичне бер җилбәзәккә кияүгә чыктым! Икенче бер җилкуар минем арттан сөйрәлгән булды! Сөешү дип шуны атадык! Күңелләребез буп-буш булса да, рәхим итегез, дип башкаларны чакырдык Кайда соң син, дигән булып, юк җирдә мәгънә эзләдек. Бер стакан судагы давылда адашкан булып, күк капусы ачылганны көтеп буталышып йөрдек! Арзанлы сөешүләр, төче ялганнар алып уздық сәхнәне!

Л ә р и я. Бик кызыклы театрлар иде ич алар.

Д и л ә р ә. Шулай шул!

З и л ә. Дача, гараждан башы чыкмаган, үз гомерендә бер китап укымаган, әллә ничә елга бер тапкыр сәнгать белән очрашкан бәндәләргә бәлки кызык та булганнардыр. Әмма безгә, үзебезгә, җан азыгы юк иде. Һәр көн уен сүзләр сиптереп, күбәләктәй очынып җырлап-биеп йөргән булдым. Еллар буе! Тормыш миңа мәзәк, тоташтан уен, кызык тамаша кебек тоела иде. Ә аңа? Ә ул ? Төннәрен ничек уздырды икән? Салкын йолдызлар янган күккә карап, ялгызы ни уйлады икән?.. Ялгыз яшәве белән дә сәер тоелган кыз таңнарын ничек каршылады икән?.. Без бер Наиләне генә беләбез!.. Тормышта Наиләләр азмы әллә? Ялгызлар, толлар азмы? Үз ишләрен таба алмаган бәхетсезләр азмы?

Л ә р и я. Кем уйлаган бит, йөрәге сау түгелдер дип кем уйлаган.

Р а б и г а. Заманында йөзеп Идел кичкән кыз иде бит!..

Н а җ и я. Син әйтәсеңме анысын, мин әйтимме...

Р а б и г а. Бераз газапланганнан соң, мин Наилә янына киттем.

З и л ә. Рәхмәт сиңа, Рабига. Әле дә ярый син бар!.. Син бар.. Нигә елыйсың?

Р а б и г а. Үтерден рәхмәтең белән, Зилә. Бармаган булсамчы! Күрмәгән булсамчы! Ул сүзне башламаган булсамчы! Хәзер бәлки барыбызга да җиңелрәк булыр иде. Юк, юк, Лэрия, сине генә гаепләмибез. Син үзеңчә дөрес эш йөрткәнсең. Усаллык теләгәнсең дә шуңа ирешкәнсең. Кайчагында без, яхшылык теләп, кешене һәлакәткә этәрәбез. Бусын кичерү авыррак... Бәлки Наиләне үлемгә китереп җиткерүче миндер әле. Әйе, мөгаен, миндер. Тик мин дә ул чагында алай тирәнтен уйламадым!.. Җыенып чыктым да киттем... Барын да артык гади дип санадым шул, гадәти хәл дип исәпләдем. Дөньяда гади кешеләр юк, кешеләр арасында гадәти мөнәсәбәтләр дә юк. Бар да яңа! Әчкерсез рәхмәтең белән үтердең мине, Зилә!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

Алгы планда Наилә бүлмәсе. Ул ялгызы. Зилә, Диләрә, Наҗия, Ләрияләрдән аерылып, аның янына Рабига килә.

Н а и л ә. Ой, Рабига җанашым!

Р а б и г а. Җанашым дисең, ә үзең каушадың. Беренче мәртәбә врач каршында чишенгән яшь кыз кебек.

Н а и л ә. Әллә ничек карап торасың бит.

Р а б и г а. Ничек?

Н а и л ә. Сынныйсыңмы, нидер эзлисеңме... Кайбер эрсез ирләр трамвайда шулай капшап, йотлыгып карый.

Р а б и г а. Гафу ит, күңелемдә инә очы хәтле дә усаллык юк.

Н а и л ә. Ә мин... ниндидер, моңарчы татылмаган тәмле хыялларга бирелеп киткәнмен. Музыка тыңлый идем.

Р а б и г а. Син татымаган нинди хис калды икән инде?

Н а и л ә. Карашың гына түгел, сүзең дә бүтән бүген, Рабига җанашым. Уз, утыр, чакырылмаган кунак күк торасың. Бирче сумкаңны!

Күңелеңнең изге тамыры сине күрәсе килгәнемне тойгандыр. Син булып син тәмам оныттың. Кермисең, шалтыратмыйсың. Үпкәләп әйтүем түгел, һәркемнең үз тормышы, сүз арасында гына әйтүем.

Рабига. Тагын ышанмаска туры килә. Узган якшәмбедә, кунакка чакырып, хат җибәргән идек.

Наилә. Хатыгызны алдым, рәхмәт.

Рабига. Хатны да алгансың, килми калуыңа гаҗәпләндек.

Наилә. Бара алмадым шул.

Рабига. Нигә дип сорамыйм. Әйтмәсеңне күңелем сизә. Димәк, синең бездән якынрак кешең табылган! Яки безнең чакырудан да олырак эшең килеп чыккан. Акланма, сиңа килешми.

Наилә. Акланмыйм.

Рабига. Нигә көлеп торасың алайса?

Наилә. Сорама, Рабига.

Рабига. Сорасам? Бәлки сорарга дип килгәнмендер. Ныклап сораштырырга әзерләнеп торамдыр. Сораулар алар, җавап бирелмәгән очракта да, күп нәрсәне белдерәләр.

Наилә. Төпченү сиңа хас сыйфат түгел... Алдашуны яратмыйм, ә бүген дөресен сөйлисем килми. Рабига җанашым, бар бит дөньяда шундый сүзләр, алар әйтмичә дә аңлашылырга тиеш. Әйтсәң, кадере кими.

Рабига. Күндердең. Сорашмыйм. Тик шунысы — безгә кунакка килми калырга ярамый иде сиңа!

Наилә. Әле соңгы чакыруыгыз булмас.

Рабига. Ул көнне килергә иде!

Наилә *(шикләнеп)*. Нигә алай икән?

Рабига. Колагың тордымы? Әле сәбәбен белсәң, апакаем-җаныкаем дип, йөгерә-йөгерә чәй куярга тотынып идең.

Наилә. Чәйне бик иркенләп эчәбез аны.

Рабига. Ашыкма! Бездә ул көнне бер егет бар иде.

Наилә. Егет?

Рабига. Тагын көлә! Нигә авыз ерасың?

Наилә. Син — әйбәт врач-хирург, ипле дус. Әмма, яучы буларак, бер тиен бакырга да тормыйсың. Сүзне шулай башламыйлар инде!

Рабига. Кайчаннан бирле бу темага сүз кузгаткан булмады, хәзер яхшылап тыңла әле бер.

Наилә. Мондый гәпне колагым ишетми — тонган, саңгыраулангаң.

Рабига. Корыны бушка әвеш-тәвеш китереп йөрүче әпчи карчыгы түгелмен. Инде сөйләшәбез икән — әзеп, конкретно! Иремнең энесе кайтты безгә. Аспирантурага кереп йөри. Мәскәү егете. Өйләнмәгән. Бераз бездә торды. Исламгали абыең белән бер көнне сине телгә алдык.

Наилә. Кирәкмәс иде.

Рабига. Егеткә фотоңны күрсәттек. Бәйнә-бәйнә барын сөйләдек.

Наилә. Сөйләр сүз таба алдыгызмы?

Рабига. Тормышыңны, холык-гадәтләреңне. Тик кенә утыра алмый башлады бит егетебез. Ишекле-түрле йөри. Пилмән бөккән идем, гөбәдия пешердем. Син килмәгәч, табынның яме генә булмады. Ашапэчкәч, егетебез «әйдәгез, бераз тән язып керик, уңайсыз булмаса, Наилә туташның хәлен белешеп тә чыгыйк», диде.

Наилә. Әрсезлекне сөймим, беләсең.

Рабига. Барыбыз да син авырып ятасың дип уйладык.

Наилә. Сәламәт икәнлегем сиңа мәгълүм.

Рабига. Килсәк, ишегең бикле.

Наилә. Бикле иде шул.

Рабига. Анысына исем китмәде, кая булса да чыккан дип уйлар

идем, почта ящигына күзем төште. Шыплап тутырылган... Монысын берсенә дә сиздермәдем.

Наилә. Ике көн өйдә булмадым.

Рабига. Булдыңмы, булмадыңмы, анысы синең эш. Мин сиңа конкрет тәкъдим белән килдем.

Наилә. Егет бер дә өйләнмәгәнме?

Рабига. Әһә, балык җимгә килде! Өйләнмәгән.

Наилә. Нигә өйләнмәгән?

Рабига. Төссез яучы диденме мине?.. Балык җим тирәли йөри, хәзер килеп кабачак!.. Менә син ник кияүгә чыкмаган?

Наилә. Минем язмышымны беләсең: моңарчы җан сөйгәнемне очрата алмадым.

Рабига. Бәлки ул да шулай парын, тиңен эзлидер.

Наилә. Ирләр алар башкача эзли.

Рабига. Армиядән соң бераз эшләгән, институт тәмамлаган. Чибәр үк димим, сөйкемле, акыллы, сабыр. Киләчәге өметле, чөнки егет тырыш. Син мине тыңлыйсыңмы?

Наилә. Егет яхшыдыр, сүзем юк. Рабига хәтле Рабига күтәрелеп килгәч, буш куык түгелдер. Тик соң, Рабига җанашым, соң. Мин инде кияүгә чыкмаячакмын. Ялгыз калуым белән килештем. Бөтен кеше дә кияүгә чыгарга димәгән. Мин шуларның берсе.

Рабига. Килешәм. Тормышта уртак язмышлар юк. Мәгәр шундый өметле егет тәкъдим ясап торганда, икеләнүең ошамый.

Наилә. Нинди тәкъдим?

Рабига. Тынычлыгын җуйды дидем ич инде.

Наилә. Миңа шул да җитә дип уйлыйсыңмы?.. Сазаган, карт кызга тагын ни кирәк дисеңме? Хәзер мине тыңла. Язмышым, ялгызлыгым белән килештем мин, Рабига. Яшермим, җиңел булмады. Озак көттем мин үземә насыйп кешене. Нишлисең, табылмады. Күңелем төшенкелеккә бирелә язды. Әмма мин тормыш шуның белән чикләнә дияргә җыенмыйм, юк! Бирелмим дә, үләргә дә җыенмыйм. Дәшми тор. Барын да беләм дип уйлама. Курыкма, җинаять ясаганым да юк. Әмма ялгызлык газабына бер чик кирәк иде. Шуны сөйләргә дип көттем Рабига җанашымны. Әмма ул килде дә бик борынгы җырны суза башлады. Кеше ихтыярына буйсынып яшәү юк миндә. Киңме, тармы — үз язмышым, үз юлым бар. Кеше җырын җырларга остардык, ахры, без. Алны-артны уйлап бетермибез, мә тотынабыз кул чабарга. Уникe кыз — уникe инкубатор чебеше дигән сүз түгел!

Рабига. Син каядыр ашыгасың бугай! Очып китәргә җыенган төсле кыланасың. Кулларың канатка әверелә.

Наилә. Очар идем, валлаһи, очар идем.

Рабига. Чү-чү, котырма, егасың. Мин сине бүлдердем.

Наилә. Очар идем дә күңелем буш түгел. Туп-тулы. Мөлдерәмә тулы.

Рабига. Ялгызлык сагышы белән тулымы?

Наилә. Сагышны түктем дә моң белән тутырдым. Мәхәббәт белән. Бәхет белән.

Рабига. Сүзеңнең асылын аңлап бетермим. Шулай ук ерагайдыкмыни без?

Наилә. Ә син аңла. Аңларга тырыш.

Рабига. Теге егеткә ни дип әйтим соң?

Наилә. Әнә шулай диген. Бик бәхетле диген.

Рабига. Ләрия тараткан сүз дөрескә чыга алайса?

Наилә. Ләрия нинди сүз тараткандыр, мин аның белән киңәшеп эшләмим. Ул тормышны кыек көзгегә карап бәяли бит, кыек көзге-

дә исә гарипләрне генә күреп була. Мин аның бер сүзенә дә ышанмыйм.

Сөйләшә-сөйләшә, кочаклашып, авансцена буйлап әйләнгәләп йөриләр, сиздермичә генә Наилә югала. Рабига ахирәтләре янына бара.

Рабига. Менә шулай ярым-йорты аңлашып аерылыштык без ул көнне.

Лэрия. Ләриянең бер сүзенә дә ышанмыйм дип әйтмәгәндер лә!

Зилә. Нигә бу очрашуың өчен үкенәсең, Рабига?

Диләрә. Ие. шул! Нигә?

Рабига. Азагын белмисез шул аның, азагын... Егете бик әйбәт иде, тигез пар булырлар дип уйлаган идем... Һаман шул гадилек, беркатлылык комачаулаган. Ә тормыш бер чакта да гади була алмый.

Зилә. Инде чират миңадыр... Ләрия, карама миңа андый ямьсез күз белән. Ихлас сөйлим, яман хәбәр дә таратмадым, әзәрлекләп тә бармадым Наиләне. Кеше күңеленә кыек юллар йөз икән, туры юл — бер генә. Тик ул юлны таптым дип мин дә мактана алмыйм. Наилә үзе безгә килеп керде.

Рабига. Ә мин, башсыз, икенче тапкырында да үзем бардым. үзем!

Нажия. Нигә шул чаклы кыйналасың?

Рабига. Үкенече зур бит аның, үкенече. Азагы фаҗигале аның, Нажия. Шул үкенеч белән калган гомерне яшисе бар бит әле.

Зилә. Театрда ял көне иде. Дүшәмбе. Ирем дә ялда чак туры килде. Кисловодскига озаткан идем аны. Япа-ялгызым китап укып ятам шулай, ни укыганымны да белмим, әллә китабым күңелсез, әллә көне ямьсез, шомланып та куям. Тышта җил, чамасыз! Басынкы гына килеп керде ул.

Зилә сөйләгәндә, Наилә керә һәм ул сөйләгәннәрне эшли.

Чишенде. «Торма, торма, бик тәмле ятасың, кырыңда утырып кына торам», — диде. Шунда мин туп-туры аның күзләренә карадым. Абау, күзләре ут булып яна, битләре алланган, бөтен кыяфәтендә наз, иркәлек, бер үк вакытта көчле рух аңкый иде.

Диванга барып ята, китап ала, Наилә аның янына килеп утыра.

Наилә. Торма, торма, зинһар. Кырыңда гына утырып торам. Бигрәк тәмле итеп ятасың.

Зилә. Әй, болай уңайсыз. *(Тора, Наилә белән кочаклашып утыралар.)*

Наилә. Ни хәлләрең бар, Зиләйлүк?

Зилә. Һәммәсе әйбәт. Гомер генә уза.

Наилә. Шуны сизә аласыңмы?

Зилә. Сизмичә, актерның бәхетсезлеге шунда, ул ярты гомерен көзге каршысында, икенче яртысын халык күз алдында үткәрә. Теләсәң-теләмәсәң дә, һәр көн барлык җыерчыкларыңны санап чыгасың. Арталар! Үзеңдә ниләр?

Наилә. Дөнья матур, Зиләйлүк.

Зилә. Шуны исбатлый аласыңмы?

Наилә. Исбатлыйм.

Зилә. Көтәм.

Наилә. Мин сиңа тагын бер яңа җыр алып килдем. Яңа дип, иске җыр ул, борынгы җыр, Болгардан ук калмадымы икән?

Зилә. Элегрәк ел саен җыр белән куандыра идең, һәр җырың күңелеңнең серен ача торган иде. Бүген нинди сер китерде икән сине минем катыма?

Наилә. Җыры барның — сере бар. Минем моңарчы ул җырны ишеткәнем юк иде. Аны миңа бер кеше җырлады... Җырчы түгел,

гап-гади кеше. Әмма гаҗәеп кызыклы, акыллы, тирән фикер иясе кеше. Тормышны яратучы бай рухлы кеше. Җырлап күрсәтимме?

З и л ә. Җырла.

Н а и л ә. Миңа җырлаган кеше аны «Ләке авыле көе» дип атады.

З и л ә. Ул шушы авылныкымы?

Н а и л ә. Түгел. Шул якта гына туган. Тыңла.

Олы юлга чыккан идем,
Чакырым саен багана.
Әллә теләп, әллә болай
Рәхәт килде замана.
Әйдә, әйдә! Кайда, кайда?
Әйдә барыйк урманга.
Урман буйлары абага,
Урман суы шәп ага.
Сөймик икәү бер чибәрне,
Әйдә салыйк шобага!
Олы юлга чыккан идем,
Чакырым саен багана.
Әллә теләп, әллә болай
Авыр килде замана.
Әйдә, әйдә! Кайда, кайда?
Әйдә барыйк урманга.
Урман буйлары абага,
Урман суы шәп ага.
Сөймик икәү бер чибәрне,
Әйдә салыйк шобага.

З и л ә. Искиткеч җыр! Аерата кушымтасы төгәл эшләнгән. Тик бер ягы сәер — башта замана рәхәт килде дип җырлана да, азагы күңелсез бетә.

Н а и л ә. Мин дә аннан сорадым шуны!

З и л ә. Аңлаттымы?

Н а и л ә. Җырны кем генә җырламый аны диде. Рәхәттә дә, михнәттә дә җыр юлдаш... Әллә дөньяда бар кеше рәхәткә чыккан дип уйлыйсыңмы, диде.

Әйдә, әйдә! Кайда, кайда?
Әйдә барыйк урманга.
Урман буйлары абага,
Урман суы шәп ага.

Н а и л ә. Уйлап караганың бармы, Зиләйлүк, безнең арабызда иң бәхетлесе син бит!

З и л ә. Көнләшәсеңме?

Н а и л ә. Сиңа нигә икәнен дә аңлатып бирергәме?

З и л ә. Минем тормышны ничегрәк күз алдына китерәсең икән син? Шуннан чыгып, мин синең идеалыңны, кая табарак һәм нindiрәк кешегә омтылуыңны белер идем.

Н а и л ә. Син бөтен барлыгың белән, юләрләрчә гашыйк булып кияүгә чыктың. Ике ел буе сөешеп кияүгә бардың. Лаеклы ир сайладың. Асыл ир-егетне. Җаның теләгән хезмәткә гомереңне багышладың. Лария дә артистка булам дип йөргән иде, зарплатасының күпме икәнен белгәч, документларын бик тиз барып алды. Диләрә дә врач булам диде, җиде ел укырга кирәклеген аңлагач, коерыкны сыртка салды. Дөрес, алар да яшь, файдалы эштә эшлиләр, мәгәр син генә үз теләгеңә ирештең. Авыр дип тормадың, аена утыз сум түләп чит кеше бусагасында торсагыз да, лаф ормадыгыз, матур тормыш кордыгыз. Тәнегез генә түгел, рухыгыз да бергә булды. Бергә! Бергәлектән бер-береңне эчкерсез хөрмәт итә белүдән һәм мәхәббәттән олы бәхет бармыни бу дөньяда?

З и л ә. Әнә көн дә хат яза, сагынам, ди.

Н а и л ә. Сагынуына да ышанырга була аның. Рәхәттер ул шашып сагынышкан чаклар!.. Уйлар тоташ ут булып аккан минут-

лар... Очрашып кочышканда җир тирбәлеп китә торгандыр... Яхшы, тату, дус яшисез, тик шулай да сезнең өйдә җылы юк.

Зилә. Туңасыңмы?

Наилә. Синең урында булсаммы мин...

Зилә. Озак югалып торасың да, очрашкач, ятсынып карап торам: кем соң син? Очрашмый торган арада кемгә әверелдең?

Наилә. Бала белән тутырыр идем мин бу йортны!

Зилә. Һич көтелмәгән сүз сөйлисең, һәм матур сөйлисең, каһәр суккыры! Белеп сөйләмисең, шунысы кызганыч.

Наилә. Бала тавышы яңгырамаган өйдә кот юк. Бу идәннәр гомергә ятим — алардан тупырдап, үкчәләрен ялтыратып бала йөгереп китмәгән. Синең утлы күкрәкләреңә кабарынкы иреннәре белән бәби капланмаган...

Зилә. Җаным, үз балаң булмаганга гына сөйлисең. Баланың мең дә мең мәшәкате, бәла-казасы бар аның. Төн уртасында елап уяна ул, киреләнә, интектерә, җәфалый таңнан торып мәми сорый, чүпрәкләрен пычрата. Кызамык сагалый аны, ютәл, томау, свинка, теше авырта аның, колагы котырып сызлый. Борынын идән ярыгына кыстыра ул, бармагын электр розеткасына илтеп тыга. Ботка ашамый, әфлисун даулый. Куйган әйберең урынында түгел, «Нефертети» хушбуен кер юу порошогында бутый ул. Вата, җимерә, ерта, буйый, кыра, пычрата, тарката, урамнан канга тузып сугышып керә, кыскасы, татар телендә нинди фигыльләр булса, барын да эшли.

Наилә. Сәламәт, гаиләсе төзек хатынның баласыз калуы җинаять.

Зилә. Кем каршында җинаять?

Наилә. Барыннан да элегрәк, үзе каршында.

Зилә. Мин артистка. Көч, егәремне, талантымны халыкка бирергә бурычлы.

Наилә. Ни өчен халыкка гына?

Зилә. Сәнгать мәңгелек.

Наилә. Әгәр үз кәефебез өчен генә яшәсәк, сәнгатьнең кемгә кирәге калыр? Бозлы атаудагы пингвиннарга күрсәтербезме без аны? Менә сиңа авыл көе ошады. Борынгы көйдер ул! Кемдер саклаган бит аны. Кадерләп күңелендә йөрткән, буыннан-буынга, сөйгән ярларга тапшыра килгән.

Зилә. Син бу көйнең иясенә гашыйк булгансың! Ур-ра!

Наилә. Ашыкма, Зилә. Син уйлаганча ук түгел... Бала хакында ни диден инде?

Зилә. Үгетләмә, Наилә.

Наилә. Ирең бала кирәкмиме?

Зилә. Кайсы ирнең әти дигән сүз ишетәсе килмәс? Ул бик тели.

Наилә. Син — җинаятьче. Балаң бәлки ирең төсле галим булыр. Бәлки сиңа охшап, сәнгать юлын сайлар. Ил сакчысы, сугышчы булыр. Бала — мәхәббәтнең иң татлы, иң затлы җимеше. Бала — синең дәвамың. Сөюеңне юкка булмаганын раслау. Бала алда син күрмәгәнне күрәчәк. Бала — сине якты киләчәк белән ялгаучы. Бала — куаныч. Җан азыгы. Һәр иртәдә балкый торган назлы кояш. Синең бөтен күзәнәкләреңдә тереклек уятучы. Ир белән ике араны ныгыту!

Зилә *(кинәт калкынып)*. Син минем ирем белән хат алышасың! Яки очрашасыз сез!

Наилә. Синең ирең белән дә очрашам икән әле мин!

Зилә. Ул котыртып җибәргән сине!

Наилә. Ул да мине котырта икән әле!

Зилә. Югыйсә, аның сүзләрен каян белер идең? Бөтенесе ту-

ры килә, җөмләләренә кадәр!.. Син аның белән язышасыңмы? Әйтәм җирле ул гел сине мактый.

Н а и л ә. Синең шундый сүзләрне әйтә белә торган фәрештә ирең бармы? Юләр! Сине үгетләргә килмәдем, юк, юк, хафаланма. Мин сине акыллы дустым санап, үземне тикшерер өчен яныңа килдем. Үгетләмим сине, юк, юк! Соңгы тапкыр үз иманымны, үз ныклыгымны тикшерәм.

З и л ә. Бәби алып кайтырга җыенмыйсыңдыр ла?

Н а и л ә. Җыенсам ни диярсең?

З и л ә. Гафу ит мин тинтәкне, кияүгә чыкканыңны да ишетми калдым. Туеңа да чакырмадың. Читләтәсез мине хәзер.

Н а и л ә. Бәби туеннан калдырмам.

З и л ә. Кемгә чыктың? Сиңа да иш табылыр икән. Ну үзең дә сайлап карадың инде! Бәбинең әтисе кем?

Н а и л ә. Бәбинең әтисе юк.

З и л ә. Ничек юк? Яратасың инде, Наиләкәй, кыландырырга!

Н а и л ә. Менә монысын чын күңелеңнән әйтәсең, үпкәлим. Юк шул бәбиемнең әткәсе... Хөкем чыгарырга ашыкма, мондый очракта сак бул. Берәүгә заманның рәхәте эләксә, икенче берүгә михнәте язгандыр, икесе дә янәшә йөриләр алар. Мин бик озак көттем! Көтмәде дип кем әйтә алыр? Дөньяның дүрт ягыннан күңел үзенә пар эзләде. Инде бер мәхәббәттән мәхрүм калдым. Хәзер монысын шикләнми расларга була. Ап-ачык. Тиңдәшләр өйләнгән. Өйләнмәгәннәре яшьрәкләргә карый. Әгәр хатын аерган икән, андыйның миңа кирәге юк. Юньле ир булса, хатын-кыз аны үз кулыннан ычкындырамы? Тәрбияли ул аны, юна, таслый, килешмәгән җирләрен төзәтә, кеше итә, аякка бастыра. «Ирем ташлап китте» дигән хатынга ышанма, юри кыланалар алар, ирләрен яратмыйлар. Бары шул гына. Сөйсәләр ычкындыралармы ирләрен? Мең төрле тышау бар хатын-кызның ирне тотарга! Уйлап кара, кемнәр белән, кайда очраша алам мин хәзер? Белешмәләр бюросына барып сорый алмассың!.. Бардыр ул миңа дигән егет, бардыр! Мөгаен, без табыша, кавыша алмый гына калганбыздыр! Азмы андый хатын-кызлар?! Шулай итеп, көннәрнең берендә мин дә кияүгә чыкмаган карт кыз дәрәҗәсенә ирештем. Налог түлим, графаларга «не замужняя» дип язам. Ир-атның күбесе үзенең кемлеген белми, һәрбере үзен мәһабәт, батыр йөрәкле, гаярь зат дип саный, буе җиткәне дә, җитмәгәне дә сиңа үрелә! Чөнки син ялгыз! Һәркем синең хәзинәңнән өлеш алып калырга тырыша, сүз куша, күзе чепи булса да кыскан була... Ә эштә?!. Ялгыз икәнлегеңне анда ныграк беләләр!.. Тәмам сару кайнаталар. Көненә унбиш җирдән звонок. Ресторанга чакыралар, утрауга дәшәләр, аулакка өндиләр. Хатыннарыннан урлап хушбуй бүләк итәргә азапланалар... Ниһаять, мин ул туктаусыз эзәрлекләүләрдән туйдым. Миңа бары бер генә нәрсә кирәк — Мәхәббәт!.. Дус кирәк миңа, киңәшче, юаныч, яклаучы, таяныч кирәк. Инде икенче тиңдәшсез Мәхәббәттән — бала мәхәббәтеннән коры калырга риза түгелмен!.. Шундый газапларда яшәгән чакта мине акыллы, сәламәт, җитди бер кеше яратты... Беренче тапкыр мин ир-атның эчкерсезлегенә ышандым...

З и л ә. Ялгыз башың белән бала алып кайтырга җөрьәт итәсеңме? Гайбәтчеләр сине тотып кимерәчәк! Сиңа ямьсез тәкъдим ясап йөргән ирләр өеренә ничек күренерсең?

Н а и л ә. Барысы хәл ителгән. Кооператив квартирага урын алдым. Башка эшкә күчәм! Исән-аман тусын гына. Минем белән бергә коляшка карасын! Бергә утырып елашырбыз да, кочаклашып көлешербез. Бергә! Син шул сүзнең тирән, газаплы мәгънәсен аңлыйсыңмы? «Суның кадерен чүлдән килгән юлчылардан сорап бел!»

дигәндәй, бергәлекне ялгыз калгач кына бәһалисең аны, Зиләйлүк! Адәм баласының иң куркыныч дошманы — ялгызлык. Таңда да ялгыз, кичен дә ялгыз. Ялгызлыкның караңгысы куерак, шомлырак... Хатын-кыз ялгызлыгы исә тагын да аянычрак!

Зилә. Ялгыз түгел ич син! Ә мин? Ә без?

Наилә. «Без-без без идек, без унике кыз идек!» Бу бит бала чак, Зилә! Хатын-кыз дуслыгы чуалчык нәрсә. Әле икәүдән-икәү дус булу да читен. Ә син унике хатынны бер учка сыйдырмакчы буласыңмы?..

Зилә. Мин дуслыкка ышанам. Безнең Рабигалар, Айсылулар, Наҗияләр бер чакта да хыянәт итә торган зат түгел.

Наилә. Мин дә ышанам! Тик яхшы чакта бар да яхшы. Тормыш ага... Аның үлеме-җитеме бар дигәндәй, бәласы-казасы...

Зилә. Син бик еракка сикердең. Әле генә бала иде, хәзер кабер?..

Наилә. Беребез дә мәңгегә килмәгән.

Зилә. Син авырыйсыңмы?

Наилә. Авырмыйм. Бу йөрәк ничек чыдый икән дип гаҗәпләнеп кенә куям.

Зилә. Куркыттың мине.

Наилә. Ә син бернидән дә курыкма! Мин сыңар канат килеш курыкмаганны...

Зилә. Минем дә бәби алып кайтасым килеп китте.

Наилә. Чынлапмы?

Зилә. Идәннәрне тупырдатып чабып китәр дисеңме?

Наилә. Китәчәк!

Зилә. Шушы бүлмәләрне тутырып бер елар дисеңме?

Наилә. Елар!

Зилә. Синең сафлыгыңа, батырлыгыңа сокланам!

Наилә. Рәхмәт, Зиләйлүк! Синең сүзең бик кадерле миңа!

*(Җырлыйлар.)*

Бергә.

Әйдә, әйдә! Кайда, кайда?
Әйдә барыйк урманга.
Урман буйлары абага,
Урман суы каты ага.
Сөймик икебез бер чибәрне,
Әйдә салыйк шобага!

Наиләне озатып, Зилә башкалар янына кайта. Сәгать суга. Пауза.

Рабига. Ул шикләре белән кемгә барды икән дип уйлаган идем, синең янга барган икән, синең янга. Сине сайлаган!

Ләрия. Хәзер барысы да аңлашылды. Син гаепле монда, Зилә, син! Әгәр андый киңәш белән минем янга килгән булсамы!..

Рабига. Әле берни дә ачыкланмады.

Диләрә. Булды туганкайлар, зинһарлап сорыйм: әйдәгез, шушында, яхшы чакта тукталыйк. Кем бу дөньяда эч серсез яши? Нигә хәзер юк-барларны казып чыгарырга? Ләрия дөрес әйткән — кирәкми!

Ләрия. Этә-тә-тә! Бер мин гаепле булып калыйммы? Һәммәгез гаепле, барыгыз да!

Зилә. Мин дә дип өстә.

Наҗия. Әйе шул.

Ләрия *(Наҗиягә).* Син, йомыкай! Җил кагылмагач, селкенмим дип уйлыйсыңмы?

Наҗия. Мин нишләгән?

Рабига. Чиратлашмыйк алай. Теләмәгәннәр сөйләмәс. Беркемне көчләү юк. Шуннан ни булды, Зилә.

Зилә. Шул. Үз вакыты җиткәч, бәбәй алып кайттым. Без аңа Айгөл дип исем куштык. Наиләнең Чулпан исемле кызы туды...

Рабига. Юк әле, юк. Чулпан калыкканчы байтак эшләр бар!

Наҗия. Мин генә берни белми яшим икән.

Диләрә. Шулай икән, катышма. Син гадел, чишмә суыдай саф.

Наҗия. Нигә үчеклисез мине, нигә?

Рабига. Иң аянычы шунда, егетебез Наиләне күрү бәхетенә иреште! Югославия эстрадасы концерты килгән иде, ирем белән өчәүләшеп шунда киттек. Ике рәт аша гына утырган Наиләне күргәч, шатлыгымнан нишләргә белмәдем. Тәнәфес арасында егет белән Наиләне таныштырдык, ирем, әйдә, Наилә белән бергә утырыгыз дип, аның урынына китте. Наиләне уртабызга алдык. Концерт дәвамында сөйләшмәсәләр дә, сизенәм, бер-берсенә карап-карап алалар болар. Егетебез гел карый, Наилә дә ара-тирә күз ташлый. Чыккач озата бардык, Наиләнең күңеле күтәренке...

Зилә. Җырны-моңны бәяли белә иде.

Рабига. Безнең дә кәефләр шәп! Беләсезме, ышанасызмы, егетебез үлеп гашыйк булды Наиләгә! Бездән яшермәде. Наиләдән дә яшермәгәндер дип уйлыйм. Алар очраша башладылар. Эшнең тирәнгә кереп барганын чамалап, мин тагын аның янына киттем. Теге каһәр суккан хәбәр, Ләрия тараткан коткы тынычлык бирми иде миңа!

Ләрия. Миңа типмичә генә үтеп китә алмыйсыңмы?

Рабига. Бу очрашуыбыз тагын да аянычрак булды.

Диләрә. Үткән — беткән инде.

Рабига. Яхшылык теләгәннән яраланган йөрәк ыграк сызлый диләр!

Зилә. Җәберләмә үзеңне, сөйлә. Без дә аңлыйк. Тик мин бая сөйләп бетермәдем.

Рабига. Син артык еракка сикердең. Эзлеклелекне югалтмаска тырышыйк без.

Зилә. Алайса, син сөйләп бетер, Рабига.

Рабига. Җыенып чыгып киттем. Тик ул көнне мин барганга кадәр, Наилә янында тагын берәү булып киткән иде.

Зилә. Сөйлә, Рабига.

Наҗия. Мин берни дә белмим.

Диләрә. Наилә белән без генә очраша идекмени? Аның тормышы бер безнең белән чикләнгән идемени?

Рабига. Бәлки Ләрия берәр сүз өстәр?

Ләрия. Өйгә кайткач, Габбасыма ни җавап бирермен дип баш ватып утырам. Үткәннәрне искә алып, кыланып, әрләшеп утырдык дисәм, икмәктер ышанмас.

Зилә. Юк әле, Ләрия. Болары җавап биралмаслык сораулар түгел! Дөньяда шундый сораулар була кайчакта, җавап таба алмыйча, сының катып кала!.. Баллы җавап алыр өчен татлы сорау биреп гадәтләнгән шул без. Күзгә карап тайчанмаска, бер-беребезне алдарга гадәтләнгән.

Наҗия. Үзең сөйлә дә бир, Рабига.

Рабига. Миңа кадәр Наҗия бер-ике сүз әйтсен.

Наҗия. Мин?

Рабига. Чебенне дә рәнҗетмәс Наҗиядән гаеп-кыек эзләргә рөхсәтем юк! Дәшми утыргач та, кара аны, тәмам узындыгыз! Әүлия бит ул!

Зилә. Рабига шулай ди икән, ышанмый хәлебез юк. Ул берни дә яшерми.

Л ә р и я. Без дә яшермибез.

Д и л ә р ә. Рабига, теләмәгәннәр сөйләмәс, диден. Үз сүзең.

Р а б и г а. Тик без фикернең әзлеклелеген югалтмаска мәҗбүр. Әйе, мин барып кергәндә Наилә чиксез дулкынланган, борчылган иде. Моңа минем килү сәбәп булмады ич!

Л ә р и я. Кем белгән анысын!

Р а б и г а. Без дулкын-дулкын бәрелеп, аның йөрәгенә җимереп килгәнбез. Ягез.

Д и л ә р ә. Юк дим ич, гаебем юк!

Н а җ и я. Булды, Диләрә, җитте. Кыланмыйк. Мин дә аңлыйм, син дә күптәннән белеп утырасың. Очрашканда Наиләнең гайбәтен сатмый идекме?

Л ә р и я. Берәрегездә баш даруы юкмы?

Н а җ и я. Булды инде, безнең катнаш та җитәрлек булды.

Л ә р и я. Кем синнән сүз сорый? Кем?

Н а җ и я. Мин балалар бакчасында идем... Минем янга башта Диләрә килеп керде.

**Балалар бакчасы. Балалар чыр-чуы яңгырап китә. Наҗия янына Д и л ә р ә керә.**

Н а җ и я. Ахирәт, синме бу?

Д и л ә р ә. Мин бу, мин. Мин! Исән-саумын, бик әйбәт йөрим! Тормыш ал да гөл! Яши белгән кешегә шөкеранадан башка сүз юк!.. Сиңа мөһим бер йомышым бар. Алдан ук искәртеп куям, аны бер син генә башкарып чыга аласың.

Н а җ и я. Нинди зур йомыш икән алай?

Д и л ә р ә. Мөдир белән мөдир килешә алмаган эш булырмы?

Н а җ и я. Әллә ул камытны син дә киденме?

Д и л ә р ә. Тутаң кибет мөдире булды. Торг начальнигы әллә кайчаннан вәгъдә бирен йөри иде.

Н а җ и я. Син дә мөдир, мин дә мөдир, атка печән кем сала?

Д и л ә р ә. Дөрес, безнең мөдирлекнең исеме генә аның... Ишәк кебек көне-төне эшлисе, кулыңда бер власть юк. Әмма мөдир барыбер мөдир инде! Дус-иш белән аралашканда уңай. Әле дә ярый дусиш онытып бетерми. Шулар белән яшисең. Гади кибетче чагында читенсенә башлаган идем. Рабигалар, Зиләләр алдында оят. Ә хәзер ярыйсы! Тигез урында без дә түмгәк. Карап атла, абынырсың!.. Сиңа да йомыш шул — торг начальнигыбызның внугы бар. Үтә дә шук малай! Бер көн шаярып, йөз илле тәңкәлек хрусталь вазаларын төшереп ваткан!.. Җәлләп елаштык!.. Шул наянның садигы бик ерак. Алар шушы тирәдә яшиләр. Шул башкисәрне синең садикка урнаштырасы иде. Тегендә кагалар да икән үзен...

Н а җ и я. Бездә урын юк бит, Диләрә.

Д и л ә р ә. Теләсәң табылмыймы? РОНОда, райбашкармада танышларың!

Н а җ и я. Танышлар дип, бер дә андый йомыш төшкәне булмагач, читен.

Д и л ә р ә. Өйрән! Таныш-белештән йөз чөерсәң, әнә, Наилә кебек гомер буе тукран тукылдатырга калырсың. Керми бит, кибеткә кермәгән була, янәсе, үзенчә яши, берәүгә дә баш бирми. Иярсең җаным, баш та иярсең, бил дә бирерсең!

Н а җ и я. Җайсызрак йомыш белән килгәнсең, Диләрә.

Д и л ә р ә. Ай аллакайгынам, әллә ахирәт дустыңа шул ярдәменне дә кызганасыңмы?

Н а җ и я. РОНОда эшләүче Нина Ивановна Ләриянең дусты. Син шуңа сүз салып кара.

Д и л ә р ә. Ләриядән болай да күп файда күрәм! Чая хатын! Бу юлы йомышны үтәү сиңа йөкләнә. Юкса, нинди дус буласың ди син миңа? Өйрән, оялма, чәтердәп тор. Врач булмасак та яшибез, артистка булмасак та яраталар безне!

Ләрия болар янына килә.

Н а җ и я. Мең яшәр әле безнең Ләриябез.
Л ә р и я. Яшәмичә! Утта янмый, суда батмый Ләриягез! Ахирәтләрем!
Д и л ә р ә. Икмәктер, сине сагынып телгә алган идек.
Н а җ и я. Яңа мөдирнең сиңа бер гозере бар.
Л ә р и я. Ишеттек, сөендек, котладык. Яңа мөдирнең үзенә бер үтенеч: әйбәтрәк колбасагыз юкмы, Диләрә? Габбасым мин пешергән ризыкны бер дә яратмый.
Н а җ и я. Колбаса да булдымы ризык?
Л ә р и я. Ярый ла синең детсадыңда ит тулып ята.
Н а җ и я. Әбәү, ни кыйланасың? Балалар өлешенә керергә әллә мине...
Д и л ә р ә. Безнең Наҗия фәрештәдәй яшәмәкче! Ашамый, эчми...
Л ә р и я. Тормыш аны да бөгәр! *(Җырлый.)*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Наласа.
Колбаса да булмас иде,
Дуңгыз балаламаса.

Д и л ә р ә. РОНОдагы Нина Ивановнага күлмәкләрне һаман син тегәсеңме?
Л ә р и я. Андый клиентны кулдан ычкындырган юк.
Д и л ә р ә. Торг начальнигыбызның оныгын шуның аша Наҗия садигына урнаштырасы иде.
Л ә р и я. Синдәй дус өчен, Диләрәкәем, садикта яңа бүлек ачтырам!
Д и л ә р ә. Наҗия карышып маташкан була.
Л ә р и я. Наҗия җүләр балык бит ул — өстә йөзә!.. Әй, ник кергәнемне әйтергә оныттырдыгыз. Наҗия, ачык авыз, Мәрданың урамнан кем белән китеп бара дип беләсең?
Н а җ и я. Мәрданга моңарчы сакчы кирәкми иде.
Л ә р и я. Казанның иң тыйнак, иң спай, иң намуслы...
Д и л ә р ә.. Наилә беләнме?
Н а җ и я. Нигә Наиләгә бәйләнәсең син, Ләрия?
Л ә р и я. Мин сине кызганам.
Н а җ и я. Кайчан күрдең?
Л ә р и я. Менә әле генә.
Н а җ и я. Мәрдан кичке поезд белән Мәскәүгә китте.
Л ә р и я. Кайткандыр!
Н а җ и я. Синең юха телеңә ышанып, тынычлыгымны җуйдым... Мәрдан берәр җиргә китсә, йөрәгем сикерә, температурам күтәрелә! Командировкаларга йөрмә дип ялынам! Торабыз да ызгышабыз! Мин синең бер сүзеңә дә ышанмыйм!
Л ә р и я. Намус белән ир хакын хаклап торучыга ышанмый! Көне-төне семья дип янучы, кыз үстерүче анага ышанмый, уйнашчы Наиләгә ышана! Ирләребезне аздырып, ара бутап йөрүчегә ышана!
Н а җ и я. Нигә бу сүзне миңа әйтәсең. Батыр икәнсең, Наиләнең үзенә сөйлә.

Л ә р и я. Сөйләрмен дә! Әйдәгез, өчәүләп киттек. Әгәр ул бәбәен тапса... У-у, бөтен шәһәргә фаш булачак! Безнең ирләр ни әйтер? Барыйк та кисәтик: хатын-кыз исемен пычратып йөрмәсен!

Н а җ и я. Теләсәгез нишләгез, мин бармыйм.

Д и л ә р ә. Лэрия, без синең сыман оста сөйләшә белмибез, Үзең генә барып, сөйләшеп кайт булмаса.

Л ә р и я. Сезнең исемнән дә сөйләргә рөхсәт бирәсезме? Өчебез исеменнән вәкил итеп җибәрсәгез, барам.

Н а җ и я. Мин...

Д и л ә р ә. Син дәшмә! Дуслыкның бәһасын, кадерен аңламыйсың син! Лэрия, ичмасам, кеше! Дуслары өчен җаны фида!

Л ә р и я. Намусын җуйган хатын-кызны хөкем итәсеңме-юкмы, Наҗия?

Н а җ и я. Беребезгә дә куңелле түгел инде анысы...

Д и л ә р ә. Шулай дип котыл! Барсын, Наҗия! Кыланчыкларны мин дә яратмыйм!

Лэрия бер мизгелгә генә югалып тора. Диләрә белән Наҗия, Рабига, Зилә янына баралар.

З и л ә. Шулай дәртләндереп, Лэрияне намус, вөҗдан сафлыгы өчен көрәш кырларына озаттыгызмы?

Д и л ә р ә. Алай ук түгел лә!

Р а б и г а. Үзегез җыйнаулашып этлек эшләргә килешеп...

Д и л ә р ә. Нинди этлек?

Р а б и г а. Баланы законсыз рәвештә бакчага урнаштыру этлек түгел инде синеңчә, дуслык, шулаймы?

Д и л ә р ә. Инде Лэрияне чәйнәкләп ташлагач, миңа тотындыгызмы?

Л ә р и я. Арага мине кертмәгез зинһар. Болай да эссе!

Р а б и г а. Чынлап бәяләгәндә, син Лэриягә караганда да куркынычрак.

Н а җ и я. Барыбызда да гаеп җитәрлек.

З и л ә. Диләрә утны астан йөртә. Лэрия башкаручы, аңа диңгез тубыктан... Ә менә Наҗия... Кул кушырып, ризалык биреп тора! Рольләр шәп бүленгән!

Л ә р и я. Илчегә үлем юк. Мин алар исеменнән вәкил булып бардым.

Р а б и г а. Нишләдең инде барып? Хәер, син киткәч Наилә ашыгыч ярдәм машинасы чакырткан...

З и л ә. Нишләдең?

Л ә р и я. Нишләдем? Ярсып, гайрәтләнеп барып кердем. Дөньяда нинди әшәке сүз бар, берсен дә калдырмадым. Ичмасам, нигә берәрсе, я Наҗия, я Диләрә мине тыймады икән?! Бозык, дидем. Азгын, дидем. Әгәр бәби алып кайтсаң, күрмәгәнеңне күрсәтербез, дидем.

Д и л ә р ә. Булган, беткән.

З и л ә. Сабыр идең бит син, Диләрә.

Д и л ә р ә. Бик бәйләнсәгез чыктым киттем булыр!

Р а б и г а. Кит. Бар.

Д и л ә р ә. Китәм дә шул. Ничә елга бер очрашып, сез мине белән дип уйлыйсызмы? Без бит бөтенләй яңа кешеләр, башка кешеләр. Кайчандыр мәктәптә укып йөргән уникe сабый түгел.

З и л ә. Диләрә, зинһар, чыгып тор!

Д и л ә р ә. Әллә тотар идегезме? *(Чыгып китә.)*

Р а б и г а. Сафлар тарала... Бәлки тагын берәрегезнең кайтып китәсе киләдер? Хәзер мин сезгә иң үкенечле очрашуыбызны сөйлим... Кичкә кырын мин Наилә янына барып кердем...

Наилә диванда ятып тора, Рабига керә.

Рабига. Нигә мине түргә өндәмисең?
Наилә. Уз дип әйтмәдеммени?
Рабига. Авырыйсың бугай син. Яле.
Наилә. Юк, сәламәт мин. Кайчагында, бу йөрәк ничек түзә икән дип кенә куям.
Рабига. Байтактан синең янга керергә дип йөрим.
Наилә. Үземнең дә сине күрәсем бар.
Рабига. Очрашуыбыз кирәк булган алайса.
Наилә. Син... каенәнеңә әйт, яңадан мине күрергә тырышмасын. Шалтырата, эштән кайтканны сагалый, өйгә килә.
Рабига. Боларын беләм.
Наилә. Минем нигә очрашырга теләмәгәнне дә беләсеңме?
Рабига. Шуны ачыкларга дип килдем дә. Исламгали әйтә, кай җирен ошатмады икән егетнең ди.
Наилә. Их, Рабига! Рабига!
Рабига. Мин дә гаҗәпләнәм.
Наилә. Их, Рабига, Рабига! Фаҗигасе дә шунда бит аның! Егет менә дигән булып чыкты...
Рабига. Сиңа гына ошамады.
Наилә. Миңа? *(Көлемсери.)* Эшне алыштырам дигән идем. Китмим. Алыштырмыйм... Һәммәсе элеккечә калсын. Егет дисеңме?.. Кызганычка каршы, ул миңа искиткеч ошады. Беренче мәртәбә йөрәгем мәхәббәттән тетрәнде!
Рабига. Шулай булгач?
Наилә. Шушы кыска гына очрашуларда да яратып өлгердем мин аны... Күңел сусаган икән... Төшләремдә күрәм! Көндез һәрчак күз алдымда, янымда, кырымда, куенымда... Менә хәзер дә монда ул, әнә тегендә елмаеп басып тора... Акылы, холкы-фигыле, омтылышы — һәммәсе мин көткәнчә! Мәхәббәтне тату миңа да насыйп икән! Бу бит зур, тиңдәшсез бәхет!..
Рабига. Ул үлеп сиңа гашыйк!
Наилә. Беләм, ышанам. Тик... соң, Рабига, соң! Бәбәй алып кайтырга җыенуымны беләсең. Ул да белә. Һәм аның миңа нинди тәкъдим ясавын да беләсең.
Рабига. Авыр булса да, әйбәт кешегә барыйм дигәндә, андый гына эшкә күнми булмас шул. Өйләнмәгән егет нишләп чит кеше баласына әти булырга теләсен, Наилә?
Наилә. Бала минеке!.. Бирәү булса ризалашыр да иде! Без-без без идек, без уникә кыз идек! Ләкин мин андыйлардан түгел. Бала үтереп, тормыш кора торганнардан түгел.
Рабига. Тумаган ич әле!
Наилә. Син? Врач, минем дустым?.. Шул киңәшне бирергә килдеңме?
Рабига. Тормышың җайга салынмаган. Шул синең сәламәтлегеңә дә зарар итә.
Наилә. Картайгансың син, Рабига. Фикерләреңнән ләм исе, черек исе килә. Каенәнеңә әйт, җәфаламасын минем йөрәкне. Миңа бик кирәк чакларда кайда йөргән ул? Хәзер белдем, мәхәббәт юклыгы бер авыр булса, соңарып килгән сөю аннан да авыррак икән!..

Наилә чыгып китә. Сәгать суга. Пауза. Рабига ахирәтләре янына бара. Диләрә керә.

Рабига. Нигә кайтып китмәдең, Диләрә?
Диләрә. Белмим.

Зилә. Мин Наиләгә ана булуым белән бурычлы... Тик шулай да бәби туена чакырып алмадым. Онытылган. Әллә ялгыз кеше дип каралганмы?..

Нәҗия. Шул, шул... Ирсез бәби тапкан дип саналган...

Диләрә. Мин Наиләне тәмам онытхан идем инде.

Зилә. Ул онытмады. Быел гастрольгә киткәндә... Әй, сөйләдем ич!

Нәҗия. Ничек яшәде икән ул?

Зилә. Белмим.

Ләрия. Таралышыйк булмаса.

Рабига. Ә бала?! Кызын, Чулпанны нишләтәбез? Балалар йортына бирәбезме?

Ләрия. Кызын? Нигә монысын да миннән сорыйсың? Әллә Габбасны...

Нәҗия. Телеңне тый, җәфа!

Рабига. Моңарчы сорауларга җавап биреп була иде әле. Менә шушы сорауга җавап табып карагыз: кая куябыз Наиләнең кызын?

Зилә. Әгәр Чулпан булмаса, минем Айгөлем тумаган була иде бит!

Чулпан килеп керә.

Чулпан. Рабига апа, мин килеп тә җиттем.

Рабига. Кайттыңмы, балам? Кайттыңмы, нәнием? Исламгали абыең кайда?

Чулпан. Ул миңа «керә тор» диде.

Зилә. Син нинди зур кыз булгансың!

Чулпан. Рабига апа, әнине барып алып кайтыйк инде. Озак йоклады. Барабызмы?

Рабига. Я, кайсыгыз бу сорауга җавап бирә ала?

Чулпан. Сезнең Азаматның әтисе дә бар икән! Нигә минем әтием юк, Рабига апам?

Рабига. Бу сорауга кайсыгыз җавап бирә ала?

Зилә. Чулпан, балам! Рабига, кызны мин үзебезгә алам. Айгөл белән бергә үссеннәр.

Ләрия. Син аласыңмы, Зилә?

Зилә. Әйе. Үзебезгә алам. Үзем карыйм. Үзем тәрбиялим. Миңа ышанасызмы?

Рабига. Сиңа ышанабыз, Зилә.

Чулпан. Мин синең кыз буламмы? Кем соң син?!

Зилә. Наилә урыны буш кала алмый... Курыкма, кызым... Буш булуы мөмкин түгел Наилә урынының. Безнең арада әнисе урынын хәзер Чулпан алачак.

Рабига. Әйдә, шулай булсын!

Ләрия. Таралышабызмы инде?

Рабига. Киресенчә, тупланырга кирәк безгә, Ләрия. Без-без без идек, без унике кыз идек...

Зилә. Унике булып калырбыз да.

Пәрдә.

1976—77 еллар. Казан.

≈≈≈≈≈≈

## Михаил Клипиницер

# МУСА ҖӘЛИЛ «ОРЛЕС» ЗАВОДЫНДА

*Бер шигырь эзеннән*

Муса Җәлилнең «Орлес» заводында» дигән шигыре 1926 елның җәендә язылган. Яшь шагыйрь бу вакытта комсомолның Оренбург губерна комитетында инструктор булып эшли. Комсомоллар арасында ялкынланып йөрү аны дәртләндерә, идея-политик яктан тагын да чыныктыра, иҗатына илһам бирә. Бу чорда Муса Җәлил Оренбург шәһәренең төрле предприятиеләрендә эшләүче татар яшьләре белән аралаша, комсомол оешмаларында идеологик тәрбия һәм культура-масса эшләрен яхшырту өчен бөтен тырышлыгын һәм сәләтен куя.

Ул чакта шәһәрдә иң зурлардан саналган агач эшкәртү заводы — «Орлес»та татар яшьләре аеруча күп булган. Шул завод, аның эшчеләре белән танышу, гражданнар сугышы елларында җимерелгән халык хуҗалыгын аякка бастыруда комсомолларның фидакарьлеген күрү шагыйрьнең уйларын канатландыра. Ул ирекле хезмәтнең батырлар тудыруын, матурлыгын җырларга ашкына, станоклар гөрелтесендә, заводның ритмлы шау-шуында яңа тормыш симфониясен ишетә.

Мостафа авылында туып, шунда мәктәптә, аннары Оренбургта, рабфакта һәм хәрби-политик курсларда укыган шагыйрьнең моңарчы язган әсәрләрендә завод-фабрикалар телгә дә алынмый, революция давылында туган яңа илнең индустриаль сулышы сизелми. Бу гаҗәп тә түгел. Комсомол инструкторы Муса Җәлилов танышкан беренче зур предприятие шул «Орлес» заводы була. Шагыйрь беренче тапкыр «Орлес»ка килүен, иркен цехларда йөрүен, «куәтле станоклар хорының күңелле, дәртле җырын» тыңлавы турында яза.

Заводта бернечә мең кеше эшләгән. Уналы урында — такта яру рамнары гүли. Предприятиедән җәй айларында Урал бассейнындагы елгалар буйлап ел саен миллионлаган такта озатылган. Революциягә кадәр бу завод акционерлар компаниясенә зур табышлар китергән. Оренбург эшчеләрен рәхимсез эксплуатацияләү нәтиҗәсендә барлыкка килгән бу «симез калҗаны» бүлешүдә патшаның әнисе Мария Федоровна да катнашкан. Ул инде кайдан һәм ничек байлык сыгып алу әмәлләрен яхшы белгән.

Революциядән соң предприятие яшь совет дәүләте карамагына күчә һәм агач эшкәртүдән алынган бөтен керемнәр илнең халык хуҗалыгын торгызуга бирелә.

Муса Җәлил заводның тарихын да белгән, әлбәттә. Шагыйрьгә «Орлес»та үткәргән бер көне аеруча истәлекле булган, күрәсең. Бу заводка багышланган шигъри повестен ул нәкъ менә шул истәлекле көн тәэсирләре белән яза. Монда шагыйрьгә бөтен нәрсә яңа: ул станоклар гөрелтесе, ул сузып-сузып кычкырткан гудок тавышлары, ул кечкенә вагонеткаларның келтер-келтер тәгәрәве, ул ялкынлы йөрәкле яшьләр... Хәер, цехларда эшләүче егетләр һәм кызларның күбесе — аның күптәнге танышлары. Муса Җәлил алар белән завод клубында очраша, драмтүгәрәктә катнаша. «Орлес» заводының хезмәт ветераннары ул көннәрне әле дә хәтерлиләр.

Мин Оренбургта ул ветераннардан алты кешене эзләп таптым. Г. Абукаев, В. Е. Елфимов, комсомол райкомының шул чактагы секретаре П. Шахов һәм башка эшчеләр егерменче елларда «Орлес» заводы клубында үткәрелгән күңелле кичәләрне, куелган спектакльләрне искә төшерәләр һәм, әлбәттә, һәркайсының күз алдына яшь, дәртле Муса килеп баса.

Элекке завод хуҗасының йортында урнашкан клубка (хәзер анда ял йорты) оренбурглылар, бигрәк тә «Орлес» эшче-

ләре бик теләп йөргән. Татар драмтүгәрәге спектакльләрен һәм концертларын зур кызыксыну белән караганнар. Ветераннарның әйтүенчә, мондый кичәләргә татарлар гына түгел, рус эшчеләре дә килгән. Клубка ул елларда йөргән ветераннар барысы да диярлек Муса Җәлилне хәтерли.

«Орлес» заводының беренче комсомолларыннан Гобәйдулла Абукаев үзе дә драмтүгәрәктә катнашкан, спектакльләрдә уйнаган.

— Безнең коллективта егермеләп кеше бар иде, — дип искә төшерә ул. — Драмтүгәрәккә Абдрахман Әбҗәлилов җитәкчелек итте. Бөтен гаиләләре белән талант иясе иделәр. Абдрахманның бер туганы Хәлил Әбҗәлилов соңыннан Татарстанда күренекле сәхнә остасы булып танылды, СССРның халык артисты дәрәҗәсенә күтәрелде. Муса Җәлил безнең түгәрәкнең үзәгендә була торган иде. Тагын Зөбәерова, Гафарова, апалы-сеңелле Солтановаларны хәтерлим. Репетиция үткәреләме, кичә-спектакль буламы — Муса Җәлил инде бөтерчектәй бөтерелеп йөри. Берәүгә ролен башкару турында киңәш бирә, икенчесен сәхнәдә үз-үзен ничек тотарга өйрәтә, өченчесенә җыр-көй борылмалары турында аңлата. Белмәгәне юк иде аның. Үз пьесаларын да укый идек. Кара күзләреннән нур чәчеп, үз шигырьләрен укуы әле дә күз алдымда. Мандолинада бик яхшы уйный иде. «Карурман» көен сыздырып җибәрсә — сокланып тыңлыйсың...

Муса Җәлил завод эшчеләре белән аларның хезмәте урынында да, ял сәгатьләрендә дә аралаша. Шагыйрь күңеле эшчеләр сыйныфының революцион һәм сугышчан рухын тирән аңлый. Заводта солдат шинелен моннан ике-өч ел элек кенә салган кешеләр дә эшли. Алар яшь Совет властена хәтәр янаган чакта, кулларына корал алып, аны якларга, саклап калырга дип, яуга күтәрелгәннәр. Колчак армиясенә каршы көрәшкә «Орлес» заводы меңләгән эшчесен озаткан, алар 217 нче полкны оештырганнар. Бу полк сугышчылары 1919 елда Оренбургка һөҗүм иткән колчакчыларга каршы канкойгыч сугышларда катнаша. Ул көннәрнең дәһшәтен Муса үз күзләре белән күргән, шагыйрь йөрәге белән кичергән. Оренбург эшчеләреннән оештырылган полклар Колчак һәм Дутов бандаларына каршы дәррәү күтәрелеп, Совет властен саклап калу өчен батырларча сугышкан чакта, унөч яшьлек Муса «Бәхет» шигырен яза һәм кызылармеецлар өчен чыгарыла торган «Кызыл йолдыз» газетасы редакциясенә тапшыра. Азатлык өчен барган сугышта үлү — бәхет ул, дип саный яшь шагыйрь, батырларча һәлак булган көрәшчеләргә дан җырлый. Унөч яшендә ук шундый «иман ныгыткан» Муса Җәлил үзенең бу инанганлыгын гомер буе йөрәгендә саклый һәм палач балтасы астында да аңа турылыклы булып кала.

Яуда батырлык күрсәткән кешеләр тыныч хезмәттә дә фидакарь. Шагыйрь шуңа сөенә. Аның геройлары — менә шушында, «Орлес» заводы цехларында. Муса Җәлил аларны яхшы белә һәм шигъри юлларында шуларның хезмәттәге батырлыгын җырлый. «Орлес» заводы турындагы повестьта шагыйрь бер карт эшче-машинист турында сөйли. Аның керфекләре кап-кара, әйтерсең лә, аларга дары сөреме сеңгән. Бер чагыштыру белән Муса Җәлил машинистның яулар кичкән сугышчы булуын да аңлата. Ул кеше умыртып эшли дә белә. Шагыйрь «аның башында барлык сыйнфый бәрелешләрнең тарихы саклана» ди. «Орлес» заводындагы эшче бригадаларны Муса Җәлил кызыл гвардия полкларының отрядларына тиңли.

Шагыйрь сурәтләгән машинист кем ул? Завод ветераннары беравыздан:

— Әлбәттә, Иван Яковлевич Силкин, — диләр.

Силкин нәкъ шул елларда «Орлес» заводының баш механигы иде. Күпне кичергән кеше. 1905 елда Кара диңгез флотында матрос булган.

Иван Яковлевич Силкинның кызлары — Маргарита һәм Таисия — әтиләренең легендар «Потемкин» крейсерында хезмәт иткәнлеген әйттеләр. 1905 ел революциясеннән соң аны «Три святителя» крейсерына күчергәннәр. Матросның керфекләренә дары сөреме бәлки шул чорда — самодержавиегә каршы көрәшкән чакта сеңгәндер?

Муса Җәлил шул кешене — рус флотының легендар матросын, коммунист Иван Силкинны шигъри повестена кертә. Шагыйрь бу батыр һәм гаҗәп тыйнак кешене, алтын куллы останы нәкъ тормыштагыча итеп сурәтли. Муса Җәлил аның керфекләренә сеңгән дары сөремен генә түгел, янып торган күзләрендә бишенче ел бәрелешләренең шәүләсе уйнавын да күргән. Бу сурәт төгәл дә, сәнгатьчә дә. Шагыйрь геройның биографиясен яхшы белеп яза, аның революцион рухын ышандырырлык итеп кенә түгел, күзең белән төсмерләрлек детальләрдә сурәтли.

Әсәрдә завод гудогына багышланган юллар дулкынландыра. Муса Җәлил гудокны шәһәр белән авылны берләшергә чакыручы символ итеп күрә. Гудокның аһәңле авазы хезмәт кешеләрен яңа дөнья корырга, көрәшкә, бердәмлеккә чакыра. Бу авазны эшчеләр яхшы аңлый, ул инде ерак авылларга да ишетелә, кырларга машиналар, тракторлар чыга. Шагыйрьнең күңел күзе шуларны күрә һәм тормышның яңаруына, совет иленең көннән-көн ныгый баруына сөенә. Аның шатлыгы, горурлыгы җыр булып яңгырый.

«Орлес» заводы турындагы әсәрнең ничек язылуы турында шагыйрьнең сеңелесе Хәдичә Җәлилова болай сөйли:

— Яхшы хәтерлим, 1926 елның җәй азагы иде. Абый комсомолның Оренбург губкомында эшләде. «Орлес» заводына бик еш бара иде. Шигъри повестьта искә алынган төндә Мусаны өстәл янына әйтерсең кадаклап куйдылар. Заводны,

аның кешеләрен күреп бик тәэсирләнгән, сокланган шагыйрь, шул хисләрен аңлатырлык иң кирәкле сүзләрне, юлларны эзләп, таңгача утырды. Өстәлдә самавар гөжләп тора, әни Мусаны чәй белән сыйлый, ә ул, чынаягын кулында тоткан килеш, нидер пышылдый. Уйлары заводта булгандыр, күрәсең. Төн буе язды...

Муса заводка, таңнан торып, иртәнге смена эшчеләре белән бергә бара торган булган. Мондый чакларда кичергән хисләрен шигырьләреннән аңларга була: «Орлес»ның гудок тавышы аңа дәртле музыка булып ишетелә. Шул музыка аның көчен арттыра, аны канатландыра, һәм шагыйрь инде завод ягына очып кына бара. Заводка ашыгучы кешеләр йөзендә таң нурлары, шатлык нурлары балкый. «Орлес» турындагы әсәр шундый канатлы хисләр һәм яктылык белән өртелгән. Муса Җәлил зур завод тормышыннан үзенең илһам чишмәсен таба, цехларда ялкынланып йөргән кешеләрне шигъри әсәренең геройлары итеп сурәтли. Повестьта фамилияләр булмаса да, «Орлес» ветераннары Муса Җәлилнең кемнәр турында язганын беләләр. Аның геройлары — гражданнар сугышы утларын кичкән кешеләр, винтовканы калдырып, станоклар янына баскан эшчеләр, матрос-машинист һәм уйный-көлә эшләүче комсомол егетләр һәм кызлар.

Ветераннар арасында сүз булып алды:

— «Орлес» турында язганда кызлардан кемнәрне күздә тотты икән Муса Җәлил? — дип, бер-беребезгә сорау бирдек.

Моңа җавап итеп, Гобәйдулла Абукаев зур ышаныч белән әйтте:

— Настя Соловьеваны хәтерлисезме?.. Мария Неверованы, апалы-сеңелле Ванчиноваларны?.. Әлбәттә, шуларны язган безнең Муса!..

Гудок музыкасы, станоклар ритмы, цехлар җыры турында язса да, шагыйрь һәр вакыт кешеләрне күздә тота. Яңа тормышны, заводтагы хезмәт ритмын шулар тудыра, шагыйрь күңелен илһамландыручы көч тә — шулар.

«Орлес» заводында» повестеның Мәскәүдә «Советский писатель» нәшриятында «Шагыйрь китапханәсе» сериясендә басылып чыккан «Совет поэзиясендә Октябрь» дигән җыентыкка кертелүе, минемчә, бик урынлы. Муса Җәлилнең Оренбургтагы бер завод турындагы повесте Октябрь революциясе елъязмасының шигъри бер сәхифәсе ул. Аның һәр юлыннан ул чорның кайнар дәртле сулышы, көраш һәм хезмәт романтикасы бөркелеп тора.

## Әмир Мәхмүдов

# «МОАБИТ ДӘФТӘРЛӘРЕ»НДӘ ЭСТЕТИК ИДЕАЛ ГӘҮДӘЛӘНЕШЕ

Үлемсез «Моабит дәфтәрләре»нең фәлсәфи-эстетик нигезендә Муса Җәлилнең Ватан турында, кешенең тормышта тоткан урыны, азатлык, кешелек намусы хакында уйланулары гына түгел, ә бәлки тоткынлыкта иза чиккән хәрби әсирләрнең, немец антифашистларының, кыскасы, фашистик Германия тарафыннан кол ителгән барлык кешеләрнең фикерләре һәм карашлары зур урын алып тора. Бу шигъри циклда әдипнең социаль-политик, этик һәм эстетик идеаллары берләшә. Шагыйрь фашистларның, егерменче гасыр инквизиторларының йөзеннән битлекләрен йолкып ата, фашизмны тудырган социаль тамырларның асылына туктала, нацизмның цивилизацияле вәхшилек булуын исбатлый.

«Моабит дәфтәрләре»нең лирик героенда совет кешесенең рухи бөеклеге, ялкынлы патриотизмы һәм тирән интернационализмы, югары гуманизмы гәүдәләнгән. Лирик герой, әдипнең эстетик идеалын билгеләүче буларак, сугыш чорының үзенчәлеген чагылдыра. Җәлил шигырьләрендә дөньяга караш мәсьәләләре — үлем һәм үлемсезлек проблемалары үзәк урында тора. Бу мәсьәләләр фаҗигалелек һәм батырлык кебек эстетик категорияләр белән тыгыз бәйләнгәннәр.

Моабит циклында без фаҗигалелекне сурәтләүнең ике төре белән очрашабыз. Беренче нәүбәттә шагыйрьнең фаҗигале язмышы ачык күренә. Җәлил үз гомеренең фашист балтасы астында өзеләчәген алдан сизә, күреп тора. Әдип фаҗигалелекне шулай ук немец халкының, югары мәдәниятле халыкның фашизм корбанына әверелүендә дә күрә. Нацизм кул астында бу халык кешелеккә каршы чыгыш ясарга мәҗбүр була, азатлыкка һәм гуманизмга каршы юнәлдерелгән корал ролен үти. Җәлил фикеренчә — мондый күренеш немец халкының зур трагедиясе. Бу фикер шагыйрьнең «Алман иленде», «Катыйльгә», «Бүреләр», «Соңгы җыр», «Җырларым» кебек әсәрләрендә һәм башка шигырьләрендә үткәрелә. Шагыйрь гитлерчыларны «кеше буе улашып, исәнәеп»

азык эзләп йөргән ач бүреләр белән чагыштыра, фашистларның ерткычлыгын фаш итеп, «бүреләр бу кадәр үк ерткыч түгелләр» дип яза. Фашизмга хас шушы төп сыйфатларны билгеләгәндә ул сарказм көченнән, халыкның үткен сатирасыннан файдалана, шигъри образлар тудырганда «үлем ялчысы», «тоткыннарның йөрәк итен чукыган козгын», «ана канын, бала канын эчкән вәхши» кебек үзенчәлекле метафораларга, чагыштыруларга мөрәҗәгать итә. Күрүебезчә, фашизмның чын йөзен ачып бирү өчен шагыйрь эстетика категорияләреннән ямьсезлеккә мөрәҗәгать итә. Шагыйрь фашизмны тулысынча җиңү көне турында, әлеге фашист йортының акылдан шашкан хуҗасын кандаладай сытып үтерү көне турында уйлана. Җәлил фашист зинданын «таш капчык» белән, ә гитлерчыларның үлем машинасын—кеше сөягеннән он тарта торган тегермән белән, ә нацист идеологларын «кан эчеп исергән тегермәнчеләр» белән чагыштыра.

«Моабит дәфтәрләре»н һич икеләнми икенче бөтендөнья сугышының героик эпопеясе дип атарга мөмкин. М. Җәлил бу дулкынландыргыч шигырьләрдә корыч ихтыярлы, зирәк акыллы, тормышның иң авыр сынауларына да бирешмәүчән Кеше булып күз алдына килеп баса. Данлыклы Моабит циклында шагыйрьнең эстетик идеалы иң югары формада — җирдәге явызлыкка — фашизмга нәфрәт булып гәүдәләнә.

Муса Җәлилнең сугышка кадәрге чордагы эстетик идеалы әдәби геройларны хезмәттә сурәтләргә омтылуда чагылса, сугыш вакытында исә ул совет поэзиясенең гуманистик принциплары өчен көрәштә, совет кешесенең сугышта чыныккан характерын, югары кешелеклелек сыйфатларын раслауда күренә.

Һәр мәшһүр язучының үз поэтик принциплары, үз әдәби-эстетик дөньясы бар. Моны ачыкламыйча бу әдипләрнең эстетик карашларын, идеалларын аңлау мөмкин түгел. Муса Җәлилнең эстетик принципларын, эстетик идеалының үзенчәлеген ачыкламый торып, шагыйрьнең художество мирасына дөрес бәя бирүе кыен.

«Моабит дәфтәрләре»ндә Муса Җәлил төп фикерләрен бер очракта сәяси образ ярдәмендә, икенче очракта — лирик герой образы аша чагылдыра. Бу үзенчәлек — лирик геройның асылы нидә, аның психологиясе нинди чаралар ярдәмендә ачыла, лирик геройда әдипнең эстетик идеалы ни рәвешле гәүдәләнә? — дигән сорауларның туууына китерә.

Мәгълүм булганча, әдипнең лирик героенда эстетик идеал киңрәк чагылыш таба. Лирик герой образына шагыйрь үткен поэтик фикерләр әйтү теләге белән мөрәҗәгать итә. Шигъри юлларда тормышның мәгънәсен ачып биреп, Җәлил күп патриотларның, антифашистларның, тормышка гашыйк кешеләрнең уй-фикерләрен әйтеп бирде.

Моабит циклында шагыйрьнең эстетик идеалы лирик-фәлсәфи уйланулар аша гәүдәләнә. М. Җәлил өчен, аның әсәрләренең лирик герое өчен үлем һич тә куркыныч түгел. Лирик герой тормышы белән күзгә-күз сөйләшә, Ватан һәм кешеләр язмышы турында уйлана, аңа үпкәсен белдерә сыман.

**Дөнья, сине Ләйлә төсле күреп,**
**Мәҗнүн гыйшкы белән яраттым.**
**Ә син минем керсез йөрәгемне**
**Вәхши этләреңнән талаттың.**

Муса Җәлилнең эстетик идеалы — барыннан да элек шагыйрьнең дөнья матурлыгы, гүзәллеге турында уйланулары. Ватанга мәхәббәт һәм тугрылылыкны җырлау, совет кешесенең намусын олылау, изгелекнең явызлыкны җиңәчәгенә ышанычны данлау. Бередә Р. Бикмөхәммәтовның «Моабит поэзиясенә ачкыч — Бөек Ватан сугышы чорында Муса Җәлилнең үз язмышының халыклар язмышы белән уртаклыгын ачык итеп күрүе», дигән фикере белән килешми мөмкин түгел [1].

Сугышка кадәр үк формалашкан, туган халкың белән бәйләнгән коммунистик эстетик идеалның гәүдәләнүен әнә шуннан чыгып карарга кирәк. Шагыйрьнең иҗатындагы мондый тенденцияне аның «Илдар» һәм «Алтынчәч» әсәрләрендә күрергә була. Бу поэмаларда ук шагыйрь халык массаларының героик характерын, халык тормышының үзенә нигезләнгән шигъри образлар, Ватанны һәр вакыт уяу сакларга әзер торучы Илдар һәм Җик образларын тудыра.

Шагыйрь тарафыннан иҗат ителгән бу образлар «Моабит дәфтәрләре»нең тамырлары бик тирәндә булуын, анда урын алган шигырьләрнең сугышка кадәргеләре белән тыгыз бәйләнештә торуын сөйлиләр.

«Моабит дәфтәрләре» сугыш кырыннан әйләнеп кайтмаган ил улларының сагышын һәм йөрәк әрнүен, мәхәббәтен һәм нәфрәтен, туган җирдән аерылуын, күңел әрнүен үзенә берләштергән бердәм, бөтен бер поэтик системаны тәшкил итә. Тимер чыбык белән уратып алынган концентрацион лагерьларда явызлык белән күзгә-күз очрашкан шагыйрь үлемсез көчкә ия. Ул көч — ялкынлы шигъри сүз дисәк, ялгыш булмас. Җәлилнең тирән мәгънәле фикерләре — шигъри сүзе максатка барып ирешә. Чөнки бу поэтик циклның һәр юлында, һәр образында вәхшилеккә каршы көрәшүче кешенең бөеклеге раслана. Җәлил әсәрләрендә эстетик һәм этик хисләр бергә үрелеп килә. Шагыйрь кешенең иң югары сыйфаты — намус турында сүз алып бара. Беренче карашка, кешенең героик һәм күтәренке халәтенә генә багышланган кебек тоелган юллар шигырьләрдә тагы да зуррак мәгънә ала. Чөнки азатлык кешенең кыюлыгы белән яулап алына, ә кем куркак, кем үз җаны өчен тетрәп яши — шул

[1] Р. Бикмөхәммәтов. Муса Җәлил. М., 1962, 230—231 битләр.

коллыкка төшә. Муса Җәлил кешелек азатлыгын батырлык һәм ныклык белән биргә бәйли, шулай итеп совет халкының җиңелмәслеге турындагы фикерне укучыга җиткерә. Бу фикер бөтен Моабит циклы аша кызыл җеп булып уза. Шагыйрьнең әсәрләре совет кешесенең көчле рухы, аның башкаларга һәр вакыт бәхет китерергә һәм кешелекне фашизм тоткынлыгыннан коткарырга әзер булуы турында сөйли.

Әдипнең эстетик идеалы заманның, җәмгыять тормышының таләпләрен гәүдәләндерә. Шагыйрьнең әсәрләрендә бу таләп сәнгатьчә гомумиләштерелеп бирелә.

Бөтендөнья әдәбияты тарихыннан мәгълүм булганча, чын шигърият һәр вакытта киләчәккә юнәлеш бирә. Аның эмоциональ көч белән, поэтик төсмерләрдә чынбарлыкны, киләчәкне сурәтләү мөмкинлеге бар. Мисал өчен Бөек Ватан сугышының иң кызган чорында язылган «Чәчәкләр» шигырен алыйк. Шагыйрь үз әсәрендә бөтендөнья балаларын чәчәкләр күкрәп үскән яшел болыннарга чакыра. Ул чәчәкләрнең поэтик образын балалар образы белән чагыштыра. Аның фикеренчә, чәчәкләр, фашизмны җиңү символы буларак, бөтен дөньяга сибелгән.

«Моабит дәфтәрләре»н сугыш чорының елъязмасы дип атарга да мөмкиндер. Чөнки Җәлил фашизмны хөкем итүче образлар галереясе тудырды. Аның шигъриятендә бер кадр киноэкрандагы кебек икенчесе белән алышына: ач һәм хәлсез аналарга һәм балаларга фашист автоматы ут ачарга әзер тора. Һич гаебе булмаган кешеләргә исерек майорның яшел күзләре төбәлгән. Һәм бу гаепсез кешеләрне ут яңгыры аяктан ега...

**Алар... Алар җыйнап аналарны,**
**Балаларны кырга кудылар.**
**Казыттылар чокыр, ә үзләре**
**Читтән көлеп карап тордылар...**

Шагыйрь үз фикерләрен калку итеп күрсәтү өчен халык иҗатының якты үрнәкләренә мөрәҗәгать итә: «киштәлдә калын бер иманнең авыр сулап җиргә ауганы», «күк күкрәде кинәт, җил сызгырды», «җир елады кысып тешләрен» кебек образлар һәм метафоралар халык иҗаты байлыкларының Җәлил поэзиясендә чагылуының якты мисалы булып тора.

Җәлилнең фәлсәфи эчтәлектәге программалы әсәрләренең берсе — «Иман» шигыре. Монда шагыйрьнең эстетик идеалы дөньяның мәңгелеген, яхшылыкның, гаделлекнең һәм гүзәллекнең тантана итүен раслауда чагыла. Безнең алга колач җитмәслек мең еллык мәгърур иман образы килеп баса. Яшендәй ашыгып еллар узган, өермәләр бөтерелгән, ә ул һаман да исән, һаман да нык, кешеләргә ләззәт бирә, аның тормышын матурлап һәм бизәп тора. Мәгърур иман күпләрнең серен үзендә саклый, ул кешеләрнең бәхетле мизгелләрен күргән, шатлык җырын ишеткән, аның каршында күпләр йөрәк серен ачкан. Шагыйрь кеше гомеренең мәңге дәвам итүен, үзе үлгәч тә Җирдә аның гүзәл эшләре калуы турында сөйли.

**Җирдә кеше торса торсын,**
**Эзе калсын тирән булып.**
**Үзе үлсә, эше калсын**
**Мең яшәрлек иман булып.**

«Бер үгет» шигыре үзенең идея эчтәлеге белән «Иман» шигыренә бик якын. Бу әсәрләр Муса Җәлил поэзиясенең төп эстетик программасын, шагыйрь тормышының төп мотивын, максатын чагылдыра. Ул кешенең тормыштагы урыны, роле турында, яшәү мәгънәсе хакында тирән уйлана, фашист тоткынлыгында булу хәле белән килешә алмый. Тоткынлыкның кыен шартлары шагыйрьдәге оптимизм утын сүндерә алыр кебек тоелса да, «Авыру сызмалар», «Соңгы җыр», «Гөл кәбере» кебек шигырьләрдә оптимистик рух өстенлек итә. Сугышчы образы булсынмы, табигать картиналары сурәтләнсенме, алар бер генә максатка, совет кешесенең җиңелмәслеген һәм Ватаныбызның какшамас куәтен раслауга хезмәт итәләр.

Табигать үзе дә кешене яхшы аңлый кебек. Ул җирдә ни барганын күзәтеп, белеп тора сыман. Җәлил фикеренчә, хәтта елгалар, хәтфә болыннар туфрагыбызны таптап йөргән дошманга каршы чыга кебек. Шагыйрь әсәрләрендә табигать җанлы итеп тасвирлана, Җәлилнең йөрәк җылысы белән сугарылган шигъри юлларда әйтерсең лә табигатьнең җанын, аның хис итүен, елавын тоясың. Чөнки табигать белән кеше һәрчак бергә, алар бер-берсен аңларга тиеш! Шагыйрь үз фикерен түбәндәге мисал белән дәлилли. Явыз дошманны илебез чикләреннән куып, курку белмәс совет сугышчысы алга ашкына. Сандугач, кыю егетне алда торган куркыныч турында искәртеп, агуланган чишмәдән бер тамчы су эчә дә һәлак була, шулай итеп, ул солдатның гомерен саклап кала. «Сандугач һәм чишмә» исемле балладаның идея-эстетик эчтәлеге әнә шундый. Табигать картиналарын оста сурәтләп, сандугач һәм чишмә образын тудырып, шагыйрь символик рәвештә җиңү тантанасын данлый.

«Моабит дәфтәрләре»н сугыш чорының фаҗигале эпопеясе дип әйтергә мөмкин. Фаҗигалелек — бик күп илләрдәге антифашистларның, совет әсирләренең һәлак булуында гына түгел, бәлки фашизм тарафыннан агуланган немец халкының кешелеккә каршы юнәлдерелгән «коточкыч коралга әверелүендә» дә чагыла. Җәлил фикеренчә, фаҗигалелек дөнья кешеләренең бер-берләрен аңламый башлауларында, немец халкының йөрәге кешеләргә үлем алып килүче бомбардировщикларга, сугыш коралына, танкларга, концентрацион лагерьларга әйләнүендә. «Фаҗигалелек турында» дигән китап авторы Ю. Борев Җәлил поэзиясендәге фаҗигалелекне үлемсезлекнең гәүдәләнеше дип карый: «Совет трагедиясенең герое — җир кешесе һәм чын мәгънәсендә үлемсезлек кешесе. Ул үз хезмә-

те һәм көрәше, халыкка хезмәт итүе, аның хакына теләсә нинди корбаннарга да барырга әзер булуы белән үлемсез данга һәм онытылмас истәлеккә лаек»[1]. Фикерләрен раслау өчен автор Җәлилнең «Җырларым» шигырен китерә. Шулай да Ю. Боре в фаҗигалелекне Җәлилнең фаҗигале язмышы белән, аның үлемсез батырлыгы белән генә бәйләп «Моабит дәфтәрләре»ндәге фаҗигалелекнең асылын тулысынча чагылдырып җиткерә алмый әле. Фаҗигалелек, югарыда әйтеп үтелгәнчә, бу поэтик циклда киңрәк мәгънәдә — немец халкының фаҗигасе өчен янып-көю, уйлану мәгънәсендә дә яңгырый.

**Шулай укмы Карл Либкнехтны,**
**Һәм Розаны буып үтергән**
**Бурзайларың бер көн алып чыгып,**
**Ыргытырлар мине күпердән!**

«Моабит дәфтәрләре»ндәге фаҗигалелек гади немец кешеләренең фашист машинасы тарафыннан вәхшиләргә һәм ерткычларга әйләндерелүләреннән дә гыйбарәт.

Эстетик идеал Җәлилгә гүзәллек белән ямьсезлекнең көрәшен тулырак чагылдырырга ярдәм итә, матурлык һәм изгелекнең кара көчләр белән көрәшен тулырак яктыртырга, кешеләрнең рухи яктан бай булган эчке дөньясын тирәнрәк ачып бирергә мөмкинлек бирә. Җәлилнең тоткынлыкта язылган шигырьләре көрәш идеясе һәм яшәүнең мәңгелеген раслау белән сугарылган. Бу әсәрләрнең нигезендә мәхәббәт һәм нәфрәт хакында, намус һәм вөҗдан турында уйланулар ята.

М. Җәлил шигырьләрендә эстетик идеал, гомумән алганда, көрәш идеалы булып күз алдына килә. Күптән билгеле булган гади әйберләр дә М. Җәлил шигырьләрендә бөтенләй яңа төсмер, үлемсезлек билгесе алалар. Мисал өчен «Яулык» шигырен алыйк. Беренче карашка, сүз егеткә сөйгән кызы бүләк иткән яулык турында гына барган кебек. Ләкин бу шигырьнең эстетик эчтәлеге бөтенләй башка. Менә шушы гади генә яулык кешеләр язмышы турында ачык сөйләүче, ил азатлыгы өчен көрәшне данлаучы символик шигъри образга әйләнә. Шулай итеп, көрәш идеалы азатлык идеалы белән тыгыз рәвештә үрелеп килә. Аларны без Җәлилнең «фашист төрмәләрен дер селкеткән» шигырьләрендә күрәбез.

**Кипер ул көн, халык хөкем итәр,**
**Карар булыр кискен һәм кыска.**
**Каным белән язган соңгы җырым,**
**Бул гаепләү акты фашистка.**

Мәгълүм булганча, эстетик идеал мәсьәләсе турыдан-туры шәхес концепциясе, герой проблемасы белән бәйле. Кешене киң планда сурәтләү, геройның эчке дөньясын, аның башка кешеләр бәхете өчен көрәшен ачып бирү — сугыш чоры әдәбиятының төп, үзәк мәсьәләләреннән берсе булды. Заман героен тасвирлап, аның эчке халәтен ачып, совет әдәбияты, табигый ки, гуманизм, кешелеклелек проблемаларын алга куя.

Сугышка кадәр үк инде күренекле совет шагыйрьләренең берсе булып танылган Җәлилне, иң беренче чиратта, кешелек язмышы борчый һәм ул фашизмга каршы юнәлдерелгән гуманистик принципларны үткәрүне үзенең төп максаты итеп куя.

Сугыш чоры әдәбияты асыл һәм эчтәлеге белән антифашистик әдәбият булды. Бу елларда бөтен совет әдәбияты вәхшилеккә, кешелексезлеккә каршы чыкты. Совет әдәбиятының гуманистик пафосы, барыннан да элек, язучыларның эстетик идеаллары белән бәйләнгән иде. Геройны сурәтләүнең югары принципларында без Җәлилнең гуманистик поэзиясенең эстетик үзенчәлеген күрәбез. Ул поэтик образлар системасында: чагыштыру, метафора, гиперболаларда һәм сәнгатьчә гомумиләштерүдә гәүдәләнә.

Җәлил шигърияте фашизмның ерткычлыгын, вәхшилеген гади рәвештә сурәтләп чыгу, кеше газапларын тасвирлау белән генә чикләнми, ә киләчәккә мөрәҗәгать итүче, кешелекне мәңге тыныч яшәргә өндәүче тирән эстетик система булып күз алдына килеп баса.

**Әкияттәге серле йомгак булып,**
**Җырым калды сүтелеп юлымда.**
**Сез табарсыз килеп шушы эздән**
**Мине соңгы йөрәк җырымда.**

Шигырьнең соңгы юллары укучыны үзенә аеруча җәлеп итә. Алар безне Җәлилнең бөтен поэзиясен игътибар белән өйрәнергә өндиләр, шагыйрьнең героик һәм эстетик идеаллары чыганагы кайда булуы турында уйланырга мәҗбүр итәләр. Бу сорауга җавапны без әдипнең сугышка кадәрге иҗатыннан табабыз. Шагыйрьнең әдәби-тәнкыйть мирасына мөрәҗәгать итү безгә аның эстетик принципларын ачыграк аңларга ярдәм итә. Утызынчы еллар ахырында язган бер докладында Җәлил героик характердагы әсәрләрнең актуальлеге турында сөйли: «Минин һәм Пожарский», «Александр Невский», «Иван Сусанин» кебек тарихи әсәрләрнең актуальлеге аларның төп идеяләре кыйммәтендә — халык патриотизмында, героизмда, үз Ватаныңа мәхәббәттә һәм бирелгәнлектә гәүдәләнә».

«Моабит дәфтәрләре»ндә Җәлил шигъриятнең рухландыручы көченә күп тапкырлар мөрәҗәгать итә. Шагыйрь иҗат кешесенең асылы, бурычы, вазифасы турында уйлана. Аның фикеренчә, чын сүз остасы түбән зәвыклы, сәнгать дәрәҗәсе ягыннан йомшак шигырьләрне дөньяга чыгармаска тиеш. Әдипнең сәнгатькә карашын билгеле торган әсәрләренең берсе — ул «Ша-

[1] Ю. Борев. Фаҗигалелек турында. М., 1961, 209 бит.

гыйрь» шигыре. Анда ачык шигъри буяулар белән язучының илһамлану халәте һәм иҗади рухлану мизгеле тасвирлана.

**Төн утырып шагыйрь шигырь язды,**
**Ак кәгазьгә тамды яшьләре.**
**Тышта давыл иде; бертуктаусыз**
**Күк күкрәде, яшен яшьнәде.**

М. Җәлилнең юмористик һәм сатирик шигырьләре дә эстетик яктан гаять үзенчәлекле. Фашист концлагерьларындагы авыр, кешелексез шартларда яраланган күңелен шагыйрь әйтерсең лә юмор белән дәвалый. «Моабит дәфтәрләре»ндәге «Сыра залында», «Хәдичә», «Томаулы гыйшык», «Гашыйк һәм сыер», «Тозлы балык», «Табут» кебек әсәрләр М. Җәлилнең соңгы сулышынача егерменче һәм утызынчы елларда ук ныгып урнашкан идея-эстетик принципларына тугры булып калуын раслый. Шулай итеп, шагыйрьнең юмор угы барыннан да элек тормыш тантанасын раслауга юнәлгән һәм совет кешесенең җиңелмәс рухына мәдхия булып яңгырый. Җәлил юмор һәм сатирага юкка гына мөрәҗәгать итми. Моның белән ул фашизм алдында, төрмә алдында үзенең көчле рухлы булуын күрсәтә, яшәешнең мәңге дәвам итәчәген раслый.

«Моабит дәфтәрләре» Муса Җәлилнең иң тирән эчтәлекле, фәлсәфи уйлануларга бай поэтик циклы булуын басым ясап, билгеләп үтәсе килә. Бу данлыклы шигъри цикл Җәлилне бөтен дөньяга танылган Шандор Петефи, Юлиус Фучик, Федерико Гарсиа Лорка кебек әдипләр белән бер дәрәҗәгә куя. Анда урын алган әсәрләр ачык характеры һәм тирән хисләргә бай булуы белән аерылып тора.

М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»ндәге югары эстетик идеал киләчәккә чиксез өмет, ышаныч булып яңгырый. Шагыйрь фашизмның тар-мар ителәчәген алдан күреп тора, җир шарында тынычлык урнашачагын җаны-тәне белән тоя. Үзенчәлекле бу шигъри циклның төп пафосы әнә шунда. Әдипнең эстетик идеалы илебездә социалистик җәмгыять төзү барышында, марксизм-ленинизм тәгълиматы йогынтысында кристаллдай ныгый.

Икенче бөтендөнья сугышы тәмамлануга утыз елдан артык вакыт үтте. Бу вакыт эчендә фашистик элементларның яңа ерткычлыклары мәгълүм булды. Менә шуның өчен дә фашизмның социаль һәм сыйнфый тамырларын, аның гуманизмга каршы характерын ачып бирә торган Җәлил шигърияте бүген дә актуаль һәм әһәмиятле булып кала. М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» Юлиус Фучик, Федерико Гарсиа Лорка, Хо Ши Мин әсәрләре кебек үк кешелекне уяулыкка, планетада яңадан-яңа җинаятьләр эшләргә омтылучы фашизмга каршы көрәшкә өндиләр.

# КҮЗ КАРАСЫ КЕБЕК КАДЕРЛЕ

Яңа әсәр «Казан утлары»нда басылып чыгуга беренче шатлыклар да үтеп китте. Язучыны инде бүтән — борчылулы уйлар тулысынча билəп алды: укучы әсәрне ничек кабул итәр, әдәби җәмәгатьчелек, тәнкыйтьчеләр нәрсә әйтер?

Тәнкыйтьчеләрдән өсәргә җитди бәя бирүне тиз генә көтмисең, вакытлары да кысан, уйланырга да кирәк. Алар бит үз әдәбиятың манарасыннан гына карамый, бөтен совет әдәбиятына күз ташлый, гомуми манзарага синең әсәр нинди яңалык өсти, алга китеш бармы, әллә бер урында таптану гынамы?

Гади укучыга исә бирәү дә, фәлән әйберне укып чыгып фикереңне яз, дип әйтми, үзе теләп укыса укый, ошаса яки ошамаса да — күңеле җилкенсә — хат язар өчен кулына каләм ала, я редакциягә, я авторына үзенең фикерен әйтә. Ул тәнкыйтьче исеменә дәгъва итми, киресенчә, борчыганы өчен гафу үтенә. Укучы хатының кыйммәте дә, самимилеге дә шунда.

Дөньяда һәр нәрсә, шул исәптән укучы да үзгәрә. Хәзерге китап укучыны моннан егерме биш-утыз ел элекке укучылар белән чагыштырсаң, аерма зур. Ул үскән, җитдиләнгән, дөньяга, әдәбиятка карашы тәпле, ул үз әдәбияты һәм башка әдәбиятлар хәзинәсе белән дә таныш, кирәк икән, чагыштырып та карый, — кыскасы, ул киң мәдәниятле укучы.

«Агыла болыт» романы журналда басылуга әле берничә генә ай үтүгә карамастан, редакциягә дә авторның үзенә дә байтак кына хатлар килде. Роман үзенчәлекле, аның төп геройлары, башка романнардагыча гомумиләштерелгән түгел, ә тормышта чыннан да булган кешеләр — ул Муса Җәлил һәм җәлилчеләр хакында сөйли. Алар турында моңарчы да бик күп шигырьләр, поэмалар, пьесалар, повестьлар, хәтта роман да дөнья күрде. Укучыларның беренче сораулары да шуның белән бәйләнгән: бу турыда яңа әсәр язарга керешкәнче автор ничек кабатланудан курыкмады икән, бер үк кешеләр, җитмәсә, нигез вакыйгалары да бер үк бит? Авторның нинди яңа дәлилләре булган, укучыны нәрсә белән җәлеп итәргә уйлаган?

Укучыларның беренче хатларына караганда, бөтенләй юкка эшләмәгәнмен икән. Шул турыда бераз тулырак тукталсам — зыян итмәс шикелле. Бәлки укучылар өчен дә, әдәбиятчылар өчен дә кызык булыр.

Иң элек әсәрнең жанры турында. Мин аны «тәмамланмаган роман» дип куйган идем. Редакция моның белән килешмәде, димәк, язып бетермәгәнсең дип уйларлар, хәлбуки язып бетергәнсең, вакыйгалар да тәгәлләнгән. Шуңа күрә, мөгез чыгарма, роман гына дип куй, диделәр. Мин күндем, ләкин эчемне һаман нәрсәдер тырный. Күрәсең, бу турыда безнең башка язучылар да уйлана. Әмирхан Еники «Кечкенә роман» терминын кулланган. Ләкин күләм зурлыгы яки кечкенәлеге терминның асылын хәл итми. Укучы (Ташкенттан М. Якупов) «тарихи роман» дип тәкъдим итә. Мин бу тәкъдим белән дә килешеп бетә алмадым. «Тарихи роман» вакыйгаларын гаять киң ала, геройларны шул яссылыкта тасвирлый, ә мин фактта бер төркем татарларны гына алганмын, алар тормышның да бер генә ягын — әсирлекне генә күрсәтү белән чикләнгәнмен. Романда, нигездә, реаль кешеләр хәрәкәт итә.

Мин Мусаны да, Алишны да, Әхмәт Симайны да күреп беләдер идем. Бу язучының эшен бер яктан җиңеләйтә, икенче яктан кыенлаштыра, син үзеңне мәгълүм рамкаларда сизәсең, юк, бу болай булмаган, дип әйтүләре мөмкин бит. Мондый очракта реаль чынбарлык белән иҗат фантазиядән башка сәнгать әсәре юк — ни микъдарда яраша ала? Иҗат фантазиясе, ахыр килеп, әсәрнең үзәгенә — гомумиләштерүгә барып тоташа бит.

Әхмәт Симай минем якташым булса, Муса Җәлил әдәби остазларымның берсе иде. Мин ул җитәкчелек иткән әдәби түгәрәктә беренче иҗат адымнарымны башладым. Аннары, Муса белән киңәшеп, белемемне күтәрер өчен Әдәби институтка укырга кердем. Фронтта чакта, Муса турында хәвефле хәбәрләр ишетелә башлагач, мин, аның күп шәкертләреннән берсе, үз фикеремне әйтергә карар иттем. Ләкин ул чакта Мусаның кечкенәдән көрәш юлына басканлыгын, Комсомол Үзәк Комитетында эшләвен (журнал редакторы булып), күренекле шагыйрь икәнен белсәм дә, безгә әле Моабит дәфтәрләре дә, дошманның үз өнендә алып барган батыр көрәше дә, җәлилчеләр галереясе дә — берсе дә мәгълүм түгел иде. Мин бары тик Мусаның намуслы булуы, көрәш традицияләренә тап төшермәве, патриот булып калуы турында гына уйладым. Ә чынбарлык күп мәртәбәләр катлаулырак, фаҗигалерәк булган, Мусаның шагыйрьлеге дә, фидакарьлеге дә безнең гади үлчәүләргә сыймый башлаган.

1944 елның язында ике фронт — Волхов һәм Карелия фронтлары штаблары бергә кушылды. Мусаның башта Волховта булганын белә идем. Аннан килгән иптәшләр Волховтагы хәлләр турында гаҗәп күп нәрсәләр сөйләделәр, Карелия фронтына бик нык охшавын әйттеләр. Болай булгач, минем эшләр шактый җиңеләя, дип сөендем эчемнән. Ләкин монда мине сагайткан икенче нәрсә дә бар иде: Волховтан редакциядә эшләүче шагыйрь Әхмәт Фәйзи дә килде. Әхмәт Фәйзи — Мусаның якын дусты, ул инде аның турында язмый түзмәс, дип уйладым. Чыннан да, сугыштан соң озак та үтмәде, ул «Җәлил» операсының либреттосын язды.

Җәлил образы бүтән язучыларны да туктаусыз дулкынландырып торды. Шагыйрьнең эзләрен эзләп аның каләмдәшләре күтәрелде. Аларга рус язучылары һәм немец язучылары кушылды. Алар арасында иң элек һәм барыннан да элек мәрхүм Гази ага Кашшафны әйтергә кирәк. Муса Җәлил аңа аеруча ышанган, васыятен дә язма рәвештә аңа җибәргән. Хәзер музейда гына саклана торган бу васыятьне кайта-кайта укыйсың да, бик тирән уйларга чумасың.

Романның беренче караламасы язылып беткәч, Гази абый Кашшафка укып карарга бирдем. Үземне аерата борчыган сорауларга туры җавап бирүен үтендем:

— Романны эшләүне дәвам иттерергәме, әллә архивка салып куяргамы?

— Сезнең Муса Җәлил турындагы хезмәтләрегездән, шулай ук башка әдәбиятчыларның китапларыннан да файдаландым. Сез моңа ничек карыйсыз? Бу ярыймы? Иптәшләр дау күтәрмәсме?

Без Гази абый белән озак сөйләшеп утырдык. Ул бик күп кыйммәтле киңәшләр бирде. Ахырда әйтте:

— Мусалар турында берничә поэма, пьесалар, повестьлар бар, шигырьләрнең, җырларның исәбе юк. Нигә роман бер генә булырга тиеш? Иң яхшысын халык үзе сайлар, ул тарихта калыр. Сиңа сүзем шул: ашыкма. Әйе, ашыкма! Минем хезмәтләремнән файдалангансың икән — бик яхшы. Мин кешеләр укысын, кирәк чагында файдалансын дип яздым, — диде.

Ул чакта мин Гази абыйның «ашыкма» дигән сүзенең тулы мәгънәсен бик үк төшенеп бетмәдем, шул турыда кайтарып сорадым. Бу юлы да ул нигәдер туры җавап бирмәде. Мине иң четрекле мәсьәлә борчыганга, үзе турындагы образга аның мөнәсәбәте ничек, аны үстерергә яки бөтенләй төшереп калдырырга кирәкмиме?

Ул озак уйланды, аннары сорады:

— Аның исеме ничек әле?

— Мирзаһит!

— Ә, Мирзаһит...

Гази абыйның үз исеме — Миргази. Монда ике уйларга урын юк шикелле.

— Бу автор ихтыяры, мин бер нәрсә әйтә алмыйм, — һәм кич буе бу мәсьәләгә әйләнеп кайтмады.

Гази абый гаҗәп тыйнак кеше иде. Бәлки үзенең сәламәтлеге турында уйлагандыр, бу вакытта аның гомере күп калмаган булган, башкалар берни сизмәсә дә, үзенә сер булмагандыр инде. Моны мин Гази абый бер дә көтмәгәндә безнең арадан мәңгегә китеп баргач, бик яхшы төшендем, үземнең саксыз сорауларым өчен үкендем. Ләкин аның «Мирзаһит» исеменә кискен каршы килмәвен уйлап, соңыннан да үзгәртми калдырдым.

Инде укучылардан килгән хатларны карап чыгыйк. Мусаны һәм җәлилчеләрне күреп белгән, аларның фидакарь эшләренә турыдан-туры катнашкан кешеләрнең хатлары авторны беренче чиратта кызыксындыруы һәркемгә аңлашыла торгандыр. Шуңа күрә Гарәф Фәхретдиновтан хат барлыгын белгәч, бик шатландым.

Гарәф Фәхретдиновның (әсирлектә ул Дим Алишев) хатын тулысынча китерергә кирәк, ул Муса Җәлилнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүче күпләгән укучыларга да, әдәбиятчыларга да кыйммәтле чыганак булырдыр.

«... Мин сезнең «Агыла болыт» романыгызны укып чыгып бик шатландым, әйтерсең яңадан шул иптәшләремне күрдем. Аларны гына түгел, Гази Кашшафны да кабат күргән, сөйләшкән кебек булдым. Роман бик матур, документальный язылган... Ләкин минем өчен бик кыска тоелды. Шуның белән бергә, әсәрне аерым китап итеп чыгарганда бераз төзәтебрәк язсагыз иде. Зиннәт Хәсәнов кара түгел, кара-сары чәчле, сарысы ялтырап тора торган. Аннан соң ул җырлый белми иде. Ул капеллага «язучы» итеп алынды. Абдулла Баттал да шулай ук — ул «шагыйрь» итеп алынды — аның аяк бармаклары юк, үкчә белән йөргән шикелле йөри иде. Үз диалекты белән сөйләүчән.

Капелладагы «артистлар»ның күбесе күрсәтелмәгән. Аларның да күбесенең заслугасы бар бит. Мисал:

1. Барабанда — Сәмирханов (кыз булып биюче дә).
2. Чәлдермәдә — Суликов (ул безнең капелла мулласы).
3. Гитарада — Рәшит Ибраһимов, Гариф Маликов, Борис Попов, Гробников.
4. Скрипкада — Кәрим Ходжаев, Дашкаев, Абдулла Турбышев, Розенштейн.
5. Аккордионда — Нәҗип Гәрәев (безнең старшина).
6. Баянда — Хамиев (ул рәсемче).
7. Хромкада — Адыев.
8. Мандолинада — Рушат Хисаметдинов, Абдерәзак Сабитов, Харис Юсупов, Җомга белән Орчык (исем-фамилияләрен онытканмын. Башкириядән).
9. Җырчылар — Дим Алишев, Салихов, Байдамшин.
10. «Язучылар» — Гайнан Курмашев, Зиннәт Хәсәнов.
11. «Шагыйрь» — Абдулла Баттал.
12. Жонглер — Абдулла (фамилиясе онытылган).
13. Курайчы — Салаватов.
14. Капельмейстер — Әхәт Аллагулов.

Моннан башка агитаторлар — Сәйфелмөлеков, Мичурин, рәсемче Шамбазов һ. б.

Шуларның хәзерге көндә җидесе исән; алар белән Казан нигәдер кызыксынмый. Күбесе үлгән, калганнары билгесез. Шуларның үлгәннәре: Сәмирханов, Рәшит Ибраһимов, Гариф Маликов, Хамиев, Байдамшин, Гайнан Курмашев, Абдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнов, Абдулла (жонглер), Фуат Сәйфелмөлеков һәм Мичурин.

Исәннәре — Кәрим Ходжаев, Абдулла Турбышев, Нәҗип Гәрәев, Рушат Хисаметдинов, Абдерәзак Сабитов, Гарәф Фәхретдинов (Дим Алишев), Җәүдәт Шамбазов. Муса турында язучылар бу исән калган капелла кешеләре белән берсе дә әңгәмәләшмәде, шуның өчен йомгакның очын берсе дә таба алмадылар. Моннан соң йомгакның очы табылыр дип ышанам.

Г. Фәхретдинов (Дим Алишев).

13.3.78 ел, Ташкент.»

Гарәф Фәхретдиновның икенче хаты да бик әһәмиятле. Исән калган капеллачылар белән Язучылар союзында бер очрашу үткәрсәләр бик яхшы булыр иде, ди. Минемчә дә, мондый очрашуның кирәклеге көн кебек ачык. Гарәф Фәхретдиновның

борчылуы урынлы. «Муса белән бергә җырланган җырларны нотага салдырып Казанга җибәрергә җыенабыз» диюе дә шатландыра. Меңләгән укучылар ул җырларны ишетсәләр — Мусага һәм җәлилчеләргә мәхәббәтләре тагын да арта төшәр иде.

Менә Оренбургтан Һибәтулла Таналин хаты. Ул Мусаның «Хөсәения» мәдрәсәсендәге классташы, дусты, хәзер укытучы-пенсионер. Аның хатында мондый юллар бар:

«...Казан утлары»ның быелгы 1,2 саннарында Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил, җәлилчеләр һәм аларның турылыклы дусты Гази Кашшафның якты истәлегенә багышланган «Агыла болыт» исемле әсәрегезне бик игътибар белән әкренләп укып чыктым. Муса Җәлил һәм аның көрәштәш дуслары турында тагын бер әдәби китап чыгуына бик куандым. Әсәр миңа ошады. Мусаның көрәштәшләренең әсирлектәге патриотик эшләре, аның нәтиҗәләре һ. б. турында тәфсыйллы мәгълүматлар өстәлде. Мәрхүм галим Мирзаһитның (Миргази Кашшафның) фидакарь хезмәте турында ихтирам белән кабаттан искә алып үттем...

«Казан утлары» журналының подписчиклары, китапханә укучылары бу әсәрне кызыксынып, яратып укырлар дип ышанам, әдәбиятчылар да игътибарсыз калдырмас дип уйлыйм...

Башкортстанның аксакал әдибе мәрхүм Сәгыйть Агиш: «Муса турындагы һәрбер истәлек кенә түгел, һәрбер аваз да бик кыйммәтле», — диган иде.

Үзенең битләрендә «Агыла болыт»ны игълан итүе өчен «Казан утлары» журналына да рәхмәт әйтәбез».

Башкортстаннан хат язучы колхозчы, коммунист Әмир Мөлеков та әсәрне бөтен гаиләсе белән яратып укып чыгуын әйтте. «Әйе, ди ул, Муса Җәлил турында күп китаплар чыкты, ә сезнең романыгыз шуларны тагы да тулыландыра төште, батыр Җәлил турында бик күп нәрсәләр ачыкланды. Роман җиңел укыла, халык әйтемнәре үз урынында дөрес кулланылган. Кире образлар да төшеп калмаган, ышандырырлык...

Олы җанлы шагыйрьне хөрмәт итеп, аның үлемсез батырлыгына сокланып, улыбызга да Муса дип исем куштык. Хәзер ул сигезенче класста укый инде, укуударнигы. Романыгызны да укып чыкты. Безнең шәхси китапханәбездә Муса Җәлил турында истәлекләр, китаплар бар. Муса Җәлил шигырьләрен гаиләбез күбесен яттан белә...»

Бу хат бер үк вакытта бүгенге колхозчы гаиләсенең рухи йөзен дә бик яхшы күрсәтә. Моңа ничек шатланмыйсың!

Алабугадан укытучы-пенсионер Маһинур апа Фәйзуллина да романны дулкынланып укып чыгуын яза. «Җәлилчеләрне өйрәнү тарихына гүзәл бер сәхифә өстәлгән» ди. Романда Гази Кашшафка зур урын бирелүен дә дөрес дип таба. Аңа романда немец антифашисты бирелүе ошаган. «Роман аз сүзле, күп мәгънәле яңа фактлар белән баетылган. Безгә, ди Маһинур апа, Мусаны күреп белгән кешеләргә, әсәрне тыныч кына уку мөмкин түгел, йөрәкне тетрәтә. Мин Алишны да кичке институтта укыткан идем. Каршы өстәл янында утырган кыяфәте әле дә күз каршымда...»

Казаннан укытучы Илсөяр Сункишева Абдулла Алишны «елак» итеп күрсәтү белән һич тә килешмәвен яза. (Вустрау лагеренда Муса белән сөйләшүен күз алдында тота.)

Алиш күренекле балалар язучысы, укучы балалар арасында бик хөрмәтле кеше. Аңа ачыграк бәя биреп китәргә кирәк дип уйлыйм.

Мин Алишны күреп беләм. Аны елак итеп күрсәтү уемда да юк иде. Тормышта шундый чаклар була, коры ихтыярлы кешеләрнең күзләреннән дә яшь чыга. Күз яше һәр очракта да көчсезлек, мескенлек билгесе түгел ул.

Мин Алишның бөтен тормышын язуны бурыч итеп куймадым (шулай ук башкаларның да), бәлки аның иң авыр, иң фаҗигале, иң батыр чорын гына алдым.

Вустрау лагеренда Муса белән сөйләшкәндә Алиш елый, шуңа күрә ул көчсез, мескен булып тоела дисез. Моны бит сугышны бөтенләй күрмәгән кешенең генә әйтүе мөмкин. Алиш явыз дошман алдында еламый. Дошманнар белән бәрелештә ул — корыч, ул алардан курыкмый, алар алдында йомшаклык күрсәтүгә караганда үлемне мең мәртәбә артык күрә. Хәтерләгез төрмәдән Шәфи Алмаска язган хатын! Менә ватандашы алдында күз яшьләрен тыя алмый. Ул Туган иле өчен, бик аз су-

гышып калуы өчен әрни, балалары, туганнары, ярты юлда өзелгән иҗаты өчен әрни. Бу йомшаклык та, мескенлек тә түгел.

Мин Алишны плакат герое итәргә теләмәдем, бигрәк тә балалар алдында ялганчы булудан сакландым. Ихтимал, теләгемне әсәремдә әйтеп җиткерә алмаганмындыр, тышкы билгеләргә — күз яшьләренә — артыграк урын биргәнмендер. Әгәр шулай икән, әсәрне аерым китап итеп чыгарганда ул ягын кайтып карармын.

Мәскәү өлкәсе Воскресенск шәһәреннән килгән хат безнең кайсыдыр редакциягә адресланган булган. Бирегә бөтенләй икенче кул белән минем фамилияне өстәгәннәр дә Язучылар союзына җибәргәннәр. Конвертта хат-фәлән юк, «Коммунист» газетасыннан бер мәкалә кисеп куелган. Мәкаләдә тиздән Воскресенск шәһәренең 40 еллык юбилее булачы әйтелеп, шәһәрнең истәлекле урыннары саналган. Бер җиренә билге куйганнар:

«Стандартная урамы. Бирегә 1936—1940 елларда шәһәрнең «Коммунист» газетасының җаваплы секретаре журналист Ә. С. Симаев яшәде. Сугыш елларында десантчы-разведчик, 250 нче һава десанты полкының рация начальнигы, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең Берлин подпольесында фашистларга каршы көрәште. 1944 елның 25 августында Берлинның Плетцензее төрмәсендә гитлерчылар тарафыннан гильотинада җәзалап үтерелгән».

Белүчеләрдән Әхмәт турында материал җибәрү сорала. Мин кыска гына мәкалә яздым.

1936—1938 елларда Мәскәүдә Муса Җәлил җитәкләгән әдәби түгәрәк утырышларында без Әхмәт Симай белән еш очраша идек. Түгәрәк татар китапханәсе каршында эшләде (Кече татар тыкрыгы).

Әхмәт шигырьләр, мин хикәяләр яза идем. Без Әхмәт белән күрше авыл малайлары: ул Яңа Аллаголдан, мин — Иске Аллаголдан, аралары 2—3 километр гына. Руслар Яңа Аллаголны Усть-Рахмановка дип атыйлар (Мордва АССР).

Ул чакта без яшьләр, бераз беркатлырак идек, барыбыз да шигырь язып маташа. Ә шигырьләребез бары тик Такташча гына булсын, башкасы безгә кирәкми. Шагыйрь һади Такташ безнең якныкы, моның белән без чиксез горурланабыз, аның мишәрчәләп җибәргән сүзләрен кычкырып кабатлыйбыз.

Бәхетебезгә, безнең җитәкчебез Муса Җәлил яшьләргә бик игътибарлы, булачак язучыларны тәрбияләү эшенә зур әһәмият бирә, телебезне һәр вакыт төзәтә иде.

Әхмәт русча да язгалый иде. Күрәсең, татарча белүенең чамалырак икәнен үзе яхшырак төшенгәндер. Әмма поэзия белән мавыгуы җитми иде. 1939 елда ул Мәскәү педагогия институтының әдәбият бүлегенә читтән торып укырга керә. Минемчә, поэзия аның күңелен, гомумән, баетып кына калмаган, кыю сугышчы булырга да өйрәткән — ул радист, разведчик-десантчы, ә разведчиклыкка, бигрәк тә десантчылыкка теләсә кемне алмыйлар инде.

Подпольеда аның холкы тулысынча ачыла, чиксез кыюлык разведчикның гаять сизгер һәм үткен акылы белән бергә кушыла. Гитлер гестапосы никадәр яхшы әзерләнгән, тәҗрибәле булмасын, совет кешесенең җанына үтеп керә алмый. Әхмәт гитлерчылардан өстен чыга, алар аңа «политик яктан ышанычлы» дип кәгазь бирәләр, герман җирендә ирекле йөрергә рөхсәт итәләр, ул хәтта Советлар Союзының вакытлыча оккупацияләнгән җирләренә барып кайта, «Идел-Урал»ның махсус радиокорреспонденты буларак, фашист министры Розенбергтан интервью ала, дөньяда булмаган «Идел-Урал» дәүләтенең яңа пешкән «президенты» Шәфи Алмас өенә кереп йөри.

Хыянәтчеләр аркасында гестапо яшерен оешманың эзенә төшеп, Муса Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен кулга алгач та Әхмәт Симаев, башка җәлилчеләр кебек үк, коелып төшми, гестапоның коточкыч казематларында үзенең антына, Туган иленә турылыклы булып кала, сыгылмас көрәшчеләр кебек, башын югары тотып, гильотинага атлый...

Яңадан хатлар актарам. Күп уңай хатлар арасында әсәрне бөтенләй кире каккан да килеп чыкты. «Аны да игътибар белән укыдым. Укучыларның төрлесе бар бит, барысы да бер төсле уйламый. Бу әсәр «Муса образын алга таба илтү түгел, ә артка таба өстерәү булып чыккан, — ди хат авторы. — Нигә кирәк булды икән әлегә кадәр әйтелгәннәрне кыскарак итеп кабатлау».

Бу хатны Әлки районыннан Ф. Хәйруллин язган. Ахырда тагын өстәп куйган. «Казан утлары» редакциясе безнең ялкынлы Мусабызны кечерәйтеп күрсәтергә ничек юл куйды икән?»

Мин бу иптәшкә хат язмадым, хәзер дә аның белән бәхәсләшеп тормыйм. Нигә? Роман кадәр роман аңа берни әйтмәгән икән, бер-ике битлек хат әллә ни өстәмәс. Берәүләргә бер әсәр ошый, икенчеләргә икенчесе. Язучы үз фикерен үткәрә, ләкин аны һичкемгә мәҗбүри тага алмый.

Ташкенттан Мидхәт Якупов дигән укучыдан ике хат килде, берсен хәтта мәкалә итеп язган һәм берәр редакциягә җибәргәндер дип уйларга кирәк. «Ни өчен язучы тапталган юлдан үтәргә уйлаган? Ул үз алдына нәрсәне этәргеч итеп куйган, аңарда нинди отышлы дәлилләр бар?»

Әсәрне укып чыккач, Якупов үз сорауларына җавап таба, язучының тапталган юлдан бармавын әйтә. Якупов хатында аерым образлар турында бәхәсле урыннар да бар, ул турыда уйлыйм, киңәшәм әле. Ашыгып нәтиҗә ясарга иртә.

Чаллыдан К. Газизов хаты. «Минем аңлавымча, ди ул, бу роман бик үзенчәлекле әсәр, хәзергәчә безнең әдәбиятта кулланылмаган иҗат ысулы белән яңа формада язылган... Романны бер тын белән укып чыктым..»

Күзәтүемне Башкортстаннан Әлфия Буранбаева җибәргән хаттагы юллар белән тәмамларга уйлыйм: «...Миңа 23 яшь, укытучы булып эшлим. Муса Җәлилгә, аның иҗатына һәм батырлыгына гашыйкмын. Яраткан шагыйремнең онытылмас образын тагын да тулырак, ачыграк итеп күз алдына китерергә ярдәм иткән... «Агыла болыт» романы минем күңелемдә әйтеп бетергесез хисләр уятты...»

Бу төрле кешеләр тарафыннан язылган хатларны тагын бер тапкыр күздән кичергәч, янә уйлап куясың, романны китап итеп чыгарганда нәрсәләрне искә алырга кирәклеген ачыклыйсың. Бәлки яңа хатлар да булыр әле. Ә бу хатларның авторларына чын күңелдән рәхмәт әйтәсе килә. Алар минем өчен күз карасы кебек кадерле.

**Г. ӘПСӘЛӘМОВ.**

Июль, 1978 ел.

## Зәки Нури

### ИҢ ЯХШЫ СЫЙ

— Сиңа бик таныш башлыгым килә.
Бүген каршылыйм кичен мин аны.
Ни белән сыйлау яхшырак булыр?
— Иң яхшы сый шул: макта син аны!

### ЕГЕРМЕ БИШ ЯШЕ ТУЛГАН КӨНДӘ

— Күп алдыңмы котлау сәламнәрен?
— Шалтыратты бары кичә әнкәм:
Бер тиен акча ләкин сала алмый...
Ә хәмергә калды... тик биш тәңкәм.

### СЫРАГА ЧИРАТ

Сатучыны бер бик Калын тавыш:
«Ник тутырып салмый?!» дип орыша.
Берәү яклый: «Соңгы мичкә бит бу!..
Һәммәбезгә җитсен дип тырыша!»

### АЧЫК АВЫЗНЫ ТИРГӘҮ

— Я беттеме, егетләр? — дип килде
Бригадир бит эшне санарга.
«Бер савыт бар әле...» — дип ник, тинтәк,
Ачып салдың серне аңарга?!

### ИКЕ ШӘҺӘРНЕҢ БЕР УЛЫ

Сугыш бара. Ул Казанда — итче.
Шигырь яза: «Даешь Берлин!» — дип.
Мәскәүләрдә сыра сата хәзер.
Инде яза: «БАМда тирлим!» — дип.

### КИТАП КИБЕТЕНДӘ

— Тик Бәйрәмнәр календары гына
Сорап керде безгә балагыз:
Ел буена ничә көн икән без
Дәрескә,— ди,— бармый калабыз?!

## КИСӘТҮ

—Сак бул, улым, инде бу никахка
Барган юлда таеп егылма!
— Минем өчен, әни, борчылма син,
Казан түгел бит бу, Бөгелмә...

## ТҮРӘЛЕК ЧИРЕ

Түрдә утыра Тычкан түрә булып,—
Мактауга һәм мактанырга әзер:
— Күсе инде пенсиягә чыкты,
Аның эшен мин башкарам хәзер!

## ӘЛЛӘ, ӘЛЛӘ...

— Әллә инде мин акылсыз,
Әллә инде тәнкыйть юләр:
Мин бер нәрсә дә эшләмим...
Һаман мине тәнкыйтьлиләр?!

## МАКТАЛУЛАР КОРБАНЫ

— Йокым качты. Хәл юк. Аптырата
Маңгаема салкын тир бәреп...
— Күп яттың шул төче мәдхияләр
Бишегендә, кордаш, тирбәлеп!

## КИРӘКЛЕ ТӨШЛӘР

— Төшемдә миңа мамык шәл алдың.
Өнемдә кайчан алырсың икән?
— Син моның өчен тагын бер йоклап
Төшеңдә йөз сум акча күр, иркәм!

## КАТ-КАТ БҮЛЕНГӘН СТАЖ

— Ник алтын туй үткәрмибез, картым,—
Кушылганга илле ел инде?
— Кушылганнан соңгы стажыбыз
Нәкъ... дүрт тапкыр чөнки бүленде...

## ПИЛМӘН КӨТКӘНДӘ

— Ник аш килми һәм ник талон алдык?
Хәтта чыгып качарлык түгел...
— Көтторәләр! Димәк, ач булмасаң
Пилмәннәре ашарлык түгел.

## КОСМИК КОЛАЧЛЫ ЯЛГАН

— Куян атып йөрим, имеш, айда!..—
Шушы бер төш өч төн рәттән керә.
— Кит лә! Айда нинди куян булсын?!
— Алай булгач эт ник айга өрә?

## ЗАРЛАНА ИКӘН БЕР ИШӘК...

Минем тиремнән барабан
Ясап кемнәр какмыйлар!
Культура әһеле итеп
Нигә медаль такмыйлар?

## ТАШЫМЫЙ КАРА...

Никахлашты ике яшь Арслан,
Биш ай инде бергә яшиләр.
Урмандагы барча җәнлек-җанвар
Бүләк ташый, ризык ташыйлар.

## ТАВЫШЛЫ РЕКЛАМА

Кытаклыйлар кайбер яшь Тавыклар
Йомырка да салмас борын хәтта,
Әйтеп гүя: «Гәзит һәм журналлар,
Мактау язмый нигә безнең хакта?!»

## НИҺАЯТЬ... АЛДАНДЫ БИТ

Әйтте Төлке: «Карга ата башлыйм,
Миндә хәзер мылтык бар!» — диде.
Авызындагы сыр кисәген онытып
Шунда тагын карга «Кар-р-р!» диде.

## ЮЛГА ОЗАТКАНДА

— Бик чиста ю, картым, күлмәгеңне,
Хатыны ялкау икән димәсеннәр!
Ир зәвыгын, ир-ат пөхтәлеген
Белеп була хәтта төймәсеннән...

## АПТЫРАГАЧ...

Бер яшь Ишәк көне-төне даулый:
«Китап бир дә, калын китап бир!»
Аптырагач лото тоттыралар:
«Мә, булмаса, шуны бутап бир...»

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ИДЕОЛОГИЯ АКТИВЫ КИҢӘШМӘСЕ

8 июньдә Казандагы Пресса йортында республика идеология активының киңәшмәсе булды. Анда республика газеталары һәм журналларында, нәшриятларда, телевидение һәм радиода эшләүче язучылар, журналистлар, район газеталары редакторлары катнашты.

Киңәшмәдә КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Ф. Ә. Табеев чыгыш ясады. Ул КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карарын үтәү юнәлешендәге бурычларга тукталды, партиянең идеология өлкәсендәге эшчәнлеге өчен бу карарның принципиаль әһәмияткә ия булуын билгеләп үтте.

Әдәбият һәм журналистика — партиябез алып бара торган идеология эшенең аерылгысыз өлеше, аның бик мөһим һәм йогынтылы чаралары. Алар белән эш итүче каләм осталары — язучылар һәм көндәлек матбугат үзәгендә кайнаучы журналистлар өчен КПСС Үзәк Комитетының әлеге карары иҗат активлыгын тагын да үстерүгә яңа этәргеч, идеология эшенең төп юнәлешләрен билгеләүче маяк булып тора.

Иптәш Ф. Ә. Табеев язучыларны, газета-журнал, радио һәм телевидениедә эшләүче барлык әдәби көчләрне хәзерге шартларда идеология һәм политик тәрбия эшен нәтиҗәле алып бару өчен тормыш күренешләрен тирән өйрәнергә, әдәби әсәрләрдә һәм вакытлы матбугатта җитди проблемаларны күтәрергә, социаль-экономик үсеш закончалыкларын объектив анализларга чакырды. Алдынгыларның хезмәтен, социалистик ярышта ирешкән казанышларын яктыртуда шаблоннан, бертөрлелектән котылырга кирәк, диде. Хезмәт батырларының рухи дөньясын аңлап язу, аларның уй-хисләрен ышандырырлык итеп сурәтләү бик мөһим. Кулыңа каләм алгансың икән — шуңа ирешү язганың кеше күңеленә үтеп керерлек булсын. Идеология кадрлары, бигрәк тә публицистлар һәм журналистлар, халыкта кызыксыну уята торган барлык мәсьәләләрне объектив бәяли һәм массаларга ачык аңлата белергә тиеш. Язучы сүзенең, журналист язмасының дәрәҗәсен күтәрергә, аларның йогынтылы, тәэсирле булуына ирешергә кирәк. Социаль-экономик тормышның өлгереп җиткән проблемаларын, фәнтехника прогрессын, политик тәрбия эшен яктырту, хезмәт дисциплинасын ныгыту өчен көрәш алып бару — болар барысы да идеология работникларының игътибар үзәгендә торырга тиешле мәсьәләләр. Социалистик җәмгыятебезгә, советча яшәү рәвешендә чит-ят булган караш һәм әхлаксызлыкка каршы көрәштә тәнкыйть көченнән тулырак, киңрәк файдаланырга кирәк.

Киңәшмә эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов, КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

## ПАРТИЯ СҮЗЕН КҮҢЕЛГӘ САЛЫП

Язучылар союзы партоешмасының ачык җыелышы көн тәртибенә дә КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карары һәм Татарстан язучыларының бурычлары» дигән мәсьәлә куелды.

Җыелышны партбюро секретаре драматург Туфан Миңнуллин ачты. Докладны Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов сөйләде.

Фикер алышуларда язучылардан Ә. Баянов, Г. Латыйп, Д. Вәлиев, М. Садри, В. Ихсанова, Н. Дәүли, Р. Ишморатова, Ә. Бикчәнтәева һәм башкалар катнашты. Язучылар союзы идарәсе председателенең урынбасары Фәрваз Миңнуллин әдипләрне КПСС Үзәк Комитеты карарын үтәү йөзеннән башкарылачак эшләр планы белән таныштырды. Коммунистлар һәм партиясез язучылар аны бертавыштан кабул иттеләр.

Партия җыелышында КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты һәм чыгыш ясады.

## РЕДКОЛЛЕГИЯНЕҢ ЯҢАРТЫЛГАН СОСТАВЫ

Татарстан Язучылар союзы идарәсе президиумы һәм партбюроның берләштерелгән утырышында «Казан утлары» журналы редколлегиясенең яңартылган составы раслады: Зәки Нури (баш редактор), Әхсән Баянов (баш редактор урынбасары), Кояш Тимбикова (җаваплы секретарь), Шамил Бикчурин, Аяз Гыйләҗев, Марсель Зарипов, Зөлфәт, Шәйхи Маннур, Фәрваз Миңнуллин, Туфан Миңнуллин, Рафаэль Нәфиков, Атилла Расих, Сибгат Хәким, Нил Юзеев, Мирсәй Әмир.

## СОЮЗНЫҢ ЯҢА БҮЛЕГЕ

Кострома шәһәрендә РСФСР Язучылар союзы секретариатының күчмә утырышы булды. Анда кара туфраклы булмаган өлкәләрдәге әдәбият проблемалары тикшерелде. Секретариат утырышында республикабызның Чаллы шәһәрендә Татарстан Язучылар союзының яңа бүлеген ачу турында

карар кабул ителде. Бу — республикабыз Язучылар союзының икенче бүлеге. Беренчесе Әлмәттә күптән эшләп килә, нефтьле якларда яшәүче әдипләрнең иҗат эшчәнлеген оештыруда зур роль уйный.

Секретариат эшендә Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов катнашты.

### ФАТИХ КӘРИМГӘ БАГЫШЛАНГАН КИЧӘ

Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында — патриот-шагыйрьнең туган җирендә — Фатих Кәримнең тууына 70 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Бу күренекле датаны билгеләп үтү өчен, бирегә Казаннан һәм Уфадан язучылар килде.

Кичәне район советы башкарма комитеты председателе урынбасары З. З. Абдулов ачты. Фатих Кәрим турында сүз белән Илдар Юзеев чыкты. Кичәдә татар шагыйре Шәүкәт Галиев, башкорт шагыйрьләре Муса Гали, Гайнан Әмири, Әнгам Атнабаев, «Дим» колхозы парткомы секретаре Х. С. Гыйззәтуллина, шагыйрьнең кызы Ләйлә Кәримова чыгыш ясадылар.

Соңыннан Башкорт дәүләт филармониясе артистлары һәм колхозның үзешчән сәнгать коллективы катнашында зур концерт булды. Кунаклар колхозда ачылган Фатих Кәрим музеена үзләренең китапларын бүләк иттеләр.

## АРХИВЛАРДАН ТАБЫЛДЫ

### ҖӘЛИЛ КАТНАШКАН ЖУРНАЛ

Егерменче еллар башында Казандагы татар педагогия техникумында укучы яшьләр әдәбият түгәрәге оештырганнар һәм «Яшь көч» дигән кульязма журнал чыгарганнар. КПССның Татарстан өлкә комитеты каршындагы партия архивында шул журналның бер саны сакланып калган.

«Яшь көч»нең зур форматлы 28 биттән торган шушы санында унбишләп шигырь, өч очерк, бер хикәя, бер нәсер, ике парча урнаштырылган. Алар арасында Муса имзасы белән бирелгән шигырь дә бар. Менә аның кайбер юллары:

**...Яшә, иптәш! Бездән сәлам сиңа,**
**Чәчәкләргә-гөлгә бизәлеп.**

**...Кызыл чәчкә, иптәш, бездән сиңа**
**Тәкъдир итеп кылган эшеңне.**

Замандашларының әйтүенә караганда, ул чакта Казанда укып йөргән Муса Җәлил әлеге техникумда үткәрелә торган кичәләрдә, әдәбият түгәрәге утырышларында актив катнашкан. Яшь каләмдәшләре белән аралашып, кичәләрдә үзенең шигырьләрен укыган.

Техникумның әдәбият түгәрәге һәм аның кульязма журналы ул елларда күп кенә яшь талантлар өчен старт майданчыгы була. Журналны оештыручыларның берсе Закир Гали, мәсәлән, техникумны тәмамлауга журналист булып китә һәм гомеренең соңгы елларынача «Кызыл Татарстан» газетасының җаваплы секретаре, редактор урынбасары булып эшли. Бер үк бинада озак еллар бергә эшләгән Һади Такташ та, «Киләчәккә хатлар» поэмасын язганда, аның белән киңәшкән. Әдипләрдән Демьян Фәтхи, Әюп Гәрәй, Мостафа Ногман әдәбиятка беренче адымнарын Закир Гали редакцияләгән шул кульязма журналдан атлаганнар. «Яшь көч» авторлары арасында хатын-кызлар да бар. Шулардан берсе — Гөлчирә Гафурова. Ул утызынчы еллар башыннан алып байтак еллар «Азат хатын» журналының редакторы булып эшләде.

Шул чорда татар педагогия техникумында укыган, әдәбият түгәрәгендә актив катнашкан язучы Ибраһим Салахов та ул елларда Муса Җәлилнең техникумда укучы яшь каләмдәшләре белән бик еш очрашуын искә төшерә[1].

### «КЕШЕЛӘРНЕҢ ҖӘҮҺӘРЕ!»

Багдадта чыга торган «Тарикъ аш-шааб» газетасы (Гыйракъ Коммунистлар Партиясе органы) Муса Җәлил турында мәкалә бастырган. Анда язучы һәм тәнкыйтьче Р. Мостафинның «Герой-шагыйрь эзләре буйлап» дигән китабы турында да сүз бара. Мәкалә авторы — гарәп илләрендә совет әдәбиятын пропагандалауда зур эш алып баручы тәнкыйтьче һәм тәрҗемәче Җәлил Камалетдин — бу китапның «хакыйкатькә ихтирам белән» язылганын әйтә.

Фашист тоткынлыгында һәлак булган татар совет шагыйре Муса Җәлил совет әдәбияты һәм бөтендөнья демократик әдәбияты мәйданнарында күренекле урын алып тора,— дип яза гарәп әдибе.— Аны гарәп дөньясы да яхшы белә.

М. Җәлилнең күп кенә әсәрләре гарәпчәгә тәрҗемә ителгән. Гыйракъ шагыйре Гадънан Хакый Шиһап тәрҗемәсендә «Моабит дәфтәрләреннән өзекләр» дигән китап Багдадта 1977 елда басылып чыккан иде. Кереш сүзендә тәрҗемәче: «Кешеләрнең җәүһәре булган Муса Җәлилнең батырлыгын кешеләр һичкайчан онытмас»,— дип яза.

### ҖӘЛИЛ ҺӘМ ҖӘЛИЛЧЕЛӘР ТУРЫНДА

Үзбәкстанның республика рус теле һәм әдәбияты педагогик институтында герой-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган әдәби кичә үткәрелде. Анда филология фәннәре кандидаты Исхак Зәбиров институт укытучыларына һәм студентларга шагыйрьнең иҗаты, җәлилчеләрнең фашизмга каршы көрәше турында сөйләде, тыңлаучыларны яңа табылган материаллар, хатлар һәм фоторәсемнәр белән таныштырды.

Галим кулына кергән материаллар арасында Абдулла Алишның Мәскәүдә яшәүче Ашира ханым Кәтиевага хаты бар. Ул 1939 елның 27 августында язылган. Бу вакытта «Пионер каләме» журналында эшләгән А. Алиш яшь шагыйрәгә киңәшләрен

[1] Материалны редакциягә Г. Миңнул тапшырды.

язган. Моннан тыш, Исхак Зәбировка Әстерхан шәһәреннән Кәрим Ходжаев, Архангельскидан Михаил Иконников, Пермь өлкәсеннән Нәҗип Горяев һәм башкалар Җәлил һәм җәлилчеләр турында истәлекләрен язып җибәргәннәр.

Ташкент галиме шундый ук очрашуларны Үзбәкстан ССР сукырлар җәмгыятенең район бүлекләрендә дә үткәрде. Җәлил һәм җәлилчеләргә багышланган мондый кичәләр һәркайда зур кызыксыну тудыра.

## АЛИШ ӘКИЯТЕ ФРАНЦУЗ ТЕЛЕНДӘ

Мәскәүдә француз телендә чыга торган атналык «Нувель де Москоу» газетасының 17 июнь санында Абдулла Алишның «Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык» дигән әкияте басылып чыкты. Атналык бу басманы Алжирда, Марокко, Мали, Того һәм Туниста алдыралар.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ КӨРӘШТӘШЕ СӨЙЛИ

Татарстан АССР Дәүләт музеенда казанлылар һәм башкалабыз кунаклары М. Җәлилнең фашизм тоткынлыгында көрәштәше булган Г. К. Фәхретдинов белән очраштылар. Ул гитлерчылар әсирлегендә шагыйрь белән сөйләшүләрен искә төшерде, музейга шул чордан сакланып калган документларны тапшырды. Гарәф Фәхретдинов соңыннан фашизмга каршылык хәрәкәтендә актив катнаша. Франция Республикасының иң югары бүләге — «Почетлы легион» ордены белән бүләкләнә. Хәзер ул Ташкенттагы төзелешләрнең берсендә бригадир булып эшли.

Очрашуны язучы һәм тәнкыйтьче Р. Мостафин алып барды.

## БОЛГАР ҖИРЕНӘ СӘЯХӘТ

Татарстан Язучылар союзының партия һәм профсоюз оешмалары борынгы Болгар шәһәре урнашкан җирләргә әдипләрнең сәяхәтен оештырдылар. Илледән артык язучы һәм журналистны Болгар туфрагында КПССның Куйбышев райкомының беренче секретаре Николай Гурьевич Гурьев һәм райком секретаре Солтания Абдулвәлиевна Низаметдинова каршыладылар.

Сәяхәтчеләр халык риваятьләрендә изге дип саналган Рабига күлендә булдылар, борынгы Болгар шәһәре урыннан һәм сакланып калган корылмаларны карадылар, шундагы музей экспозицияләре белән таныштылар.

Табигать кочагында урнашкан пионер лагеренда дулкынландыргыч очрашу булды. Очрашуда Риза Ишморат, Фатих Хөсни, Рәйсә Ишморатова, Әхсән Баянов, Рафаэль Мостафин, Габдулла Шәрәфи, Лирон Хәмидуллин, Венера Ихсанова, Гәрәй Рәхим, Диләрә Зөбәерова, Марсель Галиев, Әхмәт Рәшит һәм башкалар катнашты.

## УКЫТУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

13 июньдә язучылардан Г. Шәрәфи, Ш. Рәкыйпов һәм шагыйрь Х. Халиков Казандагы мәгариф работниклары йортында бөтен республикадан җыелган башлангыч мәктәп укытучылары белән очраштылар. Язучылар үзләренең һәм каләмдәшләренең иҗат планнарын сөйләделәр, яшь буынны тәрбияләүдә матур әдәбияттан файдалану хакында фикер уртаклаштылар, яңа әсәрләре белән таныштырдылар.

## ХЕЗМӘТКӘ — ХӨРМӘТ

Яңа Кырлай авылында халык шагыйре Г. Тукайның мемориаль музеен оештыруда актив һәм нәтиҗәле эш күрсәтүләре өчен, түбәндәге иптәшләр КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Почет грамоталары белән бүләкләнде:

**Урманче** Бакый Идрис улы — РСФСРның атказанган рәссамы, ТАССРның Г. Тукай премиясе лауреаты;

**Баһаветдинова** Дания Борһан кызы — Татарстан АССР Дәүләт музееның әдәбият бүлеге мөдире;

**Леухин** Александр Петрович — РСФСР художниклары фондының Татарстан бүлеге рәссамы.

## ЛАОС ЯЗУЧЫЛАРЫ КАЗАНДА

Июнь урталарында Казанда Лаос язучылары булып китте. Алар безнең илгә СССР Язучылар союзы чакыруы белән килгән иде. Кунакларның сәяхәт маршрутына Татарстан башкаласы да кертелгән.

Лаос дәүләт нәшрияты председателе Сувантхоном житәкчелегендәге әдипләр группасы Казанның тарихи-истәлекле ядкарьләре, В. И. Ленин булган урыннар белән таныште. Кокушкино-Ленино авылына барып, алар зур кызыксыну белән В. И. Ленин музей-йортын карадылар.

Татарстан Язучылар союзында кунакларны идарә председателе Гариф Ахунов кабул итте. Әдәбиятлар дуслыгы, китап бастыру һәм аны халыкка җиткерү турында әңгәмәдә ТАССР Министрлар Советы янындагы нәшриятлар, полиграфия һәм китап сәүдәсе начальнигы Н. С. Пушкарев, Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Ф. Миңнуллин, союз секретаре М. Хәбибуллин һәм башка язучылар катнашты.

## ӘДИПЛӘР ИЛЛӘР ГИЗӘ...

Язучыларыбызның чит илләргә сәяхәткә чыгулары безнең көннәрдә гадәти бер халгә әверелде. Быел май аенда РСФСР язучыларының махсус туристлык группасы составында шагыйрь Рәдиф Гатауллин Англиядә һәм Шотландиядә булып кайтты. Совет язучылары Лондондагы истәлекле урыннарны карадылар, мәшһүр университетлы шәһәр — Оксфорд белән таныштылар. Даһи Шекспир туган Стратфорд каласында һәм Шотландиянең бөек шагыйре Роберт Бернс туган авылда булдылар, музейлар белән таныштылар.

* * *

Язучы Кояш Тимбикова, Мәскәү һәм Ленинград әдипләре белән берлектә, Германия Федератив Республикасында булды. Язучы-туристларның маршруты ГФРдагы

алты шәһәр аша узды, алар «СССР белән ГФР арасындагы мөнәсәбәтләрне яхшырту җәмгыяте» җитәкчеләре белән очраштылар. В. И. Ленин яшәгән йортны күрделәр, «Ленин Мюнхенда» дигән китап авторы Хитцер белән очрашып, әңгәмә үткәрделәр. Гетенең Франкфурттагы музей-йортында булдылар. Канн шәһәрендә уздырылган халыкара кинофестивальдә призлы урыннар алган «Тимер барабан» һәм «Парижда биелгән соңгы танго» фильмнарын карап, шулар хакында фикер алышуда катнаштылар.

### ТЕАТРГА — КҮЧМӘ КЫЗЫЛ БАЙРАК

Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театры авылга сәнгать һәм культура шефлыгы күрсәтүдә зур эш алып бара. Авыл җирләрендә ел саен 120—150 спектакль күрсәтелә. Казан тирәсендәге аерым районнарда театр көнен үткәрү гадәткә кергән. Арча культура йортында театраль культура университеты эшли, анда ТДАТның сәнгать осталары тамашачылар белән даими очрашып торалар, яңа спектакльләрдән өзекләр уйнап күрсәтәләр, сәхнә әсәрләре турында фикер алышулар үткәрәләр. Әтнә халык театры да камалчыларның иҗади булышлыгын тоеп яши.

Авылга шефлык итү эшендә 1978 елда күрсәткән хезмәтләре өчен театрга СССР Культура министрлыгы һәм ВЦСПСның Күчмә Кызыл байрагы бирелде. Бүләкне иҗат коллективының 15 июньдә үткәрелгән җыелышында РСФСР культура министрының беренче урынбасары Е. В. Зайцев тапшырды. Байрак тапшыруга багышланган җыелышта ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

### ТӘНКЫЙТЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ ТИКШЕРҮ

Апрель азагында Мәскәүдә СССР Язучылар союзының тәнкыйть һәм әдәбият белеме советының пленумы булды. «Советский писатель» нәшриятының тәнкыйть һәм әдәбият белеме редакциясе эшен тикшерүгә багышланган бу пленумда Татарстан Язучылар союзыннан тәнкыйтьче Р. Мостафин катнашты һәм фикер алышуларда чыгыш ясады.

### СӘНГАТЬ ҺӘМ ДУСЛЫК БӘЙРӘМЕ

Украинаның Ивано-Франковск өлкәсендә совет әдәбияты көннәре булып узды. Тугандаш халыкларның дуслыгын гәүдәләндергән әлеге атналык Украинаның Россиягә яңадан кушылуына 325 ел тулу уңаеннан үткәрелде. Бу бәйрәмгә Россия Федерациясе һәм союздаш республикалар вәкилләре чакырылган иде. Язучылар делегациясен СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Сергей Сартаков җитәкләде.

Совет әдәбияты атналыгында Татарстаннан шагыйрь Равил Фәйзуллин да промышленность предприятиеләре, колхоз һәм совхозлар, хезмәт ияләре алдында һәм радиодан татар әдәбияты белән башка милләт әдәбиятлары арасындагы бәйләнешләр турында чыгыш ясады.


### «СОВЕТ МӘКТӘБЕ» ЖУРНАЛЫНА ЯЗЫЛЫГЫЗ!

Хөрмәтле укытучылар, тәрбиячеләр, мәктәп һәм мәгариф органнары җитәкчеләре, ата-аналар!

1980 елга «Совет мәктәбе»нә үз вакытында язылыгыз. Журнал Бөтенсоюз каталогына кертелгән, индексы — 73363. Аңа подписка «Союзпечать»нең барлык район, шәһәр агентлыкларында, почта бүлекләрендә кабул ителә. Язылу бәясе: бер елга — 3 сум. Урыннарда тоткарлык килеп чыкса, подписка бәясен, төгәл адресыгызны, исем-фамилиягезне күрсәтеп, түбәндәге адрес белән җибәрә аласыз: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2, республиканское агентство «Союзпечати». Для подписки на журнал «Совет мәктәбе».

## *Бала чак иле илчесе*

Әдәбият сөюче кадерле ата-аналар!

Һәр бала күңеле гүзәллеккә омтыла. Ә ул изге матурлык хисе белән иң башлап үзегез сөйләгән тылсымлы-серле әкиятләр, моңлы-аһәңле шигырьләр аша таныша. Кичләрен сездән яңадан-яңа мавыктыргыч әсәрләр укуыгызны үтенә. Бер сөйләнгән әкият-хикәяләр инде күпме тапкыр кабатланган. Бала күңелен тагын ни белән юатырга? Менә шул чакта сезгә «Яшь ленинчы» газетасы ярдәмгә килер. Балаларыгызны берсеннән-берсе матуррак шигырьләр, әкиятләр һәм хикәяләр белән сөендерер. Татар әдипләренең балаларга атап язылган иң яхшы әсәрләре беренче булып «Яшь ленинчы»да дөнья күрә. Танылган язучыларыбыз Гомәр Бәширов, Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еники, Фатыйх Хөсни, Гариф Ахунов, Гариф Галиев, Әхсән Баянов, Ләбибә Ихсанова, күренекле шагыйрьләребез Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Зәки Нури, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин һәм башка бик күпләр безнең белән тыгыз элемтәдә торалар. Ә бу язучыларның бөтенесе диярлек безнең газетада тәрбияләнеп үсеп чыктылар. Киң әдәбият мәйданына шуннан юл алдылар. Бу традиция бүген дә изге саклана. Балалар үзләренең беренче шигырь-хикәяләрен, әкият һәм рәсемнәрен газетада күреп шатланалар. Алар өчен әледән-әле конкурслар оештырыла. Менә шулай, «Яшь ленинчы» үз укучыларын иҗат итәргә өйрәтә, аларга рухи канатлар бирә.

«Яшь ленинчы» — октябрят, пионер һәм мәктәп комсомолларының бик яратып укый торган газетасы. Ул аларның барысын да Бала чак иленең бөтен яңалыклары белән таныштырып бара. Республикабызда, күрше өлкәләрдә һәм чит илләрдәге балалар тормышы, алар нинди кызыклы эшләр башкаралар, нинди язмыш белән яшиләр — боларның һәммәсе хакында газетабызны укып белергә мөмкин. Нәрсә ул Әдәп, Намус? Ни ул малайлар батырлыгы, кызлар горурлыгы? Кем ул дус? Куркак кеше нинди була? Газетабыз шушы һәм башка бик күп сорауларга тулы җавап бирер. Ә инде октябрятлар, пионерлар һәм комсомоллар үзләре һәр вакыт газетаның игътибар үзәгендә булыр.

Кадерле ата-аналар!

Менә шундый газета ул «Яшь ленинчы». Ул — сезнең балаларыгызның якын дусты да, ышанычлы ярдәмчесе дә, тугры киңәшчесе дә. Газетабызны улыгыз яки кызыгыз өчен быел да алдырырга онытмагыз иде.

«Яшь ленинчы» газетасына илебезнең һәр элемтә бүлегендә язылырга була. Язылу бәясе — елга 1 сум 08 тиен. Газетаның индексы: 54124.

**«ЯШЬ ЛЕНИНЧЫ» ГАЗЕТАСЫ**
**РЕДАКЦИЯСЕ КОЛЛЕКТИВЫ.**

## *Хөрмәтле укучылар!*

Журналыбызның киләсе ел саннарында сез татар әдипләренең күп кенә яңа әсәрләре белән танышa алырсыз. Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 110, Татарстан АССР төзелүгә 60 ел тулуга багышланган әсәрләргә аерым урын биреләчәк.

### ПРОЗА

Повестьлар:

Гариф Ахунов. **«Йолдызлар калка».**
Мөхәммәт Мәһдиев. **«Ут чәчәге».**
Барлас Камалов. **«Актуган Гапсаттары».**
Ибраһим Салахов. **«Мәхәббәт картаямы!»**
Әнәс Галиев. **«Шелтә».**
Разил Вәлиев. **«Яшисе килә».**

Романнар:

Эдуард Касыймов. **«Шиңмәс гөлләр».**
Мәхмүт Хәсәнов. **«Шөгеровлар».**

### ПОЭЗИЯ

Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арсланов, З. Нури, Г. Афзал, Г. Рәхим, С. Гәрәева, Н. Измайлова, Р. Мингалимов, Зөлфәт, М. Әгъләмов, Ф. Сафин, Р. Миңнуллин шигырьләре;
И. Юзеев. **«Мәхәббәт китабы».** Поэма.
Р. Фәйзуллин. **«Чор турында поэма».**
**Яшьләр иҗаты:** Чаллы, Түбән Кама, Лениногорск һәм Апас төбәгендә яшәүче яшь шагыйрьләрнең яңа әсәрләре.

### ОЧЕРКЛАР ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

Р. Ишморат. **Яңа документаль повесть.**
Ш. Хамматов. **Ленин һәм Татарстан партия оешмасы.**
Р. Беляев. **КамАЗ — горурлыгыбыз.**
Г. Ахунов. **Чистай сәгатьләре.**
«ВАКЫТ ҺӘМ КЕШЕ» конкурсына килгән яңа очерклар.

### ПЬЕСАЛАР

Ә. Гаффар. **Җиләк вакыты бер генә.** Драма.
Ю. Әминов. **Яңа комедия.**

Журналда урта буын язучыларының иҗат портретлары биреләчәк.

Әдәбият һәм культура тарихына караган кызыклы язмалар әзерләнә.

Классик поэзия үрнәкләре, әдәби мирас, «Елмаеп та, көлеп тә», «Мәсәлчеләр мәҗлесе», «Нәниләр дөньясы» бүлекләренә урнаштыру өчен әсәрләр, язмалар туплана.

Җыр сөючеләргә ноталары белән яңа җырлар тәкъдим ителәчәк.

**«Укучы сүзе» бүлегендә** укучыларыбызның бүгенге татар әдәбиятына, аерым әсәрләргә, язучыларыбызның иҗатына карата фикерләрен туплаган язмалар, әдипләргә адресланган теләк һәм тәкъдимнәр урнаштырылачак.

**Журналга язылу 1 нче сентябрьдән башланды**

«Казан утлары» Бөтенсоюз каталогына кертелгән, индексы **73210.** Аңа Советлар Союзының теләсә кайсы төбәгендә язылырга була.

Урындагы «Союзпечать» агентлыклары һәм элемтә бүлекләрендә ниндидер сәбәпләр аркасында журналга яздырмасалар, еллык язылу хакын — 6 сум — Казанга, түбәндәге адрес белән җибәрергә мөмкин:

**420066. Казань,**
**ул. Декабристов, д. 2**
**республиканское агентство «Союзпечать».**
**(для подписки на журнал «Казан утлары»)**

Язылуны соңгы көннәргә калдырмыйча, хәзер үк рәсмиләштереп куярга тырышыгыз. Соңгы көннәргә калдыру журналга язылуда төрле аңлашылмаучылыклар, кыенлыклар тудыра.